Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

*Галимҗан Баруди*

# ХАТИРӘ ДӘФТӘРЕ

## 1920 елның 12 июненнән алып сентябрь ахырына кадәр

Казан – 2017

УДК 82-94
ББК 63.2(2Рос=Тат)
Б 23

**Китапны басмага әзерләүче:**
филология фәннәре кандидаты *Айдар Гайнетдинов*

**Фәнни мөхәррир:**
ТР ФА академигы, тарих фәннәре докторы *Радик Салихов*

**Җаваплы мөхәррир:**
Киров өлкәсе мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе,
мөфти *Зөфәр хәзрәт Галиуллин*

Б 23 ***Баруди Г*. Хатирә дәфтәре: 1920 елның 12 июненнән алып сентябрь ахырына кадәр** / Басмага әзерләүче *А. Гайнетдинов*. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2017. – 236 б.

«Хатирә дәфтәре» – мәшһүр татар галиме, җәдидче, дини реформатор, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог Галимҗан Барудиның көндәлек дәфтәре. Анда төрле тарихи вакыйгалар тасвирланган, галимнең кызыклы карашлары, кыйммәтле фикерләре, акыллы киңәшләре, милләт һәм дин өчен борчылулары чагылыш тапкан. Китап татар халкы тарихы, дини мирас белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-94981-263-1

© Гайнетдинов А., 2017
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2017

# Кереш сүз

Галимҗан Баруди (Галимҗан бине Мөхәммәдҗан бине Бинеямин бине Гали бине Колмөхәммәд) – мәшһүр дин галиме, җәдидчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле, дини реформатор, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог, журналист. Ул 1857 елның 17 февралендә хәзерге Биектау районы Кече Кавал авылында туган, Казанда үскән. 1862 елда сабый Галимҗан Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсенә укырга кергән. 1875 елдан ул укуын Бохарада дәвам иткән. Анда схоластика, обскурантизм, мистицизм белән сугарылган дин өйрәтелгәнгә күрә, Г. Баруди, укуы белән канәгатьләнмичә, 1882 елда Казанга кайткан һәм бишенче мәхәллә мәчетенә имам итеп билгеләнгән. Тиздән ул җәдитчелек ысулындагы атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен оештырган һәм шунда укыткан. Шулай ук Г. Баруди актив рәвештә дәреслекләр төзеп бастырган, уку-укыту программасын яңарткан һәм камилләштергән. 1906 елда Казанда аның мөхәррирлегендә «Әд-дин вәл-әдәб» («Дин һәм әхлак») исемле татар дини-әхлакый, гыйльми-әдәби һәм сәяси журнал чыга башлаган. 1908 елда, кадимчеләрнең яла ягуы аркасында, Г.Барудины панисламизмда гаепләп, ике елга Вологда губернасына сөргенгә җибәргәннәр. Шул вакытларда ул чит илләргә сәяхәт кылып, Истанбул, Каһирә, Мәдинә, Мәккә кебек шәһәрләрдә булып, үзенә кирәкле гыйлемнәр туплаган. 1917 елда Г. Баруди күпчелек тавыш белән Уфадагы Русия мөселманнарының Диния нәзарәте мөфтие итеп сайланган. Ул 1921 елның 6 декабрендә вафат булган. Кабере Казанның Яңа татар бистәсе зиратында. Ташының тексты түбәндәгечә:

1) «Мәшһәдүл-гаалим-
2) – ил-фәәдыйли
3) хаадимил-гыйльми
4) вәд-диини
5) Галимҗан
6) бине Мөхәммәдҗан
7) әл-Баруди
8) рахимәһүмәәллааһү
9) рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе: «Хөрмәтле галим, гыйлем һәм дин хадиме Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди. Аллаһ аларның икесен дә киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Узган ел аның иске кабер ташы яңага алыштырылды. Кызганычка каршы, иске ташын, зиратта калдырмыйча, алып киткәннәр. Аның урынына мәрмәрдән эшләнгән яшькелт төстәге яңа кабер ташы куелып, түбәндәге сүзләр язылган:

1) «1857 / 1273–1921 / 1340

2) Галимҗан хәзрәт Мөхәммәдҗан углы

3) әл-Баруди (Галийыф)

4) мәшһүр дин галиме, ишан җәмәгать эшлеклесе

5) Мөхәммәдийә мәдрәсәсенә нигез салучы күренекле мөдәррис

6) Русийә мөселманларының Динийә нәзарәте мөфти»[1].

Мондагы текст та гарәп графикасында язылган, тик тел галимнәре белән киңәшләшмичә ясатылганга күрәдер, кайбер орфографик һәм пунктуацион хаталар күзгә чалына.

Г. Баруди бөтен көчен милләтебез, динебез өчен сарыф итеп, армый-талмый хезмәт куйган, халыкны аң-белемгә, иҗтиһадка (шәригать мәсьәләләрен үзлектән тикшереп, мөстәкыйль фикер йөртүгә) чакырган һәм схоластикадан, тәкълидтән (диндәге мәзһәбләргә сукырларча иярүдән) арынырга өндәгән. Аның турында без күп ишетсәк тә, кызганычка каршы, галимнәр, белгечләр тарафыннан галимнең бөтен хезмәтләре халыкка кайтарылды, дип әлегә әйтеп булмый. Кайберләре һаман үз чиратын көтеп ята. Мәсәлән, шундыйлардан «Хатирә дәфтәре»нең кульязмасы.

Г. Барудиның дүрт көндәлеге билгеле. Беренчесе – «Истамбулга сәяхәтем». Ул 1907 елда Төркиягә барган сәфәрендә күргән вакыйгаларны тасвирлауга багышланган булып, 1908 елда «Әд-дин вәл-әдәб» журналында басылып чыккан иде[2].

Икенчесе – 1918 елда язылганы – Төркестан һәм Казахстан якларына оештырылган сәяхәтенә багышланган. Г. Баруди шул сәфәрендә Кызылъяр, Троицк, Чиләбе, Омск, Күкчәтау һ.б. шәһәрләрдә булып, үзенең күргәннәрен, теге яки бу мәсьәләгә карата фикерләрен язган. Әлеге көндәлек КФУ каршындагы Лобачевский

[1] Ахыргы өч юлы ташның аскуймасында язылган.

[2] Баруди Г. Истанбулга сәяхәтем // Әд-дин вәл-әдәб. – 1326/1908. № 1. 22–25 б.; № 2. 57–60 б.; № 3. 86–90 б.; № 5. 149–152 б.; № 6. 184–187 б.; № 7. 209–214 б.

исемендәге фәнни китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана[3]. Ул гарәп графикасыннан кириллицага күчерелеп, 2004 елда басылып чыкты[4].

«Хатирә дәфтәре» дип аталган өченче көндәлек 1920 елның 12 июненнән алып шул ук елның сентябрь ахырына кадәр язылып барган. Монысы да КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә[5] һәм тагын бер нөсхәсе, төгәлрәк әйткәндә, Ш. Шәрәф тарафыннан күчереп язылганы, шәхси кулларда саклана. Өченче «Хатирә дәфтәре»нең яртысы «Казан» журналының 1997 елгы саннарында[6], тулысынча рус теленә тәрҗемәсе параллель рәвештә «Казан» журналының 1997–1998 елгы саннарында басылып чыкты[7]. Шулай ук «Иман» нәшриятында китап рәвешендә ике телдә дөнья күрде[8]. Тик татарча бастырылган «Хатирә дәфтәре» яртысын гына тәшкил итә, рус телендәгесе дә кыскартылып бирелгән, шул ук вакытта гарәп графикасыннан кириллицага күчергәндә кайбер хаталар да җибәрелгән. Кызганычка каршы, кыскартулар белән бергә Г. Барудиның иң кызыклы фикерләре, уйланулары төшеп калган. Бәлки, моны махсус эшләгәннәрдер, чөнки кыскартылган җирләрендә сүз дини реформа, иҗтиһад мәсьәләләре хакында бара. Мәсәлән, аның намаз уку рәвеше һәм үзенчәлекләре хакында фикерләре элегрәк басылып чыккан «Хатирә дәфтәре»ндә китерелмәгән. Анда Г. Баруди намазда рөкүгъка киткәндә (аягүрә иелгәндә) һәм аннан торганда, намазга керешкәндәге кебек, ике кулны күтәрүне сөннәт булуын һәм үзенең кайвакыт шул гамәлне кылуын язган. Шулай ук җәмәгать намазларында Г. Баруди имам артында басып намаз укучы кешегә дә «Фатиха» сүрәсен барыбер

---

[3] КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге: 1682 – Т.

[4] Галимҗан Баруди. Кызылъяр сәфәре. – Казан, 2004. – 167 б.

[5] КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге: 1604 – Т.

[6] Баруди Г. Хатирә дәфтәре // Казан, 1997. № 10–11. 71–89 б.; № 12. 106–150 б.

[7] Баруди Г. Памятная книжка // Казань, 1997. № 10–11. 71–89 б.; № 12. 118–158 б.; 1998. № 1. 21–48 б.; № 2. 66–84 б.

[8] Әл-Баруди Галимҗан. Хатирә дәфтәре / Галимҗан әл-Баруди. – Казан: «Иман» нәшрияты, 1428 / 2007. – 106 б.

укырга кирәк, дип аңлаткан. Димәк, ул хәнәфи мәзһәбенә сукырларча иярмәгән, киресенчә, башка мәзһәбләрнең, дини карашларның, фикерләрнең дәлилләрен тикшереп, үзлегеннән иҗтиһад кылган һәм дөрес нәтиҗә чыгара белгән.

Шулай ук «Һәвел» намазы хакында аңлатма биргәндә «Казань» журналында һәм «Иман» нәшриятында чыккан «Хатирә дәфтәре»ндә болай язылган: «В достоверных книгах о такой молитве не сказано, поэтому покойный Марджани считает желательным чтение по методу, общепринятому в нашем государстве»[9]. Чынлыкта исә оригинал текстта түбәндәгечә язылган: «Ышанычлы китапларда да андый намаз бәян ителмәгән, шунлыктан Мәрҗани мәрхүм мәмләкәтебездә халык арасында таралган рәвеш белән укуны бидгать ди». Димәк, басмага әзерләүчеләр «бидгать» дигән сүзне «желательное (действие)» дип тәрҗемә итеп, мәрхүм Мәрҗани хәзрәтләренә яла якканнар булып чыга. Бидгать – «догмат һәм гыйбадәт мәсьәләләрендә Коръән һәм Сөннә өйрәтүләренә туры килми дип саналган фикерләрне, гамәлләрне, йолаларны, гадәттә, шушы сүз белән атыйлар. Мәсәлән, фәтваләрдә хаын-кызның никах, җәназа укуы, мәет өстендә тәһлил әйтүе, гүр сәдакасы бирүе, «изге урыннарга» барып гыйбадәт кылуы һ.б.ш. бидгать дип бәяләнә»[10]. Икенче бер урында әлеге сүзне «бу гадәт» дип кириллицага күчергәннәр: «Сөннәт булган зыяфәтләрне хәтта мәет артындан өчесе, җидесе, кырыгы кеби бу гадәтләрне дә калдырмыйлар имеш»[11]. Оригиналда исә: «Сөннәт булган зыяфәтне (кунакчыллыкны), хәтта мәет артыннан өчесе, җидесе, кырыгы кебек бидгатьләрне дә калдырмыйлар икән», – дип язылган. Мондый ялгышу очракларын тәрҗемә итүчеләрнең компетентлыклары булмау белән аңлатып булыр иде, әмма башка урыннарда бидгать сүзе дөрес рәвештә тәрҗемә ителгән. Шуңа күрә югарыда искә алынган «хаталар»ны фальсификация дип бәяләргә мөмкин, чөнки шул рәвешле Г. Барудиның кайбер фикерләре оста итеп яшерелгән.

Хатирә дәфтәре»ндә Г. Баруди байтак дини мәсьәләләргә карата, мөфти буларак, үзенең акыллы фәтваләрен биреп, аңлашылмаган

---

[9] Баруди Г. Памятная книжка / Г. Баруди. – Казань: Изд-во «Иман», С. 106.

[10] Ислам. Белешмә сүзлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – Б. 16.

[11] Әл-Баруди Г. Хатирә дәфтәре / Г. Әл-Баруди. – Казан: «Иман» нәшрияты. Казан: 1428 / 2007. – Б. 65.

яки бәхәсле дини мәсьәләләрдә ачыклык кертә һәм дәлилләп, тәфсилләп аңлата, хәтта гает көнен билгеләү мәсьәләсен дә ачыклык кертә. Бүгенге көндә дини гыйбадәтләрнең уку рәвеше хакында күп бәхәсләр, тарткалашулар барган заманда аның бу фикерләре бик актуаль яңгырый.

Әйткәнебезчә, Шәһәр Шәрәф (1877–1938) заманында Г. Барудиның 1920–1921 елларда язылган көндәлекләрен пөхтә итеп күчереп язган булган. Ул да дин галиме, язучы, педагог, тарихчы буларак билгеле. Ш. Шәрәф хәзерге Буа районы Аксу авылында туган. Ул Г. Барудиның иң яхшы шәкерте, шул ук вакытта кияве дә булган. 1897–1919 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыткан, «Әд-дин вәл-әдәб» журналында эшләгән, Казанда имам-хатыйб вазыйфаларын үтәгән. Безгә Ш. Шәрәф күчергән нөсхәнең фотокопияләренә ия булу бәхете татыды.

Һәр кеше «Хатирә дәфтәре» белән үзлегеннән танышып чыга алмый. Бу инде аңлашыла да, беренчедән, ул гарәп графикасында язылган, икенчедән, иске татар телендә, ягъни хәзерге телдән шактый аерыла торган рәвештә язылган. «Хатирә дәфтәре»н яңадан дөресләп бастырып чыгару зарурлыгы туып (чөнки тәкъдим ителә торган бу китапта Баруди хәзрәтләре мөҗтәһид галим буларак ачыла), без Г. Барудиның «Хатирә дәфтәре (1920 елның 12 июне – сентябрь ахыры)» дип аталган көндәлек дәфтәрен кириллицага күчереп, аңларга уңайлы булсын өчен, барлык архаик грамматик формаларны хәзерге әдәби тел нормаларына салып эшләргә булдык, ягъни максималь дәрәҗәдә хәзерге гамәлдәге телгә җайлаштырдык, якынайттык. Гарәп телендәге кайбер җөмләләр татар теленә тәрҗемә ителде, аңлашылмаган сүзләргә яки терминнарга җәяләр эчендә аңлатма бирелде. Тоташ гарәп яки фарсы телендә язылган шигырьләрне, катлаулы дини гыйбарәләрне төшереп калдырдык.

Бәхеткә каршы, Г. Барудиның әле дүртенче көндәлеге дә сакланып калган һәм ул 1920 елның октябреннән алып 1921 елның ноябренә кадәрге чорны үз эченә алган. Әлеге «Хатирә дәфтәре» дә Ш. Шәрәф тарафыннан күчереп язылып, хәзерге көндә шәхси кулларда саклана.

XX гасыр башында Г. Баруди тарафыннан күтәрелгән проблемалар бүгенге көндә дә бик актуаль, әйтерсең лә, ул көндәлегендәге фикерләрен хәзерге заманда яшәүче милләттәшләребезгә юллаган, шуңа күрә дә аның әһәмияте әйтеп бетергесез. Кызганычка каршы,

хәзерге дини уку йортларында һаман шул «матүриди», «хәнәфи» сүзләре белән шәкертләрнең йөрәкләрен һәм акылларын томалап, кадимчелектә урын алган идеяләрне халыкка көчләп такмакчы булалар, хәтта дин башлыклары арасында җәдидчелеккә тел-теш тидерүчеләр дә очрый, үзебезнең җирлектә туган мөҗтәһидләребез Г. Баруди, Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, М. Бигиев, Г. Буби, З. Камали, Ш. Шәрәф тарафыннан язылган хезмәтләрне, әйтелгән фикерләрне санга сукмау кебек оятсыз күренешләр дә күзәтелә. Әгәр дә без бу шәхесләрне онытсак, алар өйрәтеп калдырган сүзләр белән гамәл кылмасак, безнең хәлебез бик аяныч булачак икәнен истән чыгармасак иде.

Иманыбыз камил, арабызда Г. Баруди кебек фикерләүче шәхесләр булса, җәдидче галимнәребезнең юлыннан читкә тайпылмасак, данлыклы дини реформаторларыбызның хезмәтләрен туплап, алар буенча гына дини мәгарифебезне үстерсәк, тиз вакыт эчендә динебездә экстремистик һәм радикаль карашлар, агымнар да юкка чыгар, мөселманнар арасында тынычлык урнашыр, милләтебезнең киләчәге матур булыр иде. Шул сәбәпле, мәгърифәтчеләребезнең мирасын халыкка кайтару эшендә галимнәргә, җиң сызганып, армый-талмый хезмәт кую гаять зарур.

*Айдар Гайнетдинов*

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим*

## Кереш

Мәхкәмәи-шәргыябезнең (Диния нәзарәтебезнең – *А.Г.*) байтактан бирле мәркәзгә (Мәскәүгә) бер адәм җибәрү фикере бар иде. Анда кайбер авырлыкларны җиңеләйтү рәвешләре, аңлату өмет ителә иде. Үткән кыш Уфа имамнарыннан икесенә тәкъдим ителсә дә, кире какканнар иде. Үз әгъзасыннан берсенең Мәхкәмәдән аерылуы вакытның һәм эшләрнең әһәмиятенә күрә, әдәпсез күренә иде. Әмма эш җитди иде:

1. Диния нәзарәтенең бинасы имин түгел иде. Уфа исполкомы (исполнительный комитеты) тарафыннан Шәрык музее итәргә, әгъзаны аннан чыгарырга карар бирелгән, хәтта Шәрык тарафындагы бинасы алынган иде.

2. Нәзарәтнең Мәхкәмә сурәтендә һәм исеме белән дәвам итүе дә шөбһәле иде.

3. Имамнар һәм мөәзиннәр күп җирләрдә гаскәрлек хезмәтенә, хәтта кара хезмәтләргә чакырылалар һәм алыналар.

4. Электән бирле дин укытылып килгән, халыкның үз чыгымнары белән торгызылган мәктәпләр хөкүмәт тарафыннан алынып, хөкүмәт дәресләре тәмамланганнан соң да, аларда дин укытырга байтак җирләрдә рөхсәт итмиләр, кайбер мөгаллим һәм мөгаллимәләрнең бу хакта халыкка каршы көчле мөгамәләләре ишетелә иде.

5. Дини хәҗәтләр өчен ихтыярлы иганә туплауда да кайбер даирәләрдә каршы хәрәкәтләр күренә һәм ишетелә иде.

6. Кайбер җирләрдә имамнар сайлауларында мәхәллә шурасы бүлекләре катышып, үзләре приговорларга имза куеп, имамлык хезмәтен үтәүгә бу җитә, дип, имамнарны урнаштырулары ишетелә.

7. Гражданский талакларын игътибарга алып, бер дә вакыт көттермичә, гыйддәт (ирсез калган хатынның икенче иргә бармый торырга тиешле булган вакыты – *А.Г.*) үткәртмичә үк, муллаларны никях укырга боерулары булгалаган иде.

8. Матбагаларда Диния нәзарәтенең эшләрен бастыру бик авыр, чират җитми, аз гына язу бастырырга айлар көтәргә мәҗбүрлек була, шунлыктан күп игъланнарыбыз туктап кала яки кичектерелә иде.

9. Нәзарәт әгъзаларына һәм аның вәкаләте һәм хезмәте белән җибәрелгән вәкилләренә юлда йөрергә рөхсәт бирелми яки бик авырлык белән генә бирелә иде.

Боларга охшашлы эшләр мәсьәләсендә мәхәллә идарәсе белән аңлашып булмаганлыктан, бу рәвешле мөгамәләләрнең мәркәздә яхшы хәл ителүе өметле булганлыктан, ул тарафка бару һәм аңлашу тиешле күренә иде. Ләкин бу 1920 елның язына кадәр юл табылмады, яхшы рәвеше аңлашылмады.

Ләкин бердәм рәвештә минем быел Казанга кайтуым тиешле иде. Кардәшем Габдрахман Тәүфикъ быел шәгъбан ахырында дөньядан кайтты. Икътисади эшләребез байтак тәртипсез булды. Мәхәлләдә яңа имам сайлау мәсьәләсе кузгалып, төрле фикерләр туды.

Һәммәдән бигрәк Русия мөселманнарында иң зур һәм кыйм-мәтле булган китапханәмне урнаштыру һәм Шура хөкүмәтенең каравына һәм эшенә тапшыру мәсьәләсе алдымда тора иде. Аның турында төрле фикерләр дә ишетелә иде, үзем кайтып, бер дәрәҗәдә тиешле чарасын күрү тиешле иде.

Минем Казанга кайту мөнәсәбәте белән, аннан бик ерак булмаган Мәскәү сәфәре дә минем өстемә төшеп, юлдашлар да шуны үтенүләреннән, туры Казанга, аннан Мәскәүгә сәфәр ният-ләнде. Ләкин пропуск (юл йөрү рөхсәте) алу шактый авыр булды. Шулай ки, бер дәрәҗәдә Кустанайга рәсми имам итеп Уфа төбәгендәге Рәсмәкәй имамы Габдулла мөдәррисне җибәрүебез дә, пропуск ала алмагач, үз исемемнән: «Диния нәзарәте хезмәте белән җибәрелә, шунлыктан бирелергә тиеш», – дип язсам да, янә кире какканнар: «Руханиларга бирелми, йөрергә ярдәм ителми», – дигәннәр иде.

Шуннан биш-алты көн үткәч, хатыным белән үзем өчен рөхсәт сорадым. «Рәсми хезмәт күрсәтеп, китапханәмне Шурага тапшырыр өчен кайтам», – дидем, рөхсәт итмәделәр. Соңра Мәгариф идарә-сендәге кайбер коммунистларның ишарәсе белән, Мәгариф идарәсенә рөхсәт сорап гариза бирдем. Алар исполком мәҗлесенә куеп, ислам җенесеннән булган Хәсән Сәйфелмөлекев каршы тавыш биреп: «Китапханәсен үзеннән башка да алырлар, йөрмә-сен», – дип бирдермәгән.

Аптырауда калып, ГубЧК (Губернская чрезвычайная комиссия) бүлегенә бирелсә, шаять, рөхсәт итәр, диюләрендә, алардан рөхсәт сорап язу җибәрергә торган көнемдә, Казаннан мине чакырып,

кайтуга иҗтимагый һәм гаилә зарурлыгы күрсәтеп бирелгән өч данә телеграмма иреште. Боларны да кушып, искә алынган бүлеккә җибәргәч, рөхсәт бирергә имза куеп, көчкә ярдәм алынды. Бу хәл дә Мәскәү сәфәрен куәтләгән иде.

Минем өчен Мәскәү сәфәре бик мөнәсәбәтле дә түгел иде. Русча белмимен, руслар белән аралашуны һәм мөнәсәбәтне күп сөймимен. Хәҗәт, сораулар кебек эшләрдә тырышлыгым, сәләтлелегем дә юк. Ләкин зарурлык сәбәпле, үз өстемә йөкләдем. Аллаһның ярдәмендә кайбер дус-ишләрнең ишарә һәм киңәшләшүләре, шаять, булыр; бер эш туар өмете белән ихтыяр иттем. Аллаһка тәвәккәлләп, 1920 елның 12 июнендә, (1338 елның 25 рамазанында) Уфадан Казанга су юлы белән юнәлдек. Аллаһ – Хуплаучы.

## Уфадан сәфәр, көймәдәге хәлләр

1338 елның 25 рамазанында (1920 елның 12 июнендә) Казанга бару нияте белән көндезге бер ярым сәгатьтә (13:30 да – *А.Г.*) Мәхкәмәдәге (Диния нәзарәтендәге – *А.Г.*) урыныбыздан хатыным Гайшә белән пристаньгә юнәлдек. Хәрәкәт алдында ЗАГС идарәсеннән берсе килеп, канцеляриядә көчле сөйләгәнлектән, аңлату, сорау өчен югарыда кабул иттек. Кыскача әйткәндә, авылларда гаилә дәфтәре сәбәпле, халык һәм имамнар шунда вакыйгаларны теркәү белән канәгатьләнеп, боларның вәкаләт идарәләренә (ЗАГСка) бармыйлар, аларның хәбәрләреннән башка никях, талак һәм башкаларны үтиләр икән. Бу исә боларның ашыгыч планнарына каршы икән. Бер атна элек, бу нәрсә өчен, мине дә чакырып сөйләгән иде.

Мөселманнарның гадәт һәм хәлләреннән хәбәрсез коммунист булганлыктан, юк-бар шөбһәләрне үзенә эш итеп йөргән адәмгә охшый. Баштагы сүзе Җиһангир ахун аркылы безгә ирештерүеннән, бераз тикшереп, әгәр хәбәре шулай булырдай булса, сәфәрдән туктауны уйлаган идек. Чакырып сөйләшкәч, эш бик вак, эш тапмагандай йөргән, үзенчә эш йөртүче коммунист түрәсе булып чыкты. Аны озаттык та, икенче тарафтан арбага утырып юнәлдек. Аллаһ хәерле сәфәр бирсен!

Су буена ирештек. Сәүдәгәрләрдән Хәсән Хәмиди, Мәхкәмә хезмәткәре Йосыф каршы алдылар. Аерым бүлмә юклыгын, урыннар шактый тыгыз булуын хәбәр иттеләр. Ни булса да, утырып

торырлык урын булды. Беренче урынның иркен бүлмәсендә (залында) икебез дә күпчелек арасында урын таптык. Сәгать ярымнан соң, озату өчен килгән казый Кәшшаф Тәрҗеман әфәнде белән ахун Җиһангир әфәнделәр килеп, бераз утырып, алар белән кайбер сөйләшүләрдә булганнан соң, саубуллашып, өч ярым сәгатьтә (15:30 да – *А.Г.*) көймәбез кузгалды, «Пьяный Бор»гача алган билетларыбыз белән юнәлдек. Юлда уку һәм язу өчен элекке көймәләр рәхәтлеге хәзерге тарих сәхифәләрендә генә, хатирә почмакларында гына калып тора икән. Алай да, дәрт буенча, юаныч итеп, бу кадәрне яза алдым. Моннан соң Аллаһ хәерле эшләремә ярдәм бирсә иде!

**Казанга кайтуның сәбәпләре**. Казанда моннан ике ел элек кенә булган идем. Озак вакыт булды, дус-ишне күрү, ата-анама барып кайту, кайбер милекнең хәлләреннән хәбәр алу, аңлатулары өстәвенә, кардәшем һәм андагы хәлфәм Габдрахман Тәүфикъ быел шәгъбан ахырында вафат булып, мәчет һәм мәхәллә рәиссез һәм яклаучысыз калып, әһелләренең сагынып, мине чакырулары, хәтта бөтенләй мөфтилекне һәм казыйлык хезмәтен ташлап кайтуны теләүләре мине кузгатты. Боларның барчасы өстәвенә, Мәхкәмәнең файдалары өчен мәркәз (Мәскәү) белән фикер алышып күрү, кайбер дини файдалар мәсьәләләрендә бер дәрәҗәдә хокук алу гаять тә таләп ителгән иде. Бу Казан сәфәре белән өмет иде ки, Аллаһның ярдәмендә, шул сәфәргә (Мәскәү сәфәренә) барырга юл ачылыр. Бу изге максатларны сәфәр теләге итеп, мондый авыр вакытларда, зәгыйфь хәлемдә, сәфәр йөкләнде. Бер нәрсәне җитди кирәксенү, дәрт белән шуны таләп итү аның юлындагы авырлыкларны җиңеләйтә, йөрәкнең кыюлыгын арттыра. Бүген һава эссе, уразалык бар, ачлык, сусау булса да, ифтарны (авыз ачуны – *А.Г.*) ихтыяр итмәдем, түзүне йөкләдем. Шунлыктан юл китеш, бездәй, матди тәрбиягә бирелгән, тән ләззәтен гадәт иткән кеше өчен бераз авыррак булганлыктан, бу язуларым бераз тәртипсез һәм кәефсез булып чыга. Ләкин ачлык белән рух куәтләнергә, йөрәк сафланырга, фикергә һәм каләмгә тәэсире яхшырак туарга тиеш иде.

Көймә (пароход) кечкенә, халык күп, тәрбиясезлек зур, рәхәт сәбәпләре юк, кояш кайнар, йокы калган, кыенлыгына түземлек юк. Шул хәлдә, акрынлап, барып ятарбыз. Ике тарафның елга кырые яшел агачлар, бай яфраклы, яңгырсызлык сәбәпле көйгән басулар күренми. Чөнки су байтак төшкән, елга кырыйларына тәрәзәдән күз салганда: «Торучы һәм йөрүчене аеру, бәс, мөшкел һаман, уйлар

керүче кеше: дәрья яры йөрер», – диелгән бәет мәгънәсе буенча, елга ярлары безне сәламләп калалармы яки алар китеп баралар, без озатып калабызмы? Ни булса да, күреп үтәбез. Калалар.

## 85 яшьлек Гайсә мулла белән сөйләшеп утыру

Көймәнең эченә чыгып йөргәндә Уфа төбәгеннән Чалмагыш авылының 85 яшьлек Гайсә мулланы күрдем, Уфа шәһәрендә дә очрашкан идек. Өченче класстагы җиргә утырган, янына чүгәләп, хәлләрен сорадым. «Тапурингә барам, аннан авылга кайтам, тугры юлчы туры килмәде», – диде. «Билет алдыңмы? Ни бәһа түләдең?» – диюемдә: «Күп алдылар, 230 сум түләдем», – диде. Сәбәбе: билет алмыйча, ашыгып көймәгә кергән икән, шуның җәзасы ун өлеш түләтү икән, 23 сум урынына 230 сум алганнар икән. Шәһәрдән яр буена килгәндә арба ташучыга да 100 сум түләгән, Уфа сәфәре арзан төшмәгән.

Югарыда телгә алынган остаз Мәрҗанинең элекке шәкертләреннән. Милади буенча 65 нче елларда шәһадәтнамә алган. Гарәпчә белүе бар, башка гыйлемнәр һәм кагыйдәләрдән дә хәбәрдар, зирәк кенә имам икән. Шәһәрдә очрашуымда дәрес бирмәвеннән сүз чыгып: «Мәдрәсәне тәрбия итүче булмады. Ярдәм булмагач, мөшкел булды», – җавабын биргән иде. Бу җавап – һәр дәртсез мулланың, ялкау галимнең сылтавы, күп тәҗрибә иттем. Шунлыктан җавабына канәгать итмәдем. «Мәдрәсәдән чыккач, дамеллага барып кайттыңмы?» – диюемдә: «Юк», – җавабын алдым, мәсьәлә хәл кылынды, бетте. Гыйлем тарату, дәрес бирү хезмәте – гыйлемнән бер дәрәҗәдә хәер-бәрәкәт күрү. Искә алынган тәҗрибәгә күрә, беренче шарты – остаздан аерылмау, аны ихтирам итү һәм аның күңелен табу, яхшы ризалыгын җәлеп итү.

Уфа белән Казан арасы якын җир була торып, егерме-егерме биш ел бармый тору – гыйлем юлындагы адәмнән гафу ителмәс явыз ният. Бу рәвешле адәм сирәк кенә гыйлемнән хәерлек күрә, дәрес бирү хөрмәтенә ирешә. Көймә бәһасен түләрлек көче булмаганда, Аллаһ биргән аяклар белән бармау – хәер-догасын алмау.

Борһанелислам «Тәгълим әл-мөтәгаллим тарикъ әт-тәгаллүм» китабында Шәмселәиммә («имамнар кояшы» дигән кушаматлы бер галим – *А.Г.*) белән бер шәкертнең кыйссасын телгә ала:

Шәмселәиммә бер сәфәрдән кайтышында шәкертләре килгәннәр, фәкать бер зирәк шәкерте килмәгән. Соңра остазы очрап, сорагач: «Карчык анам бар, аның хезмәтеннән аерыла алмадым, шунлыктан тиз килә алмадым», – дигән. Остаз Шәмселәхә җавабында: «Алай икән, озын гомер күрерсең, гыйлем бәрәкәтен күрмәссең», – дигән.

Чыннан да, тәҗрибә ителгән теге адәм озын гомер күргән, гыйлеменнән хәер-бәрәкәт, ягъни гыйлемне аңлату һәм тарату бәрәкәте күрмәгән. Бу мәсьәлә дөрес фәлсәфә буенча да шулай. Һәр сыйныф эштән бәрәкәт күрер өчен шул өлкәнең олугларыннан хәердога һәм яхшы ризалыкка юлыгу тиеш. «Бер адәм галимнәрне ихтирам итсә, үзе галим булыр яки балалары галим булыр» [дигән] әйтем әхлак китапларында һәм халык телендә билгеле. Ана матди тормышка сәбәпче булганлыктан, [аңа] хезмәте һәм хәер-догасы матди тормышның оынзаюына һәм бәрәкәтенә сәбәпче булыр. Рухи тормыш бәрәкәте өчен, рухи тормыш остазның догасына һәм яхшы ризалыгына илтүче булуы бер дә гаҗәп түгел.

Бу кадәрле язгач, көймәбез Уфадан түбән беренче тукталыш Благовещенга 6–7 сәгатьтә иреште. Нәкъ өч сәгать юл йөрүе судан 70 чакрым кадәрле аралык икән. Димәк, сәгатенә егерме чакрымнан артыграк юл китә икән, су агымы зарарсыз йөргән.

## Сәфәрдә ураза, сусау, чәй, су мәсьәләләрендә

Уфадан чыккан көнемдә ифтар итмәдем. Башта бу сәфәрдә ифтар итмәм, уразаның ләззәтен аңлаганлыктан, вакытны ганимәт [икәнен] белеп, уразаны үтәрмен, [дигән] фикердә булсам да, бу көнне авыр үткәрдем. Һава бик кайнар, юлда аз-маз хәрәкәт һәм борчу булганлыктан, хәлсезләндем, хәтта соңгы сәгатьләрне байтак зәгыйфь, авыр хәлдә кояш баю вакытын көтеп каршы алдым. Ифтардан соң һич булмаган микъдарда биш стакан чәй эчтем. Эчсәм дә, чынлап сусау басылмады, салкын суга кызыгып калдым. Чыннан да, чын сусауны басу өчен иң файдалы табигый ширбәт – су. Чәй һәм башка эчемлекләр – ясалма һәм азгынлык эчемлекләре. Хәтта безнең чәйне бал һәм шикәр белән эчү, дөрестән дә, сусау өчен түгел, бәлки, ләззәтләнү өчен. Аеруча бал авыз эсселеге белән сусауны арттыруы мөмкин. Шунлыктан куәтле бал белән эчкәндә күп эчелә. Нәфес теләве белән бал ләззәте өчен балалар кебек вакыт

әрәм ителә. Чын сусау вакытында табигать өчен иң файдалы – салкын су. Аллаһның биргән һәм боерган ширбәте – табигатнең сораган һәм яхшы кабул иткән нәрсәсе. Безнең саф судан бизү, чәйгә өйрәнү – тәрбия белмәгән аналарның тәэсире, үзебезнең дә кирәк белән кирәкмәсне яхшы аера белмәвебездән.

Чәй файдалы эчемлек булса, кирәгенчә булуы шарт. Кирәк вакытлары аштан соңрак аш сеңдерүне җиңеләйтү өчен бер яки ике стакан кадәр, уртача, артык сыек һәм куе булмыйча һәм бик кайнар эчмичә, акрынлык белән эчү тиеш, тәүлектә дүрт-биш стаканнан артык булмаска тиеш. Сусауны басар өчен эчү табигый хәл түгел. Чәйдә сусауны басу хасияте бар, булса да, безнең эчү рәвешенчә эчүдә түгел. Бәлки, суытып, бер-ике чынаяк эчү белән басу кирәктер ки, бераз тәм бирелгән су булып бассын. Бездә гадәт булган кайнарлары, биш-алты чынаяк, бал-шикәр, җиләк кайнатмалары белән эчүләр – сыйлану өчен эчелгән юл. Чәй шундый әйберләр белән эчелсә, кирәгеннән артык эчелә дә, файдасына [караганда] зарары күбрәк була. Чәйнең табигатендә уяту булганлыктан, әгъзаны сискәндерә, тора-бара адәмне нерв авырулы итә, йокыны качыра. Булган кадәрле йокы чын, яхшы һәм файдалы булмый, йокылы-уяулы бер хәл генә булып кала. Йөрәкне зәтыйфьләндерә, артык чәйгә бирелгән кешеләрдә кинәттән үлү ихтималы арта, кирәгеннән артык канны кайната, газның кирәгеннән артык мигә күтәрелүенә сәбәп булып, башны әйләндерә, хушсызлык-хәлсезлек сәбәбе булу ихтималларын куәтләндерә. Моның өстенә, чәй ашны югалта, карынны тиз ачтыра.

Чәйнең бу хәлләре китапларда күренде, кайбер адәмнәрдә тәҗрибә ителде, үземдә дә кайберләрен тәҗрибә иттем. Ләкин күп еллар өйрәнелгән, гадәт булган, әфьюнгә гадәтләнгән адәм кебек, гадәт ителгән гадәтне алмаштыру авыр, электән һәр бабтагы җитешсез тәрбиям кебек, бу бабта да тәрбиям ким булган. Яман тәэсирләрен күрсәм дә, бөтенләй саклана алмас булганмын, Аллаһ хәерле кылсын! Инде 64–65 яшькә ирешкәч, гадәт үзгәртү, тормыш алмаштыру – авыр эш. Чәйдән аерыла алмаган кеше сөт белән, бәлки, күбрәк салып, шикәр белән эчү тиешле, һәр икесе чәйнең зарарларын азайта, яхшырта.

Су эчү – бик файдалы ширбәт, дидем. Әлбәттә, саф, яхшы су булу тиешле. Аз гына шөбһәле булганда яки төрле авырулар мәйданда булып торган вакытларда кайнатмый эчмәскә кирәк. Кайнау сәбәпле суга катышкан кайбер зарарлы нәрсәләр, агулы

хайваннар (микроблар) һәлак булып, файдалы маддәләре генә кала. Кайнаган суны суытып эчү – бик файдалы ширбәт. Кайнар чәйгә гадәтләнгән адәмнәр өчен кайнар су яки аз гына чәй тамызып эчү белән канәгать итәргә тырышу кирәк. Картайганда, йокылар зәгыйфьләнгәндә бу мәсьәләгә бигрәк игътибар итәргә тиешле. Йокы өчен чәй дә, каһвә кебек уятучы булганлыктан, зарарлы. Йокы исә табигатьне һәм сихәтне саклау өчен, иң мөһим Аллаһ тәртибе һәм чарасы – кешеләрнең табигатьләрендә билгеләнгән гомуми канун. Сөбханәл-мөдәббирел-хәким (Эшнең ахырын Белеп эшләүче, Хикмәт иясе һәр кимчелекләрдән пакь – *А.Г.*)!

Чәйнең тәэсире урынның уңайсызлыгы белән төн йокысы бик аз булды. Бер сәгать кадәр булыр-булмас йокы белән үткәреп, сәгать өчтә кузгалып, иртәнге намазны түрдә үтәп, бераз вакыттан соң йокылы-уяулы ике сәгать кадәр ял итү мөмкин булды. Шул хәл белән иртәнге сәгать алтыда Бирски шәһәренә килеп җиттек, урыныбыз аз гына киңәйде. Кайбер бүлмәләр бушаса да, үз җенесләреннән башкага бирердәй булмаганлыктан, ялынмадык, барсына канәгать ихтыяр ителде.

Элек сәфәрләрдә артык муллык һәм рәхәтлек булган, табигать начар өйрәнгән, хәзерге еллардагы рәвешкә бөтенләй каршы яшәлгән. Шуның өчен бу инкыйлаблар иң олуг зарарын һәм яман тәэсирен байларга бирде. Үзләренең ниятләре дә шулай булды. «Буржуй» дип аларга бәла һәм җәфа бабларында олы аерма һәм зур өлеш чыгардылар. Табигый тәртип буенча да шулай булып туды һәм килде. Бу яктан караганда, бер яхшы гыйбрәт булды.

Бу кадәр язгач, хезмәт иптәшебез казый Ризаэддин әфәнденең бер киңәш бирүе һәм ихтыяры хәтеремә килде ки, язуда битнең ярымына гына язуны артык күрә, соңыннан төзәтү өчен калганнарны язу өчен уңайлы була. Бу язуда аны тәҗрибә иттем, онытылып калган сүзләрне язарга урын калмаган икән. Кәгазь кыйммәтлеге булса да, эшнең әһәмияте зур булганга, игътибар ителергә тиешле кагыйдә.

## Бирскида имам һәм мөәзин

Якшәмбе көн иртәнге 6–7 сәгатьләрдә Бирскига килеп җитеп, аз гына торгач, шәһәр имамы ахун Шакир әфәнде һәм Казан адәмнәреннән элек тә Бирски мәчетендә мөәзинлек кылган Габделвәли агай килеп керделәр, безне ишетеп, күрешә килгәннәр иде. Ахунның бер дистә чи йомыркасы, бер шешә сөт бүләге бар иде. Болар белән күрешеп, бераз сөйләшеп утырдык. Ахун Шакир әфәнде Шура хөкүмәте тарафыннан кайбер бәхетсезлекләргә очраган, таланган, төрмәгә кергән, байтак җәза күргән иде. Хәзер тыныч кына тора икән.

Бирскиның бик зәгыйфь, халкы аз, мәчете юк вакытларында ук Өчбүләдә укып, имам булган, әхлаклы, идарәле генә адәм, халыкны оештырды, яхшы мөнәсәбәтләрен җәлеп итте, бәрәкәт күрде.

Берәр сәгать үткәч, баягы Габделвәли агай бер бутылка сөт, бер дистә йомырка, бераз катырмач (сохари) китерде[12]. «Сыерым бик яхшы, шәһәрдә бер, үз сыерымның сөте, – дип, рәхмәт белдерү йөзеннән китерүен белдерде. Бу адәм Мәлик хаҗи ибне мулла Мөхәммәдшәриф – «Нәҗм әл-гыйлем шәрхе гайн әл-гыйлем» китабын бастыручының тәрбияләгән кызының ире икән. Бер дәрәҗәдә кәсеп итеп, мәчеттә тырышлык итеп тормыш итә икән. Җәзаһүллаһү хайран! (Аллаһ аңа хәерле әҗерен бирсен!)

Сәгать ун булганда көймәбез бу шәһәрдән кузгалды. Казанцевка юнәлде. Елдыр исемле мөселман авылы астында – Казанцевтан дүрт-биш чакрым югарыда гына – утын өчен көймәбез туктап, байтак утын алды. Көймәләр өчен әзерләнгән утыннары бар икән. Утын алуларында, ташу өчен күп вакыт үтә, конторасыз җиргә басма салып, байтак вакыт үткәрделәр.

Бу яр буеннан дүрт чакрым ераклыкта булган Яңа Яндыз исемле авылдан Әхъяр исемле бер имам килеп күреште. Мулла Насретдин мәрхүмдә укыган адәм икән. Мөхтәсибләре мулла Шәехгаттар Имакәй үткән көндә бу авылдан 6.70 сум (совет акчасы) Диния нәзарәте өчен ихтыяри иганә җыеп киткәнен сөйләде. Мулла үзе дә биш йөз сум биргән икән. Бу тукталыш һәм утын тирәсендә

---

[12] Элек катырмач дип ишеткән идем. Мишәр телен яхшы белүче мишәр Йосыф әфәнде Дибирдиев «катырмач» диде. Бу тел Казанда юк. Бары русча «сухари» дип сөйлиләр. Төрекләр французча «тиксмат» диләр. Сарытау мишәрләре «катырмач» диләр. Моны урынлы күреп яздым.

халык, мөселманнар күренде, уразалы, уразасыз төрле адәмнәр бар. Пристань тирәсендә күбрәк йөргәннәрнең төтенләп йөрүләре күренде. Бу тарафларда да, башка башкорт авыллары кебек, муллалар күп, һәр мәхәлләдә икешәр, ләкин укытулар аз; тәрбия, вәгазьнәсыйхәтләре бигрәк аз булырга охшый, әсәрләре күренми.

## Уфа тарафында рамазан вәгазьләре

Гомумән, Уфа һәм тарафында имамнарның вәгазьләре күп түгел, аеруча рамазан вәгазьләре гадәт булмаган икән. Казан һәм тарафындагы яхшы гадәт – рамазанда һәркөн икенде-ахшам арасы вәгазе калдырылмый, никадәр авыр булсын, имамнар бу изге хезмәтне үтиләр. Имамнарның гыйлемнәренә һәм хисләренә күрә, төрлечә файдалы вәгазьләр һәм укытулар була. Хәтта бер еллык дәресләр бирелеп кала. Элекке бөек, диндар имамнар, яхшы мөдәррисләр аркасында Казан йорты электән үк гыйлем йорты, динлелек мәмләкәте булып, бу яхшы гадәтне торгызып калдырганнар. Җәзаһүмүллаһү хайран! (Аллаһ аларга хәерле әҗерен бирсен – *А.Г.*)!

Уфада бу күркәм эшне үтәргә тырышсам да, булмады. Хәтта мәхәлләбез, беренче мәхәллә имамы мулла Җиһангир ахун юк-бар сылтаулар белән тоткарлады, йөкләмәде. Хәер, җомга хөтбәсендә бер-ике аять укып, озын лекция (дәрес) рәвешенчә, аятьне төркичә аңлата, байтак нәрсә сөйли, ләкин дини һәм файдалы мәгълүмат булса да, халыкка файда биргән кебек тоелмый. Речь тыңлаган кебек кенә тыңлыйлар. Нигездә, бик озын, сөннәт даирәсеннән чыгып китә, дин рухындагы йөрәккә дини тәэсир бирә торган рәвештә булмый. Үткән елда югарыда күрсәтелгән [кеше үзенә] йөкләмәгәч, рамазанда һәр көн үзем сөйләдем. Быел куәтем һәм көчем аз булганга, үземә йөкләмәдем.

Көндезге сәгать өчтә Казанцевка ирештек. Тау-тау өелгән капчыклы икмәкне ташыдылар, Шураның үз идарәләрендә җыелган, үз идарәләрендә генә теләгән чыгымнарга таратылачак иген. Ташучылар тәнәфес итә-итә (ял итә-итә – *А.Г.*), мең капчык, биш мең пот онны ташып бетереп, ярты төндә генә көймәбез хәрәкәт итте. Иртә намазы вакытында, Дүртөйледән үтеп, сәгать сигез булганда Андреевкага (Бишен Бүкәнгә) ирешеп, озак тормый хәрәкәт итте. Яныбыздагы биш баласы белән эш эзләп чыккан

маржа йомырка алып керде. «Ни бәһа белән алдың?» – диюебездә: «Акрын әйтә күр, яшереп кенә саттылар, дистәсен 150 сумга алдым, Уфада (совет акчасына) 250–270 сум иде», – диде.

Бүген дүшәмбе (14 июнь, 27 рамазан), янә һава ачык, кызу. Икенде, ахшам вакытларында һәр көн болытлар күренсә дә, яңгыр һич күренми. Бөре өязеннән көймәгә керүче адәмнәр: «Рамазанда яңгыр булгалады, каты ашлык (сабан игене) яман түгел, яхшы тишелде, җирне каплады», – дип өметләнеп сөйлиләр. Арышта өметләре азрак, яхшы җирләре бар икән. Аллаһ ахырын хәерле кылсын!

## Рус халкында бала тәрбиясе

Бу сәфәрдә урыныбыз залда, ачыкта булганлыктан, балалы маржалар байтак кереп чыкканлыктан, азрак хәлләре, балаларына караулары күзгә чалынды. Беренче класс булганлыктан, бөтенләй тәрбиясез, түбән адәмнәр түгел, балаларына караулары яхшы гына күренә. Өч вакытта, балаларын яхшы утыртып, һәркайсына икмәк, йомырка яки сөт бүлеп бирәләр, карап ашаталар. Сөт бик кадерле булганлыктан, стаканның күбрәген кайнар су белән тутырып, чәйгә салган кебек сөт катыштырып бирәләр. Сөтләре мул булса, бөтенләй сөт бирәләр. Тәртипле генә ашатып, тәмам булгач, балалары аналарына рәхмәт урынына битеннән яки авызыннан үбәләр. Ятар вакытларында урыннарын әзерләп, тәртип белән яткыралар. Идәннең уңайлы җирен ихтыяр итәләр. Кайвакыт өстәл астына урнаштыралар. Йокы диккатеннән ваемсызлык итмиләр, барлыйлар. Боларның тәрбия ысуллары безнең халык тәрбиясенә караганда яхшырак, бераз тәрбия нигезләре юлына кергәнрәк.

Асылда, егет һәм кызга элек өйләнешү хокукларын һәм балалар тәрбиясе нигезләрен яхшы өйрәнү һәм белү кирәк. Икътисади һәм иҗтимагый куәтне яхшы хасил иткәннән соң гына никях эшенә керешү тиешле. Атаның икътисади куәтенә ышанып, үзе балалык мәртәбәсеннән чыкмыйча, тәрбиячелек дәрәҗәсенә кермичә, өйләнү хәерле нәтиҗә бирми. Бары хайвани шәһвәт, тән ләззәте үтәү өчен генә бер гамәл булып чыга. Ата һәм ана элек үзләре балаларның хакларын үтәргә, аларга яхшы рухи һәм физик тәрбия бирергә тырышу тиешле; соңра алардан хәерлек, хезмәт һәм яхшы хәрәкәт көтәргә тиеш.

Әхлак һәм сира китапларында мөэминнәр әмире Гомәр радыяллаһү ганһүгә бер карт улыннан шикаять иткәч, мөэминнәр әмиренең (Гомәрнең – *А.Г.*) ачуын күреп, улы: «Баланың атасы өстендә хокуклары юкмы? Атам ул хокукны үтәдеме икән?» – дип сорагач, мөэминнәр әмире: «Элек балага күркәм исем бирү, тәрбияләү һәм укыту, балигъ булгач өйләндерү – баланың атада булган хакы», – дигән. Бу ата баласының бу хокукларыннан һичкайсын үтәмәгән булып чыккач, мөэминнәр әмире искә алынган атаны яныннан куып чыгарган.

Балалар тәрбияләү бабында руслар безнең Казан төрекләреннән алдарак булсалар да, яһүд һәм немец халыкларына караганда шактый артта. Аларның әһәмият бирүләре артыграк. Шунлыктан ул халыкларның тормышлары, сәүдә һәм сәнәгать бабларында бәрәкәтләре шактый күп. Безнең белүебезчә, ислам галәмендә бала тәрбиясенә иң яхшы әһәмият бирүчеләр – гарәпләр, фарсы халыклары. Болардан кала, һиндстан, Төркестан халыклары. Аллаһ дөресен белүчерәктер!

Сәгать уннар булганда Азаккүлгә (Азакүлгә – *А.Г.*) ирештек. Үткән төндә күптәннән бирле сагынган яңгыр явып, халыкны күңеллеләндергән, җирләрне канәгатьләндергән икән. Гадәтләренчә, көтү-көтү хатыннар һәм яшь киленнәр, кайберләре йомырка һәм сөт сатарга, кайберләре: «Германиядән әсирләр кайтмыймы?» – дип тилмереп чыкканнар. Бер яшь килен миннән дә: «Әсирләр кайтмадымы?» – диде. «Кайта башладылар, шаять, әсирегез тиз кайтыр», – дип юатып үттем.

Йөзәрләп чыккан көймә кешеләре тиз-тиз сөт, йомырка, икмәк алып керделәр. Куркып, яшереп кенә саталар. Шура әгъзалары кыйммәт бәһа белән саттырмыйлар, өч йөз сум сорап торган кешенең өстенә барып, йөзәрдән саттырганлыгын сөйләделәр. Мин дә икмәк сорашкач, шунда очраган мирза Салих бине Габделкаюм бине Габделҗәббар Зәбири ике йөз сумга дүрт кадак чамалы бер икмәк табып китерде. Бер агай яшерен генә: «Ике дистә йомырка бар, 150 сумнан», – дигәч, риза булдым. Акрын гына кесәсеннән чыгарып санап бирде. Юлда һәм Казанда азык булыр дип, өч дистә йомырка, 65 сумга бер икмәк алдым. 30 сумнан сөтнең бутылкасын саттылар.

Пристаньгә якын булган авылларга сәүдә [итү] мөмкин. Ләкин мөселман авыллары су буенда бик аз калган. Элек көймәләр йөри башлагач, кайбер авыллар үзләре эчкәрәк күчкәннәр. Хөкүмәт

сәясәте кушуы белән, елга буена һәм шәһәр якыннарына күбрәк руслар урнаштырылган. Казан һәм Нижний тарафларында да бу сәясәткә игътибар ителгән.

Азаккүлдән кичеп, Чеганда исемле яңа урынга ирештек. Бер сәгать торганнан соң, Пермь тарафыннан элекке Каменский ширкәтенең «Зур Волга» исемле көймәсенә килеп, мәшәкать беләнрәк кереп урнаштык. Төп пересадкабыз Пьяный Борда булырга тиеш булса да, көймәбез җитез китәчәк булмаганлыктан, моңда ук күчтек. Ләкин өлгер адәмнәр элек кереп, урыннарны алып бетергәннәр. Без дә беренче классның мәйданына (залына) кереп, әйберләребезне җиргә куйдык. Үзебез өстәл буена утырдык. Сәгать 6 һәм чирек булганда көймәбез кузгалып, Пьяный Борга юнәлде. Бу көймәбез элекке Пермь көймәләренең иң яхшыларыннан, зиннәтле, киң көймә булган, кайбер зиннәтләре бетеп җитмәгән. Элекке көймәбезгә караганда яхшы, алай да, хатыным ике тәүлек бергә килгән бүлмәдәшләре белән танышкан, сагынып, моңаеп утырганын сөйли. Шулай шул, бәндә, бигрәк тә, мөэминнең күңеле аралашучан, сүздә торучан, килешүгә игътибар бирүче булырга тиеш. Хәтта бу холык һәм сыйфат хайваннарда да тәҗрибә ителә.

## Бохаралы казый Гавделвахит

Бу вакыйганы язганда Бохараның остазлары һәм зур галимнәреннән казый Габделвахит бине Мөхәммәдшәрифнең[13] бер кыйссасы хәтеремә килде. Бу адәм төп Бәлх халкыннан булып, Бохарада гүзәл гыйлем алганнан соңра казыйлыкка бирелеп, кырык-илле ел кадәр казый булып үткәргән һәм даими рәвештә гыйлем юлында да шөгыльләнгән. Бохараның иң зур китапханәсе бу адәм китапханәсе иде. Яз көннәрендә бу кешенең яны һәм казыйханәсе галимнәр һәм юлчылар җыела торган урын булыр иде. Мин дә барып, бер атна кимрәк кунак булып кайтыр идем. Сәләтле һәм гыйлемне кабул итүче адәм [итеп] күреп, минем хакта хөрмәте зур

[13] Бу казый Габделвахид озак вакытлар Гыйҗдуванда казый булып торган. Үзенең мәҗлесе һәрвакыт гыйлем мәҗлесе булып, үзе бик мосафирларны яратучы булганлыктан, Бохара шәкертләре аның мәҗлесләренә барып катнашалар, мосафирханәсендә атналарча кунак була торган булганнар.

иде. Кайтыр елымда Бохарадан барып килдем һәм саубуллаштым. Минем ватаныма кайтуым мөнәсәбәте белән үзе дә ватанына омтылып, елаштык. Шунда сөйләде: «Диңгез буенда үскән бер камышның башына чыпчык кунган. Җил сәбәпле, дулкын килеп, камыш башына кадәр су сибәр. Бәрелгән саен, чыпчык күзгалып, сикереп-сикереп утырыр икән. Дулкын, әлбәттә, һаман бәрелеп тора, чыпчык та һаман кузгалып, күтәрелеп куна тора икән. Моны акыллы башрак бер кош читтән күреп: «Әй, ахмак чыпчык, бу кадәр җәфа һәм мәшәкатьне йөкләп, шул камыш башында ни өчен утырасың? Судан читтә бу кадәр тыныч урыннар бар; шунда кунсаң, рәхәтләнеп утырыр идең. Бу кадәр ахмаклык булырмы!» – дигәч, чыпчык җавабында: «Бераз заман булды, монда кунган идем, ватаным булды. Мәшәкать булса да, ватанда булу ләззәтен югалтмый, бу мәшәкатьләр авыр килми», – дигән.

Бу адәм изге һәм хөрмәтле адәм иде, шәех Җәләлетдин мәхдүм Хиябани хәзрәтләреннән тарикать алган (вафаты 1305 (1887) елда). Һәр намазда, тәһарәт яңартып намаз укыр, бер сак адәм иде. Мәрҗани мәрхүм белән сөйләшүебездә бу адәм [хакында] сүз чыккач: «Ул адәм намазда тәһарәт яңартучан иде, хәзер ничек?» – дип сораган иде.

Күзләрен каплаган керфекләре арасында гына күзләре белән һаман яхшы язуга игътибар итә. Язуын югалтмас өчен бармакларын тик тотмас, даими матур язар иде. Миңа үз матур каләме белән гарәпчә гыйбарә, иҗазәтнамә язып җибәргән иде. Җәзаһүллаһү ганни хайран һәм рәхимәһү рахмәтән вәсигатән! (Аллаһ аңа хәерле әҗерен бирсен һәм киң рәхмәтен кылсын!)

## Көймәләрнең хәлләренә бер караш

Элекке заманнарда адәмнәр төрле классларда йөртелә, араларында зур аерма булган төрле урыннарда җирләшәләр, ашау һәм эчүләр дә ирекле-ирексез шул хәлгә яраклы булыр иде. Бу соңгы инкыйлаб байтак хәлләрне алмаштырды. Беренче классларның зиннәтләре, мактаулы пәрдәләре һәм өстәл җиһазлары – бар да югалтылган. Өстәлләрендә коры такта, тәрәзәсендә пәрдә заты калмаган. Кояшның файдалы эсселегеннән урынсыз саклану өчен җиһаз калмаган. Кайбер адәм урындыкларда, кайберләре идәндә урнашырга чират калган. Бай, ярлы, гаскәри һәм башкалар тиешле,

аз гына аермалы бәһасен түләгәннәр дә капчыклары, чехоллары белән кергәннәр, тигез файдалануда.

Бу хәл бер тарафтан яхшы. Тәрбияле-тәрбиясезләрнең бергәрәк булулары кайбер җәһәттән зарарлы кебек күренсә дә, файдалы тарафы да бар, иң яхшы ихтималы да булыр. Бергәлек аңлату һәм файда алу өчен әһәмиятле. Шөбһәсез, тәрбиясезләр тәрбияле адәмнәр араларында булгаласалар, аз булса да файда алырлар. Тәрбиялеләр (бу әйтүем тышкы күренешкә карап, үзләрен тәрбияле тоткан дию мәгънәсендә) дә тәрбиясезләрдән гыйбрәт алырга мөмкин. Әдәпсезлек, әхлаксызлыкны театрларда күреп, файда алу дәгъвасында булганнар өчен бу табигый мәҗлесләр, файда алу өчен, әлбәттә, лаек булырлар. «Әдәпне әдәпсезләрдән өйрәндем», – дигән матур әйтем Гайсә пәйгамбәргә (галәйһис-саләтү вәс-сәләм) нисбәт ителә. Шунлыктан көймәдәге бу хәлләр, фәлсәфи караш белән караганда иске хәлләрне сагынырлык булмый, бәлки, аларның яраксыз булуын аңлау юлын ача.

Безнең көймәбез шактый зур булса да, элекке көймәне сагындырырлык хәлләре булды. Югарыда таһарәт бозу-таһарәт алу урыннары җимерек дип, коммунистлар, көймә хезмәткәрләре үзләренә алганнар, ачкыч белән бикләп йөриләр. Мосафирларга түбәндә өченче класс бәдрәфләрен һәм аның юынгычларын күрсәтteләр. Кайвакыт ачык хәлендә керелсә дә, бик уңайлы хәлдә калмаган, тынычлап истибра итү (бәвелне чыгарып бетерү – *А.Г.*) мөшкел, түбәндә исә аннан [да] мөшкел. Өйрәнмәгән җирдә бушануым һәрвакыт мөшкел булганлыктан, тимер юлларда бик авырлык күрә идем. Җиңел бушануым да бик авыр була иде. Монда ярым тәүлек кадәр бәвел тоткарлап, бераз мәшәкать чиктем. Бу бер хис итү һәм зәгыйфьлек бәласе булса кирәк.

Икенче, элекке көймәбездә бер рәшәткә диван булса да, җайлы булган иде, монда булмады, дәрвишләрчә җирдә яттык. Хәер, башкалар да шулай яттылар, аз адәмгә диван иреште. Ни булса да, Аллаһ ярдәме белән, бу кичә дә үтте. Иртәсендә сәгать 5 тә Чаллыга ирештек. Яр буена чыгып, алтмыш сумга (совет акчасына), әчүгә якынлашкан, тулыр-тулмас бер шешә сөт алып кердем. Иртән чәйне алдан берәр стакан чәй, яныбызда булган кара икмәк, шикәр, бал, май катыштырып, якынча 200 сумлык чыгым буларак, авыз иттек. Вәлхәмдү лилләһи галә күлли хәл! (Нәрсә генә булмасын, Аллаһка мактау!) (Кайбер сакчыл карт муллаларча, көферлек һәм адашудан

башка (ягъни бөтен нәрсә өчен Аллаһка мактау, көферлек белән адашу гына булмасын – *А.Г.*)).

## Чаллыда Хәлфиннәрне искә алу

Чаллы пристанендә дусларыбызда кабат кунак булганда бертуган Хәлфиннәрнең тау буенда корган зур тегермәннәре каршысында зур конторалары моңаеп торалар иде. Хәлләре белән элекке хәлләрен сагынып, хуҗаларын кат-кат искә алып, башларына килгән заманаың бәхетсезлекләренән шикаять итеп, зарланып торганнары күренә иде. Хуҗаларының бергә дүрт агай-эне гаиләләре белән бөтенләй күчеп һәм качып китүләреннән шикаять иткән кебек калган булсалар да, бу кадәр күп зыян күрмәгән, үзләре һәм нәрсәләре бу кадәр күп җимерелмәгән булыр иде, дигән төсле күренә иде. Олылары – котыртуга бигрәк җиңелгәне – хаҗи Шакир әфәнде хакында фаҗигале үлем хәбәре сөйләнелә (лә садәкаһәллаһ – Аллаһ раст итмәсен). Эш башындарак булганы – Гариф әфәнде – Верхний Удинда кодасы Нәҗиб бине Габделлатыйф Хәкимов белән сәламәт булулары ишетелсә дә, кияве Зәки бине Нәҗипнең кече бертуганы Зариф белән бергә Омск ат юлында угрылар тарафыннан фаҗигале рәвештә үтерелгәнлекләреннән хәбәрләр ирешә. Бертуганы Шакир (Хәкимов) хакында да фаҗигале вафат хәбәре ишетелә. Мал саклау, саулык сөю, хирыслык әсәре булмавы күренә.

Бу күченеп китү күп фаҗигалар тудырды. Хәер, качмый калган кешеләр дә рәхәт яшәмиләр. Шулай да качканнар дәрәҗәсендә бәлаләргә һәм җәфаларга очрамадылар. Бер дәрәҗәдә талансалар да, качкыннар кадәр түгел. Хәер, качучыларның төрле фикер, төрле максатлары арасында фәкать сәүдә өчен киткәннәре дә күп булды. Кызылларның сәүдәне тыячак ысуллары мәгълүм иде, Сибириягә басып алулары катгый түгел иде. Шунлыктан сәүдәдән ләззәт алган, хирыска бирелгән адәмнәр шул ният белән күчтеләр. Арада күп байлык хасил итүчеләре дә ишетелә. Арада ихластан ияреп күчүчеләр дә булды. «Эт чаба, эт чаба дип, бет чаба» кебек йөрүчеләр электән үк булды. Бертуган Хәлфиннәр, Хәкимовлар кебекләр, сабыр итеп, Шура хөкүмәте белән мөгамәләгә керешсәләр, башларына килгән аз-маз авырлыкларга түзү юлына кереп, тормышларын саклау юлына керсәләр, мөмкин булган икән. Ләкин рәхәткә өйрәнгән адәм, буш уе сәбәпле, көчтән чыккан ихтимал-

ларны күз алдында китереп, җиңелеп чыгып китә. Уйланган авырлыклардан, курыккан җәфалардан биш-ун өлеш артык җәфаларга дучар булып китә, һәммәсе дә Аллаһының тәкъдире, гыйбрәт өчен булган яхшы тәрбиясе булса кирәк.

Бу уйда җиде сәгать, җиде минутта Алабугага ирештек. Тиз үк яр буена чыктым. Рәхәтлек белән су түктем.

## Дөньяның ләззәтләре

Бу мәсьәлә – бик гади язылуы, кайбер адәмнәрчә, гаеп саналырлык булса да, дөрес, мөһим мәсьәлә, дөнья ләззәтләренең берсе. Дөньяның ләззәтләренә диккать итсәгез, чын карау белән карасагыз, хакыйкый ләззәт тапмассыз. Бар да – зарарны кире кагудан яки җәфа катыш бер хыялый ләззәт. Йокы иң рәхәт, иң ләззәт бирүче бер хәл булып, ләззәте кайвакытта булу мәсьәләсе әдипләр арасында булмый торган бәхәс ки, вакытында аңлау юк, соңыннан үткән, алдында ирешү юк. Бәс, ләззәтләнү, кайвакытта җавабында: «Чын ләззәт юк, бәлки, зарарны кире кагу җенесеннән бер рәхәтлектән гыйбарәт», – диюләрдән башкача җавап юк.

Кайбер оста сүзле кешеләрнең: «Дөньяда нәрсәләрне тели?» – соравының җавабында: «Бик кысталган вакытта рәхәтләнеп бушану», – дигән җавабына ни әйтерсең яки: «Бик кычыткан җирне кашу», – дисә яки: «Бик ачыкканда өстенә тоз сипкән арыш икмәге», – дисә, кабул итмәскә чара бармы?

Дөньяның бар ләззәте дә бөтенләй кирәклеккә карап кына йөри. Шәкертләр әйтмешли, игътибарга лаеклы әмер яки шуңа якын. Чын ләззәт булса, аерма булмаска тиеш. Дөньяда мондый ләззәт юк, һәркайсы хажәт вакытта бер дәрәҗәдә ләззәт бирә, туйгач, бар да сөйкемсез күренә. Байлар кайбер вакытта: «Алтын, җәүһәр болай түгел, ләззәт бирә, туйдырмый», – диярләр. Моңа шәех Сәгъди философның мәкаләсе канәгатьләндерерлек җавап бирә:

Бер дәрвиш сәяхәтендә чүлдә бик ачыккан. Ахыргы хәлгә якынлашканда алда кечкенә капчык белән бер нәрсә күргән. Ерактан бөртекле нәрсә булып күренгәннән, бодай бөртеге дип уйлап, гадәттән тыш куанган. Кем белер, Аллаһка никадәр шөкраналәр кылгандыр. Кулына алып, капчыкны чишеп караса, җәүһәр, вак ташлар, энҗеләр булып, элек күренешендәге шатлыгы кадәр

көенеч пәйда булган. Хәзер ул җәүһәрләр ничә миллионлык асыл ташлар булгандыр. Ләкин моның ачлыктан саклауда һич файдасы юк: һәлак һәм үлемнән коткармый, чүлдә сатып алучысы юк. Ни япсын, «җәяүлегә янчык авыр» дигәнчә, җәяүле ачка бу янчык бигрәк тә авыр тоелган да, бәлки ташлап киткән.

Алабуга берегында (ярында) сәүдәгәр марҗалар күп, кыяр сатучылар, йомырка, балык сатучылар бар. Кыярның әүвәл күренеше яңа булганлыктан, утыз сумга шактый зур гына бер данә кыяр алдым. Кыяр сөюче хатыным: «Аз алгансың», – дисә дә, мин: «Алтыдан яки дүрттән беренә канәгать итәрмен. Син җыярсың (ашарсың) җавабын бирдем. Ничектер, дүрттән береннән артыгын бетерә алмады. Дистәсе өч йөз сумнан өч дистә йомырка алдым. Азаккүлдә бер йөз илле, Чаллыда ике йөз илле иде, монда өч йөз булган. Кем белер, Казанда биш йөз бардыр. Биш-алты дистә йомырка азыгыбыз булды. Аллаһ бәрәкәт бирсен!

Озак тормый, Алабугадан хәрәкәт иттек. Ләкин сулар бик тирән түгел, көймә бик зур, мал күп төягән, саклык белән йөзә. Алабугадан үткәч, Казан вилаяте керә, яңа татар җөмһүриятенә күрә, Минзәлә һәм Алабугада ук Казан губернасы керсә дә, без иске ис белән каравыбыздан, Алабугада соңгы юнәлешне күзгә алабыз.

Нократ һәм Чулман кушылган урында беренче тукталыш – Соколка тукталышында билетлар сату белән көймә байтак юанды. Нократ елгасы белән Вятка, Мамадыш тарафыннан килгән адәмнәр көймәгә кабул ителде. Шуларның арасында «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә караганнарыннан Минзәлә, Мортыш башыннан Зәки хәлфә бине Камал, Спас Ташбилгедән Сәед Вахиди очрап, бераз аңлашылды. Зәки авылыннан Спаска, вакытлыча укытыр өчен, Сәед Мамадышта укытып, ял итәр өчен кайтып килә икән. Болардан Казанның кара хәбәрен ишеттем: 8 нче июньдә Казанда Сукырлар (Большой Мещанский) урамыннан ут чыгып, һава көчле, җилле булганлыктан, янгын зурайган. Бер тарафтан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе артын яндырып, Кызыл мәчеткә кадәр, икенче тарафтан Зәңгәр мәчетне яндырып, арттан Ак Ком астына кадәр чыккан икән. Безнең өй кварталы сәламәт икән. Якын һәм ачык хәбәр беленмәсә дә, бу кадәр фаҗигале хәбәр алынып, ватанга кайту куанычын тәкъдир итте, дуслар белән очрашу куанычын кайгыга әйләндерде. Аллаһ ахырын хәерле итсә иде! Бу урамнар янгыннан күп өлешле икән, үткән көздә дә күп, каты янганнар иде, 1902 елда да куәтле ут

үткәргән иде. Бу чиратта исә һәммәсеннән артык көчле һәм гомуми булган икән.

## Казанга якынлашу, хәсрәтләнүләр

Казанга якынлашабыз, акрынлап Казан исе килә башлады. Казан рухы сизелә башлады. Якынланган саен сагыну арта бара. Казаннан аерылганыма 23 ай һәм ун көн кадәр вакыт үткән. Бохара сәфәреннән соң бу кадәр аерылу булганы юк иде. Вологда сәфәрендә дә шул кадәр чамалы гына аерылганым булган иде. Вологда сәфәрендә Пәдәр мәрхүмне югалткан идек. Бу аерылуымда бертуганым Габдрахман әфәнде, дустым Садыйк бине Сафа Галикәй, сөекле шәкертем Казанбашы имамы Җәгъфәр бине Сираҗетдин дөньядан кайттылар. Башка танышлардан байтак адәмнәр юк, күп дәүләтлеләр дәүләтсез, бәхетлеләр бәхетсезлек хәленә килгәннәр. Киресенчә булган адәмнәр дә бар. Бу хәлләр бар да йөрәккә тәэсир бирә. Теләмәсәм дә, читтән карап торуга караганда, эчләренә кереп хәлләрендә, кандай хәл булса да, катнашу теләге күренә.

Мәхәллә әһелләре бөтенләй кайтуымны телиләр һәм сорыйлар иде. Алар белән ничек мөгамәлә итәргә, ни җавап белән биш дустанәләреннән котылырга? Уңайлы хәрәкәт исә мөмкинлек чыгуында. Милләтнең Әманәт мәхкәмәсен урамга ташлаган кебек ташлап китү кешелеклелек һәм ислам карашларына сыймас бер вөҗдансызлык. Милләтне чакырып, хисап биреп, үзләреннән ярдәм алу яки Шура тарафыннан куылу юллары гына безне җаваплылыктан коткарып, китү юлын күрсәтә. Валлаһү га-кыйбәтүл-үмүр (Аллаһ эшләрнең ахырын белгеләүче – *А.Г.*)!

## Диния Нәзарәте һәм аның дәвам итүе

Диния Нәзарәте – Мәхкәмәи-шәргыянең дәвам итүе мәсьәләсе – Русия мөселманнары өчен таләп ителгән һәм сөелгән мәсьәлә. Боларның теләүләре һәм таләпләре хакыйкатьне аңлап түгел, күбесенең өйрәнгән буенча бару, яңа һәм ияләнмәгән нәрсәдә бер зарар һәм афәт уйлауларыннан гына барлыкка килгән. Аның бу хәлдә дәвам итүе: искечә имтихан, метрика дәфтәре бастырып

тарату, гаилә дәгъваларын тоткан юлы белән хәл итү, вакыф һәм васыять маддәләрен шәригать шәрифкә яраштыру кебек эшләрне эшләп торуы җитәрлек һәм дә мөһим эшме? Шул кадәр эшләр өчен зур чыгымнар белән Мәхкәмәне дәвам иттерү теләгендәме? Яки башкачарак тәртип хәҗәтме? Бу бабта яхшы күрү һәм уйлап эшләү хәҗәт. Хәзер һәр иске искечә торсын заманы түгел. Ни файдалы, ни рәвеш нәтиҗәле – шуны эшләү тиешле. Эшләрне җиңеләйтү, тизләтү тиешле. Ислам, баштан ук, гадилек, эшне тиз эшләү, эшне үтәү, һәрбер нәрсәне табигый хәлдә саклау белән төзелгән.

Эшкә ясалмалык катыштырылып, төрле-төрле формалар кертелеп, кирәкле-кирәкмәс тәкълидләр (иярүләр – *А.Г.*) кабул ителеп авырайтылган. Бер көнлек эшне бер атна эшләргә, бер атналыкны айга сузарга, тартып-сузып эшләргә гадәтләнеп киткәннәр. Күп маддәләрдә Ауропага ияру, Ауропа маймыллыгы, Америка әмерләре кереп, күп эшне чыгырыннан чыгарган.

Элек мөселманнарга, бер күркәм [эш] итеп, тарафлардагы башкортны тынычландыру, казакъны тәмам кулга кертеп бетерү, бу ике сыйныфлардан сәясәт рухын суырып алу өчен, Екатерина Икенче (Әби патша) бу Мәхкәмәне корган. Бер яктан, казакъ, башкортның сәяси рухларын алуда күп хезмәт күрсәткән Мөхәммәтҗан мөфтигә бер хезмәт, бер дәрәҗәдә булсын дип, мөфтилекне торгызган. Аның хезмәтләрен чикләп, халык арасында абруен да бер яхшы юлга кертеп җибәрүеннән сакланып, тар гына даирәдә ихтыяр бирелгән. Табигый, безнең халык мәчет торгызырга рөхсәт бирүне, кирәкме, кирәк түгелме, бер мәчет салынса, бик зур дин яхшырту һәм исламның алга китүе булды, дип уйлый. Шундый хезмәтләр белән бу Мәхкәмәне мәшгуль итеп, милләт өчен аз гына файдалы хәрәкәт, гыйльми һәм иҗтимагый бер эш күрүне теләсә, тиз үк туктатып, хәтта: «Ходаеңнан уздың, вазыйфаңнан тышка киттең,» – дип, шелтә итеп килгән. Шунлыктан бу Мәхкәмә үзенә бер яхшы урын тота алмаган, ягъни ала алмаган. Булган казыйлар шәхси, гаять икътисади мәнфәгатьләре өчен генә бозык юллар белән урнашып килгәннәр. Мөфтиләр, кирәк яхшы, кирәк ялгыз башына, бер эш тә күрә алмаган. Шунлыктан, искә алынган мәсьәләләр белән көн үткәреп, мөфти һәм казыйлар өчен бер керем китерә торган эш кебек сакланып килгән.

Инде моның реформа вакыты бик җитте. Милләтнең, карт һәм яшенең бездән өмете зур иде. Без дә казыйларыбыз белән бу өметне күрә һәм гамәлгә чыгарырга максат куя һәм ниятли идек. Ләкин,

социалистлар рухынча, тезеннән вату, җимерү ысулын милләтнең күтәрә алуыннан чыгып күреп, бәлки, чиксез тыюларга очралыр, дип, акрынлап эшләү фикерен тоткан идек. Ләкин Милләт мәҗлесе туып, безнең планнарны сүтте. Көч һәм куәтебезне иске Романовлар кебек чикләде. Мәхкәмәи-шәргыянең яхшы эшләр бабында уңышыннан куркып, динне куәтләү һәм милләтне яхшырту эшләренең Мәхкәмәи-шәргыя тарафыннан тууына көнләштеләр яки бөтенләй мәсьәләне теләмәделәр. Милли идарә торгызып, аның рәислегенә, аның билгеләве астына мөфти, казыйларны һәм бөтен Мәхкәмәне тапшырдылар. Бу рәвеш искә алынган Мәхкәмәнең, милләт агаларының, дин әһелләренең фикерләрен бик түбәнгә төшерү һәм мыскыл итү булды, гайрәтен сүндерде, рухын алды, мәктәп һәм мәдрәсә бабында тын чыгарырга ирек бирмәде. Икътисади эшләрдә финанс министрлыгы дигән идарәнең рөхсәте һәм ярдәме белән эш күрүне мөмкин күрде. Шул рәвешле идарәсе белән Мәхкәмәи-шәргыядән көтелгән иң зур өмет булган мәктәп һәм мәдрәсә эшләре искедән дә начар хәлгә килде. Һәркайсы халыкның ризалыгына каршы булып, дошманлыкларын җәлеп итте, нәфрәтләрен уятты. Соңыннан килеп чыккан коммунистлар мәсләгенә юл гына әзерләделәр. Күп заманннан бирле мәктәпләрдә сакланып килгән дин рухын бетерделәр дә, үзләре дә тукталуга, афәткә очрадылар. Мәхкәмәи-шәргыя исә зәгыйфь хәлдә, иске микъдарда гына эшләргә калды. Инкыйлабларның тәэсиренннән котылып, җитәр-җитмәс икътисади авырлыкка очрап, аның дәвасына керешеп, бер дәрәҗәдә тәэмин итте. Вәлхәмдү лилләһи галә зәлик (Шуның өчен Аллаһка мактау – *А.Г.*)!

Инде җитди рәвештә бер хәрәкәт вакыты килде. Килмәсә дә, китереп, бер яхшырту тиешле күренә. Бу урында мин бер төрле фикер күрсәтәм, диккать белән карау һәм киңәшләшүгә тәкъдим итәм. Урынлы табылса, иптәшләрем тарафыннан да фикри ярдәм булса, милләтнең каралган җыелышында гамәлгә куелыр, өметтә, комсызлыкның афәтле күренешләренә карамастан, эшкә керешелер. Фәллаһү хайрун-насыйрин (Аллаһ – ярдәм итүчеләрнең иң хәерлесе – *А.Г.*)!

## Диния нәзарәте хакында фикерем

**Имамнар.** Һәр мәхәлләдә имам, үтә зарур булмаганда, бердән артык куелмас. Имамның үтә картлыгы яки өметсез хасталыгы, идарә һәм укыту бабында сәләтсезлеге кебек зарурлык сәбәпле, район мөхтәсибенең фикерен һәм мәхәллә әһелләренең вазыйфаларын аңлап, арттыру мөмкин булыр. Бу имамнар үз мәхәлләләрендә казыйлык вазыйфаларын үтәрләр, мәхәлләнең низагсыз һәм дәгъвасыз мирас эшләрен һәм гаилә файдаларын карарлар, мөмкин булса, тәмамларлар, мәхәлләнең дини мәктәбен идарә итәрләр, укытуга катышырлар.

Мәхәлләнең тиешле гошер һәм зәкяте алыныр яки бирәр юл белән тәмам үтәргә юл ачылыр. Моннан имамга, мөәзингә мәктәп һәм мәчет чыгымнарына өлешләр чыгарылыр. Шулай ук югары Мәхкәмәи исламияләргә өлеш алыныр.

**Ахуннар.** Муллалардан югары дәрәҗәдә, төбәк зурлыгына карап, бер волостька яки ике волостька бер ахун насыйп ителер. Мөмкин кадәр эшлекле һәм гыйлемле адәм эзләнелер. Болар имамнарның тәмамлый алмаган эшләрен тәмамларга тырышырлар. Дәгъвалы эшләр булса, ике имам белән өч әгъза буларак карап тәмамларга тырышырлар. Болар тәмамлый алмасалар яки тәмамлый алмастай гадәти булмаган, билгелесезрәк мәсьәлә булса, мөхтәсибкә тәкъдим итәрләр. Боларга Мәхкәмәи-шәргыя тарафыннан азрак айлык бирелер. Үзләрен мөхтәсибләрнең рәислегендә күрерләр һәм аларны тыңларлар.

**Мөхтәсибләр.** Мөхтәсибләр кечегрәк өязләрдә (кантоннарда) бер, зурракта – артыграк, бер йөз мең кадәр кешегә кимендә бер мөхтәсиб зарур булыр. Бөтен Русия һәм Сибириядә илле кадәрледән арттырылмас.

Элек төрле адәмнәр сайланганлыктан, боларны яңадан карау тиешле. Моннан соң, дәрәҗәләре һәм игътибарлары артыграк булганлыктан, гыйлеме яхшы, идарәгә сәләтле, намуслы адәмнәрне табып, насыйп итү тиешле булыр.

Мөхтәсибләр имамнар, ахуннар хәл кыла алмаган гаилә мәсьәләләрен тикшерерләр. Мирас, васыять һәм вакыф мәсьәләләрен тикшереп, тиешле булганнарын Нәзарәткә тәкъдим итәрләр. Шулай ук гаилә низагларында гадәттән тыш эш килеп чыкканда, Нәзарәткә тәкъдим итеп, хәл иттерерләр яки мәгълүмат алып эш күрерләр. Имамнар өчен приговорлар җыелганда, үзләре яки

ахуннары шунда булып, шаһитлек бирерләр. Нәзарәттән һәртөрле мәгълүмат ишетерләр һәм кисәтүләр алып, халык арасында таратырлар. Нәзарәтнең каравы буенча, кайвакыт имтихан эшендә әгъза сайларлар һәм мәҗлесендә булырлар.

Вакытына яраклы итеп мөхтәсибләргә айлык бирелер. Башка канцелярия һәм фатир мәсьәләсенә аерым бер нәрсә бирелмәс.

Мөхтәсибләр елына бер мәртәбә хосусый сурәттә яки гомуми җыелыш булганда, Нәзарәткә килеп, еллык хәлләреннән мәгълүмат бирерләр. Мөхтәсибләр елга бер мәртәбә үз төбәкләрендә җыелыш төзеп, еллык эшләрендә фикер алышырлар. Мөмкин булса, монда Нәзарәттән бер вәкил (казый яки башка бер вәкил) булыр.

**Гаилә дәфтәре.** Гаилә дәфтәрләре Казан матбагаларында Нәзарәт тарафыннан куелган бер икътисади вәкил белән Казан мөхтәсибе рәислеге астында басылыр.

Гаилә дәфтәрләре өчкә бүленеп, бер өлеше Казанның үзеннән, тиешле вәкилләр аркылы тәмам әзер ителеп, Мәскәү, Петербург, Вятка, Сембер, Нижний һәм Пермь вилаятләренә мөхтәсибләре арадашчылыгы белән таратылыр. Икенче өлеше Сибириядә Петропавел шәһәренә мөхтәсибкә җибәрелеп, Нәзарәт тарафыннан билгеләнгән вәкил иганәсе белән тәмам әзерләп, бөтен Сибириягә таратылыр. Акмулла, Томск, Иркутск, Амур һәм башкаларга. Өченче өлеше Уфадан Оренбург, Самара, Саратов, Хаҗитархан һәм башка вилаятләргә таратылыр. Уфадан таратылачак дәфтәрләр үзенә махсус дәфтәр вәкиле ярдәме белән тәмамланып, таратылыр. Ел ахырында бу дәфтәрләр тараткан мөхтәсибләр арадашчылыгы белән Нәзарәткә тупланып, тиешле иганәләр белән гомуми кассага куелыр.

**Диния нәзарәте әгъзалары.** Нәзарәт «Мәшәехәт» исемендә булып, рәисе – шәйхелислам, өч казый белән дүрт әгъзадан гыйбарәт булыр. Бер казый чиратлап мөхтәсиблекләрдә һәм вилаятьләрдә йөреп торыр, андагы эшләрне тикшерер, Мәхкәмә тарафыннан боерылганча, вазыйфаларын үтәр. Өч әгъза даими рәвештә Мәхкәмәдә булырлар. Имтихан һәркайсы сыйныфка елына ике мәртәбә булыр. Май аенда бер ай, ноябрьдә бер ай имтихан кылыныр. Мәдрәсәләр юлга салынса, ышанычлы идарәләр игътибары астында булсалар, шул мәдрәсә имтиханнары белән канәгатьләнер. Ләкин мәдрәсә имтиханнарында Мәхкәмәдән бер вәкил булуы шарт ителер.

Бөтен дини мәдрәсә һәм мәктәп бу Мәшәехәт кулында булыр. Өч казыйдан берсе махсус бу мәгариф эшендә булыр. Икенче казый дәфтәр эшләрен карар, дәфтәрнең яхшы һәм дөрес язылуына, электәге хәлгә караганда артыграк диккать белән карар. Язу белмәгән имам булса, яхшы язарга әмер ителер. Имамнарның җитешсезлек һәм гаепләрен күзәтер. Өченче казый гаилә, мирас, вакыф, васыять эшләрен карар һәм Мәхкәмәнең мал эшләрен күзәтер.

Шәйхелислам елына ике мәртәбә тиешле урыннарга сәяхәт итәр, хәлләрне күрү белән мәгълүмат алыр.

Мәшәехәтнең әгъзалары, рәис һәм башкалары, тормыш җәһәтенчә, тәмам һәм камил тәэмин ителер: бина, җиһаз һәм яктырту, җылыту әсбаплары – барчасы халык тарафыннан тәэмин ителгән кебек, көнлек чыгымнары өчен дә вакытына һәм заманына яраклы итеп җитештерелеп торылыр.

һәр елга бер мәртәбә мөдәррисләрдән һәм зур галимнәрдән торган галимнәр җәмгыяте төзелер[14]. Гадәттән тыш мәсьәләләр турысында фикер алышулар, милләтнең хәлләренә караган уйлап эшләү һәм яхшырту юлларында сөйләшү һәм киңәшләшүләр булыр.

Елга бер мәртәбә милләт тарафыннан сайланып җибәрелгән кырык-илле кадәр вәкилләр җыелышы чакырылып, Мәшәехәтнең идарә һәм мал эшләре рәвешләре күзәтелер, раслау һәм кире кагу юлы ачылып, яхшырту һәм алга китү юллары эзләнелер.

Мәшәехәт тарафыннан атналык бер дини журнал нәшер ителер. Моның өчен һәм башка мөһим эшләр өчен Мәхкәмә үзенә махсус бер матбага төзер. Бу матбага һәм мәгариф журналы [аның] җитәкчесе – казый –идарәсендә булыр.

Казыйлар арасында бу эшләр бүленүе, әлбәттә, якынча. Тигезләнер, берсе ахырының вазыйфасында ярдәм итәр... (*Төп нөсхәдә бу урында ике бит кадәр ачык калдырылган*).

[14] Бу җәмгыять һәм җыелышта Мәшәехәтнең үз сайлавы һәм чакыруы буенча булуы җитә.

## Чистай, Болградтагы хәлләр

Киләкилә төштән соң сәгать бишләрдә Чистайга ирештек. Ярга чыгып, Казанга телеграмма бирергә булсам да, мөмкин булмады. Контора каршысында ук торган почта һәм телеграфханә ишеге ябык, касса тәрәзәсе шулай ук бикле. Алдында кырык-илле адәм көтеп торсалар да, сәгате җитешмәгәнме, идарә әгъзаларының кәефләре килеп җитмәгәнме – ачылмады. Кабат максат иттем, булмады. Чистайның пристаненнан кузгалгач, утын көймәсенә туктап, дүрт-биш сәгать микъдары торып, кырык-илле колач кадәр утын алуны тизләтү өчен, мөсафирларны да хезмәткә чакырдылар. Байтак адәм булышты. Төнге сәгать ун булгач, көймәбез хәрәкәт итте.

Чистай ярында бала-чага кулында тәмәке котылары (портсигарлар – *А.Г.*), бераз хат букчалары (пакетлар) күренде. Югарыда урамга тезелгән кырык-илле кадәр марҗа капчыклы яфрак тәмәке саталар. Бер чынаяк чокыры йөз сум диюләрен ишеттем. Бераз сөт бар. 85 сумга бер шешә сөт, 12 сумга бер бәйләм кәраш (җуа) (суган кыягы – *А.Г.*), 20 сумга бер бәйләм кузы колак (кузгалак) алдым. Мөхтәсиб дамелла Нәҗипкә кыска гына бер хат язып, бер ямщикка биреп кердем.

Көймәдә халык күп иде, чиксез тыгызланды. Безнең беренче класс залы тәмам тулды. Коридор шулай ук тулды. Авырлык белән генә аяк басар җир табыла иде. Ятар вакытта төрлечә урнашып, кайберләре өстәл астында, кайберләре өстендә, кайберләре табылган урындык һәм караватларда яттылар. Без дә әүвәлге кичәдә яткан җирдә – идәндә – урнаштык. Кулайлы гына урын булды, рәхәт йокладык.

Адәм баласы һәрнәрсәгә күнә. Хыялый гадәтләргә әсирлектән азат булса, ияргән кыланышларыннан үзен коткара алса, кеше диярлек һәм мөселман диярлек хәлгә тиз киләчәк. Ләкин хыял һәм ияру кешене харап итә, кешелектән чыгара, башына төрле-төрле бәлаләр китерә, әхлагын тәмам боза, гомерен әрәм итә, зур үкенечкә һәм зыянга илтә.

Көймәбез көчле давылга каршы авыр йөге белән йөзә-йөзә, сәгать биш булганда, Лаеш булып үтте. Җил һәм давыл бераз азайган булса да, тәмам туктамаган. Хәзер сәгать җидедә Чулман-

ның Иделгә кушылу үсиясенә[15] иреште. Казанның кайгылы сурәтен күрү вакыты якынлашып, йөрәкләргә тәэсир итүдә.

Болградта (Богородский) (Г. Баруди, «Богородский» сүзеннән чирканып, бу авылны «Болград» дип атаган – *А.Г.*) Сембер, Спас тарафына баручылар төшкәч, көймә бераз иркенләнде. Бераз керүчеләр булса да, бик тутырмадылар.

Бу пристань Чулман белән Иделнең кушыла торган урыны булганлыктан, байтак юлчыларның пересадка ясала торган, байтак вакыт көймәләр көтә торган пристане. Шунлыктан атаклы, байтак әһәмиятле станция. Авылы кәсепле, тук, хәлле авыл. Тәтеш төбәгенең якын өлешенең юллары да бу станциядән. Элекке заманнарда бу пристань турысында су өсте, ачык ит өстендә чебен тулган кебек, көймәләр, йөк кораблары белән тула торган була [иде]. Юлчы көймәләре саклык белән генә үтәләр иде. Кирәк пристаньне, кирәк су өстен тынлык баскан, бушлык алган, дәрвиш хәлгә килгән булып күренә. Шулай ук юлда, маякта дүрт-биш сәгатьлек, иңәрдә ике-өч ярым сәгатьлек бер вакытта көймәләрнең юл сабыш сыбызгылары тоткарсыз дәрәҗәдә сызгырып, тавышлары даими рәвештә ишетелеп тора иде. Хаҗитархан тарафына юлчы көймәләреннән җиде-сигез көймә, Пермьга дүрт-биш көймә, Уфага бер-ике көймә, Казаннан һәм шул микъдар Казанга үтеп торыр иде. Йөк көймәләре дә күп, һәр ике тарафтан үтеп йөреп торырлар иде.

Искә алынган авылдан алтмыш чакрымнан артыграк араны алты сәгатькә якын киләбез. Танымаган бер көймә, соңра «Самолет» ширкәтенең матур көймәләреннән бер көймә түбән уздылар. Калган аз гына арабызда янә никадәр очрар? Һәркайсы хәл игътибарга сәбәп булырлык рәвештә. Гыйбрәт күзе белән кара: дөнья – тетрәнә торган җир, һәр камил нәрсәнең бетүе гадәти.

## Казанга ирешү

16 июнь өйләдән соң 4 сәгать булгандарак, би-гаунилләһи вә кәрамиһи (Аллаһ ярдәме һәм рәхмәте белән), Казан пристанена ирештек. Нәрсәләрне һәркем үзе ташырга тиеш булганлыктан, халык чыгып беткәч, авырлык белән, хатыным белән нәрсәләребезне күтәреп, тикшерү комиссиясе күзеннән үтеп, югары чыгып,

[15] Үсия – ике елга кушылуы тәрҗемәсендә.

ике мең биш йөз сумга бер фаэтон (өсте ачыла торган ат арбасы – *А.Г.*) алып, шәһәргә юнәлдек. Лилләһил-хәмдү вәл-миннәһ (Аллаһка мактау һәм рәхмәт), сәламәт [рәвештә] мәчетебезгә ирешеп, үзем мәчеткә, хатыным өйгә кердек. Кайбер дуслар белән аяк өстеннән очрашып, шатлыкларын күрсәтеп каршыладылар. Минем сәфәремнән бирелгән телеграмма ирешмәгәнлектән, җәмгыять белән Уфага, янә рәсми һәм рәсми булмаган идарәләргә мине чакыру телеграммасы бирергә булып, бүген янә киңәш оештырганнар икән.

## Казанда бер көн элек гает уку, имамнардан җавап алу

Юлда Казанда пәнҗешәмбе гает булачак хәбәрен ишеткәнлектән, бераз гаҗәпләнеп, мөәзин Бәдигъ әфәндене имамнарга хәбәрче иттем. Икенде намазына кадәр, алар килеп очраштылар. Гает хәбәрен сораштым. Пәнҗешәмбе көн гает укуга карар бирүләре дөрес. Дәлилләре исә, Буада алты ир, бер кыз дүшәмбе көн сишәмбегә каршы кичәдә рамазанның аен күреп, шәһадәт бирүләре һәм бу шәһадәт буенча, Буаның ике мәхәлләсе дә сишәмбе уразада булулары, искә алынган ике мәхәлләнең имамнарыннан Казанга хат ирешүе булган. Беренче мәхәллә имамы хатында Чынлыда да күргәнлекләрен язган. Буада ай күрү вакыйгасы Уфага Мәхкәмәгә дә белдерелгән булса да, кирәкле юл белән ирешмәгәнлектән, фәкать ул хәбәр белән бер көн элек гает уку тиешле күренмичә, тутырып гает уку карар ителгән иде.

Ай күрүе соң булган халыкның ай күрүе беренчерәк булган халыкка ияреп, ифтар (ураза тотмау – *А.Г.*) һәм гает уздыру да каршылыклар чыгу мәсьәләсеннән, катгый караш белән кирәкле юл – ифтар – бары шул гына. Элек ай күргән шаһитләрнең үзләреннән яки аларның казый янында шәһадәтләреннән йөкләтү һәм күтәрә алу юлы белән шаһитлек бирү. Тик ай күренгән җирдән күп җәмәгатьләр килеп: «Фәлән җирдә бер көн элек ай күрделәр, казый алдында шәһадәт биреп, шәһадәтләре кабул ителеп, шуңа муафыйк гамәл ителде,» – дип ышану хасил булырдай хәбәр итсәләр, аларга таянып, гамәл дөрес булыр. Бу бүлекне «хәбәрне тарату» диләр. Казанның бу көтмәгәндәге карары һәм кабул итүе бу рәвешле булмаган. Бары ике мулла: «Бездә дүшәмбе көн кич сишәмбегә каршы ай күрделәр, гуаһлык бирделәр, кабул иттек, сишәмбе көн

уразада булдык,» – дип язганнар. Шәһадәт юк, шәһадәттән шәһадәт юк, хәбәрне тарату юк.

Казандагы имамнар белән хәлләрне яхшы аңлар өчен фикер алышуыбыз вакытында ай бабында байтак тәҗрибә дәгъвасында [булган], күбрәк хисабын төзеп, ай башларын сөйләүче беренче мәчет имамы мулла Сафиулла бине мулла Габдулла белән кыскача булган әңгәмәбезнең эчтәлеге:

Мин әйттем: «Бу карарыгыз шәригать дәлиленә нигезләнмәгән, фәкыйһләр (шәригатьне яхшы белүчеләр – *А.Г.*) риваятенә туры килми. Бу рәвешле хәбәр кирәкле юлның берсенә дә керми».

Мулла Сафи: «Мулла Гаяс һәм мулла Габдулланың хатлары белән өстен уй хасил булды, өстен уй җитәрлек. Хисап буенча да бүген чәршәмбе көн төштән соң ике сәгатьтә ай туган. Обсерваториядән фәлән һәм фәлән сорап кайттылар».

Мин: «Бүген ай тууы башка мәсьәлә, гает өчен башка юл була. Рамазан башының сишәмбе булуына мөнәсәбәте юк».

С: «Рамазан ае сишәмбе көн иртәнге сәгать тугызда туган, обсерватория хәбәре шулай».

М.: «Алай сишәмбе көн иртән туган булса, дүшәмбе көн ничек күренгән? Тумаган айны күргән булалар».

С: «Шәригать шәһадәте булгач, игътибар итәбез, шундый вакыйгалар булган»[16].

М.: «Обсерватория хәбәренә ышанып, аның белән гамәл дөрес күренсә, катгый (анык) хисапка каршы булган шәһадәт шөбһәле булып кала, бәс, Буа хәбәре ышанычка лаек булмый».

С: «Булмаса булмас. Минем чын ышанычым үз хисабыма. Быел рамазан башы чәршәмбе, саны егерме тугыздан килә, шунлыктан пәнҗешәмбе гает булырга тиеш».

---

[16] Бу муллаларда бер сәерлек: обсерватория хисабына игътибар итәләр. Обсерваториядән алынган хәбәрләренә күрә, рамазан ае 18 майда сишәмбе көн иртәнге 9 сәгатьтә 25 минутта туган. Буадан килгән хәбәргә күрә, рамазан аен дүшәмбе көн кич сишәмбегә каршы күргәннәр. Обсерватория буенча ул вакытта әле һаман рамазан ае тумаган. Ике юлда каршылык ачык була торып, икәүдән катыштырып йөртү – мантыйксыз бер юл. Буада күргән булсалар, кояштан узмаган, югалуга ирешмәгән шәгъбан аен күргән булсалар, ихтимал, кояштан уң тарафта күренгән ай булыр. Вәл-гыйльмү гыйндәллаһ (Гыйлем Аллаһта)! Сафиулла әфәнденең быел рамазан 29 көн дигәне астрономия буенча ерак түгел, ләкин күрүсез шәригатьчә игүтибар мөмкин булмый.

М.: «Хисап буенча егерме тугыздан килергә тиеш булса да, ләкин шәригатьчә егерме тугызга игътибар итү, утызынчы кичәдә шәүвәл ае күренгәндә генә мөмкин була. Ай күренмәгәндә, быел егерме тугыздан килергә тиеш, дип шәригать дәлиленнән башка гает укып булмый».

Кайбер муллалар көлешкәләсәләр дә, сүзендә дәвам итеп:

С: «Мин бер көннең казасы (тотылмый калган уразаны үтәүне – *А.Г.*) тиешле түгел, дип күрәм, кешегә фәтва бирмәсәм дә, үзем каза кылмыйм».

М.: «Ул тәкъдирдә, Буа шәһадәтләрен арага кыстыру хәҗәт булмый, баштан ук үз ышануың буенча гамәл кылырга тиеш идең. Гамәлгә ярамаган фикердә һәм гамәлдә ни файда?»

С: «Анысын үзем беләм. Буа шәһадәтен, ияру юлы белән, игътибар иттем, халыктан аерылмадым. Әмма дөресе: рамазан башы чәршәмбе булган хәлдә, егерме тугыздан килеп, гаетне пәнҗешәмбе укырга тиешле».

Бу кадәрле сөйләшүләрдән соң мин дә сүз озайтуны тиешле күрмәдем, үз итмәдем. «Тарафларга хәбәрләр таралды, халык гает укырга тәмам карар бирде, үзгәртмәсәң яхшы,» – диюләренә игътибар иттем һәм әйттем: «Мин сезне, карарыгызны боздырыр өчен түгел, хәлләрне аңлар һәм карарларыгызның сәбәпләрен белер өчен чакырдым. Эшегез бу дәрәҗәгә килгәч, укысагыз укырсыз. Ләкин башка вакытта болай әһәмият бирмәү кирәкмәс, китапка һәм шәригатькә яраштырып гамәл кылырга тиешле. Мин дә бу тапкыр укырмым,» – дидем. Тынычланып киттеләр.

## Гает укуда имамнар фикеренә кушылуның сәбәпләре

Мин нигә укыдым?

1. Үткән ел Уфадагы күрү белән шәгъбан башы чәршәмбе шиксез булган иде. Шунлыктан, ай буенча хисапланган ел шимбә көн 354 көн ел тәмам булып, якшәмбе шәгъбан башы булып, дүшәмбе көн кич ай күрелмәгәнлектән, шәгъбанны тулыландырып, рамазан башы сишәмбе булырга туры килә, утыз көн итеп тулыландырганнан соң, пәнҗешәмбе гает көне була.

2. Чәршәмбе көн, обсерватория хисабы буенча, көндез 4 сәгатьтә 41 минутта шәүвәл ае туганлыктан, кояш батканда күрерлек дәрәҗәгә ирешә. Шуңа күрә кайбер мөхәддисләр (хәдис белгечләре

– *А.Г.*) тикшерүенчә, вакыт күрүе шиксез һәм фикыһ буенча гамәл була.

3. Буада сишәмбегә каршы кичтә алты ир һәм бер кызның рамазан аен күрүләрен ике имам кабул итеп, сишәмбе көн уразада булулары ике имамның Казанга һәм Уфага миңа язган хатларыннан ачык аңлашылды. Бу сәбәпнең үзе [белән] генә ифтар мәҗбүри булып җитмәсә дә, югарыдагы сәбәпләрне кушкач, күңел урнашуны хасил итә. Аеруча хисапка игътибар иткән кайбер мөхәддис галимнәрнең ихтыярынча, югарыдагы сәбәпләр байтак игътибарга лаек. Күпчелек галимнәр ихтыярынча, хисапка нигезләнми. Күбесенчә, сүз күпчелеккә карап гамәл кылына. Ләкин бу тапкырда тарафларга хәбәрләр таралып өлгерү, күп җирдә Казан имамнарының карарына нигезләнү, халыкның ифтар һәм гает уздыруларына катгый карар бирелгән булганлыктан, бу хисап гамәленә өстәмә буларак игътибар итү мантыйксыз бер эш итеп күрелмәде. Искә алынган сәбәпләрне игътибар итеп, гает уздыруны шәригатьтән чыгу [дип] күрмәгәнлектән, имамнар һәм халыкка муафыйк иттем, ифтар һәм гает укуны ихтыяр иттем. Тәкаббәллаһү вә гаффәнә ән әхътанә. Вәс-сәләмү галә мән әтбәгаль-һүдә вә җәнәбәлбидгатә вәл-һәвә (Аллаһ кабул итсен, хаталансак, кичерсен. Туры юлга иярүчеләргә һәм бидгатьләрдән, нәфесләренә иярүдән ерак торучыларга Аллаһның сәламе булсын – *А.Г.*)!

Казанда беренче бөтен көнем – рамазан гаете көне – пәнҗешәмбе көн 17 июнь булды. Юл хасталыгым, сәфәрдәге эсселегем, йокысызлыгым булган хәлдә, иртәнге намазга 2 ярым сәгатьтә (2:30 да – *А.Г.*) чыгып имамлык иттем. Соңра, өйгә кайтып ашап, кояш күтәрелү белән, гает урыныбыз булган мәчет ишегалдына чыктым.

## Казанда гаетне вакытсыз укыйлар

Казанда электән үк гадәт шул: иртәнге намаздан күп кичектермичә, кояш күтәрелү белән гает укыла. Күп адәмнәр иртәнге намазга килгәннән [соң] кайтмыйча, гаетне дә берьюлы үтәп кайтуны артык күрәләр. Уфада кояш чыкканнан [соң] өч сәгать микъдары соң укыла. Күбесенчә, яз көннәрендә, алты-алты ярым [сәгать] чамаларында укыла. Ислам йортларында да шулай ук байтак кичектерү белән, мөстәкыйль сәфәр һәм хәрәкәттә дүрт-биш сәгать кичектереп укыйлар. Шул яхшы гадәт тә сөннәткә

муафыйграк күренә. Бу бабта уйлап эшләргә вакыт калмаган иде. Шунлыктан халыкның үз теләкләрен бозмадым, имамнарга да әйтелмәде.

## Гаеттә ният өйрәтү

Электән үк, гает өчен зур әзерлек белән хөтбәләр әзерләп уку гадәтем, ятланган хөтбәләрем дә юк иде. Әзерлексез укуымда Аллаһның ярдәмен өмет итеп бардым. Халык тәмам туплангач: «Ният өйрәтү кирәк,» – диештеләр. Элекке заманнарда мөәзиннәр ният өйрәтү рәвеше белән, гает уку рәвешен халыкка аңлаталар иде. Ният рәвешен кирәгенчә аңлата белмәсәләр дә, намаз рәвешен әйтүләре зыянлы булмый иде. Бу тапкырда мөәзин кирәгенчә өйрәттеме-юкмы, мин ният өйрәтүне тиеш күрдем. Аякка калкып әйттем: «Намаз нияте һәрвакытта күңел белән була, тел ниятенең әһәмияте юк. Үзегезне Аллаһ янында дип белегез, күңелегезне Аңа баглап, Аңа бәндәчелек кылуны ниятләп, гает намазын укуны теләп, «Аллаһү әкбәр» дип әйтерсез. Тел белән әйтсәгез дә, әйтмәсәгез дә – дөрес. Башка намазлар рәвешенчә укырсыз. Тик элекке рәкәгатьтә (намаз өлешендә) «сәна»дән (намаз башындагы догадан – *А.Г.*) соң өч мәртәбә тәкбир («Аллаһү әкбәр» дип әйтү – *А.Г.*), икенчедә рөкүгъ (намазда аягүрә бөгелү – *А.Г.*) алында өч мәртәбә тәкбир әйтерсез. Намаздан бушанганчы күңелләрегезне анда-монда җибәрмәскә тырышыгыз,» – дидем. Халыкны кузгатып, элекке рәкәгатьтә «Сәббихисмә раббикәл-әгълә» икенчедә «Ләм йәкүн» сурәләре белән намазны тәмамладым. Икенчедә «Һәл әтәкә хәдисүл-гашийә» сурәсе сөннәткә муафыйграк, күбесенчә, шулай укыр идем, ләкин хәлем һәм куәтем азрак булганга, кыскарак укыдым. Соңра, мөнбәрне әүвәлге сафтан урталыкка күчертеп, хөтбәгә чыктым. Тәкбир, хәмед, сәна һәм салаваттан соң кыскарак төркичә вәгазь белән әүвәлге хөтбәне, соңра икенче хөтбәне тәмамлап, көчем аз булганга, мөнбәр өстендә утырып, бераз нәсыйхәт әйттем. Халык сагынып торган, мулла Габдрахман юклыгыннан да сынган булганнар, мәхәббәт һәм рәхәт күңел белән тыңладылар, күңелләре йомшап, күзләрен яшьләндерделәр. Үзем дә дулкынландым. Вәлхәмдү лилләһ галә зәлик (Шуның өчен Аллаһка мактау – *А.Г.*)! Тәмамлап, Вәли каридан Коръән тыңладым.

## Гаеттән соң күрешү мәсьәләсе

Дога кылып, гыйбадәт рәвешләрен тәмамлагач, гает күрешүе башланып, булганнарның күбесе күрештеләр. Бу күрешү мәсьәләсе галимнәр арасында бер дәрәҗәдә каршылыклы мәсьәлә булса да, ләкин чын күрешү, мөэминнең мөэмингә очраганда күрешү – сөннәт. Сәфәрдән кайткан булмаса да, һәр очрашканда кул белән күрешү тиешле һәм шәригать кушканча. Мисыр һәм башка ислам гарәп илләрендә һәр иртәнге намаздан соң, билгеле булган рәвешчә, шул вакытка хаслап, бару һәм күрешү шәригатьчәме-түгелме – бераз капма-каршы фикердә булганнар. Олуг хәдис белгечләреннән Нәвави һәм байтак галимнәр эшләргә рөхсәт икәнлегенә барганнар. Кайберәүләр махсус вакытларга хаслау игътибары белән, сөннәткә каршы эш итеп күргәннәр. Элек безнең илебездә кайбер ишаннар мәчетләрендә иртәнге намаздан соң, бу күрешү булса да, ләкин Казанда иртәнге намазда да һәм гаеттә юк иде. Баштарак мин шәкертләр белән очрашып һәм күрешеп башланды. Кайбер гадәт артыннан йөрүчеләр: «Яңа мулла янә бер бидгать (дингә туры килмәгән яңалык – *А.Г.*) чыгарды,» – дип сүз чыгарса да, бара-бара, шул адәм үзе үк, яхшы санап, эшли башлады. Башка мәчетләрдә дә булгалый башлаган иде. Сөннәт булган күрешүне тәмам үти алмасак та, анда булган серләр бөтенләй калдырылмасын, дип, дәвам иттерү яхшырак күренде.

Халыкның олысы һәм кечесе, күбесе күз яшьле булган хәлдә, күрешеп, тәбрикләү йолаларын да тәмамлап, өйгә кереп, аз гына ял итеп, килү-китү башланды. Йокысызлыктан бераз хәлсезлек тә бизгәк табигатемдә сизелә иде. Ни булса да, бу көндә халык бер дәрәҗәдә бәйрәм төсендә, дус-ишләре белән очрашып, яхшы киемнәрен киенешеп, андый-мондый кайгы һәм борчудан имин адәмнәр кебек үткәрүләре күренә иде. Мәчетләр тулы, намазга иртә киләләр, яхшы үтиләр. Вәл-хәмдү лилләһ (Аллаһка мактау булсын – *А.Г.*)!

## Гаетләшү, күрешеп йөрү

Мөселманнарның бер-берсе белән гаетләшү, күрешү гарәп халкында да бик таралган. Шәригатьтә каралган кадәрледән артык күренсә дә, ләкин рух һәм мәгънә җәһәтеннән, байтак файдаларны үз эченә алган. Араларында дошманлык һәм үпкә булганнар, бу гаеткә бару мөнәсәбәте белән, төзәлеп калалар. Кул тотышып күрешүдә мәхәббәт арту, мәхәббәт белән күрешүдә гөнаһлар коелу хикмәтләре әсәрләрдә риваять ителгән һәм тәҗрибә моны сизә. Шунлыктан Мәккә һәм Мәдинә халкы бу эшкә әһәмият бирәләр. Аз гына вакытка булса да кереп, «күп гаетләрне күрү насыйп булсын» [дигән] мәгънәне «минәл-гаидин» сүзе белән аңлатып, дога әйтеп, кечкенәданә шөкерләмә алып чыгалар. Безгә килгән дус-ишләргә файдалы кайбер сүзләр сөйләп, кайберләренә юату юллы, кайберләренә котлау юллы җөмләләр әйткәләп, кыска гына мәҗлесләрне кечкенә генә файдалар белән мәшгуль итеп, үз итә идем.

## Казанда янган урыннарны карау

Бүген икенде намазына кадәр, сәгать бишләрдән соң янган җирләрне карарга чыктым. Кәримовлар чатыннан барып, Зәңгәр мәчеткә таба карасам, мәчетнең һәр тарафыннан урамнар мәйдан булган, җәһәннәм төсен алган. Кара күмерлек. Кайбер матчалар кара янып, кяфер гәүдәсе кебек күмерләнеп, сузылын-сузылып яталар. Икешәр катлы өйләрнең мичләре һәм морҗалары иң ямьсез кыяфәтне алып, җәһәннәмиләр арасында озын буйлы, карарга куркыныч, һәр тарафы газап белән чолгап алсын өчен, бастырып куелган, динсезләр кебек сузылып торалар. Кайбер җирләрендә ун көннән артык вакыт үткән булса да, ялтырап, пыскып янып яткан җирләре күренеп тора.

Шул вакытта вәкилебез Җамали әфәнде Хөсәенов яныбызга ирешеп, үзенең йорт урынына алып барды. Таш һәм тимер ишекле кибетен күрсәтте. Бу кибет зур фаҗигале, гадәттән тыш, зарарлы һәм вакыйгалы булган икән. Эченә безнең «Ширкәте Барудия»нең миллионга бәяләнерлек сәүдә малы, хатынымның таланганнан кысылып калган байтак кына сөлге, тастымал затлары булып, аларның алдына бөтен йорт җиһазы, олы һәм кеченең киемнәре һәм китаплары куелып, яхшы ныгытылып, ут кермәслек дәрәҗәдә

балчык белән сыланып куелгач, ут якынлашкан арада, ике комиссар килеп, көчләп ачтырганнар. Йорт әйберләре икәнен күргәч, яптырып, ярдәм белән киткәннәр. Ләкин аз гына үтеп, күршесенә ут кабынгач, биш матрос, бер комиссар килеп, ачарга көчләп, Җамали әфәнде никадәр: «Хәзер генә карап киттеләр, йорт җиһазы гына,» – дисә дә, ут кабарга торуны игътибарга алмыйча, озын берсе револьвер белән куркытып, читкә чыгарып, башкалары ишекне ватып ачып куеп, бөтен кибетне яндырганнар, һөнәрләрен күрсәткәннәр. Бөтен йорт җиһазы, өсләренә кигән киемнәреннән башка киемнәре, савыт-сабалары, нәтиҗәдә, барлык нәрсәләре тәмам көл булган. Менә: «Кызылларны халык ник сөйми, коммунизмга ник дошман?» – дигән мәсьәләләр моңдый вакыйгалар белән хәл ителә. Үзләренең эченнән ахмак дуслары үз фиркаларына күп зыян китерә, дошманнарны күбәйтә, бөтен фирканың йөзләренә пычраклык яга. Юкса, чын фирка бу рәвешле Иван Грозныйда да булмаган деспотизм һәм золымга, әлбәттә, риза түгел. Анык белсәләр, әлбәттә, моңдый партия дошманнарын яки ахмак дусларын җәзалаячаклар. Йортлары яхшы адәмнәрдән кайберләре йорт урыннарында шалаш ясап утырганнар. Күбесе фатирларга урнашканнар. Күмерләрен җыеп, калган дивар һәм агачларын кисеп, әрдәнә итеп куйганнары да бар. Берсе йортыннан: «Ун мең сумлык күмер җыештырдым,» – диде.

Бу куркыныч, кызганыч хәлне күреп, икенде вакыты ирешү белән өйгә кайтып, җәмәгатькә чыгылды. Безнең Ак мәчеттә икенде намазы электәге кебек, лилләһил-хәмде вәл-миннәт (Аллаһка мактау һәм шөкер), кояш батудан бер сәгать элек укыла икән. Өлгермәгән адәмнәр дә булып, сөннәт бүлмәсендә бер җәмәгать булып укыйлар.

Ястү исә кояш батканнан соң ике сәгать үтеп, камәт укылып керешелә, бер дәрәҗәдә яхшы саклану чарасы. Икендедә бер сафтан артык, ахшамда өч саф кадәр, ястүдә икендедәге кадәр – егермеегерме биш кадәр адәм була икән. Мулла Габдрахман мәрхүмнең җәмәгать намазларына калмыйча дәвам итүе, намазны муафыйк сөннәт, игътибар белән укуы мөнәсәбәт килгәндә, нечкә күңел белән вәгазь һәм нәсыйхәте халыкны намазга яхшы иyләндергән һәм бер дәрәҗәдә игътибар белән укырга күндергән икән. Рәхимәһуллаһ (Аллаһ аны рәхим кылсын – *А.Г.*)!

Бүген үземдә байтак эсселек-авыраю бар иде. Артык дәрәҗәдә арсам, йокылар күп калса, бу хәл була. Ялга көчле ихтыяҗым сизелә иде. Чирек ким сәгать унбердә (22:45 тә – *А.Г.*) ястү намазына камәт укылып, соңра һавада аз гына хәрәкәт итеп ял螺 ителде.

**Җомга көн.** Икенче көндә иртәнге намазга чыксам, халык һәммәсе арганнар булса кирәк. Бер кемсәнә дә булмыйча, үзем азан әйтеп, сөннәт укыган вакытымда бер солдат килде. Сәгать өч булганда намазны икебез укыдык. Мескен гаскәри Минзәлә кантонынннан, Яңа Богады авылыннан икән. Ерак булган торагыннан иртәнге намазга килгән. Һәдәһүллаһ (Аллаһ аңа туры юл бирсен – *А.Г.*)!

Шул көн кәеф тә бераз уртача тоелса да, күкрәгемдә башка бер нәрсә сизелде. Уң тарафта шактый кату бар, суларга ирек бирми, хәтта уң һәм сул тарафка ятуны да тыя. Чалкан ятып кына ял итү мөмкин була иде. Бу авыру шимбә, якшәмбе, дүшәмбе көннәрендә куәтле булып, сишәмбе көн бераз җиңеләеп, чәршәмбе бетте диярлек булды. Үпкә шешү ихтималы хәтергә килсә дә, эсселек, чәнчү, ютәл булмаганлыктан, ул ихтималны кире кактым. Шул тарафымны мамык шәл каплап, шешә белән кайнар су куеп җылыттым. Дүшәмбе көн, өч-дүрт җиренә горчица куйдым. Шул чаралардан сон артык дәвалау хәҗәт күрелмәде. Гаиләм һәм башка дус-иш табиб карауны кирәксенсәләр дә, үзем зарур күрмәдем. Кайбер хикмәт ияләре һәм тәҗрибә ияләре: «Һәркем үзенә-үзе табиб булырга тиеш,» – дигәннәр. Каты һәм куркыныч авыруларда табиб кирәк булса да, әле һаман кешенең үз табиблыгына, үзенең саклану һәм тырышуына исе китми. Саклана белү, ашау һәм дәва вакытларын саклау, бозык уй һәм куркуны җиңмәү, йөрәген таза тоту кебек файдалы сәбәпләрдә игътибар тиешле, һәр эштә тәҗрибә карашын салу һәм шул тәҗрибәдән файдаланырга тырышу тиешле. Эшнең һәр хәлендә Аллаһка кайту һәм тапшырылу кирәктер ки, бу рәвеш йөрәкне ныгыта, сәламәтлекне куәтләндерә. Бу ике эш – авырудан котылуда иң файдалы чаралар. Арада аз-маз минем үткәргән чараларым кебек тәҗрибәле дәвалар белән дә файдаланырга кирәк. Бер нәрсә булды исә, табибка мөрәҗәгать итү, аз гына баш авыртты исә яки чебен тешләде исә, табиб дәвасына мөрәҗәгать итү – яхшы гадәт түгел. Дәва затлары (дарулар – *А.Г.*) агудан азат булмаганлыктан, мөмкин кадәр алардан сакланып, ахыр чиктә генә куллану тиешле.

## Җомгадан элек вәгазь сөйләү ничек

Җомга намазына вакыт якынлашты. Үземдә байтак арганлык-талганлык булса да, халык үземнең укуымны көткәнлектән, кыскарак кына, вәгазьсез укуны йөкләп кердем. Мөнбәрдә Әхмәтҗан хәлфә Мостафа вәгазь сөйли иде, ягъни нотык һәм хөтбәсе бар иде. Мин урта бүлмәдә «тәхиятел-мәчет» намазы (мәчеткә кергәч, укыла торган намаз – *А.Г.*) белән һәм башка эшләрем белән мәшгуль булганлыктан, сүзләрен ачык ишетә алмадым. Аның вәгазе, күбрәк, фәлсәфи нотыклардан гыйбарәт була иде. Шундый файдалы сүзләр сөйләгән. Тик бу билгеле хөтбәдән элек вәгазь сөйләүнең шәригатьчә булуында электән үк үземнең аз гына шөбһәм бар. Байтак җирләрдә бу мәсьәлә бар. Имамнар: «Халык җыелып җиткәнче вәгазь сөйлибез, аннан соң сөннәт укып, хөтбә укыйбыз,» – диләр. Хөтбәнең вәгазь булуына карамастан (безнең муллаларда хөтбәләр, күбесенчә, шулай бер гадәт булган нәрсәне мөнбәргә менеп укып, көйләп төшүдән гыйбарәт), яраса, ярар да иде. Ләкин бу вакытта бу вәгазь белән канәгатьләнеп, икенче кат хөтбә укып тормаска кирәк. Бу мәсьәләне аңлау өчен җомга хөтбәсенә бер шәригать һәм сөннәт буенча карау тиешле була ки (элекке заманнарга һәм ислам илләренә караганда), җомгага тарафлардан биш вакытлы мәчет халыкларыннан күп адәмнәр җамигъка (төп мәчеткә – *А.Г.*) туплана. Шунлыктан вакытына халыкның дини һәм әхлакый хәҗәтләренә күрә, хатыйб (сөйләүче – *А.Г.*) бер сүз сөйләп, халыкны файдаландырырга тиеш.

Халыкка дини хәҗәтләрен, әхлакый мәсьәләләре яңартылмаса, үзләреннән генә вәгазьләнерлек, тәрбияләнеп алга китәрлек гыйлемнәре һәм акыллары юк. Кисәтү һәм искә төшерү ихтыяҗлары күп. Шунлыктан бу җомга җыелуы уңышлы булып, бу вәгазь ягъни хөтбә шәригать һәм сөннәт ителгән. Хәтта җыелу иң мөһим максат икәнлеге беленсен өчен, шәригать буенча, фарыз ителгән. Моның хәер-бәрәкәте өчен һәр сүзнең, һәр килешүнең әдәбе буенча, башында Аллаһка мактау, пәйгамбәргә салават һәм тәшәһһедләр (шәһадәт сүзләре – *А.Г.*) белән башланып, яраклы яхшы йомгак белән тәмамларга тиешле күрелгән. Бу рәвешле хөтбә тик бер мәртәбә шәригатьтә билгеләнгән. Берничә булуы һәм кабатлануы сөннәттә бер дә күренми. Шунлыктан җомга фарызыннан элек әдәбе белән булган хөтбә исемле бер вәгазь булырга тиеш.

Элекке халык аңлардай бер тел белән бер вәгазь сөйләгәч (фарыз хөтбәне бу үтәсә кирәк), янә азаннан соң кабат икенче мәртәбә мөнбәргә чыгып, мулланың күңелгә алган гарәп гыйбарәләрен укып төшүендә шәригать төсе калмый. Тик әүвәлге хөтбә, вакыттан алда булганлыктан, кабатланса, бер хәл булыр.

Мулла Әхмәтҗан фәкыйһ адәм булса да, ничектер бу мәсьәләгә вакыт тапмаганмы? Остазлар янында шәкертләрнең һәм яшьләрнең рөхсәтсез сөйләүләре, бер төр аермалы әдәп булуга, мондый әдәп күтәрелгән заманда игътибар ителми. Азаннан соң, тарафлардан сүзен аңламаган кешеләр (күбесенчә, аның фәлсәфи һәм бөек нәсыйхәтләрен аңламыйлар да) азан укылды, дип, туктавына ишарәт итсәләр дә, сүзен дәвам итте. Бераздан соң сөннәт укылып, сөннәт бүлмәсеннән мөнбәргә мендем.

**Әхмәтҗан хәлфәнең вәгазенә караш**. Югарыда күрсәтелгән [зат] туры ниятле, милләткә хәерхаһ (хәерлек теләүче – *А.Г.*), намуслы кемсәнә. Хәзерге көндә Казанның зур галимнәреннән саналырга лаек. Ләкин табигатендә бераз гаҗәплек бар ки, һәммә кешене көчләп вәгазьли: тыңлаучы телиме, теләмиме – сөйли. Озынрак та сөйли, тыңлаучыларның акылларына карый алмый. Шунлыктан, күп сөйләсә дә, халык вәгазь һәм нәсыйхәткә бик ихлас булсалар да, бу кешенең вәгазеннән риза булмыйлар, тәэсирләнмиләр дә. Бу рәвешле вәгазь сөйләүдә муафыйк хикмәт күренми. Мин – михраб иясе – аның остазы булган хәлдә, боерсам, сөйләргә тиеш. Ләкин боерыксыз, рөхсәтсез, шәкерт тапкан хөррият, мөгаллимләр теләгән тигезлек буенча гына минем янымда сөйләү, асылда, ислам әдәбеннән күренми. Аеруча, югарыда күрсәтелгән [зат] кебек, шәригать белгече, сөннәткә иярү әмәлендә булган адәм өчен бераз ят күренә. Ләкин мин һәрвакыт иркен куям, сабыр һәм түзү белән мөгамәлә итәм.

Ни булса да, җомгада сөннәт укылды. Хәлем зәгыйфь, нервларым да бераз бозык булганлыктан, кыска гына гарәпчә хөтбә укыдым. Икенче кат вәгазь кирәк булмас, дип мөнбәргә мендем. Вәгазь урынына Мөслимнең Әбү Һөрәйрә аркылы риваять иткән хәдис шәрифне укыдым. Кыска гына тәрҗемәсен ниятләсәм дә, биш җөмлә шәрехендә байтак аңлату һәм шәрех сөйләнде. Би изниллә һ (Аллаһ рөхсәте белән), шактый күп хәлләргә караган җөмләләр сөйләнелеп, Аллаһ нигъмәтенә ирешеп, күп адәмнәрдән күз яше чыкканлыгы күренде. Хәлем зәгыйфь булса да, бер тарафтан

диварга сөялү дәрәҗәсенә ирешсәм дә, сагыну һәм тәэсирләнү белән бу хөтбәмне тәмамладым.

## Җомга намазында «Җомга» һәм «Монафикыйн» сурәләре [уку] сөннәтлеге

Намазны да муафыйк сөннәт – беренче рәкәгатьтә «Җомга» сурәсен, икенче рәкәгатьтә «Монафикыйн» сурәсен укып – тәмамладым. Вәлхәмдү лилләһи галә сүннәти рәсүлуллаһи саллаллаһү галәйһи һәм сәлләм (Рәсүлуллаһ сөннәте өчен Аллаһка мактау – *А.Г.*)! Мөнбәрдә күренде: халык гадәттән тыш күп тупланган. Соңыннан беленде ки, минем җомгамны теләп, бәлки, вәгазе булыр, дип, чит мәхәлләләрдән күп адәм килгән икән. Тәкаббәлаллаһү минни һәм минһүм (Аллаһ миннән һәм алардан кабул итсен – *А.Г.*)!

Җомга көн мөселманнар зиратына бардым. Ата-анам хәзрәтләренә, бер ай элек туфрак астына кергән бертуганым Габдрахман Тәүфыйк әфәндегә, 16 елдан бирле туфракта булган иптәшем-дустым Маһруйга һәм анасына, бертуганым Әминә Шәрәфкә, остаз Мәрҗанигә, остаз Сәлахетдин җәнабларына сәлам биреп, «Фатиха» [сүрәсе] укып кайткач, мулла Салихҗан Баруди өенә кереп, аз гына тукталдым. Каберстанда каберләр күп икән, минем вакытымнан соң байтак адәмнәр туфрак астында урын тотканнар: капка төбендә шәех Мөхәммәд Әсир, янында сөекле дуслар һәм иптәшләребездән мулла Шәмсевәли хәлфә бине мулла Бикбулат Әлмани, кари Садыйк бине Сафа Галикәй һәм башкалар күмелгәннәр. Аллаһ барчасын рәхим кылса иде!

## Шәмсевәли хәлфә, терҗемәи хәле

Искә алынган Шәмсевәли (чыгышы Сатыштан), дамелла Ярулла мәрхүм шәкертләреннән булып, аның тормышында мулла Җәлал шәкертлек вакытында, якынча [һиҗри] 1286 елларда Казанга остаз дамелля Сәлахетдин мәдрәсәсенә килеп, дәресләргә тырышлык һәм укыту хезмәтендә дә вәкил булып, остазның вафатыннан соң, [һиҗри] 1292 елда Спас төбәге Тигәнәле авылына имам һәм мөдәррис булып, мәктәп һәм мәдрәсә торгызып, яхшы хезмәт итте. Бер тарафтан, азрак сәүдә итеп, яхшы яшәп торганда,

авыл тормышын, кешеләр белән мөгамәләне авырсынып, ач булуның мөшкеллеген игътибар белән уйлап, Казанга күчте, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә хезмәт йөкләп, үз кәсебеннән тормыш итеп, дәрес укытырга кереште. Яхшы гына хезмәт итте, 25 ел кадәр дәрес белән мәшгуль булды. Башлангыч, урта [сыйныф] дәресләрен, баштарак югары һәм әзерләү дәресләрен дә яхшы укытты. Бер тарафтан, кәсебен дәвам иттерде, бәрәкәт күрде. Казанда Тегәрҗеп урамында бер йорт алып, вакыф (дин файдасына бүләк – *А.Г.*) иткән иде. 1337 елда (1918 елның 10 ноябрендә) 77 яшендә вафат булды. Вафатыннан бер ел соңра, ул йорт янып җимерелде.

Шәмсевәли хәлфә – заты белән өйрәнүче, бәхәскә оста, намуслы, диндар адәм иде. Рахимәһүллаһү Тәгалә (Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын – *А.Г.*)! «Кәримия» мәдрәсәсендә остаз Сәлахетдин янында [булган] вакытыбызда миннән биш яшькә олы булса да, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә килеп, безнең дәресләребездә утырып, бездән дөньяви һич файда күрмәгән хәлдә, мәхәббәт белән мөгамәләсе, сәламләве, байтак яхшылыгы тәэсир итте. Түнтәр мулла Ишмөхәммәднең остазларыннан булса да, аннан артык киң күңеллелек һәм яхшы мөгамәлә күрмәде. Хатыны Маһишәкәр мулла Зәйнулла кызы гомере буенча кызлар укытып, милләткә хезмәт итте.[17]

Мулла Шәмсевәли ахыргы вакытларда мәдрәсәдән аерылгач, кызларга гарәп морфологиясен һәм синтаксисын укытырга керешеп, хатынына иптәш булып, кызлар тәрбиясе бабында яхшы хезмәт итә башлаганнар иде.

Шимбә көн, 3 шәүвәл, әле һаман гает төсе балкый, килү-китү дәвам итә, көндез кунак итү булгалый иде. Үзем дә кайбер дусларга күрешергә бардым. Байларның тормышлары алмашкан: элек торган урыннарының унынчы өлешенә сыйганнар. Ат-арба купшылыкларын ташлап, җәяү йөрергә күнеккәннәр, кара икмәк ашарга өйрәнгәннәр, күңелләре төшкән, канатлары сынган. Дөнья бу – төрлечә була, булу һәм булмауның зур әһәмияте юк. Халыкның кадер һәм дәрәҗәсеннән артык әһәмият бирүләре – бик зур хата, ислам тәрбиясенә һәм хикмәтенә каршы килә торган бер хәрәкәт иде. Аллаһ Тәгалә ахырын хәерле кылсын! Байларга вакытлы бер бәхетсезлек, вакытлы бер чикләнү, вакытлы җәфа булды. Ахыры

[17] Маһишәкәр 1339 елның 26 рәбигыль-ахирендә (1920 елның 23 декабрендә) вафат.

хәерле булсын! Якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе көннәре гади хәлләр белән үтте, ят эшләр күренмәде.

## Татарстан җөмһүрияте турысында имамнар белән сөйләшү

Сәясәт галәме исә Татарстан җөмһүриятен төзү һәм аның әзерлекләрен төзү белән мәшгуль иде. Халык арасында төрлечә фикер йөри: кайберәүләр хәерлек көтә, яхшыга юрый, кайберәүләр, шомлану бәласенә тоткынлыктан котыла алмыйча, төрле сүзләр сөйли иде.

Чәршәмбе көн иртәнге сәгать унда, Ак мәчеткә шәһәр һәм Бишбалта имамнарын җыеп, бу бабта сөйләдем: яхшы каршы алу, булачак көнен куаныч көне [итеп] хисаплау, алдагы көндә өметле хәлләр тууы ихтимал икәнен аңлаттым. Башкортстан да Шура идарәсенә бер дәрәҗәдә иркенлек, мөселманнар өчен рәхәтлек булганын сөйләдем.

## «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә бару һәм тәэсир

Шул көннәрнең берсендә мәдрәсә каралты-курасы яныннан үттем. Эченә кермәсәм дә, тышыннан хәлләре мәгълүм иде. Алдында һәм каралты-курасында солдатлар урнашкан, бакча беткән, ат-арба, такта әсбаблары урнаштырганнар. Мәдрәсәдә торучы гаскәри сәнагать бүлеге икән: каралты-курасына күп такта китергәннәр, агач әсбаб ясыйлар икән. Мәдрәсәнең түрдәге урта өлеше уттан байтак зарарланган, тәрәзәләре ватылган, югары катның эченә ут кергән, тәһарәтханә тәмам янган, агач заты калмаган. Мәдрәсә бу янгын әсәре җәһәте белән дә, торучылары җәһәте белән дә бик начар тәэсир бирердәй хәлгә төшкән. Вә лилләһи гакыйбәтүл-үмүр (Эшләрнең ахыры Аллаһта – *А.Г.*)!

Өч кыштан бирле мәдрәсәнең хастаханә, гаскәрханә булып торуы бу мәдрәсә өчен бер зур афәт булды. Аллаһның рәхмәте белән, вакытлы гына булып, ахырында хәерле хәлгә әйләнеп, кыяматкә [чаклы] шәригать гыйлемнәре йорты булып, хәерле урыннардан булып дәвам итсә иде. Җылыту маддәсендә: кайнар су белән җылыту әсбабы ватылган, бүлмәләренә тимер мич куеп,

моржаларын тәрәзәләрдән чыгарып, сөйкемсез бер кыяфәт тудырганнар. Диварлар каралган, ачык тишек күбәйгән. Бу бәладән котылу тапса да, мәдрәсә хәленә китерү өчен бик күп чыгымнар хәҗәт булачак.

## Барудиядә Габдуллаҗан мөәзиннең тамга җыюы

Бу көннәрдә Барудия (Пороховой) хәленнән ачык хәбәр алдым: имамы мулла Габделбарый тир [бизгәк – *А.Г.*] хасталыгы белән вафат булган, улы Мостафа да тир хасталыгына дучар булып, рәсми шифаханәгә алынган икән. Шул хәлне ганимәт [итеп] белеп, мөәзин Габдулла бине Сафа, ялагайлану, икейөзлелеге белән байтак адәмнәрне авыштырып, имамлык өчен тамга җыйган. Мөэмин-невләргә бер нәрсә өчен күз буявы итеп, булдыклы гыйлем алучы Мәхмүд бине Әхмәтҗан бине Нургалине гыйлем алуын бүлдереп, мөәзин итеп сайлаттырган. Барудия халкының бу кадәр беркат-лылыгы, искә алынган мөәзиннең дәрәҗәсен белмичә, артык эш кылуы хәерле хәл түгел. Мулла Габделбарый мәрхүм мөәзинлектән имамлык хезмәтенә күтәрелгәч, мөәзиннәре тора алмаганлыктан, бу адәмнең дуслык һәм икейөзлелегенә алданып, мулла Габделбарыйга тәкъдим иткәч, һич кичектергесез кабул итеп, тамга җыйдырып, мөәзин билгеләгән, хәлләре яхшыланып киткән иде. Ләкин озак үтмәде, кайбер каршы булучы адәмнәргә якынлашып, аларның начар хәрәкәтләренә корал булып, искә алынган имамның зарарына хәрәкәт башлап, халык арасында үзенең йогынтысын арттырырга тырышып, төрле чара һәм мәкерләрдә булып, искә алынган имамны кәефсез иткән һәм, бу сәбәпле, мине дә борчулы иткән иде. Гарьсез, дөнья өчен һәр әдәпсезлекне алучы, ялагайлану иясе булып чыкты. Бер дәрәҗәдә гыйлеме булса да, җитәрлек түгел, мөәзинлек өчен, яхшы әхлагы булганда гына, җитәрлек дәрәҗәдә. Аллаһы Тәгалә бу эшне дә хәергә әйләндерсә иде!

## Татарстан җөмһүрияте файдалы булырмы?

24 июнь, пәнҗешәмбе көн, гает алды, җөмһүрият игълан итү алды булу мөнәсәбәте белән һәр җирдә акрынлап әзерлек бара, гомуми мөселманнар арасында бераз хәйранлык бар: мөселманнар өчен файдалымы, зарарлымы шөбһәсе җаннарын борчый иде. Коммунистларга мәхәббәт итә алмыйлар, аларның дингә карашларын җирәнгеч күрәләр. Коммунистларда да саксызлык, уйлап эш итмәү бар, тәҗрибәсезлек күп иде. Динлелектән тәкъдимнәре, динсезлек кануны нигезләреннән булганда да, халыкның карашларын җәлеп итеп, сәясәтләрен ныгытканча, хөкүмәтләрен тәмам урнаштырганча, яхшы мөгамәлә һәм ягымлылык белән һәр төркемне ихтирам белән, һәр фирканың фикерен хурламыйча, яхшы мөгамәлә тиешле. Кешеләр дә шуны тели иде. Болар фиркаларының мәҗбүри кагыйдәләреннән, асыл яхшылыкларынан һичкайсын аермыйча шаулыйлар, ачык исламга һәм башкаларга әдәпсезлек кылалар. Мөселман халкы – диндар, ышанычлы, саф күңелле, гәүдә, дин турысында әдәпсезлек кылуны һич күтәрмиләр. Шул сәбәпле: «Бу коммунистлар хөкүмәт кешеләре булсалар, һәммә хәл, эш һәм килешү төзү болар кулында булса, мөселманнарга файда булырмы икән?» – дип зур шөбһәдә торалар. Ләкин боларның бу шөбһәләре урынлы шөбһә түгел. Бу хөкүмәтне Шура хөкүмәте [белән] чагыштыру, тугры Шураның үз идарәсе белән күбесе мөселман исемендәге яки татар коммунистлары аркылы булган идарә белән чагыштыру тиешле.

Татар җөмһүрияте дигәч тә, дин торгызу һәм ислам тарату җөмһүрияте түгел, һаман да коммунизм ысулынча төзелгән аермалы бер җөмһүрият. Болар төп Шура кануны нигезе белән төзелсә дә, мөселманнарның хәлләре, татарларның рухи хәлләрен яхшырак аңларлар, җан тартмаса да, кан тарта дигән кебек, чит адәмнәргә караганда аңлашыбрак эш күрерләр. Һәрнәрсә дә башта туганда җитешмәгән була, бара-бара төрле фикерләр тоташу, сәясәтләр үзгәрү сәбәпле, үзгәрешләр, күркәм хәлләр булырга мөмкин. Диндар булмасалар да, динне рәсми сурәттә түбәнәйтмәсләр, иншалла, игътибарлы рәвештәрәк мөгамәлә итәрләр. Аеруча болар фәкыйрьләрне яклыйбыз дәгъвасында. Мөселманнарның фәкыйрьләре бигрәк тә ышанычлы, диндә ныклы. Ирекле-ирексез бу коммунистлар да уңлашырлар, карашларын үзгәртерләр. Бу мәгънәне җөмһүрият игълан ителгән (1920 нче елның 25 июне)

җомга көн намазыннан соң халыкка яхшы аңлаттым, тәбрик иттем. Ахыры хәерле булу өчен Аллаһтан халык белән бергәләп теләдем.

## Ташкент автономиясе

Бу мөнәсәбәт белән үткән бер вакыйга хәтеремә килде. 1917 елда инкыйлаб булгач, Ташкент шәһәрендә, галимнәрен туплап, Төркестан өчен яраклы да булуы мөмкин булган федеративная автономия сорау һәм алу турысында өндәдем. Мөселманнарның Мәскәү җыелышы алды иде. Анда яхшы вәкилләр җибәреп, кавказлылар һәм башкалар белән акыллашып, бу максатта гайрәт һәм дәрт итүләрен нык васыять иттем. Зур галимнәреннән берсе әйтте: «Мондый автономия булса, шәригать хөкемнәре тәмам үтәлерме? Хөдүд (үтергән, зина кылган, хәмер эчкән, урлау өчен җәзалаулар) кирәгенчә йөртелерме? Болар үтәлмәсә, ни файда?» – диде. Каршысында аптырап киттем. Бу кадәр сәясәттән ваемсызлык каршысында нинди мөгамәлә кылу кирәк? Әйттем: «Элек сездә ислам хөкүмәте булган. Искә алынган хөдүд тәмам үтәлгәнме? Истамбул шәһәрендә дә тәмам үтәлә алмый. Шулай да, бөтен мөселманнар шул ислам дәүләтенең дәвам итүен тели, Төркестанда да ислам дәүләтенең юкка чыгуына кайгыручылар акрынлап үтәрләр. Халык тырышса, галимнәр ваемсыз булмаса, акрынлап яхшылык юлын тотарлар, дин һәм милләткә файда итәрләр».

## Татарстан җомһүриятенә караш һәм аның юлы

Татар хөкүмәте, Төрек җөмһүрияте дигәч тә, аның хакимнәре һәм әгъзалары диндар, мәчеттә күренер, гыйбадәт әһелләре булу өмете тиешле түгел. Аеруча дин хөкүмәттән аерылган, хөкүмәт яклавыннан чыккан заманда, сәясәтнең дингә мөнәсәбәте бөтенләй калмаган вакытта, бу эшләрне өмет итү тиешле түгел. Бары бу җөмһүрият алган татарлар, бер дәрәҗәдә сәяси өстенлеккә ия булган Болгар төрекләре сәясәтләрен яхшы йөртсеннәр, идарәләрендә яхшы мөгамәлә итсеннәр, идарәләреңдә булган төрле халыкларны үзләренә җәлеп итеп, яхшы ныгысыннар, алдагы көннәрдә дә халык боларның тарафына күчсен, һәрвакыт болар тарафында булып, хөкүмәтебез дип, аны якларлык рәвешкә килеп,

киләчәкләрен тәэмин итсеннәр. Шул хәлдә зур өметләр туарга мөмкин булыр.

Мөселманнар үзләренең яхшы ихтыярлары белән диннәрен тотсыннар, диннәрендә ныклык кылсыннар, гыйбадәт кылсыннар, мәчет салдырсыннар, мәдрәсә һәм мәктәп торгызсыннар. Тыючы булмас, ихтыярлы булырлар, архиерей мәчет салудан тыймас, инспектор мәдрәсә салудан туктатмас, алдап-сылтап чукындыручы булмас. Берәүгә мөселманлыкка юл күрсәтүчене Сахалинга җибәрүче булмас, һәркем кайсы дин тотса, ихтыярлы булыр, ничек гыйбадәт кылса, каршы килүче булмас.

Мөселманнар хакында иң файдалы, афәте аз, зарары ким хөкүмәт булса, бу җөмһүрият рәвешендәге, гади һәм табигый тормыш мәсләгендәге, халыкны гадилек һәм фитри (табигый) хәлгә кайтарырга теләүче, бу рәвешле социалист хөкүмәте һәм сәясәте булырга мөмкин. Бары сугышлар бетеп, ияләре – югары һәм түбән әгъзалары – бар да чын хисле, туры юллы булулары, алдакчы, ялганчы, фиркачы булмыйча, җитди юл ияләре булу шарт. Тәҗрибәләре артса, халык белән яхшы хисаплашсалар, гаделлек һәм вөҗдан ияләре риза булырлык дәрәҗәгә ирешерләрдер. Вәллаһү йәһди мән йәшәъ (Аллаһ кемне тели, шуны туры юлга күндерә – *А.Г.*)!

Аллаһ Тәгалә «Касас» сүрәсендә Фиргавен һәм Бәни Исраил мөнәсәбәтләрен тасвирлаганда әйтә: Тәрҗемәсе: «Җир йөзендә зәгыйфь саналган бәндәләргә булышлык һәм яхшылык итүне, аларны эш башлары итүне, аларны җирләр һәм малларга хуҗа итүне телибез. Җир йөзендә аларны урнаштыруны, Фиргавен, Һаман һәм гаскәрләренә алардан курыкканнарның хәлләрен күрсәтергә телибез.»

Бу аятьләр Фиргавен белән Бәни Исраил турысында. Ләкин мәгънәсенә караганда, Аллаһның зәгыйфь һәм гаҗиз халыкка ахырда ярдәм итү гадәте булуына күз салганда, бу җөмһүрият һәм Шура хөкүмәте үзләрен яхшы төзәтсәләр, ислам хикмәтеннән, дин серләреннән баштагы юлбашчылары кебек гыйбрәт алсалар, бу җөмләгә керүләре һәм бу аятьнең аңлатканына ирешүләре мөмкин ки, нигездә, [ул] – фәкыйрьләр һәм зәгыйфләргә мәрхәмәт, изүче һәм горур байларга катылык өчен корылган мәмләкәт. Ләкин әхлаксыз күп адәмнәрнең катышуы, комсыз адәмнәрнең эш башларына менүләре, хикмәткә игътибарсыз, чамасыз, деспотларча идарәләре белән байтак нәфрәт казаналар. Түбән хезмәткәрләре

надан дус китергән файдаларны китерәләр, фәкыйрьләр һәм байларның тигез нәфрәтләрен җәлеп итәләр. Бара-бара, бәлки, төзәлерләр, уянырлар. Бу юлның исламга никадәр мөнәсәбәте барлыгы, исламның рухына ничек якынлыгы башка урында язылыр, иншалла. Кыскача әйткәндә, без бу җөмһүриятне яхшы каршылыйбыз, тууын яхшы күрәбез, торуын һәм төзәлүен телибез.

Бу җөмһүриятне игълан итүдә, күп дини сүз катыштырмау шарты белән булса да, галимнәрне, аеруча мөфтине катыштырган булсалар, халыкның мәхәббәтен җәлеп итүдә күп тәэсир иткән булырлар иде, халык бар да бергәләп теләгән һәм торгызган булып күренер иде. Ләкин бу рәвеш мөмкин булмаган, ягъни үзләренчә мөмкин табылмаган икән. Мәҗлес сөйләшүләрендә мөселман коммунистлар тарафыннан бу теләк әйтелсә дә, рус иптәшләре: «Алай булса, поплар, архиерейлар катышуы тиешле килер дә, бигрәк дини төс алыр,» – дип, курку күрсәткәннәр һәм куркытканнар. Мөселманнар күпчелек белән өстенлек итәрлек булсалар да, эш башында ук каршылык чыгаруны яраклы эш итеп күрмәгәннәр. Үзләре генә катышуны кирәкле күреп, эш итүне билгеләгәннәр.

1920 елның 25 июне, җомга көн, җөмһүрият игълан итү көне булуны матбугат һәм хатлар белән игълан иттеләр. Җомга көн иртүк һәркем – олы һәм кече – үз тирә-ягын себереп арулар, урамнар аруланыр, һәркем ул көнне – беренче татар җөмһүрияте көнен – гомуми эш белән башласын, һәркемнең эшләп ашавына кенәзлек, мирзалык торышыннан, ул бозык тормыштан, тәкәббер тормыштан ераклашсын өчен, бер хәерле фал тоттылар.

Чыннан да, иртәнге сәгать 6–7 ләрдә халык, хуҗа һәм фатирчы, йорт эчләрен һәм каралты-кураларын арулап, урамнарын себерергә чыктылар. Хөкүмәт арбалары килеп төяп алып китүгә, чүпләрне өеп әзерләп куйдылар. Иртәнге сәгать тугыз булыр-булмаста, билгеләнгән программа буенча, халык мәйданга туплана башлады.

Пәнҗешәмбе көн кич сәгать алтыда, ашказаны зәгыйфьлеге сәбәпле, үземдә кинәт кәефсезлек пәйда булган иде. Җиңел булмаса да, бик сирәк була торган каты косу хасил булып, җанымны күңелсез, бәдәнемне куәтсез, көчсез калдырган иде. Шулай да иртәнге сәгать сигездә акрын гына хәрәкәт итеп, күршедәге Гали бине Исмәгыйль бине Исхак Субайның үтенүенә күрә, хәл белергә кердем, бераз юатып чыктым. Температурасы кырыктан артык булып, йокыдан калган, каты хаста булган икән. Табибтан дәва алган, тир хасталыгы булудан курыкса да, галәмәте мәгълүм түгел

икән. Шәехләр тәҗрибәләрендә салават шәриф температураны бетерү өчен файдалы күренгәнлектән, салават укырга боерып: «Әсъәлүллаһүл-газыйм раббүл-гаршил-кәрими ән йәшфиһи шифәъән гаҗилә» (Бөек Аллаһтан, хөрмәтле гареш Раббысыннан тиз арада аңа шифа бирүен сорыйм») догасын укып чыктым.

Икенче көндә бераз яхшыланганлыгыннан хәбәр алып, Аллаһка шөкер иттем. Сәгать тугыз булыр алдында мулла Сафиулла әфәнде килеп, бу җөмһүриятне каршы алу бабында кайбер сөйләшү дә булды. «Барлыкны белдерү тиеш, гәрчә рәсми рәвештә галимнәрнең катышуын теләмәсәләр дә, галимнәр үз теләкләре белән катышу кирәк, мин дә хәзер барачакмын», – дип, аны капка алдыннан гына озаттым.

Бераз нигъмәт кабул итеп, хәлсезлек хәлем белән акрынлап мәйданга барып җиттем. Мәйданда байтак халык җыелган һәм һаман җыелуда, күбәюдә иде. Дүрт-биш мулла белән очрашып, бераз тордык. Шунда яшь коммунистлардан, хакыйкатьтә, исламчы Мулланур бине Муллаҗан бине Гәрәй бине Габделвахиткә, үтерелгәч, Вахитов дип мәшһүр затка һәйкәл кору һәм аңа нигез салу булып, шуның янында халык күп җыелган, төрле нотыклар сөйлиләр иде. Минем кәефем дә бертөрле генә булганлыктан, мулла Сафиулла баруны, шунда күренүне теләсә дә, бераз гына сабыр иткәннән соң, акрынлап мулла Зариф бине мулла Хөсәен Әмирхан, мулла Гариф бине мулла Мөхәммәди һәм башкалар өйгә кайттык.

Искә алынган Мулланур инкыйлабның башыннан бирле хезмәт итә килгән, ахырда мөселманнар эшенең башындарак, Мәскәүдә шактый мөһим эш тоткан, «Галия» мәдрәсәсе шәкерте иде. Безнең 1918 ел Мәскәү сәфәребездә азрак файдасы тигән иде. Күбрәк файдасы тиюе дә мөмкин иде, ләкин үзебез иптәшләрнең уйлап эшләмәүләре яки олы сыман мөгамәләләре сәбәпле, файдалана алмый, кирәкле эшләребезне кирәгенчә эшли алмый кайткан идек. Ул кеше белән танышлыгым булмаса да, исламчы, мөселман коммунист, яхшы милләтче, туры фикерле егет икәнен ишетә идем. Казанны чехлар алганда аның үтерелүе, минем уйлавымча, хата эш булган. Мин әзер булган булсам, кулымнан килгәнчә ярдәм иткән, тормышын сакларга тырышкан булыр идем. Гафәраллаһү ләһ (Аллаһ аны кичерсен – *А.Г.*)!

Элекке Шамил йортын (асылы, Ибраһим Аппаков, хәзер Вәлиулла Ибраһимов йортын) татарлар өчен театр хисаплау, шуңа муафыйк корылма итү өчен нигез салалар, диделәр.

## Театр мәсьәләсендә дөрес караш

Театр мәсьәләсе хакында 15–16 ел элек, татар егетләренең башлап татарча театр ясый башлагач, «Әд-дин вәл-әдәб» журналында җентекле мәкаләләр язылган иде. Кыскасы, театр яхшы һәм яман холыкларны гамәли сурәттә күрсәтү булып, үткән вакыйгаларны бер мисал белән аңлату өчен куелган бер рәвештән гыйбарәт.

Һәр вакыйга һәм күренештә табигый берничә әгъзалар булганлыктан, монда да берничә әгъзалар, бер гаилә тормышы яки бер иптәшләр хәлләре яки берничә каһарман адәмнәрнең хәлләре күрсәтелә. Бер яман холыкның, бер әдәпсезлекнең начарлыгын күз алдына китереп, яманлыгын исбат итеп, халыкны аннан нәфрәтләндерү, кайбер күркәм һәм файдалы эшне һәм мактаулы [эш] бабында фидакярлек кылучыны, шулай ук күз алдына китереп, аңа халыкны кызыктыру һәм өндәү кебек файдалары бар. Ләкин арада кайвакыт табигый булмаган хәлләр, күркәм булмаган уйлап чыгарулар, әдәпсез рәвешләр булып киткәнлектән чыгып, шәригатькә туры килмәгән хәлгә килә. Аеруча хатыннарның ислам әдәпләреннән чыгулары, табигый әдәпләр чигеннән чыгулары башкаларның тәрбия хикмәтеннән ераклашулары, әхлак төзәтү өчен куелган нәрсәдән бозык әхлак кәсеп итүләре бу театрның акыл һәм шәригать җәһәтләреннән начар күренгән хәлгә килүенә сәбәп булган.

Шул сәбәпләрдән халык арасында, аеруча динле, суфи булыбрак йөргән картрак мөселманнар арасында начар күрелүе, шундый байтак шәригатькә туры килмәгән сыйфатларны, табигый булмаган хәлләрне эченә алган булып киткәнлектән.

1918 елда комедия язучы Гаяз Исхакый Милли идарә әгъзалары белән Петропавел шәһәренә качак булып барганда, мөселман егетләре тарафыннан куелган театрда Гаяз әфәнде Петропавел яшьләренә сөйләгән нотыгында: «Ата-бабаларыгыз мәчет һәм мәдрәсәләр торгызганнар иде. Сез шәһәрегездә театр бинасы торгызыгыз», – дип авызыннан бер сүз ычкындырган иде. Бу сүз бик тиз шәһәр халкының олы һәм кече арасына таралып, галимнәр һәм башкаларына ишетелеп, сүзне сөйләүчедән һәм иптәшләре булган Милли идарә әгъзаларыннан тәмам нәфрәтләндерү сәбәпләренең берсе булган иде.

Җомга намазын кыскарак кына укыттым. Кәефем таманча иде. Куәтем аз, күңелем зәгыйфь, ашказаным бозыграк иде. Шәһәр хәлфәгә укытырга әйтсәм дә, бераз авырайды, әзерлеге булмаганы беленде. Үзем аз гына вәгазь белән укыттым. Намаздан соң, югарыда язылганча, җөмһүрият турысында бераз сөйләдем. Мәхәббәт күрсәтү, хәерле караштa булулары белән киңәш бирдем. Әхмәтҗан хәлфә артыграк хәерхаһ кеше, минем нотыгыма канәгать итеп җитмәгән, миннән рөхсәт алып, халыкны туктатып, бераз сөйләде. Русларның бик каршы булуларын, татарларга бу бабта көнләшүләрен әйтте.

Җомга вакытларында Бакыр бабай мәйданында парад (гаскәри тантана) булып, сәгать өчләрдән соң махсус зиннәтләнгән Сөембикә манарасы тирәсендә зур җыелыш булып, манара урталыгында ораторлар хөтбәләр сөйләгәннәр. Мөселман һәм рус ораторларының яхшы сүзләр сөйләгәннәрен әйттеләр.

Шундыйлардан, мулла Сафиулла бине Габдулла әфәнденең сөйләвенә күрә, Шура хөкүмәте түрәләреннән коммунист бер рус ораторы русларны юату юлында: «Татарлар куркыныч һәм залим халык түгел, аларга җөмһүрият бирелүе руслар өчен зыянлы һәм хәвефле түгел. Мин кулымда булган һәммә хезмәтләрне бүген барчасын тапшырдым, шатлык белән бу җөмһүриятне каршы алам», – дигән. Мулла Сафиулла да манарага мөрәҗәгать итеп, аның бер дәрәҗәдә бәхеткә ирешүе һәм бу кадәр хөрмәткә җитүе бабында иске хәлләрдән искә алып, бер нотыкны мисал итеп китерү теләгендә булса да, янында галимнәрдән бер адәм дә булмаган, өндәүче булмаган, шунлыктан җөрьәт һәм кыюлык итми сөйләми калган. Хәерле каза булсын!

## Сөембикә манарасына вәисиләрнең ай куюлары

Бу Сөембикә манарасының башыннан тәрене 1917 елда ук гаскәр имамы мулла Гатаулла бине Баһаветдин тырышлыгы белән мөселман гаскәрләре индергәннәр иде. Ләкин русларның ярсуы ихтимал тотылганлыктан, ай шәкеле куярга өлгермәгәннәр иде. Сөембикә манарасы коммунистларның баш урынлашуларыннан ук Мулланур Вахиди саклавына бирелгән булганлыктан, мөселман яклавында булып күренә иде. 1918 елда кадерләп бер кече ай куйганнар. Ләкин бу хөрмәтне башка мөселманнар алардан күп-

сенгәннәрме, башка бер сәбәптәнме – бу хезмәттә бергә катнашып эшләмәгәннәр. Халык арасында электән үк вәисиләргә [карата] дошманлык бар, нәфрәт зур. Үзләре дә мөселманнарга, аеруча галимнәргә начар карыйлар, әдәпсез сүзләре һәрвакыт ишетелеп тора, үзләрен хәвариҗ (аерылып чыгучы дини секта – *А.Г.*) фикерендә тоталар.

Шунлыктан булса кирәк, бу ай кую мәсьәләсе бик таләп ителгән эш булса да, вәисиләргә ышаныч күрсәтүчеләр булганлыктан, халык катышмаганнар. Бу хөрмәтне тик вәисиләр тарихына һәм аларның тәрҗемәи хәлләренә яхшы язу белән язылуына ирек биргәннәр һәм байтак сәяси һәм милли хата эш кылганнар. Манара башына ай кую ислам динендә асылсыз, бидгать эш (дингә туры килмәгән яңалык – *А.Г.*) булса да, халык арасында, чит кешеләр күзендә дини төс алган, милли галәмәт булып киткән. Төркиядә тик бер герб булып калган бер галәмәт. Гади халык һәм югары катлам моңа игътибар итә, чиркәү башларына куелган тәрегә капма-каршы бер мөхтәрәм галәмәт [итеп] саный.

Сөембикә манарасы, тәренең төшерелүе – иң мөһим, иң хөрмәтле эш; зур җәмгыять һәм тантана белән уздырылгач, бу ай куюда да мөмкин булган кадәр әһәмиятле рәвештә үтәлергә, бу хөрмәткә катышуда ярышырга кирәк иде.

Авылларда яңа мәчеткә манара күтәрү, ай куелу дәрәҗәсенә ирешкәндә тарафлардан, бөтен волостьлардан адәмнәр, ир һәм хатыннар булып, зур бәйрәм торгызып, күп хәерләр биреп, яшь киленнәр айга сөлге һәм ашъяулыклар асып, яшь егетләр менеп алырга тырышып, бер зур тамаша ясыйлар, тантаналы бәйрәм итәләр, бик яхшы итәләр. Дин рухыннан туган, мәчет мәхәббәтеннән килгән бер күркәм хәрәкәт.

Бичара [Сөембикә манарасы] Иван Грозный залимгә әсир төшкән, дүрт йөз елга якын христиан тоткынлыгында калган, башына тәре куелган, рәнҗетелгән ислам хакимәсе, ногай хакиме Йосыфбәкнең акыллы һәм матур кызы, мөҗаһид Сафа хан мәрхүмнең яраткан хатыны Сөембикәгә караган ислам манарасы иде. Шура хөкүмәте аркасында, аларның күрсәткән хөрриятләре астында мөселманнарга, аеруча Мулланур Вахидигә күрсәтелгән ихтирамнары хөрмәтендә бу әсирлектән коткарылып, башындагы тәре ватылып ыргытылды. Шуның урынына хәерле халәт итеп куела торган ай куюда бергә катнашып эшләмәүләре – галимнәре

белән бергә Казан халкының гафу ителмәслек җитешсезлекләре – тарихларын каралткан.

Җомгадан соң искә алынган манара әйләнә-тирәсендә булган җыенда ораторлар арасында бер гаскәри мөселман, вәисиләр җөмләсеннән булса кирәк, әйткән: «Бу манара башына без – бары егерме биш гаскәри айны урнаштырдык. Алдан муллалар халыкка: «Һичкем ай урнаштыру җиренә бармасын», – дип вәгазьләделәр. Шуның өчен һичкем булмады. Бары үзебез – аз гына кеше – айны күтәрдек, куйдык. Менә безнең муллалар белән эшебез барып чыкмаячак», – дип, муллаларга һөҗүм иткән. Бу вәисиләр бервакыт большевиклар янында байтак кадер һәм игътибар казанганнар. Үзләренә махсус полклар тәшкил итеп, байтак гаскәр җыйганнар иде, шул арада рәхәтләнеп Сөембикә манарасына ай күтәргәннәр. Рәисләре – үтерелгән Гайнан бине Баһаветдин Вәиси – урынына варис булган бертуганы һәм хәлифәсе Хуҗа Мөхәммәд Газизан бине Баһаветдин рәислегендә байтак көч туплап, яңа бистәдәге Баһаветдин Вәиси һәм улы Гайнан торган Большой Симбирский исемле урамны Ваисовский дип атап, калайга яздырып, байтак беленгәннәр иде. Берникадәр гаскәрләре Төркестанга күндерелде. Ләкин хәзер аларга хәҗәт калмаган. Кирәгенчә гаскәр алынып беткән, күренешләре беткән, әсәрләре күп калмаган, Хуҗа Мөхәммәд Газизан да Казанда юк. Полклары да тәмам югалтылган. Вәссәлам!

Ни булса да, алар мөселманнар, дәвам итүләре, ислам сәясәтенчә, яраган булыр иде, ләкин хөкүмәт өчен кирәк вакытта алар торгызылган, файдаланылган. Кирәклекләре беткәч, югалтылган булса кирәк.

Бу җөмһүрият игълан итүенә һәм аның бәйрәменә мәркәздән (Мәскәүдән) Төркия вәкилләре (Анатолиядәге Мостафа Кямаль Пашаның тәхет идарәсендә булган яңа Шура хөкүмәте тарафыннан), Казакъстан вәкилләре, Төркестан вәкилләре килде, дип сөйләделәр. Һәм манара янында төрекләрдән кайберләре нотык сөйләгән, ләкин теленә караганда Русиядә йөргән, байтак еллар калган адәм булырга охшый. Теле татарчаланган, диючеләр булды. Ихтимал, Русиядә әсир булып калган, башкалардан өстенрәк булган гаскәриләрдән кайберләренә вәкаләт биргәннәр. Бу вәкилләр белән очрашу, минемчә, кирәк күрелсә дә, үзләре килмәгәнлектән (визит бирмәгәнлектән), эзләп баруны яраклы күрмәдем, күрешү юлы ачылмады.

## Казанда туй кыланышлары

26 июнь шимбә көн гади эшләр белән үтте. Якшәмбе көн мәхәлләбездә электән бирле егерме ел кадәр мәдрәсәдә мөтәвәлли (идарә әгъзасы – *А.Г.*) булып хезмәт иткән Әхмәтгәрәй Мөхәммәтша улы Әҗимнең туе булды. Кызы Хәдичәне каракүлче Шакир Хәсән улы Исмәгыйль исемле егеткә сүз бирешкәннәр икән. Олы туе булды. Йөздән артык кунак чакырган. Элекке заманнардагы кебек бүләк салышлы туй итте. Бу заманда, бер дәрәҗәдә килешү булгач, олы туй һәм тамаша итмәгәндә дә яраган булыр иде. Бик олы чыгымнар белән зур мәҗлес кору – байтак икътисади авыр мәсьәлә. Ләкин хатын-кыз мондый бабларда бик хуҗалык итә, аеруча, бер генә кыз да булса, вакытына карамыйча, авырлыкны күзгә алмыйча, шулай булсын, болай булсын, дип мәҗбүр итәләр. Ирләр дә гаҗиз булып, гаилә эчен бозасы килмичә, теләсә-теләмәсә дә риза булып, аларның ризалыкларынча хәрәкәт итәләр. Казанда, күбрәк кыланышлар бу рәвешчә башлана, бу рәвешчә мәйдан алу, бу рәвешчә тәмамлау бер гадәт хөкеменә керә. Бу Әҗим маддәсе дә шулайрак булды. Бу туйда бераз гаҗәбрәк мәһәр мәсьәләсе булды. Гади генә адәмнәрдә мәһәр (совет акчасына) кырык-илле мең, абруйлырак сәүдәгәрләрдә йөз-йөз илле мең сум булган хәлдә, югары дәрәҗәдәге мәһәрләр ике-өч йөз мең сумнар була икән. Ләкин безнең Әхмәтгәрәй әфәнде бары ун мең сум мәһәр яздырган. Кияүдән килгән нәрсәләре ике-өч йөз меңлек булса да, артыгын бүләккә хисаплаган. Элек мәһәрне бик күп итүне сөннәткә каршы күреп, үзем дә инкяр итә идем: «Уртача гына кылыгыз», – ди идем. Ләкин бу маддәдә азлыгына каршы килдем. Чөнки бер процент Мәхкәмәи-шәргыя файдасына алу гадәт булганлыктан, аның байтак өлеше югалган. Хәзерге заманда кайгырту тиешле булган Диния нәзарәтенең хокукы югалган. Шунлыктан азсындым: «Хадимегез, мәһәрен генә кызыңның, гореф-гадәткә караганда, байтак хөрмәтсез иткәнсең», – дидем. Кайберләре: «Үзләре риза булгач, ни зыян», – дисәләр дә: «Мәһәрсез – гадәттә, мөхтәрәмсез. Мәһәрсез дип никях ителгәндә дә мәһәр шикелле әйбер (гадәттә, шул кыз кебекләрнең мәһәре) тиеш була. Шунлыктан хәзерге гореф-гадәт буенча мәһәр тиеш иде», – дип үткәрдем. Әхмәтгәрәй әфәнде: «Китапларда, мәһәр дә ифрат күп ярамый, дип укыганлыктан, шулай аз иттем, хәерле булсын инде», – дип мәсьәләне тәмамлады. Мин дә: «Хәерле булсын», – дип сүзне кистем. Байтак заманнардан бирле никях

хөтбәсе укымаган идем. Авазым да бер-ике айдан бирле куәтсез, тамагым кәефсез булганлыктан, акрынлык белән генә Мәрҗани мәрхүмнең хөтбәсе белән никях укыдым. Аллаһ Тәгалә хәерле никях итсен!

Халык таралганлыктан соң, кызга ике тарафтан биргән бүләкләрне күрсәттеләр. Ефәк, йон, яхшы ситса күлмәклек, тегелгән материяләр, алтын, фәлән һәм фәләннәр, борынгыча, бары күп. Барын хисап кылганда, Аллаһ белер, бу заман базарына күрә ике-өч миллионлык нәрсә булса кирәк. Изгелекләрен теләп, саубуллашып, өемә кайтып киттем. 28 июнь дүшәмбе көн иртәнге сәгать сигездә, чакыруы буенча, Гайнетдин хаҗи Мөэмин йортына киттем. Бу адәмнең бик яхшы, җитеш йорты үткән елгы янгында тәмам янган, бары бер мунчасы калган икән. Шул вакыттан бирле Зәңгәр мәчет мәхәлләсендә бертуганы Галәветдин йортында тора икән. Ул бу соңгы рамазандагы янгында янып, үзенең мунчасына кайтып торуны тиеш тапкан. Бер бакча язлыгы (беседкасы) да сәламәт икән. Мунча белән шул язлыкта торып торалар. Таш кладовое һәм өсте төзек дивар булып калган булса да, идән, түшәм, тәрәзә әсбабын җитештереп, торырлык итәр өчен ике-өч йөз мең сум кадәр нәрсә зарур икән. Проломный урамындагы башкалардан аерылып торган, яхшы номеры, Бристоль, безнең дача янындагы башкалардан аерылып торган күркәм, яхшы дачасы алынганнар, бу кешегә алардан һич өлеш калдырылмаган. Балалары белән язда мунчасында, бакчасында сыенып тора. Аз гына бәрәңге чәчкән, аз гына савыт-сабасы калган, шөкер итеп тора, шатлыгы бетмәгән. Мәдрәсә хезмәтләрен, икътисади эшләрендә фикерләре белән ярдәмнәрен ташламаган.

Адәм баласы киң һәм иркен вакытта тарлыкны һәм кысынкы гына тормышны ихтимал тотмый, мөмкин тапмый. Никадәр мәшәкать һәм җәфа күрсә дә, иркен тормыш белән тора. Керемнәре житсә-җитмәсә газаплана. Тормышын кечерәйтми, кирәк кадәр генә тормышка риза булмый. Бер нәсыйхәт итүче никадәр нәсыйхәт итсен, бер вәгазь никадәр китаптан һәм шәригатьтән вәгазь итсен – колагына алмый. «Китап әйткән дөрес, ләкин безнең кулдан килми, хатыннар күнмиләр» һәм фәлән һәм фәлән сафсаталары белән җавап бирә. Менә инде мохтаҗлык булды: большевиклар халыкка акыл бирделәр. Үзләре сизмичә, ислам кагыйдәләрен, шәригать боерганча тормышны өйрәттеләр. Байгуралар да бик яхшы күнделәр. Ислам гадилеген үткәрү мөмкин икән! Шәригать тор-

мышы саулык һәм тормыш өчен җитәрлек икән, дип белделәр. Хәер, безнең Гайнетдин Мөэмин электән дә мөэмин иде, кыланчык, арттыручы түгел иде. Шәригать икътисадын олылап, һәр бабта кирәк кадәр белән канәгать итүчән иде. Элек фәкыйрьлек күргән. Нужада, хезмәт итеп, күп эшләп, маңгай тирен чыгарып, байлыкка ирешкән кеше булганлыктан, исрафтан, артык иркенлек һәм сыйланудан ерак иде. Аллаһ эшләрен хәерлегә әйләндерсен! Бу көндә «Ислах» җәмгыяте тарафыннан хәзинәдар (казначей – *А.Г.*) булып билгеләнгән. Югарыда искә алынган җәмгыятьтән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе өчен билгеләнгән сумманы алып, шул мәдрәсәнең киләчәге өчен кайгыртуда, мөмкин тапкан кадәр әзерлек күрүдә.

## «Ислах» җәмгыяте

«Ислах» җәмгыяте, 1918 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең икътисади хәлләрен төзәтү өчен, шуңа караган һәм ихласлыларыннан бер җәмгыять тәшкил итү, иганә туплау, мөмкин кадәр мәдрәсә файдаларын кайгырту бабында тиешле чара күрергә сөйләгән һәм кызыктырган идем. Үзем Казанда вакытта беренче мәҗлесе булган да иде. «Ислах» җәмгыяте исемле бер җәмгыять тәшкил ителеп, рәсми рөхсәт алынган. Бу соңгы елда китап сәүдә йортларыннан дини китапларны тиешле бәһаләре белән алынып, бу җәмгыятькә тапшырылган. Хәзер һәртөрле дини китаплар бу «Ислах» җәмгыятендә сатыла һәм аларның файдаларыннан ун процент мәдрәсә файдасына алынып, хәзинәдар Гайнетдин Мөэмин кулында саклана бара.

## Яңа Бистәдә Зариф хәзрәт Әмирханда

Гайнетдин әфәндедән кайтуыма, Яңа Бистә Зариф хәзрәт Әмирхан тарафыннан безне кунак итәр өчен алырга ат-арба килгән иде. Йомышлы адәмнәрне тиз-тиз үткәреп, хатыным белән искә алынган имамның йортына бардык. Дүшәмбе, сишәмбе анда кунып, чәршәмбе иртәнге чәйдән соң бертуганым мулла Салихҗан әфәнде йортына күчтек.

Мулла Зариф бине Хөсәен бине Әмирхан ата-бабадан галимнәр нәселеннән, Казанда дамелла Сәлахетдин остаз мәдрәсәсендә, соңра

Курсадан Хәсән ишанда, ахырда Норлаттан дамелла Фәхретдин Кораэ мәдрәсәсендә булып, яшьли атасы янына 1220 (1873) елда имам булган иде. Коръәнне яттан белә, тырыш, тавышы көчле, акылы һәм зирәклеге яхшы. Бер дәрәҗәдә генә гарәпчә укуы бар. Вөҗданлы, диндар кемсәнә. Мәктәп дуслыгыбыз өстенә, Бохарадан кайтканнан бирле, дуслар булып, минем белән килешүдә һәм юлдашлык итүдә. Аның юл күрсәтүе һәм дәлилләве белән бертуганы хөрмәтле, мәшһүр мулла Нәҗиб Чистайи да шул вакытлардан бирле, яхшы аралашуыбызда булып, торышыбыз һәм фикерләребез белән гел килешеп, яхшы әхлаклы кеше булып, дусларыбыз җөмләсеннән саналуда.

Югарыда искә алынган мулла Зариф биш вакыт намазда мәчеттә булучы, күп вакытта өйлә, икенде һәм ястү вакытларын мәчеттә каршылаучы һәм зарыгып көтүдә булып, гыйбадәт итүчән. Форсат тапкан кадәр, яхшылыкка өндәп һәм начарлыктан тыеп, вәгазь-нәсыйхәт итүче, нәселенә Коръән һәм тәҗвид (Коръәнне дөрес итеп уку – *А.Г.*) өйрәтү белән мәшгуль булып, мәхәллә халкы байтак төзеклек юлына адым куйганр. Халыктан яхшы гына Коръән укырга өйрәнүче егетләре булган. Мәчеткә йөрергә бик күнеккәннәр. Ястү намазларында да кырык-илле кадәр адәм булалар икән. Мәхәлләсендә икътисади хәер-бәрәкәт тә күп арткан. Казанның иң яхшы мәхәлләләреннән саналыр дәрәҗәсенә ирешкән. Хатыны Өмме Фатих (Фатихның анасы – *А.Г.*) – Рабига бинте Зиннәтулла бине Габдулла – күп еллар кызлар укытып, тәртипле, яхшы ысуллы мәктәп торгызып, күп кызлар һәм мөгаллимәләр җитештерде. Мәхәлләсендә бик уңышлы эш итүче остазбикә буларак тормыш итеп, 66 яшенә килеп, быел 1920 елның 4 апрелендә (1338 елның 7 рәҗәбендә) дөньядан кайткан.

Бу Яңа Бистәдә кәефем бераз хушланды. Эсселегем кимеде. Аулактарак та калдым, һавасы да Иске Бистәгә караганда сафрак. Юешлектән азат ук булмаса да, чагыштырмача яхшылыгы бар.

Мулла Зарифның дүшәмбе төштән соң кунаклары булды. Галимнәр һәм дусларыннан ун-унбиш адәм тупланып, күркәм генә мәҗлес үткәрде. Очраклы рәвештә очрашуыбыз теләге белән, тугрылыклы таянычларыбыздан Буа имамы мулла Габдулла бине Гобәйдулла да бу мәҗлескә Шәһәр хәлфә Шәрәф юлдашлыгында килеп ирешеп, аның очрашуы белән бик сөендем.

Бу кемсәнә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә дәресләрен тәмамлаганнан соң, биш-алты ел яхшы дәрес итеп, минем гыйльми һәм

идарә хезмәтләрендә яхшы ярдәмче булып, яхшы ризалыгыбыз белән 1905 елда Буаның яна ачылган мәхәлләсендә имам-хатыйб һәм мөдәррислеккә сайланып урнашкан иде. Яхшы мәдрәсә ачып, элекке имам-мөдәррис һәм ахун мулла Нургали бине Хәсән алмашында, аның кайбер каршылыгына һәм максатына, мөлаемлыгына да бирелмичә, тырышлыгында һәм яхшы эштә дәвам итеп, байтак эшен, Аллаһ ярдәме белән, үстергән. Нәкышбәндия тарикате белән аз-маз шөгыльләнеп, эшләрендә яхшы нияткә муафыйк булган. Хәзерге көннәрдә эш алга баскан. Тарафларында кадер-хөрмәт артып бара яткан. Киләчәкне каршы алуда, иншалла.

Мәҗлесләрдә булган гадәт буенча, йорт хуҗасы Коръән укуымны теләгәнлектән, «Саф» сурәсен укыдым. Аллаһка мактау, аннан соң елау хасил булып, ахырында бу сүрәнең рәсүлүллаһ салләллаһү галәйһи вә сәлләмнән әс-Сәед Гали Заһир әл-Витригә кадәр риваять ителеп килгәнлеген, югарыда күрсәтелгән затның миңа укып риваять иткәнлеген уң якта һәм сулымда утырган Габдулла һәм Шәһәр хәлфәләргә тапшырдым: «Бу уку сезгә риваять», – дидем.

Казанда тормыш авыр булса да, Аллаһ җүн бирә. Һәркемнең, сәүдәгәр һәм имамнарның керемнәре авырлыкка очраган рәвешендә була икән. Бу мәҗлестә Зариф хәзрәт тә миңа бер мең сум биреп, башкаларга дәрәҗәләренә күрә, мул-мул сәдака өләште. Бу хәл, әлбәттә, көчне күрсәтә. Башка мәҗлесләрдә дә биш йөздән ким сәдака булмый, күбрәк мең сум була. Әҗим туенда һәр ике тарафтан миңа икешәр мең сум бирелеп, башка имамнарга бирәр мең сумнан өләштеләр. Аллаһ ярдәм бирә, аш-сулары да мул була. Бер табаклык аш ун-унбиш мең сумга төшсә дә, авырсынмыйча кунак чакыралар. Сөннәт булган кунакчыллыкны, хәтта мәет артыннан өчесе, җидесе, кырыгы кебек **бидгатьләрне** дә калдырмыйлар икән.

## Хәсән карины имтихан кылу

29 июнь сишәмбе көн Хәсән кари бине Зиннәтулланы имтихан кылдым. Бу адәм электән үк Ак мәчет мәхәлләсендә туып үсеп, Йосыф ахун карамагында аз гына мәктәп һәм мәдрәсәдә укып, мәчеттә кари булып, Коръәнне яттан белмәсә дә, Хәсән кари исемен күтәреп, ачык туры юлда торуы һәм искеләр арасында искелеге

белән аз-маз игътибар казанып, яхшы гына тормышка ирешкән. Хәзер алтмышка якынлашып килгән зат. Йосыф ахун вафатыннан соң, бу Хәсәннең үз калдыруы, яхшы ихтыяры белән чигелүе сәбәпле, мәчет карилыгы бөтенләй Вәли карига калса да, мәхәлләдә кайбер адәмнәрнең балаларын укыткалап, кунакчыллыктан калдырылмый иде. Хәтта мулла Габдрахман Тәүфыйк вафатында, вакытлыча һәм бөтенләйгә имамлык өчен, кәләпүшче Гайнетдин Сабитов дигән байгура мәхәллә әһелләренә тәкъдим иткән. Мәхәллә хезмәткәрләре өчен элек тупланган 140 мең сумнан 15 мең сум искә алынган [зат] Хәсәнгә иганә бирдергән икән.

Рамазан башларында Мамадыш өлкәсендә Сикертән исемле авылга имам хәҗәт булып, авылның сәүдәгәре, камчатчы Галиәкбәр Камал тәкъдиме белән, бу авылга имам булып киткән икән. Имтихан һәм указ булмаса да, имамлык [белән], хәтта җомга укып, мәшгуль булган. Җомгада солтан һәм хаким рөхсәте шарт булу мәсьәләсен хәзерге көннәрдә, шәригатьнең башка хөкемнәрен кебек, имамнар арасында санга сукмау башланган. Дөньяга терәлмәсә, шәригатьтә дөреслеккә күп игътибар ителмәс булган.

Моңа мәрхәмәт итеп, килсә, кыскача имтихан кылырмын, указы Диния нәзарәтеннән тәмам булып, килгәнче вакытлыча рөхсәт язып бирермен, дигәнемә күрә, искә алынган [зат] авылдан килгән иде. Кыскасы, сишәмбе көн яныма ике имам – мулла Зариф һәм мулла Салихҗанны алып, имтихан кылдым, Коръәннән «Кәһеф» сурәсеннән «Сә-йәкулүнә сәләсә...» аятен укытып, кыскача гына тәрҗемә иттердем. Аннан-моннан колагына кергән, безнең вәгазь мәҗлесләрендә даими булганлыктан, бер дәрәҗәдә юллады. «Фә-лә тәхәр фиһимил-үмәраи заһира» тәрҗемәсендә тукталып торды. Сыйга (фигыль төрләнеше – *А.Г.*) белүеннән сорагач, гаҗизлеген әйтте. Соңра намаз фарызларын сорадым. Унике фарызны санап чыкты. Осталык белән намаздан чыгу фарызлыгын һәм аңа ияргән берничә мәсьәләләр барлыгын әйтсәм дә, хәтерли алмады. Үзем әйтеп, аңлатып, кисәтеп, имтихан мәҗлесен тәмамладым. Бу җитәрлек имтихан булмаса да, вакытына күрә, тиешле чара иде. Моны авыл халкы сайлаганнар, никадәр кире кагылса да, указсыз, хәтта Шура токымыннан бер кәгазь алып булса да, имам булып тормыш итәчәк. Ачык туры юлда торуы бар, намазлы. Бер дәрәҗәдә намазны укый белә, шунлыктан кирәк табылды, йомшак күңеллелек күрсәтелде. Биш вакыт намаз үтәүгә язу бирдем. Имтихан шәһадәтнамәсе биреп, приговоры белән

мөхтәсибтән гуаһландырып, Мәхкәмәи-шәргыягә җибәрергә боердым. Приговоры Шура кешеләреннән шәһадәт ителмәсә дә, аларның дини эшләрдә катнашулары юлсыз, үз низамнарына да каршы булганлыктан, Диния нәзарәте ысулынча да мөхтәсибнең шаһитлык итүе шарт ителгәнлектән, китергән приговорын кайтардым. Тик Мамадышның һәр ике мөхтәсибе бу авылга бик ерак булганлыктан, якындагы Казан өязе Курса мөхтәсибе мулла Гариф бине Хәсән әфәнденең шаһитлыгын тапшырдым һәм махсус хат яздым. Аллаһ хәерле кылсын!

## Оры Сәмигулла мәхдүм

Бу көннәрдә [Күлле-]Киме имамы, Чар өлкәсе мөхтәсибе Габдрахман бине Сибгатулла Арыслан Йолкып өлкәсендә булган вакыйгалардан мәгълүмат бирде. Кулында җыелган ихтыяри иганәдән 12524 сум кадәр акча тапшырды. Элек Казан мөхтәсибенә 13 мең кадәр тапшырган икән. Аның хәбәрләре җөмләсенән берсе: Оры имамы Сәмигулла бине Сибгатулла табигатендә электән үк булган җиңеллеге сәбәпле, указын халыкка тапшырган. Үзе, улы һәм кызы мөгаллим булып, кызылларга хезмәткә керешкән. Хәербәрәкәтенә карамыйча, кулда булган акчага кызыгып, мәчет хезмәтеннән баш тарткан, халык та аннан ваз кичеп, хезмәтләрендә һәм хәерләрендә икенче мәхәллә имамына мөрәҗәгать итеп, югарыда күрсәтелгән заттан хәерләрен кискәннәр. Бара-бара Сәмигулланың тормышы уңайсыз булган, кызы бер коммунистка кияүгә чыкты, үзе дә, мөгаллимлек белән генә тормыш мөмкин түгеллеген аңлап, инсафлыкка якынлашып, халыкка мөрәҗәгать иткән. Ахырда, ялагайланып, указын кайтарып алган. Ахыры хәерле булсын! Җиңел, зирәк адәм. Ләкин зирәклек белән акыл икесе агайэне булсалар да, араларында зур аерма бар. Кешенең бәхетенә, яхшы хәленә гарантия, бозыклык һәм начар эштән саклаучы зирәклек түгел, акыл. Бу ике бертуганның акыл булганы хуҗа була алса, зирәклек һәм аның әсәре булган гыйлеме дә үз кулында тота алырлык дәрәҗәдә куәтле һәм камил булса, бу адәм чын бәхетле, дөнья һәм ахирәттә яхшы хәлгә ирешүе мөмкин була. Әгәр дә, киресенчә, акылы җиңелгән, зирәклеге һәм гыйлеме җиңүче булса, бу адәм зирәклек һәм гыйлеменнән файда урынына зарар, бәхет җиренә бәхетсезлек күрә. Бу мәсьәлә – фән буенча да, тәҗрибә

буенча да айнык һәм нык мәсьәлә, рәсүлуллаһ саллаллаһү галәйһи вә сәлләмнең сүзләре белән раслана. Искә алынган мулла Сәмигулла, вакытында күп фидакярлекләр итеп, ысуллы мәктәпләр торгызып, халыкны көчләп, яхшы укытты. Халык тарафыннан күп җәфалар күрде, хурлыклы сүзләр ишетте. Муллалардан да төрле һөҗүмнәр һәм дошманлыкка очрады. Ләкин мәсләгендә ныклык күрсәтте, авышмады, һичкайсы мулладан һәм дошманнан җиңелмәде. Ахырдан, һәммәсеннән өстен чыкты. Булдыклы, зирәк, батыр адәм. Ләкин кайбер эшләрендә деспотларча хәрәкәтләре, горур мөгамәләләре булгалады. Кызулыгы һәм җиңеллеге бар. Шул холкы белән, бу указ бабында, бер хаталы мөгамәләгә төшкән. Соңра указын кайтарып, урынына кайтып утырган, яхшы иткән. Бер тәҗрибә хасил иткән. Бу хәбәр бер адәмнең хәбәре, бәлки, асылында безгә мәгълүм булмаган сәбәпләр бардыр. Әл-гуһдәтү галәр-рави (Җаваплылык сөйләүче өстендә).

## Зират өсте мәчете һәм имамы

Яңа Бистәдә чәршәмбе көн сәгать 11 дә зират өсте мәчете имамы Сафа өенә чакырды. Бу адәм зират өстенә мәчет салу эшләрендә кайбер түрә-каралар белән катнашып, корылма рөхсәтен алуда аз-маз хезмәт күрсәтүе сәбәпле, шул мәчетне төзүче Салих бине Сабит Гобәйдулланың гадилеге һәм игътибарсызлыгы сәбәпле, шул мәчеткә хезмәте өчен икенче имам итеп билгеләнгән. Беренче имамы Мөбарәкҗан хаҗиның вафатыннан соң мөстәкыйль имам булып калган. Болар – ике имам һәм мөәзин Кыяметдин кари – зиратта каберләр өстендә өйләр салып, бәдрәфләр казып, бакчалар ясап утырганнар. Бу – зират Казан эчендә калган, өстенә Казаков мәчете торгызылган зираттан соң булган иске зират. Ташланганлыгына сиксән-туксан ел булган. Шәһәр идарәсенең бу зиратны алу ихтималы булганлыктан, мөселман җәмәгатенең мәчет салу сылтавы белән үзләренә калдырулары, үлекләрнең сөякләрен җыеп, башка бер җиргә күмеп, мәчет торгызулары тыелган һәм шәригатькә каршы [эш] булмаса да, имамнарның өй торгызулары, бәдрәф казулары, мәетләрнең сөякләрен мыскыл итүләре – яман эш. Бу өйләргә, хәтта мәчетләренә дә бу көнгәчә кергәнем юк иде. Тик элекке заманнарда шәех Морад әфәнденең Кыям карига төшүе сәбәпле, күрешү өчен бер мәртәбә барган идем. Бу тапкырда мулла

Сафаның чакыруын кире кагуны кирәк дип тапмадым. Җөмһүрият мөнәсәбәте белән имамнарны Ак мәчеткә чакырганда, имамнар һәммәсе гади халык киемендә килгәч, тик ул чалма-чапан киеп килеп, яхшылык чыганагы булганлыктан, бу чакыруын кабул иттем. Мөхтәсиб һәм мулла Зариф, остазлары мулла Хисаметдин һәм мулла Салихҗан белән бергә бер-ике чынаяк чәен эчеп, намазын шул мәчеттә укырга булган идек. Кайберәүләр таркалды, мин таһарәт яңартып, бакчасыннан каберләр өстеннән салынган туры сукмакны йорт хуҗасы күрсәтсә дә, урамнан баруны ихтыяр иттем. Гомеремдә беренче мәртәбә бу мәчет каралты-курасына кердем, ишек төбенә бардым. Ике-өч карт мәчетнең ачылганын көтеп торалар иде. Без дә Зариф хәзрәт һәм Шәһәр халфә белән өчебез: «Кем килеп ачар? Кем азан әйтер? Сукмактан имам кайчан килер икән?» – дип бераз көттек. Сәгать 12 дән 35 минут үткән иде. Әүвәлге мөәзин Кыяметдин кари вафат булып, Әҗим мәхәлләсендәге сакчыны мөәзин итеп сайлаганнарын ишеткән идем. Ул авылга киткән икән. Имам әфәнде исә, кунагы булган мөфтинең беренче булып мәчетенә килүеннән хәбәрдар булып та, мәчеткә килмәде, иң кимендә мәчетнең ачылуыннан һәм азан укылуыннан хәбәрсез булып, өендә калдык чәйләрне эчепме, чынаякларны җыештырыпмы калуы гаҗәпләнүебезгә сәбәп булды да, бу мәчеттә хәзер хәерлек юк икән, дип, җәмәгатьтән калмыйк, дип, мулла Салихҗан мәчетенә юнәлдек, андагы җәмәгатькә ирештек. Вәлхәмдү лилләһ (Аллаһка мактау булсын – *А.Г.*)!

Менә дини эшләрнең игътибар ителүе, мәчет һәм җәмәгать намазының кадер-хөрмәте, бер дөньяви күчену өчен имамлык ихтыяр иткән әдәпсезләрнең хәле.

## Әхмәтҗан хәлфәнең кызылларга карашы

Чәршәмбе көн мулла Салихҗан Барудида кунак булып, кич белән анда калып, пәнҗешәмбе көн икенддән элек Иске Бистәгә өйгә кайттык. Җомга көн иртән һава дымлы сәбәпле, үземдә байтактан бирле килгән бизгәкне сизеп, бер чынаяк чәй эчеп, тышка чыгып, Әхмәтҗан хәлфәгәчә барып, берәр сәгать анда утырып, бер аспирин һәм чәй кабул итеп чыктым. Мулла Әхмәтҗан белән сәясәттән бераз сөйләшеп, аның гадәте рәвешчә, нәсыйхәтләрен һәм фәлсәфәләрен бераз ишеттем. Коммунистлар хөкүмәте, Шура

идарәсе бабындагы яхшы уйлавын һәм яхшы каравын раслап, миңа да шул бабта васыять итүдә булды. Хәтта Мәскәүгә баруым турысында юллык (пропуск) алудан сорагач: «Боларга яхшы дуслык белән мөгамәлә максатында булсаң, җиңел эш. Булмаганда барып йөрүдә һич файда юк», – дип катгый җавап бирде. Башкаларга да әйткәләгән: «Дамелланы нәсыйхәт итегез, болар белән яхшы мөгамәләдә булсын, мөселманнар өчен хәерле юл – болар юлы. Кайбер хаталары булса да, саваплары күбрәк». Әхмәтҗан әфәндenең фикеренә тәмам кушылмасам да, тәмам каршылык кылмыйм. Арттырмыйча һәм киметмичә генә фәкыйрьләрне сөю, һәр бабта фәкыйрьләр яклы булу, аларга ярдәм итү, байларның кайбер дошманлыкларына каршы бару, фәкыйрьләргә һәм хезмәткәрләргә җәбер һәм золым итүләрен инкяр итү, акыл һәм шәригать җәһәтеннән, мактаулы һәм мөһим, бәлки тиешле күрелә. Дин һәм шәригатьнең карашы һәр вакытларга фәлсәфи һәм хакыйкый. Мал һәм алтынга гыйбадәттән югары һәм пакь. Бу мәсьәләне тәмам хәл итү, шәригать фикеренчә аңлату, әлбәттә, бу урын мәсьәләсе түгел, төрле җирдә язгаладым. Тик Әхмәтҗан хәлфәнең катгый сурәттә миңа мондый тәкъдимнәре бераз гаҗәпләнүемә сәбәп булды. Башка вак-төяк сәбәпләр кушылып, катырак сөйләү кирәк булмадымы [икән], шөбһәсендәмен.

Җомга намазына азаннан элек кердем, мөнбәрдә Әхмәтҗан хәлфә сөйли иде, сүзләрен ачык ишетмәдем, якын утырмадым. Аңлашылды: халыкның аны большевизм белән сөйләүләренә хәтере калган: «Мин большевик түгелмен, халыкны большевиклыкка чакырмыйм. Бары мөселманлыкка чакырам, мине большевик диюләре – яла ягу һәм фәлән» мәгънәсендәге сүзләре бар иде.

## Ак мәчет халкына имам алу хакында бәян

Җомга укып тәмамланганнан соң, янә мөнбәргә чыгып, мулла Габдрахманның җиренә имам сайлау мәсьәләсен бераз сөйләдем: «Имам хәҗәт булыр. Тиз көннән мин кайта алмыйм, милләтнең бөек хезмәте минем өстемә йөкләнгән. Үз теләвем белән кермәдем, артымда сайладылар. Үзегезгә киңәш иттем. Ризалыгыгыздан соң гына кабул иттем. Җиде мең кадәр мәхәллә, 12 меңгә якын имам һәм мөәзин, руханилар һәм боларның эшләре безнең кулыбызда. Фикерсез һәм уйлап эш итмичә ташлап китү егетлек түгел. Гомуми

бер киңәшмә төзергә телибез. Шул җыелыш барлыкка килсә, тәмам эшләребездән хисап биреп, Мәхкәмәне үзләренә тапшырып, рөхсәт алырга телибез. Шул вакытта гына кайтып тору мөмкин булыр яки Шура хөкүмәте үзлегеннән куып җибәрсә, Мәхкәмәне япса. Бу ике рәвешнең берсе белән генә Мәхкәмә хезмәтеннән бушану мөмкин.

Инде сез – баегыз, фәкыйрегез, картыгыз, яшегез – бер авыздан һәм бер сүздә булып, яраклы имам сайлагыз. Беләсез, милади 1882 елдан бирле мин сезгә хезмәт иттем. Мәхәлләдә байтак әсәрләр туды, Аллаһның рәхмәте белән хәер-бәрәкәт хасил булды. Шәһәрнең иң яхшы, иң чәчәк аткан мәхәлләсе булды, һәркайсы эштә безнең мәхәллә баш булды, һәр киңәш безнең мәхәлләдән туды. Һаман да шул хәлне югалтмаска, артка калмаска тырышыгыз, акыллы һәм гыйлемле, диндар адәм сайлагыз. Күз алдыгыздагы мәдрәсәне күрәсез. Хәзер мондый афәткә очраса да, иншалла, бер көн булыр, ул афәт күтәрелер, мәдрәсә кулыгызга кайтыр. Торгызырга, чын дини мәдрәсә итеп алып барырга тырышыгыз. Бу көнгәчә байларыгыз акча белән, фәкыйрьләрегез тел ярдәме белән, башкаларыгыз башкача ярдәм иттегез, хезмәт иттегез. Янә моннан соң, бер фикердә булып, бу мәдрәсәне кайгыртыгыз. Бигрәк имам сайлаганда бу хәлне исегездә тотыгыз. Минем бу кадәр еллар хезмәт итеп һәм михнәт чигеп кылган эшләрем җилгә китәрлек булмасын. Бу көнгәчә сүземне һәм фикеремне җилгә җибәрмәдегез, җиргә төшермәдегез. Моннан соң да шулай турылык һәм саклау белән булуыгызны көтәм. Казан шәһәре бөтен Русиядә атаклы шәһәр, дини мәркәз һәм гыйлем йорты булып килде. Хәзер төрле афәтләр күренеп торса да, өметне өзмичә, Казанның шул дәрәҗәсен сакларга, аның өстенлегенә хезмәт итәргә тырышыгыз. Казан шәһәре үзенең казанлыгын югалтмасын иде. Казан эчендә безнең бу мәхәллә элек хасил иткән дәрәҗәсен төшермәсен иде. Бу теләкләрне, бу максатларны югалтмаска тырышып, мәхәлләгезгә, бу мөбарәк мәчеткә бер имам сайлап алыгыз. Мин кайтсам да, бер имам кирәк булыр. Күрәсез, мин байтак картайдым, зәгыйфь булдым, бер ярдәмче имам кирәк булыр. Мин киткәнче билгели алсагыз, яхшы булыр иде. Шунлыктан яхшы ихтыярыгыз һәм яхшы бердәмлегегез белән сайлагыз. Сайлавыгызда бу мәсьәләнең кадерен, мәдрәсәнең әһәмиятен хәтерегездән чыгармагыз. Янә әйтәмен: мин электән үк иске муллаларның хәтере өчен, аның улын һәм киявен һәм фәләнен сайлауга каршымын. Моны беләсез. Шунлыктан мин фәлән кешене алыгыз боеруында булмыйм. Үзегез

иманыгыз һәм динегез буенча сайлагыз. Бары мин, сорасагыз, киңәш бирдем. Әлбәттә, хәерхаһлык белән яхшы юл күрсәтүем. Аллаһ барчагызны хәерле эшләргә күндерсен, хәерле фикергә, хәерле гамәлгә муафыйк итсен! Әмин».

Фатиха укылды, мәҗлес тәмамланды. Халык азрак тәэсирләнгән булды. Соңыннан бу рәвешле теләгемне көчләүсез, билгеләүсез үз ихтыярларына салып әйтүне кабул иткәннәре ишетелде. Билгеләп көчләмәсәм дә, читтән һәм тарафлардан ишетеп беләләр ки, күренгән ихтималларда, Шәһәр хәлфә Шәрәфтән башка лаеклырак һәм яхшырак адәм юк. Минем максатым да – күп еллардан бирле, аны үз урынымда имам һәм мөдәррис итү. Гүзәл әхлаклы, яшьтән үк дин һәм тәкъвалык белән үсте. Яшьтән үк Аллаһ Тәгаләгә гыйбадәттә булган, галим һәм хөрмәт иясе, мәдрәсәне канәгать иттererлек оратор һәм вәгазьләүче, хәзер иң яраклы кемсә. Өмет итәмен, иншалла, мәхәллә халкы да аннан узмаслар, берләшерләр. Аллаһ Тәгалә Үзенең ярдәме белән муафыйк һәм хәерле адәм насыйп итеп, мәчетнең һәм мәдрәсәнең төзеклеген яңартса, афәт һәм бәладән сакласа иде! Әмин.

## Карахуҗа имамы Садыйк хафиз белән сөйләшү

Бу җомгадан соң Каһарман Уразгилдидә кунак булып, анда Мөхәммәткәрим, Сәлахетдин хәзрәтләрдән кала Мөхәммәтсадыйк хафиз Габдесаттар Убсави Карахуҗави белән очраштык. Югарыда күрсәтелгән [зат] яшьлегендә Мөхәммәткәрим хәзрәткә килеп, хәреф [өйрәнә] башлаган. Элек мулла Шиһаб Чембулатый, соңра мулла Нургали Баруди хәлфәдән укып, дамелла Сәлахетдин заманында хәлфә арасына кереп, «Шәмсия» (мантыйк китабы – *А.Г.*) һәм гакаид (иман нигезләре хакында фән – *А.Г.*) дәрәҗәләренә кадәр дәрес бирде. Дәрес арасында Коръән ятлап, куәтле кари булган иде, ләкин тәҗвиде тулы түгел иде. Өйрәнү куәте бар. Безнең Камалетдин бине Сәйфетдин Әүрани белән фирка иптәшләре дәрәҗәсендә бер-берсенә мәхәббәтле, даими бергә укып, бер-берсеннән файда алып тормыш иттеләр. Гарәп теле буенча Камал хәлфә, акыл буенча бу адәм алданрак булганлыктан, бер-берсенә ярдәмче иптәш булып тырышканнар. Каберлеккә, кырларга барып, дога укыганнарын бу мәҗлестә дә әйтте. Кизләүгә йөргәләп, Нәкышбәндия тарикатеннән дә өлеше барлыгын, авылында укыт-

канын сөйлиләр. Бу мәҗлестә кайбер тарихи вакыйгалар турында сөйләшеп, бер вакыйга сөйләде:

Безнең Газизҗан туена Мәнгәргә барыштамы, яки минем туемда Мәчкәрәгә барыштамы, юлда намаз вакыты булып, «Кемнең таһарәте бар, кемнең юк – әзерләник», – дигән сүз булып, мәрхүм остаз Мәрҗани Шиһабетдин хәзрәттән сорагач: «Минем бик нык таһарәтем бар ки, намазда көлү белән дә бозылмаслык»,– дигән. Мәрхүм Мәрҗани бу сүзне бер гыйльми мәсьәлә итеп искә алган булса кирәк. Сорау бирүче булса, ачыклаган булыр иде. Бәлки иткәндер дә.

Бу сәфәрдән соң Әхмәтҗан Сәйдәш балалары Мостафа һәм Мөхәммәтҗанның хәлфәсе бу мулла Садыйк агайдан: «Хәлфә, шундый таһарәт бармыни?» – дигәч, барлыгын әйттем. «Госел таһарәте (госел вакытындагы таһарәт яки госел эчендәге таһарәт, башка очраклы күренеш булганча, көлү белән бозылмавы, каршылыксыз ук булмаса да, фикыһ китапларында искә алынган; шунлыктан таһарәтне бозган көлүне мөстәкыйль таһарәт дип билгеләгәннәр) бозылмый», – дидем. Әйтүемә каршы мәҗлестәге Кызыл мәчет имамы Гариф бине Мөхәммәди, кире кагулы хәрәкәттә булып, чын ачыклау юлында хәрәкәт кирәк булса да, баш тартып сүз кушып: «Дәлил кирәк, андый билгеләү ни өчен һәм фәлән», – дисә дә, Садыйк Хафиз: «Фикыһ галимнәре әйткән, дәлиле дә бар, һәрнәрсәнең дәлилен белеп бетереп булмый, фикыһ галимнәренең сүзләренә ышану кирәк, муллишкаларның ник алай, ник болай диюләре – сүз көрәштерү генә», – дип төксе генә итеп сүзен тәмамлады. Сөйли белмәсәң, шундый җавап ишетергә туры килә.

Бер ят сүз ишеткәндә ятсынып кире кагу һәм инкяр юлынча сүзгә керешми, аңлатуны таләп итү һәм файда алу белән мөрәҗәгать итәргә кирәк. Файда алу һәркөн мөмкин. Үзеңне хатасыз камил дип санаганда уңышлы сөйләшү чыкмый. Картраклар, гыйлеме күбрәк дип саналган адәмнәр алдында әдәп белән сөйләшеп, файда алырга тырышырга кирәк. Бәлки, әдәп белән мөрәҗәгать ителгән булса, мәсьәләнең аңлатуы мәйданга куелмаган да булыр иде. Элекке заманнарны, дамелла Сәлахның Борнаев мәхәлләсеннән икенче мәхәлләгә күчү мәсьәләләрен сөйләдек. Бу адәм шул вакытта шәкерт булган, дамелланың ике элекке дәресендә «Мохтасар әл-викая» (фикыһ китабы – *А.Г.*) дәресендә булып, ул вакыйганың милади 1862 елның мартта булганын сөйләде. Минем

уйлавымча, 1861 ел булса кирәк иде. Мөрәҗәгать белән тикшерелер.

## Мулла Әфтах Тәрҗеманинең никях хөтбәсе

Бу мәҗлестән чыгып, Яңа Бистәдә кәҗәче Якуб бине Ибраһим бине Әхмәд әс-Суфинең кыз бирү туена бардык. Байтак кыланышлы, зур җәмгыятьле корылган мәҗлес үткәрелде. Казый мулла Кәшшафетдин Тәрҗеман мәхәлләсе булып, аның урынбасары һәм бертуганы Әфтах бине Кыям Тәрҗеман никях хөтбәсе [укыды] һәм никяхны алып барды. Миңа тәкъдим иткән булса да, үзенең укуын артык күреп, кабул итмәдем. Мондый вакытларда, тәкъдим һәм сорау, күбрәк, Бохараның Сәмәрканд әдәп саклавы дигәннәре икейөзлелек яки бер төр әдәптән генә булганлыктан, кабул итү яраклы булмый. Зарарсыз гына Мәрҗани хөтбәсен укыды. Тәҗвиде һәм әйтелеше яман түгел, гыйбарәләре дә хатасыз, дөрес. Ләкин авазы зәгыйфь һәм нәзек аваз булганлыктан, бераз күңелсез ишетелә. Мәҗлестә байтак галимнәр булса да, кирәкле бер гыйльми мәсьәлә яки дини бер киңәшләшү килеп чыкмады.

Бу мәҗлестән соң мулла Салихҗан өенә һәм бакчасына кайтып, бераз ял итеп, Чистайдан шул көнне килгән дамелла Нәҗип Әмирхан белән очрашып, агасы һәм башка мөсафирлар белән чәй сөйләшүе үткәреп, икенде, ахшамнан соң, сабынчы Шакир бине Вафа бине Яхъя Сәйдәшнең чакыруын кабул итеп, аңа кунак булдык. Бу адәм Гыйлаҗ Әлмитов белән партнер булып, сабын заводы төзеп, зур байлыкка ирешкәннәр. Сугыш вакытында, хәрәкәтле һәм йөрәкле кемсәнәләр, байтак байлык һәм бәрәкәт хасил иттеләр. Эчке сугышлар һәм Шура хөкүмәте сәүдәгә каршы никадәр көч һәм кабарыну күрсәтсә дә, гайрәтле адәмнәр юлларын табалар, эшлиләр. Миллионнар куллану гади бер хәл булып китә. Бу Шакир дә яхшы хәлгә килгән, мәҗлестә миңа егерме биш мең сәдака бирерлек дәрәҗәгә ирешкән икән.

## Яңа Бистәдә мулла Садыйкның намазы

Шимбә көн иртәнге чәйдән соң, Иске Бистәгә кайтып, көндез өйләдән соң бер мәҗлес үткәреп, икенде җәмәгатен үтәгәннән соң, янә хатыным белән бергә җәяү Яңа Бистәгә юнәлеп, акрын гына барганлыктан, нәкъ ахшам азаны вакытында Зариф хәзрәт мәчетенә барып кердем. Мөхтәсиб Садыйк Иманколый артында намаз укырга туры килде. Бичараның тәҗвиде җитешмәгән, намаз әдәбен кайгыртуы да бик камил түгел. Ике намаз арасында михрабта кыйблага каршы утырган, карт имам һәм башка кавем аркасында утырганнар. Бу рәвеш тә – әдәпсез бер рәвеш. Башка мөселманнарга, аеруча үзеңнән карт һәм алдынгы адәмнәргә арка биреп, сәбәпсез михраб эченә кереп утыруда һичбер зарурлык юк. Бохарада белем күргән адәм бу әдәбне бигрәк белергә тиеш иде. Пакь һәм гыйлем дәгъвасында булган затларның мондый табигый әдәпләрне санга сукмавы гаҗәп. Бу кешенең җитешсез тәҗвиде һәм намаз әдәбен кайгыртуы аз була торып, үзе имамлык кылмавы һәм аны даими имам итмәве сәбәпле, мулла Зариф Әмирханны бертуганы мулла Нәҗиб һәм улы Фатих алдында каты кисәттем. Чөнки һәр җәһәт белән Зариф имамлык итүгә хаклырак.

## Галимнәр һәм имамнарның хәлләренә караш

Галимнәрнең (галимнәр исемен күтәргән кемсәнәләрнең) хәлләренә каралса, ике сыйныф адәм күренә. Бер сыйныфы – гыйлеме белән үзе файдалану юлында, үзен һәрвакытта төзәтү максатында, башкаларга түбәнчелек белән мөгамәлә итеп, яхшы әхлак күрсәтүдә. Бу төркем үзләрендәге кимчелекләрне күреп төзәлү, ул кимчелекләрне һәм җитешсезлекләрне бетереп, камиллеккә омтылу һәм яхшылану ниятендә була. Моның өстенә, милләтнең дине һәм яхшы әхлагы бабында яхшы хезмәтләре, чын ният белән карау һәм игътибар итү була. Бу төркемне туры юлда булучы галимнәр дию һәм, шәригать терминнарынча да, галимнәр дию мөмкин. Кадерхөрмәт боларга, милләт өстендә тәрбияләре тиеш, яшәтер өчен кирәк булган азыкларын бирү важиб булган галимнәр бу төркем булса кирәк. Икенче сыйныфы – азмы-күпме рәсми һәм атамасы гыйльми булып, үзен камил [дип] белә, төзәлүгә ихтыяҗы калмаган, бары юл күрсәтү, халыкка фәтва бирү генә аның вазыйфасы, дип

белә. Намаз уку беләме, Коръән уку беләме, халыкка әхлагы һәм тормышы белән үрнәк була аламы –монда һич кайгысы юк. Үзенең тормышы һәм хәлләре Аллаһ китабы һәм Рәсүлүллаһ салләллаһү галәйһи һәм сәлләм сөннәтенә муафыйкмы, күңелендә Аллаһтан курку бармы – бу баблар өчен һич тырышлыгы булмый. Иржаэ (иман булса, шул җитә, дип уйлау – *А.Г.*) гадәтендә булып, җаны чыкса, туры оҗмахка китәр дәрәҗәдә җаны тыныч була. Һәркемнән кадер-хөрмәт көтә. Аз гына җитешсез мөгамәләле адәмнән хәле рәнҗи, аны гаепли. Бу рәвешле сыйныфны «туры юлда булмаган галимнәр», «вөҗдансыз мулла» кебек гыйбарәләр белән әйтү мөмкин. Бу сыйныф – муллаларның, галимнәрнең күбрәк өлеше. Указлы имамнар күбрәк бу афәткә очраган. Аеруча, Бохарада торып, бер дәрәҗәдә дәресханәләрдә булып, тыштан гына бер китаплар да укып чыккан булсалар, бу оятсызлыкка бигрәк баткан булалар.

Аллаһтан иң курыккан, дин һәм шәригать кайгыртуында тетрәп торган, һәркемнән файда алып, дин һәм әхлак бабында үзен төзәтергә тырышкан, халыкка азмы-күпме нәсыйхәте, теле, күңеле, әхлагы һәм тормышы белән булган кеше бу галимнәр һәм имамнар булырга тиеш. Халыкның башлыгы һәм юлбашчысы чын динле булмаса, сурәте һәм көче белән хәерле үрнәк булырдай булмаса, ул галимнең үзенә ни файда, халыкка ни файда? Һич, кат-кат – һич [файда юк]!

## Имамнарның вазыйфа алулары

Соңгы заманнарда яшь муллаларда үзләренә вазыйфа (эш хакы – *А.Г.*) билгеләү, айлыклар, еллыклар билгеләтү фикере бик куәтле. Милләт мәҗлесендә дә бу мәсьәлә тәкъдим ителде. Соңыннан Диния нәзарәтеннән бик көттеләр. Шактый гыйлем эченә кергән муллалардан да бу фикерне куәтләүче кемсәнәләр, Нәзарәттә боеру максатында булучылар күренде. Хәтта Нәзарәткә иң лаек әгъзалар сайлангач: «Иң көтелгән мәсьәлә – имам һәм мөдәррисләрнең хәлләрен яхшырту, шул җөмләдән аларга хезмәт хакы билгеләү», – диючеләр күп булды. Ләкин Диния нәзарәте бу мәсьәләдә кабат карарга [кирәк дип] күрсә дә, мөмкин дип тапмады. Шулай ки, Нәзарәтнең яклавы астында җиде мең кадәр мәхәллә булып, әгәр икешәр имам һәм берәр мөәзин булу сәбәпле, 12 мең кадәр мәчет

хезмәткәрләре (имам һәм мөәзиннәр) якынча билгеләнә. Боларга урта хисап белән елга берәр мең сумнан гына куелса да (хәзерге акча белән бу да бик аз, тыныч заманда да), унике миллион сум хәҗәт була. Бу микъдарны Нәзарәт туплый алмый. Хөкүмәт тарафыннан да бу кадәр сумманы җыю өчен рөхсәт булачак түгел. Әгәр дә һәр мәхәлләгә катгый язу төшереп: «Мәчет хезмәткәрләренә һәр ел совет акчасы белән ике мең фәлән кадәр хезмәт хакы туплап бирегез», – диелсә, тыңлауда каршылыклы ара һәм төрле фикерләр туачак, берләшеп йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен, бездә сәяси көч, әлбәттә, юк. Халыкның үз инсафлыгына тапшыру тиешле була. Аз җирләрдә үтәлсәләр дә, бер кагыйдә астына керер дәрәҗәдә эш туачак түгел. Янә, бу эш эшләнсә, халык тарафыннан ихтыяри иганәләр һәм ихласлык белән бирелә торган сәдакалар киселер. Бөтенләй киселмәсә дә, азаер. Күп җирдә халык тарафыннан галимнәр һәм имамнарга бирелә торган нигъмәт һәм булышлык, мәҗбүри кебек алына торган шул хезмәт хакларына чорналган булып калыр. Бу рәвеш исә имамнар өчен бик зыянлы. Моның соңы начар. Янә, бу алыш-биреш, халыкның дөрес һәм ихласлык белән булмыйча, имана һәм башка салымлар кебек булганлыктан, җирәнү һәм нәфрәт белән биреләчәк. Бу рәвешле алынган малда һич хәер-бәрәкәт өметле түгел.

Моның өстенә, имамнар белән халык арасында, бертөрле дошманлык диелмәсә дә, мәхәббәт азлыгы туачак. Бу эш исә бик начар һәм зарарлы бер хәл ки: имамнарның нәсыйхәтләре һәм вәгазьләүләренә халык арасында мөхтәрәм һәм буйсынган булулары бер-берсенә каршы килә.

Бу рәвеш имамнарның да әхлакларын байтак бозачак ки, халыктан бертөрле моңсызлык сурәте булганлыктан, үзләрен аларга сөйдертү, аларга яхшы күренү бер дә таләп ителгән булып калмаганлыктан, үзләрен буш хәлдәрәк күреп, иркен җибәрүләре, төрле кызыксыз хәлләргә дучар булулары ихтимал. Бу хәл дә таләп ителгән һәм теләгәнчә түгел.

Янә тәҗрибәдә күренәләр: хезмәт хакы белән яшәүчеләрнең тормышларында һич хәер-бәрәкәт булмый. Үлчәүле керемнәрнең нәтиҗәләре дә бик үлчәүле була. Бәндәнең шул билгеле хезмәт хакына ышануы һәм таянуы да бертөрле ышанычсызлык, төгәлсезлек булганга, Аллаһ Тәгалә аңа бәрәкәт бирми торгандыр, дип уйга килә. Әмма хезмәт хакыннан башка урыннан теләгәннәрдә

һәм уйламаган җирдән ризык күреп торганнарда, хәер-бәрәкәт күп күрелә. Бу төркемдә аяныч хәлгә калган адәм бик аз.

Хезмәт хакы билгеләү юлында булган имамнар әйтәләр: «Хезмәт хакы булмаса, саранлык белән торыла, рия һәм икейөзлелеккә мәҗбүр булына, халык, хезмәтнең кадерен белеп, ихтыяры белән кирәгенчә бирми, – ихтыяҗ һәм аптырау хәленә төшелә», – дип, шундый төрле сәбәпләр күрсәтәләр. Мондый сәбәпләр бер дәрәҗәдә колак салырлык та була. Аеруча яшь муллалар, яшь хәлфәләр бу сәбәпләргә бик колак салалар. Ярдәм сораган хәлдә, мөгамәләдә нык тору, картларга, аеруча гади кешеләргә яхшы мөгамәләгә мәҗбүрлек күрүгә [караганда] каршы торуны артык күрәләр. Алар белән яхшы мөгамәлә һәм яхшы карауны икейөзлелек дип әйтәләр.

Үзләре җәмәгать намазына килмәсәләр, теләгән сурәттә йөрсәләр, моны риясызлык, диндә ихласлык, иманда ныклык исемнәре белән атыйсылары килә. Ләкин сәбәпләрендә, хакыйкать карашы белән карасалар, чынлап тикшереп күрелсә, боларнын бу сәбәпләре мантыйкка муафыйк бер сәбәп түгел. Әүвәл билгеләнгән хезмәт хакы алу белән билгеләнмәгән сәдака алу арасында хакыйкый бер аерма юк. Һәр икесендә бирүче, нигъмәт, яхшылык иясе, шуңа күрә ярдәмче була. Аның бәрабәрендә шөкер итмәгән кемсәнә, әлбәттә, шөкранәсез, инсафсыз, тәрбиясез адәм була. Бу нигъмәт һәм яхшылыкның каршысында аларга яхшылык күрсәтү, яхшы ризалыкларын җәлеп итәргә тырышу тиешле. Бары яхшы ризалыгы белән биргән азмы-күпме нәрсәнең хәерле һәм бәрәкәтле булуы өметле. Көчләп салгандай алу, налог кебек салым белән алынган нәрсәдә күп хәерлек өметле түгел.

Гадел шаһит шул: электән бирле хезмәт хакыннан башка, халыкның үз ихтыяры белән тәрбия ителгән муллаларның йортсыз, мал-туарсыз, ач-ялангач калганы юк. Бик иркен тормыш итмәсә дә, аз-маз үзе дә авыл хуҗалыгына мохтаҗ булса да, исрафы булмаса да, яхшы гына яшәп калганнар. Боларның каршысында учитель-ләргә карасак, анык фатир, ут, җылылык, берникадәр хезмәт хакы алып киләләр. Хәлләренә карасак, сигез аршинлы өйгә, бер кәҗәгә ия булганнары бер процент та юк. Көнлек тормышларын көчкә генә үткәрәләр. Бары ай саен кырык-илле сум акча кулларына кереп, читтән караган бишәр-унар тиен генә сәдака алган сай карашлы, нәтиҗәдән сукыр булган муллаларны кызыктыралар.

Бу бабта минем карашым: мөмкинлек табылып, муллаларга хезмәт хакы билгеләнсә, боларның халык арасында дәрәҗәләре төшәр, игътибарлары кимер, мәхәббәт белән караучылар булмас. Боларга ялчыга караган күз белән генә карарлар. Халык арасында хуҗа хөрмәтен югалтырлар. Вәгазь һәм нәсыйхәтләре митинглардагы речь, башка гыйльми җәмгыятьләрдәге лекция төсен алыр. Мәгълүмат бирер, дини рух бирмәс. Күңелләргә тәэсир итмәс, дин сөйдермәс, Аллаһка якынайтмас. Шунлыктан бер төрле генә булса да, элеккедән бирле сакланып килгән дингә һәм [дин] әһелләренә мәхәббәт, дини бер рух халык арасында калмас. Мәчетләрнең мәһабәте, аларда булган тәэсир һәм рух кимер. Бу хәлләр ислам галәме өчен зур афәт һәм чиксез яман нәтиҗә булыр. Муллалар өчен ике яхшы хәл: үзләрен яхшы тотсыннар, яхшы мөселман булсыннар, чын иманлы булсыннар. Биш вакыт намазда даими булып, кимендә атнага берәр мәртәбә вәгазь һәм нәсыйхәт әйтсеннәр. Моның арасында, урыны булган саен дини серләрдән бәян итә торсыннар, һәр җомга көн хатыны, хатыннар җыеп, дин карарларыннан, ахирәт хәлләреннән, әхлак бабларыннан вәгазь сөйләсен. Елында сигез-тугыз ай кадәр балаларны яхшы укытсын. Менә бу муллага һич хезмәт хакы кирәкми. Бу мулланың ике өе, аты-сыеры, биш-алты баш сарыгы, ындырында кибәне, сандыгында аз-маз акчасы булачак, ач калачак түгел. Тәҗрибә һәм фәлсәфә бу эшкә ике гадел шаһит. Яхшы фигыльне белмәгән, изге вазыйфаларны үтәмәгән муллалар, халыкның яхшы карашларын җәлеп итә алмаган, турысын ала белмәгән, ялкау, рухсыз, динсез муллалар – хезмәт хакы, хезмәт хакы дип кычкыручылар. Андый муллалар урыннарын ташларга һәм бушатырга тиешләр. Сукаласыннар, сәүдә итсеннәр, башка кәсеп итсеннәр, әрәм тамак, дармоед булып, халык өстендә йөк булып ятмасыннар. Милләттә иманлы, ышанычлы адәмнәр чыгар, имам булырлар. Тиешле рәвештә дини вазыйфаларын үтәрләр, би-гаунил-ләһи Тәгалә (Аллаһ Тәгалә ярдәме белән – *А.Г.*)!

Якшәмбе көн, 3 июль. Ак мәчет мәхәлләсенең картларыннан, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең дусларыннан хаҗи Сибгатулла бине Гайнулла Хәсәни Ашыти тир [бизгәк – *А.Г.*] хасталыгы белән вафат булып, дүшәмбе көн 4 июльдә мәйданда җеназасын укыттым. Җирләвенә килеп, дуслыгы мөнәсәбәте белән, ләхетенә урнаштырып, Аллаһның мәрхәмәтенә һәм рәхмәтенә тапшырдым. Бичара электән [үк] Ашыт авылы кешеләреннән, шунда кызыл мал белән

сәүдә итеп, байлык хасил иткән. Соңра Казанга килеп, безнең Ак мәчет әгъзасыннан булган иде. Хаҗ вазыйфасын да үтәп, яхшы дин юлына кергән мәчет карты иде. Мәдрәсә киңәшмәләрендә минем белән килешүдә һәм булышуда булучы дусларымнан иде. Тир хасталыгына дучар булып, бер атна ятакта булып, ахирәткә сәфәр кылды. Аллаһ ярлыкасын! Әхмәтгәрәй, Габделбари исемле эшлекле һәм акыллы ике улы калды. Әхмәтгәрәй «Гасыр» китапханәсен торгызып, нәфис матбугат һәм «Аң» исемле бер журнал нашире. Габделбари – гаскәри, уку йортларында булып, атасының сәүдәсенә бертуганы белән эш итүдә.

Бу дүшәмбе көн элекке мәдрәсә кешеләреннән Садыйк бине Гайсә Мусинның кунак итүен кабул итеп, сәгать жиделәрдә икенде укып, Ибраһим бине Сөләйман Идрисинең дачасына юнәлдек. Искә алынган Садыйк морзаларча, кечегрәк икътисадлы, кылануларсыз, бер каралтыга лаек өендә, ләкин түбән катта кечегрәк ике бүлмәсенә урнашып: «Аллага шөкер, үз өемдә калдырдылар», – диебрәк канәгать итеп торуда икән. Югары катын бөтенләй хәзерге хөкүмәт басып алды. Түбән өйнең яртысын каенэнесенә вакытлы файдалануга биргән. Бу хәл – тормыш икътисадын өйрәтер гыйбрәт.

Ибраһимның тайлы байталына (биясенә) утырып, бер кулга камчы тотып бара-бара җиде чакрым кадәр ераклыкта булган дачага кояш баер вакытта гына барып ирештек. Казанның тарафында, комлык, наратлык урманда, удельный җирдә корылган дачалар – 1914 елда үземнең дә күршеләребез Вафа Гайнуллин, Гайнетдин Мөэминнәр белән бер-бер артлы төзелгән дачалар. Ибраһим да бик икътисади, тактадан гына бер дача корган иде. Бәрәңге һәм башка яшелчә игеп, яхшы файдаланып, һаман үзе эшләп ашаучы исемен алып, үз кулында саклап калган. Бу кичәне кунып, икенче көндә янында булган үзебезнең дачаны барып күреп, дөньяның соңгы хәлен белеп кайттык. 1919 ел язында гаскәриләрне торгызганнар, кышында, мунчасында, кайбер кемсәнәләр торганнар икән. Төп корылмасы яхшы, төзек. Хәзер гаскәриләрдән музыка мөгаллиме гаиләсе белән торуда икән. Бик зур, озын һәм калын баганалы. Катының бөтен әсбаблары җирендә юк. Каршысындагы ат-сыер, арбалар урыны, баз өсте югарысындагы печәнлек тәмам харап ителгән. Такта заты алынган. Ике тавык оясы, ике бәдрәф беткән. Коеның насосы бозылган. Бурасы эчендә суы әйбәт күренде. Ике бакчадагы 40–50 кадәр алмагачлардан һәм башка кура һәм карлыган кебек җимеш агачларыннан әсәре [дә] юк. Мич янында су кайната

торган агач кисмәк алынган. Башкасы, ягъни дивары, миче һәм тәрәзәләре төзек.

Бу хосусый җимерелүләрдән дөньяның гомуми хәленә фикеремне күчереп, гыйбрәт алып кайттым. Башка күрше-коланнарның дачалары да, күбесе шул хәлгә якынлашып килгәннәр. Дөнья һәрвакытта да игътибар өчен, гыйбрәтләнү өчен торгызылган бер йорт. Ләкин элекке хәлләрендә: гыйбрәт алучы аз булып, күбрәк ваемсызлык белән үткәрелә иде. Хәзер аз гына гыйбрәтләнергә сәләтле адәм уяна, гыйбрәт карашын кузгатып, төрле файдалар ала яки алырга мөмкин.

Сишәмбе көн тәмам дачаның матур һавасыннан файдаланып, янә кунып, чәршәмбе көн каты яшен, бераз яңгырдан соң, өйлә алдында Казанга кайттык. Саулыгым өчен берәр атна кадәр анда калу яраклы һәм файдалы булса да, кайбер вәгъдәле чакырулар һәм кирәкле шөгыль һәм файдалар сәбәпле, шәһәрдә булу тиешле булганга, мондый сихәт файдаларымны кайгыртмауга мәҗбүр булдым, һәрвакытта да шундый сихәт хәлләренә соңгы хәлдә генә игътибар ителеп килүдә. Эшнең ахырын уйлап эшләмәү, шәхси хәлләремне кайгырту бабында җиңел карау мина гадәт була язган. Ахыры хәерле булсын!

## Гаскәри ахун Гатаулла Баһаветдинов

6 июль чәршәмбе көн, өйләдән соң Шәһәр Шәрәф хәлфәнең бертуганы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе таянычларыннан Гыйльметдин Шәрәф йортында кунак кабул ителде. Аз гына халыктан гыйбарәт [булган] кунаклар белән сөйләшеп, кунакчыллыкны ахырга ирештергәндә, элекке гаскәри ахун Гатаулла Баһаветдин әфәнде килеп, озын сөйләшү булды. Бу зат элек Шура хөкүмәтенең башлыклары [буларак] танылып, үзенең өлгерлеге белән качып, күп вакыйгалар кичереп, Истамбулга чыгып, Әнкараның яңа хөкүмәте тарафыннан [куелганга], Одесса консуллыгы һәм башка хезмәт-ләрдә булып, Әзәрбайҗанда байтак вакытлар үткәреп, бу көннәрдә Казанга килгән. Анатол реформаторы, хәзерге Мостафа Кәмаль паша идарәсеннән тәэмин ителеп, Шура хөкүмәтенә җибәрелгән. Вакытында Милләт мәҗлесе әгъзасыннан, динче һәм милләтче. Сөембикә манарасыннан тәрене ватып иңдерүче каһарманнар җөмләсеннән иде. Истамбул хәлләреннән һәм андагы союздаш-

ларның золымнарыннан, Сүрия һәм Хиҗазда булган явыз ният белән кулланууларыннан бик ачык белә, аңлата. Мостафа Кәмаль пашаның тәхет идарәсенә керми калган Исгамбул белән Әдернә вилаятенең бик начар хәлдә икәнлеген бәян итә.

Бу кичә Яңа Бистәдә Исхак Карташовта булып, кунып калдык. Чистайдан мулла Нәҗип Әмирхан һәм искә алынган Гатаулла белән кабат сөйләшү булды. Иртәсендә чәйне Әмирханнар белән кабул итеп, безнең өйгә кадәр мине озаттылар.

## Чистайдан мулла Нәҗип Әмирханның тәрбия хакында фикере

Дамелла Нәҗип халыкның намуслылыгын һәм яхшылыгын бик тели, әхлак бозылуга чынлап кайгыра торган зат. Хөр фикерле, һәрнәрсәгә иярмичә карауучан, хәзерге хәлләрдән, аеруча укытучыларның китүләреннән риза түгел. Алдагы көндә болардан хәерле хәл бер дә көтми. Шунлыктан гаилә тәрбиясен кайгыртуны бик тиешле күрә. «Гаилә төзелсен, шул күләгәдә генә балаларның хәлләре өметле булыр, киләчәктә бер хәерлелек көтелер, укытучыларның бозык тәэсирләренә каршы саклану мөмкин булыр», – ди.

Чистайда бер дини оешма төзеп, шәһәрдә һәм тарафларында дин укытуга керешүгә дә зур өмет белән карамый. Хыял мәртәбәсендә калырлык эш дип карый. Бер дәрәҗәдә коммунистлар мондый инициатива күрсәтүгә яхшы күз, яхшы сүз күрсәтәләр. Максатлары дини куәтне киметү, халыкны Диния нәзарәтеннән аеру һәм аны кирәксендермәү. Шул юл белән дингә һәм дини инициативаларга зәгыйфьлек ирештерү булса кирәк. Төрле җирләрдә шулай сөйлиләр. Аңламаган яки аңлап та бозык ниятта булган кайбер муллалар, муллишкалар бу бабта аларга ярдәм бирәләр икән. Казан тарафында, яңа муллаларның, хаксыз булып, Шура тарафыннан расланган приговорлар белән генә хезмәт үтәп торулары да бу фикерне бик ачык аңлата булса кирәк.

Пәнҗешәмбе көн 8 июльдә якшәмбе көнгә шәһәр имамнарын һәм икешәр мөтәвәллиләрен Ак мәчет мәктәбенә чакырып, Шәһәр Шәрәфнең күзлегеннән иҗат ителгән язмалары таратылды. Язманың сурәте бу: «Соңгы елларда төрле агымнарның тәэсире белән дин укыта торган мәдрәсәләребез берсе артыннан берсе ябылды. Үткән ел бик аянычлы бер эш булды. Имам булырга укучы

зур шәкертләргә, дин мөгалиме булырга әзерләнүчеләргә укырга мәдрәсә булмады. Бу дини мәдрәсәләребезнең сүнүе, динебезнең зәгыйфьләнүе булып, бөтенләй һәлакәтебезгә сәбәп булачак. Шунлыктан динебезне һәм дини мәдрәсәләребезне кайгырту – һәммәбезнең өстенә, шәригать һәм акыл буенча тиешле булган бурыч. Бигрәк тә Казан кебек Бөтен Русия мөселманнарының мәркәзе саналган бер шәһәрдә мәдрәсәләрнең ачылмавы, дин дәресләренең укылмый торуы – Аллаһ каршында һәм халык каршында зур җаваплылыклы зур йөз каралыгы. Моны кайгырту бер мәхәлләнең, бер төркемнең генә түгел, бәлки, барча мөселманнарның өстенә йөкләнгән бурыч. Ничек кенә булса да, моны кайгыртырга, бер чарасын күрергә тиешле. Шунлыктан бу дини мәдрәсәләр турысында бер чарасын уйлашу, җыелып киңәш итү өчен, барча мәхәлләләрдән вәкилләр чакырып сөйләшергә уйладык. Алдагы җомгада бу язуны халыкка игълан итеп, үз яныгызга мәхәлләгездән ике вәкил сайлатып, якшәмбе көн 11 июльдә көндез искечә сәгать дүрттә, вәкилләр белән бергә, Ак мәчет астындагы мәктәптә булачак киңәш мәҗлесенә рәхим итсәгез иде». Бу дәгъвәтнамәгә мөфти Галимҗан Баруди, Ислах җәмгыяте рәисе Мөхәммәтрәхим Хәнәфи имзалары куелган.

## Гыймади агай

Пәнҗешәмбе көн ахшамнан соң 78 яшьлек көнлекче Гыймади агада кунак булдым. Бу адәм егерме биш ел элек мәдрәсәдә урын-җир карауны хезмәтендә булып, соңра көнлек кара хезмәтләрдә йөреп, яшәп йөрде. Үзе намазлы, аз гына догалы, кайбер суфи кыяфәтле адәмнәргә ихлас булып йөреп, үз тамагын үзе туйдырып, бердәнбер улын укытып, янә шул хезмәткә кушып, үзләрендә азрак акыл һәм аң булганлыктан, агач, таш, чокыр казу хезмәтләре җенесеннән төрлесен булдырып киләләр. Бу кемсәнәнең диндә ихласлыгы, мөмкин кадәр намазын калдырмыйча, үз көче белән тормыш итүе мине электән үк үзенә җәлеп итә [иде] һәм сөя идем. Бер җомгадан соң күзе яшьле хәлдә: «Кайчан китәсең?» – диюенә: «Бераз торам, сиңа кунак булмый китмәм», – дип әйтүемә куанып, рәхмәт әйтеп аерылган иде. Бу пәнҗешәмбе көн иртә белән очрап: «Миңа барсаң, бүген форсатым бар»,–дигәч: «Ахшам укып барырмын», – дигән идем. Самовар кайнаткан, икмәк тураган. 1650

сумга бер кадак май, 1800 сумга бер кадак бал алган. 250 сумга кура җиләге алган иде. «Ник бу кадәр кыландың? Зур чыгым тоткансың», – дидем. «Ходай ярдәм бирде, һәрвакытта да шикәр белән чәй эчәм, коры чәй эчә алмыйм. Чәй эчмәсәм, икмәк ашый алмыйм. Икмәк ашамасам, эшли алмыйм», – диде. Шикәрнең кадагы ике мең сум булса да, шикәр белән генә чәй эчә икән. «Хәлләрегез, керемнәрегез ничек?» – дидем. Улы әйтте: «Әти көненә бер мең, мең ярым чамасы, мин өч мең чамасы акча табам. Базарда шкафлар кебек нәрсәләр эшлим. Эш күп, эшче аз, акча табыла», – диде. Аталы-уллы аерым тормыш итәләр. Күп заманнан бирле үк фатирлары бергә булса да, тормышлары, чыгымнары аерылган иде. Бер-берсенә ярашлы, дусларча хәрәкәт итәләр. Ач күзле булмыйча, һәркайсы үз көннәрен үзе күрә. Атасы: «Улым, җитте, мин игелек күрим», – дип, мич башына менеп ятмаган. Куәте булганча эшли, эштән кайту белән мәчеткә килә. Икенде-ахшам араларында зикер (Аллаһны искә алу, мактау – *А.Г.*) һәм фикер белән утыра. Баласы Закир да эшкә тырыш, исрафсыз, күп бала үстерә. Коръән укуны сорадылар. Мәхәббәт белән тыңлады. «Бирмә», – дисәм дә, көчләп 25 сум сәдака бирде. Улы 250 сум бирде, «Әни бирде», – дип йөз сум чыгарып бирде. Үги анасы бар, өлфәт белән генә торганга охшыйлар. Эшләп ашый, вакытында гыйбадәт кыла, сакларлык булса да, мал җыймый, сакламый.

Җомга көн иртәнге сәгать тугыздан соң базарга чыктым. Печән базарының күл тарафы очындагы җәмгыять, электр машинасы кибете янында бик тыгыз толчок базары корылган. Кулда төрле нәрсә күтәреп, сатып йөриләр. Бер егет кулында көмеш сәгать күреп, бәһасен сорадым. «18 мең», – диде. Янә берсе кечегрәк көмеш сәгать тәкъдим итте, «13 мең», – диде. Нәрсә күп, сәүдәгәр күп, алучы күп, минем кебек тамашачы да, бәлки, бардыр. Күл буена «Америкaн базары» исемле ике яклы вак-вак балаган кыяфәтле кибетләр төзелгән. Аяк, баш киемләре, чынаяк затлары, энә, тегәр җеп, пычак, кадак кебек вак-төяк, иске ислемай саталар. Җитмеш-сиксән кадәр кибет тезелгән булыр, һәркайсы: «Яшәү өчен кирәк булган мал килә», – дип рәхмәт әйтеп торалар. Кибетчеләр барчасы мөселманнар. Бер чынаяк кибетчесеннән, таныш булу мөнәсәбәте белән, хәлләр сораштым. «Бер гади стакан – ике йөз сум. Асты начар гына тарелкасы – өч йөз сум», – диде. Икесе унбиш тиенлек нәрсә иде. Янымдагы Казаков имамы Габдулла бине Хәбибулла ахун өч йөз сумга элек кырык тиенгә сатыла торган аш

чүмече алды. «Күпме файда иттең?» – диюемдә: «Илле сум чамалырак булыр», – диде. Көлтәле печәннәр сатыла, гади көлтә җитмеш биш сумга төшкән икән. Бер данә башланган икмәк күтәреп килгән адәмнән: «Берсе ни хак булды?» – диюемдә: «Бер мең сум», – диде. 1918 елда Мәскәүдә Габделвөдүд ахун: «Бүген илле сумга бер данә икмәк алдым», – дигәч, гаҗәпләнгән идек. Ләкин ул икмәк ун кадаклы иде. Бу исә, бөтен булганда да биш кадактан артык күренми иде. Базар халкы биш меңне биш, ун меңне ун дип әйтәләр икән. Йөз яки мең кушылмаган сан базарда сирәктер, ахыры. Алай да, хәзер Русиядә кыйммәтлек булса да, чын ачлык юк. Акча күп, ләкин ясалма акча. Күп акчага азык һәм башка нәрсәләр табыла. Ләкин алыпсатарлар спекуляция һөнәрен бик алга сөргәннәр, спекуляция сәбәпле, азык нәрсәләре мәйданда азайган. Ләкин читтән килә торган яки читтән килү туктатылган булган, кергән нәрсәләр, чынлап ук, кыйммәт. Мәмләкәт чолгап алынган хәлдә, блок ителгән союздашлар җибәрмиләр. Мәмләкәт эчендә туган нәрсәләр, спекуляция сәбәпле, югалган, азайган. Шәригатьтә спекуляция ләгънәт кылынган. Бик муафыйк ләгънәт, халыкка бик зарарлы эш. Яман, бәдбәхет кеше эше.

## Шәһәр Шәрәфнең беренче җомгасы

16 июльдә җомга көн намазын Шәһәр Шәрәф хәлфә үтәде. Сәбәбе шул: имам сайлавы турысында мәхәллә вәкилләренең киңәшләшүләре булып, җомга укыту, вәгазь сөйләү күренешен теләгәннәр; егерме ел кадәр мәхәлләләрендә дәрес укытып торган, зур мәүлед мәҗлесләрендә дини хөтбәләр сөйләгән, минем фикеремдә, ачык рәвештә булмаса да, беленгән адәм хакында мәхәллә башбаштакларының бу теләкләре бер салкын хөкем сөрү һәм үзенчә хөкем итү [булганга] начар күрелсә дә, нигъмәт шикелле булганлыктан, бер күренеш лаеклы күрелде. Хөтбә вакыты ирешкәч, җомганы үтәве белән әмер иттем. Яхшы гына, сөннәткә муафыйк хөтбәне үтәде. Тәүхид өлешендә файдалы, халык та аңларлык рәвешчә, аятькә таянып, төркичә вәгазь сөйләде. Бераз озынлыгын санамаганда, вәгазе яхшы һәм тәэсирле чыкты. Вәгазенең эчтәлеге: «Аллаһка иман һәм тәүхид адәмне фәхеш һәм гөнаһлардан, аеруча хыянәттән тыярлык, мактаулы әхлакка караган булырлык [рәвештә] булырга тиеш. Бәндә шайтан вәсвәсәсе белән

бер гөнаһка һәм хыянәткә күңел куйганда: «Чынлыкта, мин Аллаһтан куркам», – дип, шул иманы һәм искә төшерүе гөнаһтан һәм хыянәттән туктатырлык булырга тиеш. Әгәр дә бер кешенең иманы шул дәрәҗәгә килгән булмаса, анын иманы зәгыйфь иман булыр».

Безнең Ак мәчет мәхәлләсендә, укытып карап, имам сайлау – беренче вакыйга. Элек ишетелгән юк. Минем имамлыгымда да, шәкерт вакытымдагы һәм Бохарадагы бүлмә һәм уку өчен бер айга тәүләне карап, кайбер каршы килүчеләр булса да, имтихансыз кабул иткәннәр иде. Бертуганым Габдрахман Тәүфикъ маддәсендә дә, тышкы күренешенә карап, сайлаганнар һәм ризалык биргәннәр иде. Мәгълүм булмаган адәм хакында, башлыклары янында имтихан һәм хәлләреннән сорашып хәбәр алу, әлбәттә, зарур. Кешенең атасы яки остазы сүзенә карап кына, бер дәрәҗәдә тикшермичә изге имамлык дәрәҗәсен тапшыру, олуг дини рәислеккә күтәрү урынлы түгел.

Шәех Шиһабетдин Мәрҗанине Ибраһим бай Юнысов, Казан галимнәре һәм башкаларны туплап, гыйльми имтихан мәҗлесе торгызып, кадере һәм һөнәре ачыклангач, тамга җыеп билгеләттергән. Әхмәт бай Хөсәенов та Казан тарафында салган мәчетләренә пишкадәм (мәдрәсә программасын тәмамлагач тә, аннан китмичә яшәүче – *А.Г.*) шәкертләрне җыеп, галимнәр алдында ярышу имтиханы торгызып, имам билгеләттерер иде. Бу рәвешле галимнәр янында имтихан – файдасыз эш түгел, бәлки, файдалы һәм кабул ителгән рәвеш. Ләкин халыкның: «Үзебез имтихан итәбез, күрәбез», – диюләре – юлсыз эш. Мәхәлләбез дә яңарак туган, мәҗлес һәм тәрбия күрмәгән. Җиңел рәвешле сәүдә белән байлык хасил иткән төркем, үзенчә хөкем сөреп: «Укып күрсәтсен һәм фәлән», – дигәннәр иде. Ни булса да, «арусызлар гыйлем иясен итәр имтихан» шигыренчә имтихан иттеләр. Хөтбәсен, вәгазен ишеттеләр. Гаепчән булганнары да сүз әйтергә мөмкинлек тапмаганнар икән, [дигән] хәбәре ишетелде. Ахыры хәерле булсын! Үзе Шәһәр Шәрәф сигез яшьтән бирле мәдрәсәдә, мәхәлләдә үсте. Укучыларның саташулары вакытында ике якның уртасында булуны югалтмыйча, диндарлыгын бозмыйча, дөрес юнәлеш белән гыйлемнәр кәсеп итү бабында тырышып килде. Укып бетереп, һәртөрле фән һәм гыйлемнән дәрес укытып, укучыларын яхшы файдаландырды. Күп имамнар аның тәрбиясеннән имамлык мәртәбәсенә ирештеләр. Акыл гыйлемнәре яхшы булу өстенә, яңа гыйлемнәрдән хәбәрдар. Дин һәм шәригать гыйлемнәре, бу заманга чагыштыр-

ганда, бик яхшы. Хәдис гыйлеме һәм сирада (Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлын белү – *А.Г.*) осталыгы бар, гарәпчәсе дөрес, әдәбияттан да яхшы хәбәрдар. Димәк ки, бу заманның сирәк очрый торган мәртәбәләреннән. Күп еллардан бирле, бу мәхәлләдә имам итеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең зур мөдәррисләреннән итү теләгендә идем. Мулла Габдрахман тормышында ук, үзем эштән китеп, урнаштыру максатында булсам да, үземнең Казанга бару нияте белән булса да, кайтуым бәйләнешендә, калдырып тора идем. Габдрахманның вафаты бу теләкне ашыктырды һәм моның максатына керешелде. Ләкин гади халык кешеләренең зирәксезлеге, пакь булмаган наданнарның эш башына менәргә, һәр эшнең хәл һәм килешүен үз кулларына алырга ниятләүләре бу эшне бераз кичектерде. Өметкә кичегеп булса да, бу эш туар һәм бу теләк һәм максатыбыз хасил булыр. Бигаунилләһи тәгалә вә кәррамәһ (Аллаһ ярдәме һәм аның рәхимлеге белән – *А.Г.*)!

**Галимнәр һәм мөтәвәллиләрнең**
**дини мәдрәсә турысында җыелышлары**

11 июль якшәмбе көн сәгать 4 тә Казанның барча имамнары һәм һәр мәхәлләдән икешәр вәкил җыелдылар. 4 ярым сәгатьтә (16:30 – *А.Г.*) мин дә кердем, мәҗлесне тәбрик итеп, ачтым. Аллаһны мактау һәм салават (Мөхәммәд пәйгамбәр өчен дога – А.Г.) белән керешү нотыгын башлап, дүрт-биш маддәгә катнашып, хәзер Казанда, иң азы, бер җирдә дини мәдрәсә торгызуның тиешлеген сөйләдем. Иван Грозный һәм варисларының динебезгә һөҗүмен, мәчет һәм мәдрәсәләрне ваттыруын, дин өйрәтү юлларын кисәргә тырышуын, бу һөҗүм һәм хәрәкәтләрнең каршысында, Аллаһның ярдәмендә, Казан мөселманнарының диндә ныклыкларын, кандай авыр хәлләр булса да, йөкләп, диннәрен югалтмаска, укырга, укытырга тырышуларын, шул ныклык һәм мәхәббәт белән бу көнгәчә диннәрен һәм дин гыйлемнәрен саклап килүләрен, бу бабта иске карт имамнарның фидакярлекләрен, соңгыларның алар хакында рәхмәтле һәм ризалыкта булуларының тиешлеген халык аңлардай тел белән сөйләдем. Соңра шуны да куштым:

«Казан һәм Болгар кавемендә диндә ныклык һәм мәхәббәт бар. Куәтле иман һәм ышану бар, әлхәмдү лилләһ (Аллаһка мактау булсын – *А.Г.*)! Шунлыктан элек ирексезләнгән никадәр халык,

никадәр заманнар христиан дәфтәреңдә языла торып та, диннәрен һәм ислам игътикадларын саклап килделәр. 1905–1906 елларда аз гына дин хөррияте булу белән, ике йөз меңнән артык кеше исламнарын игълан иттеләр. Авылларындагы чиркәүләре янына мәчет торгызып, чиркәүне буш калдырдылар. Бер тарафтан мәктәп салып, рәхәтләнеп дин укырга, укытырга керештеләр. Менә бу халыклар безнең Казан төрекләренең һәм Болгар кавеменең дин эшендә ныклыкларыннан, гыйлем юлында тырышлыкларыннан туган зур фазыйләтләре. Әл-хәмдү лилләһи галә зәлик (Шуның өчен Аллаһка мактау – *А.Г.*)! Казан тарафлары белән бу көннәргәчә бөтен мәмләкәткә дини һәм гыйльми хезмәтләрне үтәп килде. Бөтен Русиягә гыйлем таратты, дин өйрәтте. Бу хәл галимнәр һәм башка халыкның дәрт һәм гайрәтләре белән булып килде. Инде бу соңгы елларда кайбер афәтләр сәбәпле, мәдрәсәләр ябылып, дәресләр тукталып тора. Бу хәл, иншалла, вакытлы бер хәл, вакытлы бер гыйбрәт булыр. Дин, иман, игътикад бу хәлдә калдыртмас, дин укуыбыз туктамас. Инде бу максат, бу хәерле гамәл өчен хәзер зур тырышлык кирәк. Рәсүлуллаһ саллаллаһү галәйһи һәм сәлләмнән безгә калган мирас – дин. Авырлыкларга очрасак та, бар көч һәм куәт белән аны саклау, маллы малы белән, фәкыйрь теле һәм көче белән ана ярдәм итү. Актык куәтебезгәчә без – Казан мөселманнары – дин һәм дин гыйлемен, иншалла, сакларбыз. Бер кеше дә безне диннән һәм дин гыйлеменнән аера алмас, һичбер котырту бу бабта безгә тәэсир итмәс, иншалла. Инде, туганнар, дәрес вакыты якынлашты. Бу елда дини бер дәресханәне әзерләп дини дәресләрне бердәмлек белән торгызырга кирәк. Бөтен мәхәлләләр бердәмлек белән хәрәкәт итеп, кайсы мәдрәсә хәзер җиңеллек белән аякка басарга яхшы, шуны төзәтеп, шәһәрдә булган имамнар һәм мөдәррисләр булдыра алган хәлфәләрне үзара билгеләп дәрес укытырга кирәк. Хәзер күп фәннәр хәҗәт түгел. Гарәп теле гыйлеме, Коръән, хәдис һәм фикыһ яхшы укытылса, җитә. Диния нәзарәте, дини мәдрәсәләрне торгызуны, имамнар әзерләүне бик мөһим вазыйфасы итеп күргәнлектән, бу изге хезмәтне сездән бик көтә. Миңа да бу эшне сезгә ирештерүне йөкләп җибәргән иде. Шунлыктан да мин сезгә ирештердем. Өмет итәм ки, шаять, сез бу бабта артыгызда булган мәхәллә халыклары белән киңәшләшеп, тырышырсыз, бу сүзләрне файдасыз итмәссез».

Соңра, икенчегә, «Ислах» җәмгыяте тарафыннан Шәһәр Шәрәф әфәнде, «Ислах»ның максат һәм теләген бәян итеп, барча

мәдрәсәләрнең реформасын, матди һәм мәгънәви якларына ярдәм итүен ният итеп корылган җәмгыять икәнен бәян итте. 1918 елда мөфтинең бу җәмгыятьне корып, әгъза һәм рәис билгеләп киткәнлеген, шул вакыттан акрынлап хезмәт итеп килгәнлеген һәм хәзер төрле китапханәләрдә дини китаплар сатуы тыелган булып, һәммә китапханәдән дини китаплар бу «Ислах» җәмгыятенә алынып, билгеләнгән бер кыйммәт белән сатылып, аннан бер микъдар процент мәдрәсәләр файдасына билгеләнгәнлеген сөйләде. Янә өч-дүрт адәм имам һәм башкалар, кайберләре гыйлемнең кадерен, кайберләре укуның кирәклеген, кайберләре алай һәм болай сөйләде. Соңра, мәҗлесне бик озайтмау тиеш күрелеп, минемчә, нинди хискә килделәр, шуны белү мөһим булганга, мөрәҗәгать итеп: «Ни әйтәсез, бу елда ук дини мәдрәсә торгызуга һәм шул бабта тырышырга вәгъдә бирәсезме?» – дидем. Мәҗлестә булган галимнәр һәм башкалар һәммәсе бер авыздан: «Бирәбез, тырышабыз», – диештеләр. Мин дә рәхмәт укыдым: «Сезнең ант бирү һәм вәгъдәгездән Диния нәзарәтен сөендерермен. Аллаһ мөбарәк кылсын, хәерле ниятегезгә ирештерсен!» – дидем дә һәммә кешедән «Фатиха» укуны сорап, барча халык «Фатиха» сүрәсен укып, мәҗлес тәмам булды.

Соңра «Ислах» җәмгыятенең кайбер эшләре өчен һәм мәдрәсәнең матди һәм мәгънәви хәлләрен күзәтер өчен, киләчәк якшәмбедә җыелырга булдылар, һәртөрле хезмәт өчен кешеләр сайларга булдылар. Мәҗлес күркәм рәвештә үтте. Икендегә бер сәгать кала таралдык, хәерле ният белән кайттык.

Бу теләккә, әлбәттә, быелдан калмыйча керешергә тиешле. Бер кечегрәк мәдрәсәне дәрес укытырлык итеп, төзекләндерелер. Имамнар, бердәмлек белән, кыска гына дәресләр расписаниесе буенча укытырлар. Фәннәр өчен Шураның мәктәпләре хәзергә җитәрлек. Бу мәдрәсә ялгыз дин укытыр өчен кирәк. Шунлыктан мин бу бабта бу дәресләрне җитәрлек күрәм: 1) биремнәре белән гарәп кагыйдәләре; 2) фикыһ; 3) пәйгамбәр тормыш юлы; 4) ислам тарихы; 5) Коръән тәҗвиде һәм тәрҗемәсе белән; 6) хәдис шәриф; 7) вәгазь; 8) матур язу; 9) инша. Вәс-сәләмү галә мән әтбәгал-һүдә (Туры юлда баручыга сәлам – *А.Г.*)!

Казанда, башка җирләрдәге кебек, көннән-көн әйбер күтәрелә, азык кими, кая китә – Аллаһ белер. Арыш оны ун-унбиш мең сумнарга җиткән, Казан артында 18 меңгә җиткән икән. Шәһәр идарәсе, өч дәрәҗәгә бүлеп, икмәк һәм башка нәрсәләр бирүдә. Карт

һәм зәгыйфь адәмнәргә бер кадак, башкаларга кимрәк бирә. Кадагын 85 тиеннән бирә икән. Бу байтак җиңел. Ихтыяри сәүдәләрдә кадагы өч-дүрт йөз сүм йөри.

## Шәһәр идарәсеннән алынган ашамлыкның хәләл булуы

Шәригать мәсьәләсе: шәһәр идарәсеннән алынган икмәкне начар күреп, ашамаган адәмнәр дә бар, талап алу юлы белән алынган, диләр. Башка нәрсәләре дә шулай. Һәркайсы шөбһәдән сакланучы адәмнәр бик яхшы итәләр. Саклык – яхшы эш, «Ник сакланасың?» – дигән сорау килми. Саклану – кылану гына булмаса, табигатендә һәм холкында шул саклык булса, бик хуп эш. Әгәр дә мондый гомуми бәла хәленә карап, фәтва өчен карасак, ашау юлсыз кебек күренми. Шулай ки, шәригатьтә бәя кую яхшы түгел. Рәсүлүллаһ саллаллаһү галәйһи вәсәлләм базар күтәрелгәндә, бәһа билгеләү, такса куюны тәкъдим итүчеләргә яратмыйча җавап биргән: «Бәя куючы – Аллаһ», – дигән. Ләкин халык шашып һәм адашып, бәһаләр артык китсә, халыкка зыянлы дәрәҗәгә ирешсә, бәя билгеләүнең дөреслегенә юл тапканнар, бу очракта дөрес күргәннәр. Рәсүлуллаһ саллаллаһү галәйһи вә сәлләмнең бәһа билгеләмәве вакытлы гына, чиктән тыш һәм арттырып җибәрү дәрәҗәсенә бармаган күтәрелүдә булган, дип күрәләр. Бәя билгеләү, әлбәттә, хөкүмәт тарафыннан була. Хөкүмәт, кайсы хөкүмәт булса да, халык файдасын кайгыртып куйган бәһасендә һәм шул бәһа белән сатмыйча, артык күп файда көтеп торган адәмнәрдән үзләреннән арткан кадәрлесен, көчләп һәм җәберләп алмаганда, гадел, залим түгел. Шунлыктан хөкүмәт кулыннан, низам булып, бәһа белән алган икмәк, низамлы бәһа белән алу һәм ашау дөрес булса кирәк. Гомуми бәла дә бу мәсьәләгә карашны бераз җиңеләйтә. Раббиг-фир вәр-хәм (Аллаһым, гафу ит һәм рәхмәт кыл – *А.Г.*)!

### Шәһәр Шәрәфкә имамлык өчен карар. Бозыклар гаугасы

12 июльдә дүшәмбе көн Шәһәр Шәрәф әфәнде өчен имамлык карарын төзеп, күрше-күләннән имза иттерү башланды. Кайбер шөбһәлерәк адәмнәр дә вәгазеннән тәэсирләнгән булганлыгын сөйләп, каршы төшүгә урын калмаганлыгын әйтеп, ризалык күрсәттеләр. Алай да гади халыкның хәлләре, наданлыкның әсәре бик авыр һәм кыен. Аеруча мәхәлләгә яңадан килгән яки безгә читтәнрәк карап йөргән элекке кешеләр бик гади халыкларча мөгамәлә сиздерделәр. Елына тик имамга бер-ике сум файдасы булган кемсәнәләрдән арага кысылып сөйләүчеләр, тиешсез хәрәкәттә булучылар бар, дип ишетелде.

Кайбер Сембер һәм Нижний вилаятләрендә кайбер имамнарның халык һәм куштаннарны сыйлап, шәраб эчертеп, тамга алганлыкларын сөйлиләр иде. Мужикның мулла алуны бик жиңел эш күреп: «Эт белән мулла алуга акча чыкмый», – дигән начар, бәлки, көфер мәкаль сөйләгәнлекләрен әйтәләр иде. Бар да наданлык, төбендә имамнарның үз кимчелекләре, яхшы укытмаулары, яхшы тәрбия бирмәүләре әсәреннән. Әслиһуллаһү үмүрүл-мүслимин вә рәхимә гыйбадәһүл-мүэминин (Аллаһ мөселманнар җитәкчеләрен төзеклəндерсен һәм мөэмин колларын рәхим кылсын – *А.Г.*)!

Бу төркемнең арттырып җибәрү һәм бозыклыклары җомга намазында ачык күренде дә. Шулай ки, җомгада 16 июльдә халыкка әйттем: «Ике атна элек: «Имам сайлауны үзегез карагыз, тикшерегез, кем яхшы булса – шуны билгеләгез. Хәзер мин беркемне билгеләмим. Киңәш сорасагыз, бирермен», – дигән идем. Ләкин бу сайлау һәм билгеләү сезнең көчегездән туар кебек күренми. Баштан ук минем мәчет-мәдрәсә һәм мәхәллә өчен ышанычлы булуыма, куәтемә карап, минем сезгә яхшы мөгамәләмемә һәм сезне ихтирам итеп, ягымлылык күрсәтеп әйткән сүземне аңлап, минем киңәшемә мөрәҗәгать [итү] һәм шунда туктау тиеш икәнлеккә төшенүегез ирешмәде. Дамелла кайткач, аның фикере белән эш күрербез, дигән сүзегез дә булган икән. Минем фикеремчә һәм карарымча, Шәһәр Шәрәф – иң туры килгән адәм. Гыйлеме, диндарлыгы, яхшы әхлагы һәм юлда уртада булуы мәйданда, утыз ел кадәр алдыгызда тора, егерме ел кадәр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә дәрес укыта, һәр хәле тәҗрибә ителгән. Шәкертлегенә һәм кияү булуына карап әйтмим, бәлки, кияү булуы

шул яхшы сыйфатларына төзелгән», – дигәч, яңа эшкә катыша, кеше арасына керә башлаган бер зат торып: «Арада Әхмәтҗан хәлфә дә бар. Байтак адәм аны таләп итә. Шунлыктан без тавышка куеп, кем тарафында күп, шуны сайларга тора идек», – диюендә: «Әхмәтҗан хәлфә – яхшы, галим һәм лаеклы. Аңа каршы әйтмим. Күпчелек халык теләсә, туры килә, күпчелеккә карап эш күрерсез», – дидем. Ләкин болай дисәләр дә, югарыда искә алынган затның тарафында бик аз адәм барлыгы, күп заманнан бирле аның яхшы әхлагы һәм кадеренә карамастан, халыктан югары сүзләре һәм хәрәкәтләре булып килгәнлектән, җирәнгеч булып килә иде. Нигездә, үзе дә бу көнгәчә рәсми имамлык таләп итүче түгел иде. Хәзер картлыгы бар, мәйданда аның кадере һәм абруен сакларлык, һәр вакытта дәрәҗәсен хөрмәт итәрлек, уртача юллы һәм яшьле Шәһәр Шәрәф булып торганда, аның имамлыкка теләге ихтимал тотылмый иде. Шулай да кайбер халыкның сүзенә күрә тәкъдим иттем. Минем морадымны ачык белә килгәнлектән һәм бу мәҗлестә ачык күрсәтүемнән, аның миңа кушылмавы, үзенең катышмавын һәм теләмәвен күрсәтүе ихтимал икән, ул дәшми торды.

Мәҗлестә бозыклар һәм әдәпсезләр тарафыннан байтак гауга күтәрелеп, мәчетне каравыл өе хөкеменә кертеп алдылар. Мин кайбер сүзләрен ишеттем, кайберләрен ишетмәдем. Алай да бүрекче Галәви исемле бер яңа байның байтак ахмак сүзләре ишетелде.

Соңра намаз укылып, эш башланмады. Бу мәсьәләдә иске мәхәллә агаларының яшьләргә юл куюлары, алардан кайбер сүзләр ишетеп: «Тәмсезләнербез», – дип дәшми торулары – урынсыз, үзләрен эштән һәм абруйдан чыгару. Егерме-утыз ел мәхәлләне карап, мәдрәсә чыгымнарын күтәреп килгән биш-ун адәм һаман да әдәпсез гайрәтлеләрнең каршыларыннан качмыйча, артык юл куймыйча, батырларча хәрәкәт итсәләр, күпчелек алар тарафында булачагы анык.

Бу рәвешләрдә түбән акыллы халыкка инкыйлабның байтак начар тәэсир булганлыгы күрелде. Ак мәчет мәхәлләсе биш-ун адәм аркасында, егерме-утыз елдан бу як бөтен шәһәргә тәэсир итеп килә, сүзләре һәм хәрәкәтләре белән үрнәк булып, гомуми милли чыгымнарда, матди иганәләре хисабынча да бөтен мәхәлләләргә алмаш һәм тигез булып, абруй саклап яшиләр иде. Инде бу адәмнәр байтак зыян күреп, рәсми ярдәм ителгән сәүдәләре туктап, яшерен мөгамәләләрдән чирканганнар. Башкалар, боларның хадимнәре, кайбер искечеләр, толчокчылар, бүрекчеләр һәртөрле мөгамәләгә

катышып, спекуляция, алдау, бозыклык кебекләрдән чирканмый, кыршылган бүрекләре, ертык бишмәтләре астында өретелеп, кесәләрен акча белән тутырганнар да үзләрен һәр бабта тәмам азатлыкка чыгарганнар. Бу рәвеш яхшы хәл күрсәтми, шомлы хәл. Элекке, хезмәт итеп килгән, халык файдасына авырлыклар йөкләгән картлар һәр вакытта хөрмәт ителергә, алар бәрабәрендә рәхмәтле булырга кирәк. Ислам һәм әдәп кагыйдәсе шул. Вә лә йәзләмүнә иллә әнфүсәһүм вә мә йәшгурун (Алар үзләренә генә зыян салалар, ләкин шуны белмиләр). Мин вазыйфамны үтәдем. Шәһәрдә, хәтта Русиядә галимнәрнең күпчелеге белән яхшы һәм хаклы адәмне күрсәттем. Оешса (иншалла, оешырлар), бик яхшы. Булмаса, гаеп һәм җаваплылык үзләрендә. Хисаплары Аллаһ Тәгалә янында булыр.

Мондый хәлләр, миңа авыр, бер дә ихтимал тотылмаган рәвеш булса да, йөкләнелә, төзелә, дини һәм әхлакый вазыйфам. Мәхәлләгә яңа килгән адәмнәр тәрбия һәм укытуда аз булганнар, хезмәт һәм хөрмәт тәкъдир итү, кеше таныр дәрәҗәгә ирешмәгәннәр. Болардан мондый хәл гаҗәп түгел. Мужикның үзен күрсәтә торган, белер-белмәс исемен яза яки сәнәк тамгасын сала торган вакыты. Дөньяда беренче дәрәҗәдә яшерен булган фиргавенлеген мәйданга чыгара торган вакыты – мулла сайлау вакыты. Фәкать бер-ике әдәпсез сәбәпле мәхәлләгә яманат булды. Фәллаһү йәхкәмү бәйнәнә вә һүә хайруль-хәкимин (Аллаһ безнең арада булган хәлләрдә хөкем чыгара һәм Ул – хакимнәрнең Иң хәерлесе – *А.Г.*)!

## Акылсыз кыяфәтендәге зиһенле бер наданның киңәше

Бу җомга алдында дусларыбыздан бер карт кайбер яхшылык кылу бабында мөрәҗәгать итте, арабызда бераз сөйләшү булды. Әйтә: «Картайдым, дөньядан күчәр вакытым якынлашты. Дөньядан күчүем кәфенләү һәм күмәргә әзерләү, бидгать һәм хорафаттан саф булып, ахыр хәлем сөннәткә муафыйк рәвеш белән тәмам булса икән. Соңгы эшләремдә бидгать-фәлән катышмаса икән. Бу ахырымны күзәтергә сез дә һәм мулла Кәшшаф та, Шәһәр дә булмыйсыз, кемгә әйтергә белмим. Мәхәллә имамына һич дошманлыгым юк. Ләкин ни хәл итим ки, динне ихтирам итми: Коръән укый белми, намазны игътибарсыз укый. Намазында имин

булмаган, җиңелгә санаган адәмнән ни өмет итәсең? Аллаһ янына тапшырылган сәгатьләрдә, динем ихтирам ителеп, пәйгамбәр сөннәтенә игътибар ителеп, тапшырылсам иде», – диебрәк телим һәм кайгырам. Фидия (мәет өчен сәдака – *А.Г.*) дәверләренә дә күңелем тулмый. Кемнәрне васыятемне гормышка ашыручы итәрмен икән? – дип, җитди кайгыларын бәян итте. «Хуз әл-фикъһә мин гайри фәкыйһ» («Фикыһны фәкыйһтән башка гына ал») [дигән] хикмәтле җөмләсе бу кеше хакында искә алынса, лаек. Бер дәрәҗәдә юаттым һәм тынычландырдым: «Шаять, имамың элекке имам-остазыннан күргән рәвеш белән мөгамәлә итәр, күп хорафат катыштырмас, сөннәтне игътибарсыз калдырмас вә фәлән», – дидем.

Бу карт шул сөйләшүебездә әйтә: «Илле яшьләрем чагымда дөньядан киткән булсам, бәлки, гөнаһ азрак булган булыр иде. Ул вакытларда аны-моны белми идем. Китап укымый, муллалар ни әйтсә, ышанып йөри идем, тикшерүем юк иде. Инде бик укыйм. Төрле китаплар һәм журналлар укып, байтак фикер алдым, усалландым, һәркемгә ышанмас булдым. Күп мулланы сайлыйм, гөнаһым күбәя торгандыр, дип тә куркам.

Бу җөмләләре җитдиме, кыланумы – ачык белмәдем, ләкин игътибарга лаек сүзләр. Янә әйтә: «Ризаэтдин хәзрәтнең «Җәвамигыль-кәлим» китабы шәрехен укыйм. Бер адәм: «Менә бу китапны укып кара», – дип биргән иде. Бик күп гыйлем бар икән. Икешәр-өчәр сәгать тоташ укып утырам. Башта «әгузе-бисмилла» әйтеп: «Я, Рабби, бу китаптан файда алуны насыйп ит һәм моны язган кешегә хәерле хәлләр бир», – дип, һәрвакыт дога әйтәм. Соңра укый башлыйм.

Бу адәм гади халыктан булса да, игътибарлы булганлыктан, картайган көнендә дини һәм әдәби журналлар укып һәм җыентыклар күреп, байтак мәгълүматлы булып киткән. Башында, яшь көнендә шәех Мәрҗани янында аралашуы булганлыктан, уяну, гыйбрәтләнү нигезен аннан алган. Димәшкъ, Шамда мулла Катимдә очрашканда, җамигъ өммәвидә (өммәвиләр нәселенең мәчетендә – *А.Г.*) җомгадан соң шафигыйларның (Шәфигый мәзһәбе тарафдарлары – *А.Г.*) җәмәгать белән өйлә намазын укыгач, көчле каршы төшүен миңа сөйләгән иде. Бу ничек бер вакытта ике җәмәгать намазы, бу ничек шәригать һәм фәлән дип, үзе булдыра алуынча, шөбһәләр сөйләгән иде. Китап караргa керешүендә дә өметле хәле бар. Китапны һәм гыйлемне ихтирам белән башлавы, үзенә һәм

иясенә дога-хәер кылуы – күңелне үзенә тартучы хәер-бәрәкәтле бер эш. Әлбәттә, һәр кайсы хәерле эшкә керешелсә, башта, Аллаһка сыенып, исеме белән ярдәм, туры юл һәм бәрәкәт сорап керешү тиешле. Гыйльми китапка керешкәндә бигрәк кирәк. Шәех мөхәддис (хәдис белгече – *А.Г.*) Ибнел-Каййим әл-Җәүзия «Зад әл-мигади фи һүдә хайрил-гыйбәд»тә остазы Ибне Тәймия хәзрәт-ләренең гыйлемгә керешкәндә [шулай], гадәтенчә, укыр булган-лыгын сөйли, хәдис-шәрифләрдә бар, булган. Әлбәттә, бу бабта кайгырту тиешле.

## Казанда юстиция урынбасарын күрү. Кызыл муллаларның зарары булуы

17 июльдә шимбә көн татар җөмһүриятендә хокук вәкиләсе Фәсыйх кызы Әминә Мөхетдингә юлыктым. Бу ханым Уфада мохтарият составында әгъза булып хезмәт иткән иде. Хәзер искә алынган җөмһүрияттә юстиция җитәкчесенә ярдәм итүче булып билгеләнгән. Диния нәзарәтенә караган дүрт-биш төрле мәсьәләдә фикер алышу да булды.

1. Регистрация (халыкның яңа туган балаларын һәм вафат булучыларны, никях һәм талакны язып кую) муллалар дәфтәренә ышанып, волость дәфтәренә беркетелмәүне сөйләде. Бер волостьта кышта бары илле кадәр туган бала булганын сөйләде. Әйттем: «Бу эшне җиңеләйтү кирәк. Волостьлар авыллардан ерак, ат азайды. Мәетләрне барып әйтеп кайтканчы күп вакыт үтә, искерә башлый. Бу эшне һәр авылның үзендә эшләү кирәк. Гамәлгә куеп бетерә алмаса да, Уфа ревкомы шулай карар чыгарды: авылда мулланың үзенә бу хезмәте тапшыру мөмкин булмаса, авыл шурасында эшләнер. Икенче юл: муллалардан атналык рәсми хисап ала барып, канәгать [итү] мөмкин булыр. Шурага да, халыкка да бу рәвеш җиңелрәк булыр. Муллалар бу хезмәтне үтәрләр. Айлык ведомостьны элекке заманнарда да бирәләр иде. Бу атналык ведомость булыр». Моңарга каршы: «Кызыл муллаларыбызга да тапшыру мөмкин булыр», – диде.

2. Сүз кызыл муллаларга күчеп, муллаларны кызыл һәм акка аеруның файдасыз бер эш икәнен әйттем: «Рәсми рәвештә кызыл мулла һәм фәлән мулла ясау халык арасында һәм муллалар арасында аерма салу гына була. Бер төркемне тартып, икенчесен

төртү, берәвен якын, икенчесен каршы булырга әзерләү була. Һәркайсы муллага ышанып эш кушсагыз, һәркайсы хезмәтегезне үтәр. Акрынлап бар да шулай кызарырлар. Безнең халыкның мулласы һәм башкасы кызыл канлы. Үзегез төрле бүлүләр белән бозмасагыз, халык оешыр, яхшы булыр», – дидем. Гаҗәпләнебрәк тыңлап торды. Хәзер гаҗәпләнсә дә, шаять, уйланыр. Бу рәвеш Казанда Баембит тарафыннан чыгарылып, шундый җәмәгать тәшкил итү максатында булса да, күп уңыш казана алмаган икән. Сарапул тарафында Шакирҗан, аңа ияргән Г. Буби һәм иярүчеләре кызыл булып танылсалар да, халык тарафыннан артык мәхәббәт казанганнарын сөйләмиләр. Мондый рәсми рәвешләр чыгарудан башка акрынлап катышсалар, муллаларга мөлаемлык күрсәтеп, мөгамәлә итсәләр, иң җиңел рәвеш белән үзләренә җәлеп итәрләр иде.

3. Дини мәдрәсә һәм мәктәп маддәләрен сөйләдем: «Мөселманнар өчен дини тәрбия мәҗбүри. Алар бу рәвешле тәрбиядән һич аерыла алмаслар һәм аерылырга риза булмаслар. Шунлыктан аларның мәктәпләре, уку йортлары үз кулларында булырга тиеш».

Бу шимбә көн 17 июль ревкомда сәркятиблек вазыйфасын үтәүче, Пәлдәнгедә мөгаллимлек иткән хаҗи Хәйрулла Хафизның улы Шамил иптәшкә хатыным белән Мәскәүгә барыр өчен пропуск алып җибәрүе өчен язу җибәрдем. Яхшы кабул итеп, бланкалары әзер булмаганлыктан, якшәмбе көн тәмамлап җибәрде. Уфада пропуск бюросы: «Духовныйларга бирмибез», – дигәч, Мәгариф идарәсе бирү юлында хәрәкәт итсә дә, соңыннан милли коммунистлар идарәсендә каралып, рәисләре Хәсән Сәйфелмөлеков: «Йөрмәсен, китапханәсе булса, үзеннән башка да алыныр, тапшырылыр», – дип катгый каршы торганлыктан, өмет киселеп торганда, Казаннан чакырып, кайтуның тиешлеген бәян итеп, берьюлы өч телеграмма килеп, боларны кушып, особый отделдан сорагач, бюрога бирер өчен әмер язганнан соң гына алырга муафыйк булган иде. Татар җөмһүриятендә бу кадәрлесе җиңел булды. Вәл-хәмдү лилләһи галә зәлик (Шуның өчен Аллаһка мактау – *А.Г.*)! Бәлки, Шамил Госмановның да кешелеклелеге булгандыр.

## Казан имамнары белән ял итәргә чыгу. Имамнарның теләкләре

Дүшәмбе көн 19 июльдә Казанның имамнары һәм мөәзиннәре күл башына һава сулар өчен чыгуны карар биреп, мине дә чакырганлыктан, бүген сәфәрдән туктап, сахрага чыгуны ихтыяр иттем. Азрак кәефсезлегем дә бар иде. Ашказаны хасталыгы – эч китү – белән борчылып, сәфәр итәрлек түгел идем. Үзләре иртәрәк көймәләрдә барды. Мин галимнәргә яхшы рәвештә аралашучы, дәртле һәм әхлаклы сабынчы Ибраһим бине Исхак бине Йосыф Апанай белән анда барып, һава да саф, кояшлы булганлыктан, яхшы ял иттем һәм уртача кәефләндем. Өйлә һәм икенде намазларын анда үтәп, янә атта кайттым. Кайбер мөһим мәсьәләләрдән азрак сөйләшүләр һәм киңәшләшүләр булып үтте. Имамнарның һәм гомуми галимнәрнең үзләрен төзәтү, күңелләрен сафлап, әхлакларын тәрбияләп, халыкларга яхшы үрнәк булып, иң азы, атнага бер мәртәбә гомуми вәгазьнең тиешлеге, мәхәлләнең үзендә балаларга дини дәрес укыту, имам һәм мөәзин бу турыда үзләре керешү, өлгермәсәләр, булышчы хәлфәләр алу тиешлеге әйтелде. Бу бабта тырышлыклары васыять ителде. Мәскәүдә, мөмкин булса, руханиларның гаскәри хезмәттән азат ителүләре, мәктәп һәм мәдрәсәләрнең дә азат ителеп, хәлфәнең үз ихтыярларына тапшырылулары, ризыклар бүлү бабында руханилык сәбәп, ташлама булмавын сорау кебек кайбер муллалар тарафыннан тәкъдим ителде.

Бу соңгы маддә берникадәр өлешчә һәм кече булса да, картларга беренче я икенче дәрәҗәдә ризык бирелү рөхсәт була торып, шулай ук карт имамга тик өченче дәрәҗәдән бирелү – байтак гаделсезлек, «динне хөкүмәттән аердык, диннең файдасына да, зарарына да бер эш кылмыйбыз», – дигән Шура кагыйдәсенә каршы бер хәрәкәт. Бу – бәлки, түбән даирәләрнең генә һичбер законга буйсынмый үзенчә хөкем итүедер. Мәскәүдә сөйләрлек мәсьәлә булмаса да, мәхәллә идарәләренә дучар булучылар үзләре мөрәҗәгать итәргә тиешле. Казанда эшчеләрнең эш ташлаулары булгалый башлаган. 25 июльдә Барудиядә һәм башка мәхәлләләрдә: «Икмәк бирелсен, сугыш бетсен, гаскәр алу тукталсын», – [дигән рәвештә], тавышларын күтәргәннәр, дип ишетелде. Олыларга икмәк бирүне вакытлы дип туктатканнар икән, он таба алмаганнар булса кирәк. Халык бик аптырауда, кулында саклыгы булмаган адәмнәр

ач калганнар. Аллаһүммәх-фәзнә вә лә түъәхыйзнә (Аллаһым, безне сакла һәм газаплама – *А.Г.*)!

## Казан мөхтәсибенә бирелгән ярым рәсми кәгазь

21 июльдә Казан мөхтәсибенә ярым рәсми кәгазь җибәрдем: 1) Казанда сөйләшенеп, карар бирелгән дини мәдрәсә торгызуны кайгыртып, күзәтеп, бер урында торуында үз теләге белән тырышу; 2) бу июль ахырынача дәфтәргә караган керемнәрне туплап, миңа тапшыру; 3) мәхәллә имамнарының дини мәктәп торгызуга керешеп укытуы, өлгермәсәләр, булышучы алып, тырышуы; 4) Казанда бер имамнар курсы ачу; 5) атнага бер мәртәбә һәр имамның дини һәм әхлакый вәгазь сөйләве бабларын да искәртеп яздым. Съездга әзерлектә ашыгуның тиешлеген дә куштым.

## Имам сайлауда бозыклар җыелышы

Сишәмбе, чәршәмбе көннәрдә Ак мәчет мәхәлләсендә имам сайлау турысында егерме-утыз кадәр мәхәллә адәмнәренең сөйләшүләре булып, бозыклар тавыш күбрәк чыгарып, төрле ихтималлар сөйләгәннәр. Бу төркемнең асыл фикере: янә кадим һәм җәдид низагын күтәреп, ысуле җәдидтән (җәдидчелектән – *А.Г.*) большевик туды, Галимҗан мулла ысуле җәдидне чыгарды, шунлыктан инде кадим тарафлы имам сайларга кирәк икән.

Бер-ике кәләпүшче мәхлукларның сүзләре, тавышлары, зур әдәпсезлекләре күп булганлыктнан, башкалар, рухсызланып, боларга юл куеп, эшне кичектерүгә сәбәп булганнар. Бу төркем [фикеренчә], Оренбург мулласы Нигъмәтулла, Мәләкәс мулласы Гатаулла, хәтта Күлбаштан Гыйниятулла хаҗи, һинди Минһаҗ Кадермәт кебекләрне чакыруны әйткәннәр. Эшне сузулары, бәлки, алардан хәбәр алу өчендер.

Боларның бу хәрәкәтләреннән күренә ки, тәрбиясез, әхлаксыз адәмнәрнең кулларына идарә бирү, ихтыяр салу бозыклыкка гына сәбәп була. Болар бик аз вакытта муафыйк булалар. Әгәр дә арада гыйлемле адәм булса, бердәм аңарга иярсәләр, дөреслеккә ирешәләр. Булмаса, аерым һәм хата фикер белән зарарга очрыйлар. Халыкның яхшы тәрбиясе, укыту һәм гыйлемнең гомумиләшүе

шарты белән генә халыкның хөкүмәтен дөрес күрүнең сәбәбе дә – бу. Чын тәрбия һәм укыту күргән халык кына үзләренә яхшы идарә һәм яхшы рәис сайларга муафыйк булып, үз эшләрен яхшы юлга куя алалар. Булмаса, зарардан башка нәрсә тумый. Безнең мәхәлләләр, гомум вилаят һәм мәмләкәтләрнең тәрбияләре тулы түгел, аңлылыклары зәгыйфь, үз эшләрен үзләре идарә итәр дәрәҗәгә ирешмәгәннәр, файда һәм зарарын аерыр хәлгә килмәгәннәр. Шунлыктан һәр бабта хаталары беленеп тора, алдан күрә алмаулары күренеп тора. Аллаһ үзе бәндәләренә мәрхәмәт итсен!

Мәхәллә мәсьәләсендә иң яхшысы бу иде: электән бирле мәхәллә файдаларын күреп, мәдрәсә һәм мәчет хәҗәтләрен үтәп килгән картлар, хәзерге шәригать каршында дөрес булмаган юллар белән булган кәсепләрдән туктаган булсалар да, бу эшне үз кулларыннан ычкындырмаска, кыска фикерле, аз уйлап эш итүче адәмнәрнең ихтыярларына салмыйча һәм аларның тавышларына игътибар итмичә, үзләре белгән рәвеш белән эшне алып барырга тиеш иде; акрынлап барып чыгар иде. Ләкин бу картлар ничектер рухсызланганнар, гайрәт һәм дәртләре кайткан. Сәүдәләре туктау, аз-маз бала-каза күрү белән бик изелеп киткәннәр һәм сүнгәннәр. Бу рәвеш, шәригать һәм акыл буенча, күркәм түгел. Дөньяви бәла-казага бирелмәү, аның сәбәпле генә рухны төшермәү, гайрәтне сүндермәү тиешле. Бу эшләр – акчага артык әһәмият бирүдән туган афәт, һәр нәрнәрсәгә тиешенчә генә әһәмият бирү тиешле. Вак-төяк нәрсәләргә рухны бәйләмәү, бәхетне аларда күрмәү тиешле. Югыйсә, бәндә гомере буенча куркудан котыла алмас, җан тынычлыгын, гыйбадәт ләззәтләрен югалтыр.

## Китапханә турында Һади Максуди белән сөйләшү

Бу көндә Һади әфәнде Максуди белән китапханәбез турысында сөйләшүебез булды. Шундый ки: Казанда коммунистлар арасында бер гыйльми комиссия төзелгән. Алар атаклырак китапханәләрне бер җиргә туплап, бер зур китапханә ясарга булганнар. Һади әфәнде, лаеклы була торып, искә алынган комиссиягә сайланмаса да, электән бирле шәһәрнең ислам китапханәсенең мөдире булганлыктан, китапханәне төзү һәм идарә итүдә аңа мөрәҗәгать итәчәкләренә өмет ителгәнгә күрә, аның карамагына тапшыра-

чаклар икән. Шунлыктан югарыда телгә алынган фәкыйрьгә юлыгып: «Китапханәгез хакында ни фикердә син? Әлеге комиссия сүз кузгатса, ни әйтим?» – дип сорагач, шул җавапны бирдем: «Китапханә мәсьәләсендә ике нәрсә игътибарга алынган һәм таләбем: 1) китапларым һәркайсы сакланган булсын, югалган булмасын; 2) бөтен мөселманнар алардан файдалансын. Бу теләкләрем хасил булырлык булганда, бу комиссиягә тапшыруны начар күрмим». Элекке ислам китапхасе минем һәм Ак мәчет каршысындагы Кәримовларның түбән өйләрендә урнашкан булганлыктан, өске каты да китапханә өчен муафыйк булганлыктан, тәмам алуны яхшы күргәнлегемне, тартып алып, китапханә кылуда хәербәрәкәт күрмәгәнлегемне сөйләгәч, Һади әфәнде: «Элекке китапханә өчен бу вакытка кадәр түләү биреп киләм. Бәлки, ихтимал, моннан соң да тәмамлануына түләү бирелер һәм фәлән», – диде.

Бу шимбә өчен Мөхәммәтҗан хаҗи Кәримовка: «Шул чаттагы йортыгызны нәшрият һәм магазиныгыздан аерып, милләткә багышласагыз, китапханә булу өчен, Аллаһ ризасы өчен вакыф итсәгез булмасмы?» – дип, элек Шәһәр әфәнде Шәрәф аркылы, соңра телдән мөрәҗәгать итсәм дә, өметле сүз ала алмаган идем. Инде бу гыйльми комиссия коммунизм ысулы белән алу ихтимallары бар; шунда Хәсән Акчурин китапханәсе кебек атаклы китапханәләрне дә туплап урнаштырулары мөмкин икән.

Китапларым өчен үз бинам, атам мәрхүмнеке яхшы һәм имин булса да, кечкенә булганлыктан, анда рәсми һәм гомуми китапханә кылып, ачып булмый. Чыгымнары өчен дә җитәрлек көч юк. Хөкүмәтнең карашына да карамый хәл юк; төрле җәһәттән булган зарурлык бу рәвешле үз өстемә алырга юл күрсәтеп тора. Бик иске язма, тарихи, кадерле нөсхәләр өчен Кәримовлар йорты бик ышанычлы булмаганлыктан, аларны үз бинабызда калдыру, кайбер мәсьәләләр хакында да сөйләшенде. Ихтимал, шул эшкә муафыйк булырбыз. Аллаһ Тәгалә ярдәме белән.

## Мәркәздәге төрле милләтләр идарәсенең вәкиле Диманштейн белән күрешү һәм сөйләшү

Җомга көн 23 июльдә 9 ярым (9:30 – *А.Г.*) сәгатьтә мәркәздә төрле милләтләр министрлыгында Сталин урынбасары булып торучы Диманштейн иптәш белән Казанда җөмһүрият әгъзасының

уртак йортларында юлыктым. Бу кеше белән Мәскәүгә барып та юлыгу уйланган иде. Монда булуын ганимәт [икәнен] белеп бардым. Сәгать ярым кадәр сөйләшүебездә бу сүзләр үтте:

Эчке Русия һәм Сибириядә җиде мең кадәр мәхәллә, 12 мең кадәр имам һәм мөәзиннән гыйбарәт [булган] руханиларның дини эшләрен карап торучы Диния нәзарәтенең рәисе һәм мөфтие икәнемне һәм күп заманнардан бирле хөррият юлында хезмәтләрем һәм кайбер вакыйгаларым булганын кыскача итеп аңлатканнан соң әйттем:

«Диния нәзарәте, үз вөҗданы буенча да, 1918 елда Сталин иптәшнең: «Милли идарәне япкан вакытта, сәясәттән битараф тору шарты белән, Диния нәзарәте калып торыр», – дигән телеграммасы буенча да, битарафлыкны саклап һәм руханиларны да битараф сакларга тырышып дәвам итүдә. Битараф булган хәлдә дә хөкүмәт файдасына байтак хезмәтләр итүдә. Ләкин хөкүмәт тарафыннан кайбер кысынкылыклар күрелү Нәзарәтне һәм халыкны бераз куркуга төшерә. «Дин һәм хөкүмәт аерым» [дигән] кагыйдәгә күрә дә, дини эшләргә һәм дини оешмаларга тыкшыну булмаска тиеш иде», – дигәч, Диманштейн: «Нинди маддәләрдә кысу, фәлән бар? Мисалы?» – диде.

1. Әйттем: «Менә Диния Нәзарәтенең бинасын музей итеп игълан иттеләр дә, акрынлап алырга да керештеләр. Мөселманнарның тик үз суммаларыннан төзелгән, бер дини оешма дип танылган Нәзарәт бинасының музей булуы мөселманнарның хисләрен рәнҗетә».

Әйтте: «Мин элек тә бинасына һәм үзенә тимәскә әйтеп, Милли эшләр комиссариаты исеменнән телеграмма биргән идем. Янә миңа бу турыда бер гариза бар. Мин бу сәфәремдә Уфада да булачакмын, шунда карармын».

2. Янә әйттем: «Диния нәзарәтендә хезмәт итүче казыйлар һәм башка зур хадимнәрнең имамнар кебек гаскәри хезмәтләрдән һәм башкалардан азат ителүләре мөселманнарның таләпләре. Бу турыда мин Мәркәзгә гаризалар тәкъдим иткән идем. Бер дә җавап ала алмадым».

Әйтте: «Почта яхшы йөрми. Янә гариза бирсәгез, Мәркәзгә җибәрермен. Христиан руханиларын гафу итмәгәнебез хәлдә, гаскәри комиссариатка мөрәҗәгать итеп, мөселман руханиларын гафу иттерербез, бу турыда янә Милли эшләр комиссариатына

мөрәҗәгать ителсә, Шәрык коммунистлары Мәркәз бюросы белән сөйләшүдән соң хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итәрбез», – диде.

3. Янә әйттем: «Мөселман халкы фәкать дини тәрбия буенча үзләрен яхшы саклап киләләр. Шунлыктан аларның дини тәрбияләрен киметергә һәм югалтырга ярамый. Шунлыктан мөселманнарның дини мәктәп һәм мәдрәсәләре хөкүмәт тарафыннан тартып алынмаска һәм үзләренә кайтарылырга тиешле».

Әйтте: «Дин хөкүмәттән аерылган. Хөкүмәтнең сәясәте буенча, һичбер мәктәптә дин укытылмаска тиеш. Яшь балалар дини тәэсирдән азат тотылырга тиешле күрелә. Шунлыктан аларны мәктәпләрдә укыту бигрәк мөмкин күрелми. Бары хосусый укыту гына мөмкин булыр», – дип, бу турыда декретларыннан чыгу мөмкин түгеллекне катгый әйтте. Ләкин бу җавабы канәгать итәрлек булмады. Алай да бу кыска сөйләшүдән гыйбарәт булып, алда Мәркәзгә бару уйланганлыктан, артык сүз көрәштермичә икенче мәсьәләгә күчтем.

4. Янә әйттем: «Коммунист ораторлар халыкка булган хөтбәләрендә ислам диненә артык тыкшыналар. Үзләренең юнәлеш һәм юлларын бәян [итү] белән генә канәгать итмиләр. Мөселманнар диннәренә бик ихласлы, һәрнәрсәне фида итсәләр дә, диннәрен һичвакытта фида итмәячәк булганлыктан, мондый тыкшыну һәм һөҗүмнәрне күтәрә алмыйлар, бу һөҗүмнәр халык белән хөкүмәт арасын байтак ераклаштыралар. Уфа тарафларындагы кайбер уңайсызлыклар чыгуы да шундый тиешсез хәрәкәтләр белән мөнәсәбәтле булуы уйланыла.

Диманштейн әйтте: «Бу мәсьәлә партиягә карый, хакимият белән турыдан-туры бәйләнмәгән. Хакимият вәкиле булу сыйфаты белән бу турыда бер сүз дә әйтә алмыйм. Партия оешмалары белән аңлашырга кирәк булыр.

5. Сөйләшүне тәмамлау вакыты якынлашканлыктан, әйттем: «Кайбер Аурупа дәүләтләренең мөселманнарга, аеруча Төркиягә һөҗүмнәре һәм Төркияне тәмам бетерергә тырышулары Русия мөселманнарын бик кайгырта. Аларга ярдәм бирүне бик тиешле күрәләр. Әгәр Шура хөкүмәте бу турыда яхшы тырышса, Русия мөселманнарының карашларын җәлеп итәчәк һәм мәхәббәтләрен казаначак. Шура хөкүмәте мөселманнарның дини мәсьәләләрендә кысуда булмаса, байтак якынлашачаклар».

Мөселманнарның бу Татар җөмһүриятенә карашларын сораганда: «Карашлары яхшы. Байтак реформалар өмет итәләр. Җөм-

һүрият игълан итүеннән элек, шәһәр руханиларын җыеп, җөмһүриятнең файдасын сөйләдем. Халык өчен файдасы булачагын әйттем. Һәммә руханилар катнашып, халыкка ирештерделәр, һәр җирдән мәхәббәтләре һәм хәерле өметләре ишетелеп тора», – дидем.

Сүз ахырында шуны да әйттем: «Элек монархия заманында мөселманнар төрле җәфалар күрделәр, дин һәм башка эшләрдә зарар һәм мәшәкатьләр чиктеләр. Шунлыктан мөселманнар хөрриятне сөяләр. Шура җөмһүриятенә яхшы өмет белән карыйлар. Ләкин, әйткәнчә, дини эшләрендә элекке монархия кебек тарлыклар күрсәтмәвен көтәләр».

Соңра, очрашуына рәхмәт белдереп: «Уфада минем урынбасарларым очрашуыгыз өчен килсәләр, кабул итсәгез иде», – дидем, саубуллашып чыктым.

Диманштейнга юлыгудан алган тәэссирләрем: болар халык белән яхшы мөгамәлә кылырга тырышалар, халыкның теләгенә бөтенләй каршылык кылмаска телиләр, ләкин үзләренең юл декретларын бозмаска, «бүре тук, сарык та исән» [дигән] кагыйдәне йөртергә булалар. Ләкин бу эш юл булмый, тик үлгән сарык күп булып, шуның белән канәгать иткән бүре булса гына мөмкин. Һәркайсы хөкүмәт тә милләтнең рухсызлыгыннан, дәртсезлегеннән файдалануны максат итә, мөселманнарның йомшаклыгыннан, куркаклыгыннан файда күреп килә. Бу кеше үзе дә зирәк, сәяси яһүди. Хөкүмәт файдаларын бик хөрмәт итүчән булырга охшый.

Җомга көн бу Диманштейнга Нәзарәт бинасын саклау турысында бер гариза җибәрдем. Эчтәлеге шул: «Диния нәзарәте барча руханилары белән сәясәт бабында битарафлык саклап килә. Битарафлык сакласа да, Шура хөкүмәтенә файда китерүдән читтә тормый. Хөкүмәтнең Шәрык эшләре өчен Диния нәзарәтенең шул рәвешчә битараф булып, мөселманнарның дини эшләре белән мәшгуль булулары байтак файда итүе ихтимал. Шунлыктан Диния нәзарәтенең дәвам итүе һәм бинасының да барча элемтәләре белән үзләренә тапшырылуы, һич җәһәттән каршылык күрсәтмәве тиешле күренә».

Бу җомга көн 23 июльдә Мәскәүгә сәфәребез уйланылса да, ашыгыч поездны ялгыш аңлап хәбәр иткән булганлыктан, җомга көн фәкать өйләдән элек гади поезд булып, ул исә тәрбиясез, акрын йөрүче булганлыктан, шимбә көнгә калдык.

Шимбә көн Гыйльми комиссия әгъзаларыннан Габделгазиз бине Салих Гобәйдулла килеп, китапханә турысында хәерле хәрәкәттә булачагын, яхшы саклап, төзиячәкләрен сөйләде. Комиссиясенә Һади һәм Шәһәр әфәнделәрне сайлаганлыкларын белдерде. Шәһәр Шәрәфнең бертуганы Галимҗан да Гыйльми комиссия әгъзасыннан икән. Элекке китапханә бинабызны да аларга тапшырсак, кайбер кадерле, сирәк табыла торган китапларының шул бинада саклануы мөмкин икәнен бәян итте. Минемчә, бу эш кирәк иде. Китапларым мәсьәләсе, иншалла, хәерлек белән хәл ителер өметендә калдым.

Сәгать алтыда вокзалга чыгарга торганда, Төркия вәкиле Сабикъ ахун Гата бине Бәһаның Мәскәүдән җибәргән хатын алдым. Хатында күп башлыкларның Петроградка Интернационал конгресска киткәнлекләрен, Шәрык мәсьәләсендә Ленинның байтак уңлык белән хәрәкәт ниятендә булганлыгын, үзе 25 июльдә Казанда булачагын сөйләгән, минем дә Казанда аны көтүемне әйтеп сүзне бетергән.

## Казаннан Мәскәүгә сәфәр

Ләкин мин көтә алмыйча хатыным Гайшә бинте Сәетбаһадиргәрәй белән бергә юлга чыктым. Сәгать җиде булганда вокзалда булдык. Тик торучы бер солдат нәрсәләребезне караганнан соң: «Июльдә мәхәллә идарәсе тарафыннан махсус кайгыртулы урын бирү турысында вокзал комендантына булган тәкъдимне билет алып куячак хәммаль (носильщик) кайгырткан булса да, үземне сораганлыктан, үзем чират саклап юлыктым. Бер адәмнәрен җибәреп, делегатны вагонга бер хатыныбыз белән өчебезгә дә берәр ятарлык урын табып бирде. «Алдан хәбәр иткән булсаң, бер бүлмә әзерләгән булыр идем», – дип бер әдәплелек тә күрсәтте. Бу поездда булган яхшы вагон да ятаклы өченче класс вагоны икән. Гади почта поездларында вагоннар йөк һәм хайван вагоннары икән. Адәмнәр һәммәсе шунда утыралар икән. Әлхәмдү лилләһ (Аллаһка мактау), яхшы урнашып, озатырга килгән кайбер дуслар белән саубуллашып, мәчет сәгате белән сигез, хәзерге сәгать белән унда поезд «сәламәт булыгыз» [дигән] чакыруы белән урыныннан кузгалды, тиз хәрәкәтенә сөенде.

Бу сәфәр чыгымы: билет данәсе 410 сум. Хәммаль һәр кешедән берәр мең сум алды. Хатыным белән икебезгә барлыгы 2820 сум чыгым булды.

Поездның хәлләре, тәртип белән йөреше яхшы, урыннар бар, тамгалы иске кондукторлар булса да, тәртип саклаулары яхшы. Элекке ундүртенче еллардан элекке хәлне күрсәтерлек дәрәҗәгә килә язган. Бары нефть булмаганлыктан, утын алулары озаграк булу сәбәпле, 30 сәгатьтә Казаннан Мәскәүгә ирешә торган поезд 38 сәгатькә калган. Һаман сугыш вакыты була торып, бу кадәрле кичегү – бик аз кимчелек.

Барачак җирләремә: «Каршылагыз», – дип телеграмма бирүне начар күрсәм дә, асылда, бару хәбәремне белдерә идем. Бер адәмгә дә хәбәр бирми чыктым. Юлда очраган Әҗи егете Габдрахман бине Фатих Урманов фатир әзерләү өчен Сабир Шәмголовка хәбәр бирүне кирәк күргәнлектән, Зөя шәһәреннән бер телеграмма бирдек.

## Юлда укылган китаплар

Юлда вагонда имам Бохариның «Хайр әл-кәлям фи әл-кыйраәти хальфә әл-имам» дигән китабын укып чыктым. Бу китапта эчтән һәм тавыш белән укылучы намазларда имамга ияреп укучының [да] «Фатиха» сүрәсен укуының тиешлелеген бик яхшы хәдис дәлилләре белән бәян иткән. Һәрбер шәкерт, хак, инсафлы адәм өчен канәгатьләнерлек аңлатулар китергән. Намаз тавыш белән укылганда имамның тукталышларында «Фатиха» укуны тиешле күргән. Имамнан элек «Фатиха» сүрәсен тәмамлап, имам белән бергә аның «Фатиха»ны [укып] тәмамлаганда «Әмин»гә өлгерүне артыграк һәм сөннәткә муафыйграк күргән. Мин бу мәсьәләдә күптән канәгатьлелек хасил итеп, гамәл кыла идем. **Унбиш-егерме елдан бирле, имам артында булганда, «Фатиха»ны укып киләм**. Әлхәмдү лилләһ галә зәлик (Шуның өчен Аллаһка мактау – *А.Г.*)! Бу китапны уку белән мәсьәләгә күңелемнең урнашуы артты, ислам күркәмлегенә игътикад һәм иманым ныгыды. Бу китапта бу мәсьәләдән башка байтак файдалы нәрсәләр дәлилләре белән искә алынган. Сүз арасында, кайбер кешеләр гарәптән башка халыкларны бозыклык һәм адашу [ияләре] итә, дигән мәгънәдә кайбер хурлаулар бар. Кайберләр бу сүзләрне имам Әбү Хәнифәгә йөкләсә дә, Аллаһү Әгъләм (Аллаһ белүчерәк),

алай булмаса кирәк. Бәлки, имам Бохариның гасырдашларыннан Бохарада байтак кеше булгандыр. Имам Мөхәммәд шәкертләреннән Әбү Хәфс олы түгелме икән, дип уйлыйм. Бохари белән бу кеше арасында Бохарада кайбер вакыйгалар булган. Бохариның ул кемсәнәдән байтак шикаятьләре булган икән. Аллаһү әгъләм бис-саваб (Аллаһ белүчерәк).

Соңра имам Бохариның «Хайр әл-кәлям» янында басылган «Курат әл-гайнәйни фи рафг әл-йәдәйн» исемле китабын укыдым. Бу китапта рөкүгъ вакытында, рөкүгътан калыккан вакытта да ике кулны күтәрүнең сөннәт булуын, рәсүлуллаһ саллаллаһү галәйһи вә сәлләмнең шулай эшләвен, хөрмәтле сәхабәләрнең дә шулай эшләгәнлекләрен ачык риваятьләр белән исбат итә. Инкяр итүченең бидгатьче икәнен күрсәтә. Бу мәсьәлә – имам Әбү Хәнифә белән имам Әүзагый хәзрәтләренең Мәккәдә «Дарел-хаятыйн»да йолкышып бәхәсләшкән мәсьәләләре, «Һидая» шәрехләрендә искә алынган. Әбү Хәнифә иярченнәреннән Габдулла бине Мөбарәк хәзрәтләре дә бу сөннәт белән гамәл кылган. Хәтта Әбү Хәнифә белән намаз укыганда ике кулын күтәргәнлектән, Әбү Хәнифә намаздан соң: «Очасыңмы, дип уйлаган идем», – дигәч, [ул]: «Намазны башлаган вакытта очмадым ич», – дип сүздән туктаткан җавап биргәнлеген бу китапта язган. Мин күп еллардан бирле бу мәсьәләдә уйландым. Баш төшенүем [һижри] 1292 [милади 1875] елда иде. Әлхәмдү лилләһ (Аллаһка мактау), күп китаплар һәм тәрҗемәләр тикшереп, күп еллардан бирле күңелем карар тапты. **Егерме-егерме биш еллардан бирле, сөннәт икәненә ышанып, кайбер вакытларда гамәл кылам һәм дусларыма бәян итәм**. Әлхәмдү лилләһ галәл-ислам вә сүннә (Ислам һәм сөннәтне биргән өчен Аллаһка мактау – *А.Г.*)!

23 июль якшәмбе көн Сергач урынына ирештек. Вокзал алдына чыктым. Бер-ике мишәр очрап: «Абзый, син кем, кайда барасың», – дип сорый башладылар. Үзләренең Казан җөмһүриятенә керми калуларына борчылуларын бәян иттеләр. Сергач шәһәренә Печә авылы бик якын икәнен сөйләп торганнарында: «Әнә, Печә комиссары килә», – дип безнең Печәдән Гата әфәнде килде. Мәскәүдән кайтышында Пәдри белән күрешү һәм аны туена чакыру өчен авылына иңгән. Инде Казанга китәр өчен Мәскәү поездын көтеп тора икән. Бик яхшы булды. Хәлләр сораштык, безне Казанда көттереп, сөйләячәк сүзләрен сөйләде.

Сергач өязе мишәрләренең бик җыелган җире, халкы бик рухлы, һәммәсе кәсепле, тырыш халык. Мәскәү, Петроград, хәтта Финляндия шәһәрләрендә сәүдә итеп, зур байлыкка ия булганнары байтак бар. Бераз дини рухларын арттыру, мәктәп тәрбияләрен киңәйтү өчен минем Мәскәүдән кайтышта бер-ике көнгә шул авылларда булуымны теләп, туеннан соң үзе дә авылларына әйләнергә булганын сөйләде. Мин дә: «Әгәр мөмкин булса, берәр көнгә төшеп, имамнар һәм башкалар белән күрешеп узармын, иншалла», – дидем. Бераз сөйләшүебездән соң безнең поездның икенче звоногы чалынды. Тиздән өченче звонок булып, ашыгып саубуллашып вагоныбыздан иңде. Аллаһ иминлегендә, без дә юнәлдек. Югарыда искә алынган зат: «25 се Казанда булырмын,» – дисә дә, 26 сы кичкырын гына була алачак. Сәламәт юл йөреп, дүшәмбе көн 26 июль көндезге сәгать бердә Мәскәүгә ирештек. Нәрсәләремне үзара өч адәмгә бүлешеп, үз хезмәтен үзе үтәү заманы булганга, мөселманга бигрәк тә шулай тиеш булганга, күтәрешеп чыктык. Арбачылар аз, җиңел арба фаэтон – сигез мең сум, авыры – биш-алты мең чамалы, җиңел арба булса, ике арба хәҗәт булачак иде. Биш мең сумга эш арбасы алдык та өчебез дә төялеп, киттек. Трамвайлар йөрми, урамнарда әүвәлге заманга караганда кеше бик аз йөри. Зур урамнарда гына аз-маз трамвай күренә, исемен югалтмас өчен генә диярлек дәрәҗәдә икән. Нәрсәләребез белән элек 1918 елда үзем торган Пятническийда 55 номерлы Карамышевлар йортына юнәлдек. Заһид, Шамил дә анда булганлыктан, өй хуҗаларыннан Ибраһим Карамыш, Зыя бине Хәмид Фәйз өйдә булганлыктан, башка урыннарга караганда артыграк күренде. Юлда килүебездә Таһир Госманов очрап: «Чәй эчеп, бераз ял итеп чыгыгыз», – дип кыстаганлыктан, нәрсәләребезне иптәшебез Зиннәт белән Карамышлар йортына җибәреп, хатыным белән Таһир торагына кердек. Солтангалиев, Сәетгалиев белән таныш бер зат (Мөбин Сәлимов) очрап, мине алар белән таныштыруны йөкләде. Бераз дөньяның хәлләреннән хәбәр алдым. Бу сөйләшүебез бераз хәерле фал [булып] күренде. Намаз укып, Карамышлар өенә килсәк, Ибраһим һәм Зыя әфәнделәр безгә каршы барырга торалар икән. Очрашу итеп, өйдә Заһид әфәнде һәм башкалар белән күрешеп, яхшы хәлләреннән хәбәрдар булып, күңел тынычлыгы хасил иттек. Сәясәт хәлләренең исә хакыйкате һәм нечкәлекләре сәясәт әһеленә генә мәгълүм була торган хәл. Тик бөтен дөнья сәясәтләреннән тупланган интернационал оешмасы

Петроградта башланып, хәзер Мәскәүгә күчкән. Яхшы берләшүләре шатлыгы белән 27 июльдә сишәмбе көн зур бәйрәм ясыйлар икән, һәр җирдә ял бирелгән.

## Инглиз һәм Шура хөкүмәте арасында сәяси сөйләшү

Инглиз хөкүмәте тарафыннан бер атналык ультиматум бирелгән ки: «Польша белән сугышны туктатыгыз, ике тараф гаскәрләре фәлән җирдә чигенеп торсыннар, арагызда безнең аркылы солых сөйләшүе булыр. Врангель белән дә сугышны туктатып, аның гаскәре кырыемда карарлансын. Сезнең гаскәрегез фәлән урында булып, аның белән сөйләшерсез. Врангель карар һәм кабул [итү] хакларына ия булмасын!» Болар бик тиздән катгый җавап биргәннәр ки: «Безгә инде солых тәкъдим итәсез, поляклар безгә һөҗүм иткән вакытта кайда булдыгыз, ник солых димәдегез. Тиешле вакытында сездән башка да поляк белән солых кыла белербез. Врангель исә үзе һәм гаскәре коралларын ташлап, безгә тапшырылсын – тормышын тәэмин итәрбез, солых шунда булыр», – дип инглизнең борынына чиерткәннәр, бәлки, йөрәгенә кадаганнардыр.

Инглизләр бу арада шундый ультиматумнар белән мәшгуль була икән. Коры дары шартлатып, вак хөкүмәтләрне куркытырга өйрәнгән, шулай итә-итә икмәгенә май сөртергә, чәенә каймак салырга өйрәнгән.

Бу арада инглизләр хурлыклы солыхнамәгә имза куймый торган солтан һәм вәзирләренә: «Солыхнамәгә тиздән имза куймасагыз, тиз арада Измирдән һәм пайтәхеткә якын булган башка шәһәрләрдән гаскәрегезне таратмасагыз, Истамбулны бөтенләй үземә ия итеп игълан итәм, солтанны аннан чыгарам», – дип ультиматум җибәргән.

Мостафа Кәмаль гаскәренә каршы торырлык гаскәр торгызудан гаҗиз булган, Юнан һәм башкаларга ялыну хурлыгына төшкәч, бу рәвешле куркытулар белән сәясәт саклау, бозык морадына ирешү булган. Аллаһүммән-сур мән нәсарад-динә вәхзүл мән хазәләд-дин вәсълих үмүраль-мүслиминә вәрхәм гыйбәдикәл-мүэминин (Аллаһым, ислам диненә ярдәм итүчеләрне ярдәмеңнән ташлама, исламга ярдәм итмәүчеләрне ярдәмеңнән мәхрүм ит!

Мөселманнарның эшләрен яхшырт һәм Үзеңнең колларыңны рәхим кыл – *А.Г.*)!

Бу заманда һәм элекке заманда ислам галәменең тамырына балта чабучы, һәртөрле мәкер һәм хәйлә белән мәмләкәтләрен үз идарәсенә алучы – инглиз дәүләте. Илле-алтмыш миллионлы һинд мөселманнарын, алар кадәр өч-дүрт өлеш һинд мәҗүсиләрен аз-маз гына гаскәре белән басып алып тора, исламның зур мәркәзләреннән, гыйлем учакларыннан булган Мисырны 82 нче елдан бирле аз гына гаскәре белән төрле мәкерләр белән алып, буйсындырып, аз-маз хөррият белән алдап-сулдап, бөтен учына кертеп, һәртөрле бозыклыкка иркенлек биреп, халыкны диннәреннән аерырга, дини һәм милли тормышларыннан ераклаштырырга тырышып, басып алып, диндар мөселманнарны елатып асрый. Инде гомуми Ауропа сугышына катышуына, Дарданилдә бер эш тә булдыра алмаганы, бәлки, бик күп гаскәрен югалтуына, байтак сугыш көймәләренең батырылуына ачуыннан, Төркияне алырга тырыша. Аеруча биш йөз елдан артык вакыттан бирле ислам дәүләте, биш йөз елга якын ислам хәлифәлеге булган Истамбул шәһәренә кереп, гаскәрен урнаштырып, ислам гаскәрләрен мыскыл итеп, мөселманнарның хәлифәләрен хурлап, үз ихтыярынча хәрәкәт итә. Моның өстенә, Төркияне тәмам тар-мар итәчәк, Хиҗаз һәм Йәмәнне йотачак, Күвәйт һәм Мәскатны Төркиядән аерачак, алдагы көндә үзенә майлы өлеш әзерләячәк һәм мөселман шәһәрләренә моңа охшашлы зарар һәм бозыклыклар китерәчәк солых килешүе имзасына солтанны көчләп мәҗбүр итүдә. Бу дәүләтнең каршысына чыккан, моның кулын золымын туктаткан бер дәүләт юк. Алманиянең җиңелүеннән соң бөтенләй чиктән үтте. Гаделлек, вөҗданны артка ташлады. Тик төрек каһарманнарыннан Мостафа Кәмаль паша Анатолиядә пәйда булып, сакланулы мөселманнардан гаскәр туплап, бер тарафтан Русия Шура дәүләте белән килешү төзеп, аңа каршы хәрәкәт итүдә һәм Төркия шәһәрләренең күбрәк алынуын коткаруда. Шура дәүләте ярдәм итсә, корал һәм динар белән дә куәт биреп торса, Мостафа Кәмаль паша гаскәрендә байтак өмет бар. Гәрчә инглиз моңа каршы Юнан һәм башкалар белән файдаланса да, төрекләрдә булган саклану һәм сугыш бабындагы дәртләре күләгәсендә өстен һәм җиңүче булулары өметле. Аллаһ ярдәм бирсә иде!

Инглизләрнең бу рәвешле золымнарына чыдамыйча, үз яклавында булган һинд мөселманнары каршы төшкәннәр, бу рәвешле хәрәкәтенә нәфрәт бәян иткәннәр.

Һинд мөселманнары искә алынган дәүләткә ияргән булган хәлдә, бу гайрәтне кылганнар, бу кадәр дәрт һәм батырлык күрсәткәннәр. Аңа сәясәтчә бер дә аңлатуы булмаган без Русиядә булган мөселманнардан бер хәрәкәт тә күренми тора. Алай да үткән җомга көн 23 июльдә мәҗлестә байтак имамнарга кисәттем. Бер җомгада бердәмлек белән халыкка мәсьәләне аңлатып, инглизләргә бу рәвешле ислам галәменә зарары, ислам хәлифәлеген куркыту өчен нәфрәт игълан итәргә тиешлекне белдерерсез һәм газеталарда нәшер итәрсез, дидем. Бердәмлек белән батырлык итә алырлармы, юкмы. Иншалла, бу мәсьәләне башлап үзем Мәскәү мәчетендә игълан итәрмен, дип өмет итеп торам. Аллаһ муафыйк хәерлелек бирсен![18]

## Өченче интернационал мөнәсәбәте белән демонстрация

27 июль сишәмбе көн Мәскәүдә бик сәяси бәйрәм. Сишәмбе көн иртәнге сәгать сигездән безнең торак урамы Пятническийда үз төбәгендәге эшче төркеме вак, эре хатын-ир җәмәгатьләре сыйныфлары белән, зур-зур язулы кызыл байрак күтәргән хәлдә, акрынлап җыела башладылар. Хатын-кыздан төзелгән гаскәр сыйныфы үзләреннән булган командачы хатын идарәсендә йөрүдә һәм җыелуда иделәр. Сәгать 10 булгач, музыка уйнап боларны акрынлап тәртип белән озаттылар. Бу төбәктә генә 10–15 мең кадәр кеше тупланган, күбрәге эшче төркеме булу белән 10 ярым (10:30 – *А.Г.*) сәгатьләрдә китеп беттеләр. 40–50 төбәктән шулай тупланып килеп, Красная площадька җыелачаклар, гаскәри демонстрация

[18] Чыгармагыл авыздан кылмас эшне,
Кылырмын димә кулдан килмәс эшне.
Авыздан чыкты сүз кайтармагыл каш,
Гәрчә китсә дә ул сүз өчен баш.
Кирәк ирмен дигәннең вәгъдәсе төз,
Әгәр төз булмаса, аннан өмет өз!
«Сөбател-гаҗизин».

булып, төрле нотыклар һәм хөтбәләр булып, халыкка рух биреләчәк, эшчеләрнең шатлыкларын арттырачаклар, коммунизмга күп хезмәт итәчәкләр. Ауропадан килгән социалистларга русия халкының социализмга карашларын күрсәтәчәкләр. Ләкин халыкның, хәтта эшчеләрнең күбесе көчләп чыгарылганнар, ихтыяр һәм теләк белән килгәннәр аз икән.

Бу бәйрәм өченче интернационал (милләтләр союзы) мөнәсәбәте белән ясалган.

## Бәйрәмнәр файдасы, гыйлемнән бигрәк гамәл кирәк

**Фасыл.** Мондый бәйрәмнәр, мондый күренешләр – һәр эштә дә кирәкле һәм файдалы эш. Ачык күз карашында бер уенчык, гомерне заяга уздыру кебек күренсә дә, акыл күзендә бик файдалы һәм мәгънәле эш. Исламдагы бәйрәмнәр хикмәтсез төзелмәгәннәр. Һәр бабтагы җыеннар, мәҗлесләр, сүзләр халыкның шатлыгын арттыра, рухын куәтли, шул юлда ныклык һәм дәвамлылык күнекмәсен тудыра. Үзгәртелгән мәктәпләрнең элек туган заманнарында имтихан мәҗлесләре, андагы нотыклар, андагы урыннар таратулар, андагы «афәрин» һәм «тәхсиннамәләр»гә кадәр тәэсир итә иде. Балаларның, хәтта ата-аналарның зур әһәмиятләрен җәлеп итә, алда зур-зур әзерләүләр күрергә мәҗбүр итә, ел буена дәресләрнең күркәм рәвештә барышына тәэсир итә иде. Шул юлда саклау һәм омтылу урнаштырып, яшь шәкертләрнең фикерен ача, телләрен шомарта, кием-салымнары бабында да караш һәм пакьлекләрен арттыра. Шундый җыеннар, милли бәйрәмнәр һәр вакытта файда бирә, мәсәлән, Мәүлид бәйрәмнәре, асылында дини булганнары да файдасыз булмый. Тик дини бәйрәм төзү – бәндә вазыйфасы түгел, бәлки, Диннең төзүчесе [Аллаһ] һәм пәйгамбәр тарафыннан гына куелырга тиеш булганга, дин исеменнән ясау бидгать булып китә. Бары милләт һәм миллилек исеменнән төзү кирәк. **Мәүлид бәйрәмен дин исеменнән ясауны да дөрес күргән галимнәр бар, ләкин минем [аны] милли бәйрәм дип карыйсым килә**. Аеруча бездә Русиядә милли һәм сәяси төс биребрәк ясалуы бидгатьтән саклану өчен артыграк күренә. Бәйрәмнәрне гади халыкка да милли диебрәк аңлату тиешле. **Гыйбадәт нияте белән дини рәвештә итсәләр, бидгать булуы ихтимал**. Әмма имтихан җыеннары һәм

башка төрле бәйрәмнәр һәм җыеннар да, аеруча авыл халкының сабан туе һәм атна саен төзелгән кабак, зур телү, убса һәм фәлән җыеннар кебекләр, әхлакны саклау шарты белән дәвам итүе яхшы. Миллилекне саклау өчен халыкка рух һәм шатлык бирү өчен файдалы эш. Халыкның бер-берсе белән танышуга бер юл. Бары аңлы имамнар һәм башка фикерле егетләр мондый җыеннарны бушка үткәрмичә, файдалы итеп үткәрергә, шул җыен сылтавы белән милли һәм дини файдаларны юнәтергә тырышырга кирәк. Бу милләтара оешма бәйрәменә карап, коммунистларның башка вакыттагы эшләре кебек, эшлекле халыкны эшкә өйрәтүләре, бала-чагага да укулары өстенә яшьтән эш өйрәтүләре, хәтта гаскәри тәртипкә төшендерүләре яхшы дип саналырга лаек хәрәкәтләреннән. Дөрес эшкә өйрәнмәгән, иркә табигатьле халык өчен утын кистерү кебек авыр хезмәтләр иттерүләр, бер адәмнең әйткәне кебек, арестант хезмәте булса да, һәр адәм бу хезмәтләрне үтәү күнекмәсенә хуҗа булу, башына төшәчәк һәртөрле эшне булдырырга сәләтле булу тиешле. Безгә дә бу хәлдән файдаланып, эшкә өйрәнергә, балаларны яшьтән үк үз эшләрен үзләре эшләргә өйрәтергә тиешле. Хәтта мәктәп һәм мәдрәсәләрдә гаскәри тәгълиматны һәм гимнастиканы эшләтү мөһим, сәламәтлеккә караган һәм фәлсәфи хәҗәт. Коры укыту белдерү белән эш тумый, һөнәр һәм камиллек белемдә түгел, белеп кылуда. Белемнең кирәклеге һәрвакытта да бары эшләү өчен генә. Кайбер мөхәррирләр, ислам – гыйльми дин, дип язалар һәм шул юллары белән гыйлемгә кызыктыралар, гамәл хәтерләреннән чыгып китә, бәлки, күз алларыннан да югала торгандыр. Дин һичкайсы да, кирәк ислам дине, кирәк башкасы булсын, бөтен мәгънәсе белән гыйльми булырга тиеш түгел. Бәлки, дин гамәли булырга тиеш. Ислам дине бигрәк тә шулай, бөтен дин гамәлдән гыйбарәт. Бары гамәл гыйлемсез мөмкин түгел, гыйлемсез гамәл – әрәм гамәл, шуның өчен гыйлем зарур. Әмма гамәлгә һәм гыйбадәткә өйрәнмәгән ялкау мөхәррирләрнең язулары һәм фикерләренең, асылда, дингә мөнәсәбәте юк. Сәхабәләр радыяллаһү ганһүм (Аллаһ алардан риза булсын – *А.Г.*) хәлләренә каралса, ачык күренә ки: аз гыйлем өйрәнгәннәр, шул гыйлемне гамәлгә керткәннәр дә, шул аз гыйлемнәре иманлы йөрәкләрендә үскән, «Нүрун йәкъзифүһүллаһү фи кальбил-мүэминин» («Мөэминнәрнең йөрәгенә Аллаһ нур салган» – *А.Г.*) [дигәнгә] туры килгән. Безнең замана халкы кебек, мәгълүмат туплау, иман һәм мәгърифәт саклавычы булган

йөрәкләрен хәерче капчыгы кебек юк-бар нәрсәләр белән тутырмыйча, гамәл һәм Аллаһка якынаю нуры белән тутырганнар. Аеруча, күп нәрсә белгән булып, акыллы баш булып, мәгълүмат сатучы булма, диннән ераклашырсың. Аз белсәң дә, белгәнең белән гамәл кыла бар, файдалана бар, аз булса да, Аллаһка якынлыгыңны арттыр. Шул вакытта гына булырсың чын галим, чын мөселман, ягъни иманлы мөселман. Дөньяви гыйлемнәр дә шулай ук: күп мәгълүмат белән хәерле нәтиҗә тумый. Эшкә яраклы, гамәлгә кертелгән мәгълүмат белән генә файдалану була. Аурупалыларның, аеруча немецларның соңгы кабул иткәннәре дә шулай. Рус мәктәпләре кебек теория мәктәбе кормыйлар. Бәлки, практикалар мәктәбе корып, шул практикаларны яхшы рәвештә төзер өчен күркәм һәм файдалы рәвештә тудырыр өчен, яхшы укыйлар.

Сүзнең кыскасы: гыйлем – кирәк дини, кирәк дөньяви, кирәк сәяси булсын – барчасы гамәл өчен генә таләп ителә. Гамәлгә алып бармаган гыйлем иясенә хәсрәт, үкенеч, [бу –] әрәм гыйлем.

Кыскасы, балаларны яшьтән үк гамәли [рәвештә] тәрбияләргә кирәк. Элек ата-ана гамәле тәрбияләргә тиеш. Эшкә ярамаган нәрсәне, эшкә кертелмәгән гыйлемне төшендермәскә кирәк. Икенче дәрәҗәдәге мәктәп укытуында шулай ук ни нәрсә өйрәтелсә дә, гамәли рәвештә өйрәтү кирәк. Шулай булганда гына чын укыту була. Бу рәвешле укыту мөмкин булмаганда, балаларны буш калдыру яхшырак. Надан калсын, өметле булыр, бозылмаган булыр. Укып белеп, гамәлгә илтифат итмәгән, үзен төзәтмәгән адәм – бозылган адәм.

Заманыбызда халыкның динилеге көннән-көн начарлана, зәгыйфьләнә бара. Моның сәбәбе нәрсә, диючеләр күп, дәвасын эзләүчеләр дә бар. Моның төп сәбәбе – гамәлсез гыйлем. Гыйлем алуында гамәлгә кертүне кирәксенмәү, гыйлем булып торсын, бер заман кирәк булыр да, файда күрермен, дип уку. Бу рәвеш ислам ысулына муафыйк түгел. Тәһарәт һәм намаз мәсьәләләрен укып, намаз укымый йөреп, мулла булгач, укырмын, шуның өчен мәсьәләләрен белеп кую кирәк, дигән надан шәкерт кебек гыйлем алу – зарарлы бер рәвеш. Балага яшьтән дин рухы бирү тиешле.

Большевиклар, Аурупаның бозык фикерле мөгаллимнәре балага динне аңлатмауны, балигълыкка ирешкәч, үзе ихтыяр итәр, фикерен тараталар. Шул юлны кулланма итеп тоталар. Безнең башкаларга ияргән мөгаллимнәребездә, шат педагогларыбызда да моңа якын фикерләр бар. Ләкин хатасыз булган фикер моның

каршысында, Аллаһның вәхие (иңдерүе – *А.Г.*) белән ныгытылган кешенең укытуы моның өстендә ки, рәсүлуллаһ саллаллаһү галәйһи вә сәлләм: «Балаларыгызга җиде яшендә намаз өйрәтегез, ун яшенә җиткәч, орып укытыгыз, урыннарын бер-берсеннән аерыгыз», – дигән. Бу өйрәтү – дөрес өйрәтү. Шөбһәсез, хак һәм дөрес булган тәрбия.

Балага яшьтән дин рухы бирелмәсә, дини һәм әхлакый кисәтүләр үтәлмәсә, башка рухны үзенә күнекмә иткәч, бозык һәм динсезлек фикерләрен үзенә ияләндергәч, алмаштыру бик читен, бәлки, булмый торган бер эш.

## Гыйсмәти белән сөйләшү

Сишәмбе көн төннең яртысында мәгариф әһелләреннән Габдулла әфәнде бине Төхфәтулла Гыйсмәти торагыбызга килеп, берәр сәгать сөйләшеп утырып китте. Бу адәм, асылда, Троицкидан мулла Мөхәммәд бине мулла Зариф шәкертләреннән, Коръәнне яттан белүче, укыган, туры фикерле егет. Университет студентларыннан икән, Шураның мәгариф хезмәтенә алынып, Петроградта торуда, хәзер юлы Шура белән муафыйк күренә. Шулай да динче, сакланучан адәм. Эстәрледә булачак рәсми җыелышка барышы икән. Башкортларның таркалуга очрауларын, андагы мөселман түрәләрнең үпкәләп, хөкүмәт акчаларын, хисап бирмичә, алып качуларын үкенеч белән сөйләде. Шәех Бәрәкәтулла, шәех Муса, шәех Габдерәшитләрнең барып йөрешләрен дә шикләнүгә сәбәп булды, дип сөйләде. (Чөнки Зәки Вәлидинең хезмәттән чыгарылуы, хөкүмәт әгъзаларының алмаштырылуы, Җөмһүриятнең хокукын азайтулар – бар да аларда миллилек хисе күбәеп, Шура юлына тугрылык белән хезмәт итмәү ихтималына корылган. Зәки әфәнде бу бабта байтак сакланып эш итә иде, шулай да сүз йөртүчеләрнең дошманлыгы белән азын күп итеп күрсәттеләрме – ни булды – бичара афәткә очрады).

Сүз Казан хәлләренә күчеп, Диния нәзарәтенең ислам мәркәзе булганлыктан, Казанга күчүен тиешле күргәнен, Уфа һәрвакыт татар белән башкорт арасында бер явыз аеручы кебек торганлыктан, Нәзарәт өчен яхшы булмаслар, дип фикерен бәян итте. Чыннан да, бу мәсьәлә шулай: Диния нәзарәте мөселманнарның бердәнбер югары дини мәхкәмәсе булгач, диннең мәркәзе һәм гыйлем шәһәре

булып танылган Казанда булуы бик табигый эш. Элек Екатерина казакъ һәм башкортларны аулау, җәлеп итү өчен (бу хезмәттә чын тугрылык һәм хөррият белән хадиме һәм ихласлы булган мөфти Мөхәммәдҗан Борындыкыйга бер икмәк булуын да карап булган) караңгы һәм кечкенә җирдә генә ачкан. Инде Романовларның андый планнары сүтелде, бетте. Мөселманнарга ихтыяр бирелде. Дин хөкүмәттән аерылып, хөррият игълан ителде. Мөселманнар үз теләүләре белән Казанга күчерәләр икән, хөкүмәт тарафыннан каршылык булмаска тиеш. Аеруча Казанда Татар җөмһүрияте игълан ителү, чын эшкә керешүләре бу хәлгә бигрәк тә туры килә. Халык күзендә дә җөмһүриятнең куәтләнүенә сәбәп булачак. 1917 елда Казанда галимнәр җәмгыятендә бу мәсьәлә вакытсыз булып күтәрелеп калса да, әзерлексез, киңәшләшүләрсез башланганлыктан, нәтиҗәсез калган иде. Хәзер Уфа тарафы мөселманнарына башкалар тарафыннан инкяр ителмәсә кирәк, Казанның әһәмиятенә күрә, күплек тарафыннан кабул ителсә кирәк.

Уфада булуы уйланган җыелыш мәсьәләсенә сүз күчеп, мәркәзнең каршы тормаудан гыйбарәт булган рөхсәтен, ләкин киләчәк әгъзаларга пропуск бирүдә җиңеллек итүне йөкләмәүләрен сөйләгәндә: «Мәҗлес булачагын газеталарда игълан ителсә, мәхәллә идарәләре рөхсәт итсәләр кирәк», – диде. Ләкин кайдагы газеталар игълан итәрләр, Уфада мәхкәмә эшләреннән бер нәрсә дә яздырып булмый, дини эшләргә катышмыйбыз, катыштырмыйбыз, дип кенә җавап бирәләр.

Бу җыелыш була калса, үземнең һәм казыйларның эштән азат ителүләре турында сорагач, эштән китүебезне яраклы эш итеп күрмәде. «Мөфтилек өчен халыкта диненә ышанырлык, күңел бagларлык, һәркемгә дини эшләрдә сыену урыны булырлык, аптыраганда юаныч бирерлек бер адәм кирәк. Мәйданда андый абруй казанган адәм юк. Сезнең ташлавыгыз һич дөрес түгел. Икенче: эшнең авырлыгыннан хөкүмәт белән дә мөгамәләнең кыенлыгыннан чыкмакчы буласыз, ул авырлыктан үзегезне коткарып башкасына йөкләтү янә кешелелектән түгел, дип яраклы сүзләр кушып, ныклык күрсәтте. Бер кат хисап биргәнегездән соң халык күпчелек белән теләсәләр, янә хезмәттә калуыгыз тиешле», – диде. Ләкин бу сүзләре – халык тарафыннан карап сөйләү. Халык өчен файда китерердәй булганда, авырлык йөкләп булса да, дәвам итү, шаять, яхшы булыр иде. Ләкин бу заманда файдалы эш эшләп булмый, халыкның көткәне тумый. Шаять, кыю, уйлап эшләүчән,

акыллы адәм чыгып, бу заманда да юлларын табып, файдалы эшләр торгызса, яхшырак булыр, дип уйлыйбыз. Минем үзем өчен дә кулайлы хезмәт түгел, гыйльми эшләргә гадәт ителгән, бик вак имтиханнарга, вак дәгъваларга вакыт бирү җиңел түгел.

Мөфтилек өчен гади гыйлеме һәм өйрәнүе булып, акыл һәм уйлап эшләве өстенә динилеге булса, җитә. Мәсәлән, Габдессәлам мөфти уртача гына гыйлеме, уйлап эшләве һәм динилеге белән бу хезмәткә җитәрлек булган. Хөкүмәткә аз-маз ялагайлануыннан һәм бу хезмәт урынын да бик олы хезмәт урыны дию дәрәҗәсенә масаюына карамастан, яраклы гына адәм булган диярлек. Хәзер дә билгеләп булмаса да, моның мисаллары байтак чыкса кирәк.

Гыйсмәти мөфтилек өчен кайбер адәмнәрне искә алып, лаек булуларында туктаганлыктан соң, Муса әфәндегә килеп, югарыда күрсәтелгән затка ихласлылык һәм мәхәббәт бәян иткәненнән соң: «Әгәр ул мөфти булып сайланса, таңыннан ук кулга алырбыз. Үзен бер дәрәҗәдә тота алмый, халыкны акыллы юл белән алып бара алачак түгел», – дип көлке катнаш сүз белән мәсьәләне кисте.

Муса әфәндедә тугрылык, ялагайланусызлык, сәясәтне саклавамы бар. Якын заманда Мәскәүдә булган зур митингта сөйләгән: «Хәзер замана үзгәрде, бик кыйммәтле нәрсәләр очсыз, бик очсызлы нәрсәләр кыйммәтле булып китте. Мәсәлән, Романовларның таҗы рынкада (базарда – *А.Г.*) бик очсыз бәһагә, бер тиенлек бер кадак тоз мең сумга сатылуда. Шуның кебек бунтта һәм бунтны саклауда мөселманнарның бу кадәр олы кыйммәтле хезмәтләре кирәк. Ләкин бик очсыз тәкъдир ителде. Бик өлешчә генә, хокуксыз гына мохтарият бирелде. Мөселманнар үзләре ала алмадылар, бирделәр генә», – дигән. Моңа охшашлы сәясәткә каты тиярлек сүзләр сөйләгән. Солтангалиев яхшы җавап бирсә дә, мәйданда байтак тәэсир калдырган. Солтангалиевнең яхшы уйлап эшләве белән Муса әфәндегә артык һөҗүмнәр булмаган. Алай да күңелсезрәк калганнар. Хәтта китәрендә Солтангали пропуск бирергә уңайлык тапмаган икән.

Муса әфәнде – хөрмәтле, диндар, саклanучан, кадерле адәм. Ләкин уйлап эшләү һәм идарә эше башкарак хасият. Югарыда күрсәтелгән затның гадилеге, тугрылыгы, ашыгуы һәм сүзгә керешкәч, кызулык белән биләү даирәсеннән чыгып китүе бераз уңайсызлык китерергә мөмкин. Аллаһ ярдәм бирсен дә бар булсын!

Зыя Камалигә дә сүз күчкәнлектән: «Хәзер Коръәнне алай-болай тартып маташу заманы түгел, ул хәл үтте. Коръәнне үзе

әйткәнчә генә тугры һәм дөрес мәгънәсе белән аңлап, халыкны тугры һәм ачык юл белән алып бару тиешле. Зыя әфәнде Төркестанга барса, ярар иде. Бер дәрәҗәдә фикерләр чуалтып алыр өчен, бәлки, файдасы тияр иде», – диде.

Гыйсмәти фикеренчә, хакыйкатькә ирешер, халыкның фикерен кузгатыр өчен бер дәрәҗәдә чуалту, яшел, кызыл нәрсәләр күрсәтеп, халыкны кызыктыру кирәк икән. Без дә исә бу мәртәбә булып узганбыз, дөрес карарга килгәнбез. Инде тугры хакыйкать белән барырга, халыкны да шулай җитәкләргә кирәк икән. Төркестанда фикерләр һаман туңган хәлдә, аны кузгатып, хакыйкатьне эзләтеп таптыру кирәк икән. Бу арада хакыйкатькә ирешмичә, бозык нәрсәләргә алданып, бозык ышану, яраксыз иман белән калучылар булмаса, яхшы булыр иде. Шайтан котыртуы белән талашып, сугышып, кичеп, хакыйкатькә ирешү – әлбәттә, зур ганимәт. Ләкин котыртуга бирелеп, юлда калган, азган-тузганнар да аз түгел, һәлак булып, мәңгелек үкенечкә очраганнар да күп.

## Мәчеттә кояш сәгате

Мәскәүнең беренче мәхәлләсендә мөәзин Мөхәммәдкәрим мулла Зәйнетдин улы Агиев үз дәрәҗәсендә фикерле генә адәм иде. Календарь төзеп, намаз вакытларын, ай башларын билгеләп, нәшер иткән китабы да бар иде. Мәчет ишегалдында кояш сәгате дип бер тәхминнамә (билгеләү әйбере – *А.Г.*) төзегән. Бу сәфәремдә карадым: таш багана өстенә ясаган, әлбәттә, тигезләп ясаган. Күләгә сызыкларын ачык төшереп, кыйбла тарафына күләгә өчен тимердән нык кечкенә индикатор утырткан. Төшлекне (төш вакытын – *А.Г.*) билгеләгән багананың бер кабыргасына, рус календарендә язылганча, айларны язып куеп һәр айда төшлек кайсы сәгатьтә булачагын ачыклаган. Сәгатьләрне якын дөресләр өчен яхшы хезмәт калдырган, мөәзиннәр мондый мәсьәләләрне яхшы белергә тиеш. Намаз вакытларын да нигезле, яхшы белмәсәләр, ничек эш күрәләр. Коры белер-белмәс азан әйтү белән эш тәмамланмый, дөреслегенә игътибар итәргә тиеш. Казан мөәзиннәренең кайберләре кебек һөнәрсез, мәгърифәтсез азан һәм камәт белмәс, дин танымас, тамак мөәзине булып тору – зур гарьсезлек һәм намуссызлык. Мәскәү гыйлемсез, мөселманнары аз җир булса да, бу

мөәзин үз вазыйфасын яхшы үтәргә тырышкан. Аллаһ аның гөнаһларын гафу итсен!

Искә алынган мәчет янында ике-өч карт яныма килеп утырып, кайбер сөйләшүдә булдылар. Мулла Хәйретдин Агиевтан соң кияве Габдулла бине мулла Хәсән кыска төннәрдә тәравихне ястүдән элек укый икән. Йосыф исемле карт: «Хәйретдин ахун Фәхретдин хәзрәт, Казанның Мөхәммәдкәрим хәзрәт ястүдән соң укымыйлар, дип, асылда, тәравихне элек укуга риза булмаган иде, Габдулла мулла элек укыта», – диде. Гомәр исемле берсе: «Син ни башыңны ватасың, син аңламассың, аның хикмәте ястү вакыты керә төшсен, дип элек укыта, юлсыз эш түгел», – диде. Чыгышы белән Бохарадан Гадел бине Рәхимбирде бине Шир: «Бу хәлнең асылы ничек, бәхетле заманда (сәхабәләр вакытында – *А.Г.*) ничек укылган, сәхабәләр (радыяллаһү ганһүм) ничек укыганнар – шуңа карау кирәк булса кирәк», – диде. Боларның сүзләрен бер дәрәҗәдә тыңлаганлыктан, бер дә уйланмаган җирдә гыйльми мәсьәләләрдә аз-маз мәгърифәт белән сөйләшкәнлекләренә хушланганлыгымнан соңрак, кыскача бу сүзләрне әйттем: «Рәсүлүллаһ салләллаһү галәйһи вә сәлләм вакытында да, сәхабәләр вакытларында [да] ястүдән элек тәравих укылмаган. Шунлыктан асыл сөннәт – ястүдән соң укылуы. Кайбер галимнәр ястүдән элек укуны да дөрес күргән. Мулла Габдулланың атасы дамелла Хәсән ястү намазы вакытында сакланучан иде, кичектереп укуны артык күргәнлектән, тәравихны алдан уку тарафында иде. Иркутск мөхтәсибе миннән фәтва сорагач: «Үзем ястүдән элек укуны туры килгән сөннәт була, дип белмим. Фикыһ галимнәреннән кайберләре дөрес күргәнлекләренә күрә, бер адәм тикшереп, элек укый икән, тыймыйм», – дип җавап биргәнемне дә сөйләдем. Шәех Мөхәммәдзакир Чистаи һәм башкалардан да бу рәвеш сөйләнелә. Остазым шәех Сәлахетдин рәхимәһүллаһ (Аллаһ аны рәхим кылсын – *А.Г.*) элек укуны дөрес күрмәс иде: «Сөннәт намаз бөтен рәвешләре белән рәсүлүллаһ салләллаһү галәйһи вә сәлләм һәм сәхабәләр радыяллаһү ганһүмнең укуларына туры килгәндә генә шул сөннәт намаз була, рәвеше я вакыты алмаштырылса, сөннәт намаз булмый, башкача бер намаз булып китә», – ди иде.

## Мәскәүдә Төркия түрәләренә бару

Пәнҗешәмбе көн 29 июльдә Төркия түрәләренә бардым. Тышкы эшләр комиссары, мәҗлес депутатлары әгъзасыннан Бәкер Сами бәк, икътисад комиссары Йосыф бәк, мәҗлес башлыклары әгъзасы Госман бәк, доктор Ибраһим бәк, доктор Фуад бәк коммунист. Болар элек килгән гаскәри түрәләр Җамал паша, Хәлил пашалар урынына килгәннәр. Мостафа Кәмаль паша тарафыннан Шура хөкүмәте белән сәяси мөнәсәбәтләрне саклау һәм ныгыту, шәрык мәсьәләләрендә берләшеп инглиз һәм грек элиталарында хәрәкәт итеп, Төркияне ул ике дәүләтнең хакимлегеннән коткару юлында бик тырышачаклар. Аллаһ муафыйк итсен!

Элекке очрашу һәм күрешүләрдән соң сәфәремнең һәм боларга очрашуымның сәбәбен бу рәвешчә бәян иттем: «Шура хөкүмәтендә дин аерым иптәш булганлыктан, сәясәттән бөтенләй битараф буларак дини мәсьәләләр белән генә яшәп килә идек. Хәзер хәлләр бераз алмашынды. Бик әһәмиятле буларак шәрык мәсьәләсе туды. Русия мөселманнарының олы һәм кечеләренең күңелендә ихтирам казанган, мәгънәви бер сыену урыны күрелеп килгән, ислам хәлифәлегенең тора торган урыны булган Төркия һәм Истамбул инглиз хакимлегенә күчәргә һәм аның авызына керергә тора. Бу хәл бөтен ислам галәме өчен зур хәсрәт, бу бабта мөселманнарга Шура хөкүмәте генә ярдәм бирсә бирә алыр. Шунлыктан без Шура хөкүмәте белән бу турыда аңлашу ниятенә керештек. Мөмкин кадәр бу мәсьәләне кайгыртышуны кирәксендек тә Мәскәүгә килүне ихтыяр иттек.

Ислам бер гәүдә булып, төрле урында таркалган әгъзалары беренче мөмкинлектә затларында утыртылган булган куәт, мәгънә иярүе белән, элекке мәртәбә буларак, сез карендәшләребез белән очрашуга ашыгып, сезне аптыратуга батырчылык иттек. Очрашуыгыз белән дә хөрмәтле булдык», – дидем. Рәисләре Бәкер Сами Бәкер җавап биреп: «Сәясәтчеләр, дипломатларча гына саклык белән очрашуыбыз өчен рәхмәт әйтеп, Төркиянең хәленә кайгыруын белдереп, Русия мөселманнарының Төркия хакында шундый хистә булуларына рәхмәтен өстәде. Шура хөкүмәте белән берләшеп, Төркия хакында булышуда булуларын, алдагы көндә дә өмет иткәнлекләрен, шаять, бер шатлык һәм өстен булачакларын һәм бу хәлләрнең милләтнең уянуы өчен бер сәбәп икәнен сөйләде. Сүз арасында мөфтилекнең хәлләре, урыны, идарә рәвеше бәян ителде.

Шәрык мәсьәләсе өчен бөтен мөселманнарның яхшы карашларын җәлеп итү мөһим була торып, кайбер мәхәллә идарәләре тарафыннан аңлашылмау сәбәпле, халыкның хисенә тиярлек хәрәкәтләр туган, шул сәбәптән, хакыйкать хәлләрен дөресрәк аңлашу нияте белән Мәркәзгә килгәнлек сөйләнде. Болар белән һәммәбезнең хәзер нәтиҗә булганлыктан, боларның матур хәлләрдән хәбәрдар булуларын кирәксенеп аңлатма бирелде. Төркия иле хәлләреннән хәбәр алгач, элекке шәйхелислам бертуганым Муса Кәзыйм әфәнденең инглизләр тарафыннан хөкем астында тотылып, Әдернәгә сөрелеп, төрле кыйнаулар белән хасталанып, бер ай элек дөньяны калдырган икәнен аңладым. Сүрия исә рәсми рәвештә әмир Фәйсаль бине әмир Хөсәен әш-Шәриф идарәсендә булса да, хакыйкатьтә, Франция саклавында икән, Исламбулда (Истамбулны Г. Баруди шулай атый – *А.Г.*) бигрәк идарә итүче Юнан һәм аның гаскәре, аның диңгез көче икәнен, Аясуфия хакында аларның ай урынына тәре куябыз, дип урыны килгәндә кычкырганнарын аңладым. Исламбул өчен зур хурлык, олы кимсетү. Зур банклар ачып, Юнан һәм Румнарга ике-өч процент белән генә бурыч биреп, мөмкин кадәр мөселманнар кулларыннан маллар алырга тырышалар, үз җәмәгатьләрен күбәйтәләр икән. Әлбәттә, бу кадәр хурлыкларны гайрәтле һәм сакланулы мөселманнар күтәрмәсләр, тәмам сәяси гаҗиз һәм зәгыйфьлек хәленә ирешсәләр, ихтыярлары белән күченерләр, бәланең күз алдында булуына күрә, артында булуы бераз җиңелрәк булыр. Сәгать ярым сөйләшкәнебездән кечкенә чынаяк Төркия кәһвәсен тәмамлаганнан соң, рөхсәт алып чыктым. Һәркайсы тышкы баскыч башына чыгып озатып калдылар. Тышкы эшләр министры Чичирин боларга килсә дә, башка зур түрәләр белән һаман очрашмаганнары, аеруча Ленин белән очрашмаганнары ишетелгән иде. Аллаһ Тәгалә уңышлы, хәерле хәлләр насыйп итсен. Хәзер иң өметле эшләре – бу Шура хөкүмәте белән яхшы мөгаләмәдә булулары.

Барышыбызда Заһид бәк Шамил белән өч чакрым кадәр җирне җәяү барган икән. Кайтышта Пятнический елга күперенә җиткәч, юлның яртысыннан күбрәген 100 сумга арба алып кайттык.

## Җаубаштан мулла Гарифның вафаты, тәрҗемәи хәле

Бүген 29 июльдә Касыйм шәһәреннән килгән бер адәм очрап, Җаубаштан Муллагариф бине Биктимернең вафатын хәбәр итте. Сәртан (яман шеш – *А.Г.*) авыруы белән вафат булган икән. Аллаһ ярлыкасын! Элек Касыйм өлкәсе Чутай авылында мулла Шиһабетдин Алтынбай хәзрәттә укып, соңра Кышкар мәдрәсәсендә тулы гыйлем алып, берникадәр еллар дәрес укытып, кыюлыгы, сүзгә осталыгы белән Кышкар мәдрәсәсендә булган мәгълүмат белән байтак шөһрәт казанган. Саф күңеле, фикыһ китапларын өйрәнерлек гарәп телен белүе бар, хөрмәте шөһрәте кадәр булмаса да, бәхәсләшү куәте яхшы, инсафлыктан тыш булмаган иманлы йөрәге бар адәм иде. Минем белән мөнәсәбәте яхшы, пәрдәсез сөйләшүләребез булганга: «Әзерлегең яхшы, фәкать урынлы сарыф итмисең, чын гыйлемгә бирелсәң, яхшы фазыйләт хасил итәр идең», – диюемдә: « Әле бу кадәр гыйлемгә дә урын юк, мәшәкать чигеп хасил итеп, кая куярга белмим», – [дигән] мәгънәдә җавап бирер иде. Бу сүзе көлкеле сүз булса да, Кышкар рухына һәм аның тәрбиясенә күрә, ышану сүзе булса да, гаҗәп түгел. Алар, ниһаять, гыйлемдә бер дәрәҗәдә гарәп телен өйрәнү хасил итүне Габидиннең «Радд әл-мохтар» китабыннан мужик мәсьәлә сораганда, эзләп җавап табарлык куәт булса, җитәрлек күрәләр. Аннан артыкны артык эш юклыгыннан шөгыльләнү [кебек] күрәләр. Шунлыктан аларда шәкертлек вакытларындагы акыл һәм куәт яхшы булса да, шул дәрәҗәдә кала, зур фикри тукталышта багланып, гомерләре үтә. Тәрҗемәи хәле сөйләнелә торган затны да кузгалтып булмады, әзерлеген әрәм итте. Гафияллаһү ганһ (Аллаһ аны гафу итсен – *А.Г.*).

Шәех Зәйнулла хәзрәттән Нәкышбәндия юнәлеше ысулынча зикер әйтә иде. Ләкин шөгыльләнүе аз булды. Соңгы инкыйлабта буфетчы Халикъның тормышы начарлыкта булганлыктан, мәхәлләсендә имам өчен тормыш маддәсе зәгыйфьлек хәлгә төшкәнлектән, башка җиргә күчәчәк булып, яраклы мәхәлләгә дәлилләремне сорап язган иде. Юатып, яраклы җир күренгәндә хәбәр итәрмен, дип җавап та язган идем. Казандагы дуслары да кайбер урыннарда маклерлыкта булсалар да, язмышы, якында, кабергә күчү булган икән. Аллаһ яхшы тәмамлану биргән булып гафу иткән һәм рәхмәтенә алган булса иде. Котаймастан (Кышлаудан – *А.Г.*) мулла Лотфулла бине мулла Сибгатулланың олы кызына никяхланып, Кирмән өлкәсенә кызларны ысуллы укыту кертте.

Аннан элегрәк Кырымнан ысуле җәдид өчен махсус мөгаллим китереп, башлап бу өлкәгә өйрәтү ысулын таратты. Зур эш булмаса да, фанатизм белән танылган булган кышкарлылар арасында билгеле булган бу дөреслек һәм урталык – байтак кыйммәтле дөреслек һәм урталык. Якынча 66 яшьләрендә булса кирәк.

Мәзәк: Сөйләнүче зат Нижнийга ярминкә вакытында сәяхәтче булып килгән елында имам Хәлил бине Габделгалләм йортында чәй мәҗлесендә бер сүзлектән сүз чыгып, «Укъянус»ны (энциклопедик сүзлекне – *А.Г.*) карарга ихтыяҗ күрелде. Табигатендәге ашыгуы буенча сөйләнүче зат мулла Гариф нөсхәне кулына алып актарырга тотынды. «Әхтәри» («Әхтәри кәбир» сүзлеге – *А.Г.*) үрнәгенчә сүз башындагы хәрефләр игътибары белән тикшереп, сүз эзләве сизелгәндә, мәҗлестәгеләрдән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә соңгы урта бүлектә сүзлектән сүз тикшерү ысулын өйрәнгән укучылардан Габдулла бине Хәлилнең сүзне табып күрсәтүе белән тәмамланган иде. Югарыда искә алынган зат зирәк, шөһрәт хасил иткән адәм булса да, үткән биттә язылганча, башлангыч гыйлемнән башканы бер остазсыз гына хасил иткән. Чын гарәп теле, тиешенчә гыйлем эченә кермәгәнлктән, сүзлек карарга да ихтыяҗы тумаган.

## Инглизләргә нәфрәт бәяне

30 июльдә җомга намазы икенче җамигъ мәчетендә укылды. Җомга намазыннан элек бу сүзне сөйләдем:

«Хәзер ислам галәмен кайгырткан зур вакыйга – инглизләрнең Исламбулга хуҗа булулары, Мисыр һәм Сүриянең, Йәмән һәм Хиҗазның аның карамагында булуы, бөтен ислам хәлифәлеген кимсетүе, шулай ук бөтен ислам галәмен мыскыл итүе. Мөселманнарга зур кимчелек, олы үкенеч! Бу хәлгә бөтен мөселман кайгылы. Исламбул дәүләте, ислам хәлифәлеге һәркайда булган мөселманнар өчен мәгънәви бер сыену урыны, рухи таяныч, күңелләренә куәт, җаннарына юаныч, рәхәтлек иде. Шунлыктан мин, Русиядә булган мөселманнарның дини рәисләре һәм мөфтиләре булу сыйфаты белән, инглизләрнең бу золымлыкларына ризасызлыгымны белдерәм. Сез дә бу бабта миңа кушыласыздыр», – дигәнемә һәммә халык: «Кушылабыз, инглизләрнең бу эшләренә риза түгелбез», – дип бакырыштылар. Байтак адәмнең күзләре яшәргәне беленде. Халыкта Төркия һәм Исламбул турысында

куәтле хис бар, үзләренә арка кебек күрәләр. Шунлыктан хәзер Шура хөкүмәтенә карашлары үзгәреп бара. Төркиягә булышу ниятендә булганлыклары белән байтак халыкны үзләренә үзләренә җәлеп итә башлаганнар. Мин дә Җамигъта (төп мәчеттә – *А.Г.*) сүз ахырында әйттем: «Төркияне, Истамбулны, изге җирләребезне инглиз кулыннан коткаруда ачык сәбәп ни булачак, кем булачак? Хәзер Шура хөкүмәтеннән башка хөкүмәт һәм дәүләт күренми. Шурадан бу эш көтелә һәм Шура бу кайгыга кергән, хәтта бөтен Шәрыкны инглиз хакимлегеннән коткару ниятенә керешкән. Шул җәһәттән, мөселманнарга бу бабта Шурага бу эшендә аңа ярдәм бирү тиешле. Бу хезмәтендә бергәрәк булырга кирәк».

## Төркия-Шура мөнәсәбәте<br>һәм инглизләрнең фикер йөртүе

Төркия белән Шура арасы хәзер яхшы, Төркиягә Шура ярдәм итәргә вәгъдәләр биреп тора, Төркиядән дә Шурага файдалар тияргә мөмкин һәм тигәне дә байтак булган икән.

Ишеткәнлегенә күрә, яхшы, ныгып килә торган зур дәүләт хасил иткән Әзәрбайҗан хөкүмәте, мөстәкыйль булып, Шурага бирелмәслек дәрәҗәгә килә язган. Идарәләрендә төрекләр дә байтак катышканнар. Тышкы һәм гаскәри (хәрби – *А.Г.*) эшләрендә төрек түрәләре ярдәм итешкәннәр. Соңгы вакытта гаскәр башында булган Хәлил паша Шурага каршы куелган фронтта юлбашчы булганлыктан, фронт ачып, Шура гаскәренә юл биргән. Бу бабта хөкүмәттән килгән телеграмманы да башка төрле күрсәтеп яки өйрәнеп, гаскәргә канәгатьлек биреп, илле мең кадәр ялангач аяклы Шура гаскәрен Бакуга керткән, үзе Бакудан бер якка киткән икән. Бакуның хисле адәмнәренә бу хәл бик каты тиеп, төрле кызу хәлләр булган икән. Хәлил пашаның бу хәрәкәте дөрес булса, гомуми файданы максат итеп эшләгән булыр. Әзәрбайҗанның Шура белән сугышында, ахырда каршы тора алмавын уйлап, бушка кан түктермичә әзәрбайҗан һәм башкаларны Шура белән берләшеп, ныгытып, Анатоль Төркиясенә кушып, инглиз һәм юнанга каршы куеп, Исламбулны һәм иярүчеләрен коткаруны уйлаган. Бу җөмләсе белән Шурага байтак якынаю һәм аннан байтак гомуми файданы максат иткән. Хәзерге көндә Анатоль Төркиясе сугыш коралы белән алтынга байтак ихтыяҗлы булса, Шурадан боларны алу мөмкин,

башкача алуы мөмкин түгел. Бу юл белән гаскәр куәтен яхшыртып, Исламбул тарафын басып алып, Исламбулны (анда булган инглиз һәм юнан гаскәр куәтен) тар-мар итеп торуда. Бу көннәрдә Анатул идарәсе (Мостафа Кәмаль паша) белән Исламбул хөкүмәте арасында сугышны туктату булганлыгын газеталарда укыдылар. Мәскәүдә булган Төркия вәкилләренең укыганнарына күрә, падишаһ белән Мостафа Кәмаль арасында сугышны туктату булган ки, инглиз Төркия өчен яман, бөтен куәтен һәм рухын алыр дәрәҗәдә төзелгән килешүне падишаһтан имза куйдыру ниятендә һәм тиз-тиз аны көчләп кушуда, падишаһ та якыннары риза түгел сылтавы белән имза куюны кичектерүдә. Инде падишаһ белән Мостафа Кәмаль арасында яхшы аңлашу туып, һәр икесенең дә максатлары Төркиягә зарарлы булган имзадан котылып, бер дәрәҗәдә урынлы солых төзүдә. Шул сәбәптән, бу ике арада сугышны туктату булган булса кирәк. Валлаһү әгъләм бис-саваб (Аллаһ белүчерәк – *А.Г.*).

Төрек вәкилләреннән Мәҗлес депутатлары әгъзасы Госман бәкнең бәян итүенә күрә, Анатул Төркиясенең оешуы һәм гаскәре төзелүе бу рәвешчә туган. Исламбулда Мәҗлес депутатлары зарарлы булган инглиз тәкъдим иткән килешүнамәне имзага ризалык бирмәгән. Солтанның җизнәсеме Фәрид паша инглиз тарафлы бер адәм булганлыктан, инглизләрнең: «Падишаһ риза булса, инглизләрдән киң күңеллелек, булышулар һәм фәләннәр булачак», – дигән төпсез вәгъдәләргә падишаһны канәгатьләндергән. Мәҗлес бу сүзләрнең алдау икәнен, инглизләрдән һич хәерлелек булуы мөмкин түгеллеген ни кадәр сөйләсә дә, падишаһны күндерә алмаган. Ахырдан, падишаһ Мәҗлес депутатларын таркаткан. Мәҗлес Анатольгә күчеп, «Зур мәҗлес депутатлары» исемле Мәҗлес корып, гаскәр туплап, хәзерге гаскәр хәрәкәтен дөньяга китергән. Бу көндә инглизнең көймә тубы ирешмәс җирләрне Анатоль гаскәре басып алган. Бу көннәрдә – кирәк боларның хәрәкәтләреннән, кирәк инглизләрнең ультиматумына каршы – Шураның көчле җавабыннан инглиз дәүләтендә байтак дулкынлану булса кирәк. Аш сеңдерсә, гаҗизлек һәм зәгыйфьлек галәмәте, гаскәр хәрәкәте башласа (кадерен саклау өчен шул кирәк тә), кешедән эшләтеп, җимеш җыярга һәм тупларга өйрәнгән инглиз политикасына каршы, янә бер Польша кебек аның мәкеренә һәм хәйләсенә алданып, хәрәкәткә килүче бер-ике дәүләттән ярдәм һәм булышу күрерме – байтак зур вакыйгаларның алдында торабыз.

Бу көннәрдә Хивадан дә вәкилләр бара икән. Эчләрендә байтак мәгълүматлы адәмнәре дә бар, диделәр. Шәрык белгече бәяненә күрә, Бабаҗан исемле берсе һәр бабта мәгълүматлы, дөнья хәлләреннән хәбәрдар, байтак зиһенле кемсәнә икән. Бохаралыларга күрә байтак югары дәрәҗәдә икән. Хивада беренче еллардан бирле баш күтәрүләр һәм инкыйлаблар булып, мәмләкәт халкы дулкынлану эчендә яшәп киләләр. Әсфәндияр хан да үтерелгән, башбаштаклык байтак хөкем сөреп килгән. Бу хәлләрдән йөдәгән халык тәртип һәм тынычлык теләгәнлектән һәм таләп иткәнлектәнме, Шура идарәсенә тиз күнеп, кабул иткәннәр икән. Элек Киринский заманында да болар тизрәк эш аңлап, Шура ысулындагы бер хөкүмәт торгызу юлына кергәннәр иде. Хива халкының Бохара халыкларына караганда гаҗәпләнүләре һәм горурлыклары кимрәк, дөнья хәлләрен белүчерәк булулары сәбәпле, реформалар юлына тизрәк керүчән халык. Хәзер бер дәрәҗәдә Шура ысулындагы идарә кабул итеп, нигезләрен саклап калу ихтималлары бар. Әмма Бохара халкы һәр бабта ысуле җәдидәне кабул итмибез дип, бүләкләр һәм фәләннәр белән арада булган кайбер ач күзле түрәләрне вакытлыча канәгатьләндереп, алданып мәмләкәтләрендә эченнән зур инкыйлаб һәм баш күтәрү туды-рылып, тулы зарарга һәм җимерелүгә очраулары ихтималдан тыш түгел. Надан муллаларның надан хәрәкәтләре белән Сәмәрканд сугышында да Сәмәрканд, Кәттәкурган һәм башка шәһәрләренең Русиягә керүенә сәбәп булган. Шуның мисалы бу заманда да барлыкка килүе бик ихтимал. Бу арада Мәскәүдә күренгән адәм-нәрендә бер дә өмет күренми. Яхшы арбаларда хөрмәт йөртеп, хөрмәт һәм кадер күрсәтүләре, Русия дәүләте: «Безгә хуш килдегез», – дип әйтүләре ихтималдан ерак түгел.

Җомга намазын мин укыттым. Хөтбәсендә «Вәл-гаср» сүрәсен тәфсир кылдым (аңлаттым – *А.Г.*). Ислам нигезләрен озынрак бәян иттем. Намаздан соң намазга килгән Бохара вәкилләре белән күрешеп, мөәзин Галим бине Габделҗәлил Куйсави йортында чәй мәҗлесендә сөйләштек. Болар Мирза Мәһди, Хуҗа Дадхава, мулла Сәед Мәхмүд, Туксабәярым мулла, гаскәри түрә Нәүрүзбәк, сәүдәгәрләрдән Җүрәбик гарәп, Гарифулла хуҗа кияү мөәзин, янә өч-дүрт адәмнәре, Троцкий якыннарыннан бер Муса пәйгамбәргә иярүче (яһүди – *А.Г.*), икешәр атлы хөкүмәт фаэтоннардан дүрт данәсен кулланып, Җамигъка килгәннәр. Намаздан соң мөәзин өендә берәр сәгать утырып, бераз сөйләшеп килделәр. Сәед Мәхмүд

исемле 71 яшьлек карт зур ак сакаллы мулла Зәйнелбәшәр Саратагый иптәшләреннән икән. Кайбер хәбәрләребезнең хәлләреннән сораштык. Бер шатлыклы хәбәр ишеттек: [һиҗри] 1335 елда бохаралыларның җәдидләргә каршы ахмак хәрәкәтләрендә бер байтак казанлыларны хатын һәм бала-чагалары белән, үзләреннән дә җәдидлек (фикри инкыйлабка мәхәббәт) белән танылганнарын суйганнар иде. Шул арада Бохараның казые Мирза Шәриф бине дамелла Габдешшәкүрне дә үтергәннәр, дип билгеле булды. Бу кешеләр хөрмәт белән аның тормышын, кайсы шәһәрдән икәнен сөйләп бирделәр. Фәкать шул дулкынлану арасында казыйлыктан чыгарылып, инкыйлаб рухы белән элекке казый Мирборһан бине казый Бәдретдин бине казый Садретдин бине әмир Бәйзаины аның урынына казый ителгән. Искә алынган дулкынлану вакытында Бохара мөдәррисләре арасында иң зирәк, яхшы фикерле, һәр фәннән хәбәрдар, күп шәкертле мөфти, хаҗи, дамелла Әкрам шәһәрдән Хазар казыйлыгына сөрелгән иде. Бичара, рәнҗетелгән [бу зат] һаман да шул бозык һавалы, кечкенә шәһәрдә, Бохарадан шактый ерак җирдә казыйлык белән тоткынлыкта тотыла икән. Элекке елларда да кайбер тугрылыгы, Бохарада булган кайбер бидгатьләргә каршы килүе сәбәпле, галимнәрнең көнчелеге сәбәпле, Чарҗуй казыйлыгына сөрелеп, шәехләрдән берсенең арадашлыгы белән кайтарылган иде.

Бохаралылар [белән бергә] сөйләшеп утыруым белән 1335 (1917) [елгы] Төркестан һәм Бохарага барышымны искә төшердем. Ул сәфәрем бер җирдә дә язылмаганлыктан, бу урында язарга булам. Шулай күп еллардан бирле Бохарага бару һәм анда булган укымышлылар белән сөйләшү теләгендә йөри идем. Элекке елда Ташкент һәм Чимкент шәһәрләрендә булып, бераз кәсеп итеп йөрдем. Бу елда Бохарага бару теләге, инкыйлаб булу мөнәсәбәте белән, бик вакытсыз, рәхәтсез вакыт булса да, барырга булдым, сәфәрне тәвәкәлләдем. Инкыйлаб белән бәйле төзелгән милли Шуралар, Бохарага карата бер уй тудырырга теләп, минем сәфәремне уңышлы күреп, сәфәремдә бу хезмәтне күрсәтүне теләделәр. Петроградтан рәсми комиссарлык кәгазен тәкъдим итсәләр дә, кабул итмәдем. Гади кеше буларак дустанә фикердә булуны гына лаек күрдем.

Апрель башларында Казаннан чыгып, Төркестанга юнәлдем. Ташкентта кайбер галимнәр һәм дуслар белән очрашып, ул арада Петроградтан Ташкент мөдирлегенә килгән җөмһүрият бүлеге

Габделгазиз бине Габдулла Дәүләтшин, Садретдин бине Низаметдин Максуди һәм башкалар Ташкентта иделәр. Ташкентта бер гыйльми мәҗлестә Мәскәү киңәшмәсенә гомуми халык тарафыннан җибәрелгән вәкилләр өстенә галимнәрдән бер-ике кеше җибәрелү мәсьәләсе кузгалып, ике галимнең баруын яхшы күрделәр. Аларга Төркестанның таләбе булган җирле мөхтәрият алу турында Кавказия вәкилләре белән очрашуны киңәш итеп, Тупчибашевка бер язу-гариза бирдем. Сарт (Урта Азия – *А.Г.*) халкы федеративный автаномия дип өйрәнеп алганнар, ләкин хөкүмәт ничек идарә итәчәк, кешеләре бармы – анда аларның эшләре юк.

Шул вакытта Нәмәнгәндә Милли шура сайлау турында халык арасында бер аңлашылмау чыгып, зураюыннан, тирә-якка таралуыннан куркып, Ташкенттан Габделгазиз Дәүләтшин, мин, Ташкент шәһәре казые карый Габделвахит һәм бер мөдәрристән гыйбарәт 4 кеше делегация булып, Нәмәнгәнгә барып, реформа бабында тырыштык. Сәбәбе бер кечкенә нәрсә икән. Үзе яшьләрчә, хатыны марҗача ачык йөргән кемсәнәне Милли шурага сайлауга кешеләр риза булмаган, бу адәм керсә, безне динсезлеккә өстерәр, яманлыкка тәэсир итәр, дип куркып, гауга чыгарганнар. Халкы динле, фикерсез, уянмаган халык булганга мәсьәләне зурайтканнар, аз нәрсәне күбәйткәннәр. Безнең яшьләрнең дә чамасызлыклары сәбәп булган, җиренә җиргә хәрәкәт итмәгәннәр, бу хәл бер дәрәҗәдә уңайланды.

Бу шәһәрнең укымышлыларыннан кайберләре белән очрашу булды, Мәдинә шәһәре вәкилләре шәех Сабит һәм туганнары белән сөйләшенде. Шәех Сабит Төркестанда сирәк күрелә торган тикшерү юлына бераз кергән адәм. «Һидая»нең ибне Җәмәга әсәре «Хәлү мүшкиләт әл-һидая» исемле шәрехен Мәдинәдә Шәйхелислам китапханәсендәге нөсхәсеннән язып алган, бик сирәк нөсхә. Мин дә Түнтәри Нәҗип Шәмс нөсхәсеннән нөсхә эшләткән идем. «Һидая»дә хәдисләргә каршы күренгән, мәзһәб фанатизмы белән язылган мәсьәләләрдә бер фикер бәян итеп кителә. Хорасан хәдис белгечләреннән «Мишкят әл-мәсабих»ның сәнәд (хәдис чылбыры – *А.Г.*) кешеләреннән мәшһүр шәех Җамал хәдис белгеченең нык нөсхәсен бу кешедә күреп кызыккач, бер зур нөсхәне миңа үз кулы белән язып биргән иде.

Нәмәнгән шәһәре – дин һәм гыйлем шәһәре. Электән бирле бу ике үзенчәлек белән Фирганәнең өстен шәһәре. Яхшы мәдрәсәләре

бар, галимнәре, шәкертләре күп, шәрык, гарәп гыйлемен яхшы укый торган халык.

Габделкадыйр хаҗи исемле сәүдәгәрдә кунак булып, аннан кайтканда, кызыксынып Хуканд һәм Әндиҗан шәһәрләрен күреп үтү өчен иптәшләремнән Хукандта төшеп калдым. Иптәшем Сәлах хәлфә белән Хукандка кереп, анда берәр кичә калып, Габделгазиз мәхдүм дамелла Фәйзулла кебек карт мөдәррисләрен күреп, кайбер мәҗлесләрендә булып үткәрдем. Мөмкин кадәр бу заманнан хәбәр биреп, замананың хәле белән хисаплашу кирәклеген, булмаса, һәркайсын рус һәм яһүд алып китәр, хурлыкта калырсыз, дип сөйләсәм дә, артык тәэсире булыр, дип уйлый алмадым. Тик яшь гыйлем ияләреннән бер төркем җыелып, фикерле кешеләр белән лаек булган киңәшмә үткәрдек. Болар вакытлы бер уку йорты ачачак булып, башлангыч укытуны алып барырлык бер мөгаллим, гарәп телен укытырлык бер мөгаллим, һәр дәрәҗәгә фәнен күрсәтерлек өченче бер мөгаллим җәлеп итәчәк булып, юллыкны минем кулыма тапшырдылар. Көчле теләк белән укытучылык эшенә керәчәк иделәр. Ләкин безнең тарафтан бер кимчелек булды. Тиз арада мөгаллимнәр җибәрә алмадык. Мөгалимнәр җитәкчесе буларак эш күрер өчен, тәрбия эшләре өчен дә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгалимнәреннән Борһан Хәбибне Төркестанда калырга күндереп, һәр җирнең кайгысын күреп, мөгамәлә итәр өчен вәкил хөкемендә калдырдык. Бүген дә Ташкент мәктәпләре һәм уку йортларында хезмәт итә. Хуканд Фирганәнең пайтәхете булып, гыйлем итү куәтле, башка шәһәрләргә караганда өстенрәк. Хукандта гыйлем алганнарның күбесе Бохарада урнашып, Бохараның шөһрәте, мактанычы өчен болар хезмәт итеп киләләр. Электән бирле Хуканд халкы намуслылык, чыдамлык белән Бохарада билгеле. Безнең халык исә тырышлыгы белән танылган. Бохаралыларның телләрендә: «Бохаралының төшенүе, Хукандлының тугрылыгы, нугай тырышлыгы булса, гыйлемлек итәргә мөмкин», – [дигән] әйтем билгеле. Бохара халкы зирәклеге белән алдыра. Ләкин тырышлыклары ким булса да, билгеле дәресханәдә укыйлар. Фәкать фикыһны, фикыһ нигезләрен сирәк укыйлар, шунлыктан араларында мөдәррисләр аз чыга, укып, дәресләрне тәмамласалар дә, казый һәм рәис булып гомерләрен үткәрәләр. Укып гыйлем һәм дәрес юлында дәвам иткәннәре күп югары күтәрелеп, башкалардан шактый оста булалар, ләкин сирәк. Бохараның гыйлемен саклап килгән кешеләр һәм мөдәррисләр күбрәк Бәлх, Хуканд (Нәмәнгән,

Әндиҗан белән), Себез шәһәре, Куһистан һәм Казан кешеләре. Бохаралыларның үзләреннән күп түгел. Ләкин һәммәсенең чыганагы һәм сәбәбе – Бохараның мөсафирлар сөюе, халкындагы хәер-бәрәкәт, хакименең дә мөсафирларны чит күрмәве, тугры каравы.

Хукандтан Әндиҗанга барып, Шурага сайлаулар эшчәнлегенә туры килдем. Мостафа Сәфәров йортына килеп, икенче көндә милли Шурага сайлаулар мәҗлесенә кадәр, элек Милли шураларының рәисе Нәҗметдин исемле берәү, Камил бай дигән атаклы миллионерлары белән күрешеп (бу кеше үз тарафдарларын сайлату фикерендә һәм шул эштә байтак ел сарыф итеп, тарафдарлар җыйган икән), Камил байның пар ат җигелгән фаэтоны белән барып, төп мәчеткә җиткәндә, аның капкасына урнаштырылган музыкалардан уйнап, халык каршылады. Бер ягы мәдрәсә, кыйбласы мәчет булган зур ихата эчендә бик күп халык җыелган. Мөдәррисләр тарафына мине китереп, алар белән сөйләшеп, мәҗлесне миннән ачтырдылар. Урталыкка бер урындык куеп, сүз сөйләү өчен урын әзерләп, тавыш җитәр кадәр кычкырып, хөррият турында, дин һәм милләткә ярдәм турында, сайлауларда тарафчылык кылмыйча, чын дөреслек белән сайлау тиешлеге турында озын нотык ирештерелде. Нотыктан соң иң карт мөдәррисләре тарафыннан укалы бер чапан кидерделәр. Сайлау вакыты җиткәндә мин кайтыр өчен саубуллашып чыктым. Ләкин безнең Камил бай битараф сайлау кирәк, андый-мондый тарафдарлык кылу тиеш түгел, дип сөйләгән нотыгыбыздан риза булмаган булса кирәк. Мине китергән атлары, арбасы күренмәде. Башка бер кешенең пар атын әзерләп, мине озаттылар. Ул кичтә мулла Сөләйман Әндиҗани өендә мәҗлес булды. Укымышлылар җыелган иде. Бу Сөләйман әфәнде сәүдәгәр кыяфәтендә булса да, укымышлы иде, халык фикере яклы иде. Кайбер мөселманнардан сүз чыгарып, файдалы мәҗлес булып, ястү намазын аның өендә җәмәгать белән укып, ашаганнан соң кич белән Мостафа Сәфәров өенә кайттык. Бу Әндиҗан халкының да сәләтләре шактый яхшы, белемле халык. Йортыбызга килеп китүче яшьләр һәм мәхдүмзадәләр (мулла балалары – *А.Г.*) булды, һәркайсына гыйльми һәм әхлакый нәсыйхәтләр, чын гыйлем юлларын күрсәтү буенча сүзләр сөйләнде.

Ике кичәдән соң Әндиҗаннан туры Бохарага юнәлдем, тик Бохарага бирелгән телеграммабыз ирешмәгәнлектән, Кәгәндә, яңа Бохарада, русский мосафирханәсенә килдек. Кайбер яшьләр

Бохараның дулкынлануыннан куркып, Кәгәндә ятарлар икән. Бохараның бик эссе вакыты, шәһәрдә тормыш бик авыр, Кәгән бер дәрәҗәдәге иркенлеге белән һавалырак иде. Яшьләр хәленнән хәбәр алдым. Болар, инкыйлаб булу белән, иранлы, әрмән, башка байлар белән бохаралылар тупланып, демонстрация ясыйлар, кызыл байраклар белән урамнарны гизгәннәр. Дворец янына килеп, хөкүмәттән музыка теләгәннәр. Хөкүмәт, хәбәр табып, бу ни хәл дип, инкяр сурәтенә кереп, боларны таркатып, баш булганнардан кайберләрен таяк астына алып, байтак тәртип бозу туган. Казый һәм рәисне әзерләп, казый реформа тарафлы булганлыктан, әүвәлдә аз-маз халык тарафыннан бераз кимсетү күреп, рәисне исә атыннан төшереп, органнар да хезмәтеннән алганнар. Бу хәлне күргән яшьләр таркалып качып, кайберләре Яңа Бохарага, Русия яклавына килеп тора башлаганнар иде. Минем сәфәрем бик уңайсыз вакытка очраганлыктан, ихтимал булган нәтиҗәләреннән берсенә дә ирешә алмадым. Үземдә дә кайбер тәрбиясезлекләр булды. Мәдрәсәләрдә дә иске белешләр азайган, киңәшләшерлек кеше калмаган. Бу инкыйлаб хәрәкәтендә булганнарның барысын да ысуле җәдидкә нисбәт белән җәдидләрне хурлауларын яңартканнар. Ул яшьләрне ордыруда, җәзалауда рух биреп торган, электән үк җәдидләргә каршы фанатизмы белән билгеле булган мулла Камәретдин мөдәррисне рус шәһәрендә кулга алдырганнар иде. Бохараны коткару фикеренә керсәм дә, бөтен яшьләр бердәм каршы төшкәнлектән: «Тоткынлыктан чыгарсаң, башыбызга зур бәла арттырасың», – дигәнлекләреннән, Куш биге Низаметдин хуҗа коткару турында миннән үтенсә дә, катышуга батырчылык итә алмадым. Яңа Бохарадагы кулга алу буенча комитет боларга җитди мөрәҗәгать итсә дә, канәгатьләндерү ихтимал иде. Куш биге белән әңгмәдә булдым: «Хәзер Русия дәүләте алмашынды, башка төрле ысулга куелып бара, яшьләр хөкүмәт сөрә. Бу эшләрендә халыкның файдасын, аеруча фәкыйрь төркемнең файдасын карыйлар, изүче хөкүмәт ихтыярынча каралачак түгел, сезнең исә Русия дәүләтенә каршы килә торган көч дөрес түгел, искечә мөнәсәбәттә булуыгыз кирәк. Шунлыктан бераз яшьләр тарафына аңлавыгыз, азрак булса да, хөррият биреп иркенәйтүегез, фәкыйрь халыкка җиңеллекләр күрсәтүегез кирәк», – дидем. Әлбәттә, әйткәнегезне эшлибез, байтак җиңеллекләр яптык, гаделлек белән эш иттек һәм фәлән кебек сүзләр сөйли иде. Ләкин шул арада халык, аеруча муллалар арасында бер дулкынлану бар иде. Шәһәргә барып килгән, мәдрә-

сәләргә катнашкан хәлфәләр, шәкертләр кораллар әзерлиләр, риваятьләр төзиләр, җәдидләрне кяфер саныйлар имеш, дигән сүзләрне күчерәләр икән. Бер көнне Бохарада мулла Имамханга кердем, бик һуш күрде. Электән үк мөнәсәбәтебез бар иде. Хәзер дә күп шәкертләр шул Бохарада укып, дәрәҗәле, абруйлы булдылар. Бу халыкның дулкынлануы турында сүз чыкты, әйтте: «Бу җәдидләрне өч мәсьәлә сәбәпле көферлектә гаеплиләр икән: 1) намазны бары ике вакыт фарыз, диләр икән; 2) ике апа-сеңелләрне җыю (аларга өйләнү – *А.Г.*) – хәләл икән; 3) хиҗаб бетәргә тиеш, диләр икән. Шуңа күрә болар шау-шу кылалар, диде. Әйттем: «Бу сүзләр һәммәсе яла, хакыйкатьне тикшереп, яхшы аңлашып эш күрергә тиеш иде», – дип җәдид ысулын, мәмләкәттә чыккан яңа җәдид ысулын аңлаттым. «Алай булса, дөрес икән», – диде. «Сез халыкка яхшы, дөрес белдерәсез, боларга мәрхәмәт итеп белдерсәгез булмасмы», – диюемдә: «Асылда мөмкин түгел, мине үтерерләр, бу ахмак халыкка сүз аңлату мөмкин түгел», – диде.

Бу яшьләр демонстрациясендә бабилар да катнашканлыктан, аларның мәзһәбләрендә булган кайбер көферлекне бөтен демонстрантларга һәм демонстрантларны җәдидләр дип, гомумән, җәдидләрне көферлеккә чыгарырга батырчылык иткәннәр. Бу бабта Ташкентта мулла Хәлмөхәммәд исемле игътибарлы чал казакъ сартның зур хезмәте һәм тәэсире барлыгын әйттеләр. Бер кичәдә бу риваятьне дамелла Кәрам мөфтигә алып барып сөйләделәр. Тоткынлык белән куркыткач, мөфтилек мөһерен чыгарып биреп, мөфтилектән гафулар үтенеп, мөһер куймаячагын белдергән. Икенче көнне көндез дамелла Мирсадыйк Казанига барганнар. Ул да язуны укып: «Бу эш дөрес түгел, җәдидләрдә мондый ышану юк, шунлыктан мин мөһер куймыймын», – дигән. Русияле булганлыктан, аңа һөҗүм итмәгәннәр һәм арттырып җибәрмәгәннәр. Зәйнелбәшәр аркылы риваятьнең нөсхәсен сорасам да, күрсәтмәделәр. Хәтта консуллык хезмәтен үтәүче рус түрәсе аркылы да сораттым. «Ул риваять Ташкент өчен генә булган, инде җибәргәннәр», – дип җавап китерде. Бу түрә дә икейөзле, вөҗдансыз мәкерле рус иде. Әйттем: «Ташкентка җибәргән булсалар, Русиядә бер фетнә чыгарачаклар. Мондый инкыйлаб һәм реформа вакытында шундый бер кирәксез, бәлки, килешү юлына toткарлык итә торган эшнең Ташкентка җибәрелүенә ничек риза булдың? Син Русиянең вәкиле булгач, аның өчен хәерхаһлы булуың кирәк түгелме иде?» – дисәм дә, кайбер ялган нәтиҗәләр белән үткәрде.

Ташкентларның карар сораулары булса булгандыр, әлбәттә, нөсхә җибәргән булырлар. Ташкентта дамелла Фәхретдин кебек фанатик, фикерсез мөдәррисләрдә шундыйрак рух бар иде. Ләкин Бохарада вакытта ук безгә, кайберләрен күреп, кайберләрен ишетеп белгәнлектән, дәресләре дә түбәнрәк булганлыктан, каршыма чыгып сөйләргә батырчылык итмәделәр. Бохарада Куш бигегә әйттем: «Галимнәрнең кайбер мәсьәләләрдә шөбһәләре булса, минем белән җыегыз, бер мәҗлес төзегез, хак һәм ялганны тикшерик, шөбһәләре урынсыз булса, җавап бирермен. Урынлы шөбһәләре булса, кабул итәрмен», – дидем. Башта: «Карарбыз», – дип мөлаемлык күрсәтсә дә, икенче мулла яныбызда гафу үтенде: «Сезнең белән сөйләшердәй кешебез юк», – дигән булып, йомшаклык белән үткәрделәр. Дамелла Кәрам, табигый, бу бабта каршы сөйләячәк түгел, башкалары артык көчле түгел. Алай да күпчелек белән тавыш итәрләр иде, күп файда чыкмас иде, булмавы хәерле булган.

Бохарада артык торуда да файда күрелмәде. Дуслар да халыкның рухын аңлап, сакланып эш итүне ихтыяр иттеләр. Хәтта гыйлемлерәк Бохарада мулла Имамхан бер көндә кунакка чакырган иде, шул көн иртәсендә гафу үтенде. Әлбәттә, курыккан, хакы бар. Русия вәкиле минем өчен бераз куркуын белдерде Зарарланмасыннар, дип, дуслар белән саубуллашмыйча, Ташкент тарафына киттем. Фәкать гайрәт кайтты, рух сүнде, Бохарадан өмет киселде. Шунлыктан Сәмәркандта туктап, бераз ял итү соралса да, Ташкентка кайттым. Кайтып керүемә Казаннан хөррият вәкилләре Габделбари Баттал, Исмәгыйль Габид, Борһан Шәрәф килгәннәр иде. Шәех Хавәнд Тоһур мәчетендә митинг ясарга булганлыкларыннан, башлап җибәрү өчен мине чакырдылар, барып бераз нотык белән башладым.

## Мөфтилеккә сайлану хәбәре

Бер-ике көн Ташкентта торганнан соң, бераз ял итү өчен Төркестан курортының иң хуш һава җире булган Чимкент шәһәренә барып, элекке елдагы дуслар белән күрешеп, 3–4 көн үткәч, искечә майның 23 ләрендә булса кирәк, Ташкенттан мулла Исмәгыйль Габиттән мөфтилек [белән] тәбрик итү телеграммасы алып, хәйранлыкта калдым. Мәскәүдә 15 майда зур мөселман съезды

булачагы мәгълүм булса да, мөфтилек мәсьәләсе кузгалышы мәгълүм түгел иде һәм минем сайланырга ризалыгым да мәгълүм түгел иде. Ничек сайлаганнар? Берәр көннән соң Әхмәтбәк Салиховтан да телеграмма алдым. Җавап сораса да, тиз ризалык күрсәтмәдем. Казанга кайткач, җавап бирәчәгемне бедереп, телеграмма бирдем. Июнь башларында Казанга кайттым. Юлда һәр җирдә халык кабул итүемне сорап: «Бик кулайсыз вакыт, синнән башка лаеклы адәм юк, бер дәрәҗәдә саклык белән алып баруга иң лаеклы син, бу кадәр милләтнең теләген екма, нәфесләрен бушка җибәрмә», – дип йөдәттеләр. Казанда бер җомгада халыкка сөйләдем. «Боларда мәктәп һәм мәдрәсәләргә реформа гаять тә мөһим, кабул итүең кирәк», – дип уңай тавыш бирүләреннән соң гына Петроградка уңай җавап бирдем.

17 июньдә Уфада рәсми мөфти буларак катнаштым. Бу көчле вакыйгалар вакытында «Хатирә дәфтәре»нә [бернәрсә] язылмаганлыктан, кыскача бу җирдә әзерләнде.

4–5 көннән бирле Мәскәүдә температура бик куәтле, 32 дәрәҗәгә чыккан, диделәр, Төркестан эсселегеннән искәртә. Кояш орбитасы ерак булса да, озын иртә ярдәме белән эсселек байтак арта. Төннәрдә дә бөркү, җил юк, сирәк була торган һава. Ризыклар бик кыйммәт. Уфага караганда ризыклар Казанда ике өлеш югары, Мәскәүдә Казанга караганда ике-өч өлеш югары. Кайбер ишеткәннәрем: сыер мае кадагы биш мең сум, шикәр дүрт мең сум, кара икмәк алты-җиде йөз сум, тоз бер мең сум һәм артыграк, алма-җиләк затлары шулай ук бәһале, карлыган дүрт йөз сум һәм артыгарак икән. Халыкта янә, Аллаһ ярдәме белән, бар, мул. Аллаһ бәрәкәт бирсен!

Мөселманнар ач түгел икән. Вәллаһү йәрзүку мән йәшәъ (Аллаһ кемне тели, шуны ризыкландыра – *А.Г.*).

Мәскәүнең сәясәт һавасы да бик җиңел түгел. Сәясиләр һәрвакытта үзләренең тоткан сәясәте белән барып торалар, халыкның фикеренә һәм сәясәтенә карау юк.

Хәзер безгә бәйле сәясәткә килсәк: мөселман эшләрен күрер өчен куелган Мирсәет Солтангалиев белән очрашып булмый, вакыты юк, бик мәшгуль икән, чөнки дин эшләренә һәм боерыкларына хәҗәтләре юк. Бүген Мәскәүгә килүемә җиденче көн, ничә адәм күреп очрашу өчен вакыт сорасалар да, вәгъдә итә, ләкин вакыт таба алмый икән, вәгъдә үтәлми кала. Чыннан да, эшләре дә бик күптер.

## Бохара вәкилләре һәм Бохара хакында фикерем

Бохаралылар да байтак көннән бирле яталар, бер дәрәҗәдә кадер һәм хөрмәт күрәләр, ләкин эшләре беткәне юк икән. Төрекләр дә шулай ук. Төрекләрнең ихтыяҗлары бар, ихтимал, аларга наз беләнрәк мөгамәлә итәрләр. Бохаралылар белән үзләренә тарту рәвешенчә мөгамалә иткәнгә охшыйлар ки, Бохарага коммунизм кертәсе бар. Бохаралылар исә шартсыз яңарудан куркып, иске ысулларыннан аерылмаска, чакмак чагып, мылтык атуны ташламаска тырышалар. Җәдидләр дип Төркиягә дә бер нәфрәт белән карыйлар. Хәзер ислам дәүләтен саклау, дин ысулын саклау утлы күмерне саклау кебек. Кулда тотсаң, кул пешә, җиргә ташласаң сүнә. Нишләү кирәк, динне саклау тиешле. Бу – һәр мөселманның бурычы, шәхси һәм сыйнфый вазыйфа. Бу да дини һәм тормышның бер вазыйфасы. Дөньяның китүенә карап, күршеколан белән ярышырга, тапталмаска, изелмәскә тырышу да тиешле. Бу да – дин һәм тормыш вазыйфасы. Бу бабта йомшаклык күрсәтү, гомумән, диннең зәгыйфьлегенә, ислам милләтенең югалмавына сәбәп булачак. Шунлыктан олуг кагыйдә булган ислам бөеклеген югарыдагыларга тырышып, күршеләр белән яхшы мөгамәлә итеп, мөмкин кадәр файдаланып, куәт җиткәнчә, зарар һәм җәберләреннән саклану кирәк. Җәдид дип курку, файдалы эшләрдән качу акыллы эш түгел. Бохара үз ихтыяры белән уңайлаштырмаса, халык файдасын күзәтмәсә, җөмһүрият куймаганда да Шура идарәсе төземәсә, зур инкыйлабка очрап, куркыныч көенечкә төшеп, авыр хәлгә калу ихтималы бар. Чөнки Бохарадан җиде чакрым җирдә яңа Бохара (Кәгән) да – Русия милке, анда совет хөкүмәте, 50–60 елдан бирле Русия яклавында торган Бохарада искечә деспотизмны, нәрсә эшләгәнне сорамаучы дәрәҗәсендәге идарәне дәвам иттерергә риза булырмы, әлбәттә, риза булмас. Бу кадәр фәкыйрьләрнең китмән чабып, иген игеп, авырлыклар күргән эшчеләрнең үзләре өчен эшләүчеләр булсалар да, изелеп яшәүләренә чыдамаслар. Кырмыска оясына кечкенә генә таяк тыгылып чуалса, реформа сылтавы белән рәсми рәвештә шәһәрне буйсындырырлар, куәтле һәм көчле рәвештә коммунизмны гамәлгә куярлар. Әмма хәзер җиңел рәвеш белән яхшылык һәм кайбер җиңеллекләр белән боларны риза итү мөмкин була белер иде. Аллаһ хәергә күндерсен!

## Бохара хакында минем фикерем

Минем фикерем: Бохарада ислам падишаһлыгы Шура ысулы белән мәңге булырга тиеш. Исламбулдагы кебек милләт мәҗлесе төзү кирәк. Һәр төркемнән яхшы ихтыяры белән сайлап куелган вәкилләр мәмләкәтнең хәлләрен күзәтергә тиеш. Вәкилләр һәркайсы сыйныфлардан булырга тиеш. Боларның карарлары белән падишаһка эш күрергә кирәк. Мәмләкәтнең үзен сакларлык та коралга ия булырга тиеш. Гаскәренә низамлы, яхшы өйрәтелгән булырга тиеш. Гаскәре һәм милке башлыклары Аурупа һәм Русия тәртипләрен күргән һәм белгән адәмнәрдән булырга тиеш. Яхшы нәшрият ачып ике данә газета чыгарырга кирәк. Берсе рәсми хөкүмәт газетасы, икенчесе халык газетасы. Болар азат сәясәттә булырга тиеш. Газеталарның һәркайсына хөкүмәт һәм башка байлар ярдәм итеп, бәһасе арзан булырга тиеш. Мәхәллә мәктәпләре үзгәртелергә тиеш. Дини дәресләр өстенә хисап, география, заман хәлләре бераз укытылу кирәк. Һәркайсы мәктәп Мәгариф министрлыгы хисабында булырга тиеш. Берәр йөз адәмлек уку йорты сурәтендә бер тәрбияханә (курс) ачып, бик тиз мөгаллимнәр җитештерергә тиеш. Бу тәрбияханәдә динилекне, дин рухын таратуны ике мөһим нокта итеп тотарга кирәк. Бу тәрбияханәдә гыйлем алган адәмнәрне динилекләренә һәм әхлакларына карап, мәктәпләргә мөгаллим итеп билгеләргә кирәк.

Бу мәктәпләр һәр мәхәлләдә булмаса да, бөтен Бохара шәһәрендә иллегә кадәр булырга тиеш. Башка шәһәрләрдә шулай ук үз гадәтләренә нисбәтле төзелергә тиеш. Бу мәктәпләргә, әлбәттә, балалардан электәге рәсми пәнҗешәмбе кебек ярдәм алыныр. Заманасына күрә, халыкның эшенә күрә алып, мәктәп чыгымнарына, тиешле китапларны әзерләүгә сарыф ителер, җитмәгәнне хөкүмәт үзе күндерергә тиеш. Бу мәктәпләрдә мөмкин кадәр иске мөхтәрәм китапларны укыту тиешле. «Дүрт китап» кебекләр, әлбәттә, укытылырга тиеш. Матур язуга игътибар итәргә кирәк, бер ел мәктәптә дәвам иткән бала уку-язу белсен. Мәдрәсәләргә килгәндә, мәдрәсәләрне, вакыф булганлыклары өчен, шәригатькә каршы идарә итүдән, сафсатачылардан азат итеп, сату-алудан акрынлап чыгару тиешле. Вакыфларның шартларын кайгыртып, тиешле юлына кую кирәк.

Дәрес программасы исә, дәрес бирү-аңлату рәвешләре, Бохарада кимчелексез яхшы дип әйтү мөмкин. Шәкертнең алдан

әзерләнеп килүе, аңлаган кадәрлесен остазга сөйләп, тәнкыйтьләү һәм җитешсезлекләрен күрсәтү ысулы – укучы өчен иң файдалы тәртип. Бу ысул Америка һәм Ауропада күп тәҗрибәләрдән соң гына беленеп, кабул ителгән, Америка мәктәпләрендә гамәлгә куелган. Төрекләрнең, русларның мөдәррисләр тарафыннан гына сөйләнеп бирелә торган ысулга караганда бу рәвеш күп дәрәҗәдә файдалы. Бохарада укучыларның башкаларга караганда тикшерү һәм хакыйкатьне эзләү бабында булулары бу сәбәптән булса кирәк. Бары өйрәтелә торган маддәләр алмаштыруга мохтаҗ. Бу иске хәлләре начар җиргә начар орлыкны яхшы осталык белән чәчү кебек, яхшы нәтиҗә бирми. Дәрес календарьле, дәрес китаплары тәмам алмаштырылырга, кирәксез, файдасыз мантыйк һәм хикмәт дип укып йөргән нәрсәләре һәм афәтле әсәрләре төшереп калдырылырга тиеш. Һәр фәнне кирәгенчә сайлап, бөтен иске белән бөтен яңа арасында хәерле урталыкка куярга. Ысуллы хисап, геометрия, табигать турындагы яңа фәннәр кабул ителергә, илаһияттән файдалы, аеруча нурландырган илаһиятне кертергә. Озын-озын китаплардан сак эш итәргә ки, ахун Йосыф, ахун шәех әсәрләре, мулла Әхмәд, мулла Габделхәким әсәрләре кебек китапларның кирәкләре юк. Болар урынына кыска ысул белән Коръән тәфсирен, хәдис укыту, гарәп телен укыту, гарәп әдәбиятын кертергә. Бу дәресләр яхшы ысулга куелганда, янә элекке заманнан кыскарак вакытта тәмамлана белер. Гарәп синтаксисы һәм морфологиясеннән башланып, 12–13 елда шәригать һәм гарәп гыйлемнәрен, акыл һәм математика фәннәрен бер дәрәҗәдә тәмамланыр, иншалла.

Вәгазь: ысулсыз, надан, имансыз мактаучыларга соңгы чик биреп, атнада кимендә ике көн бөтен шәһәрдә 3–4 җирдә изге галимнәр тарафыннан Изге китап һәм пакь сөннәттән вәгаз әйтелергә тиеш. Бохарада кереш сүзнең нигезе укылган сира рәвешенчә генә булмыйча, ягъни китап уку ысулынча гына булмыйча, яхшы вәгазь сурәтендә, рухлы рәвешчә вәгазь һәм нәсыйхәт ителү, шул вакытта халыкка дин, дөрес ышану һәм яхшы әхлак өйрәтү тиешле. Шул вәгазьләр астында кайбер бидгатьләр, халыкта гадәт булып киткән кайбер шәригатькә туры килмәгән эшләр бетерелергә тиеш. Әлбәттә, чын ияләре тарафыннан бирелгән бу вәгазьләр матур тәэсир итәр, халыкның әхлагы төзәлүенә ярдәм итәр иде. Бу мәктәп-нәсыйхәт баблары кебек шәһәрләрдә һәм авылларда да эшкә ашырылыр иде, әлбәттә.

Шулай ук хатын-кыз галәменә мәрхәмәтле карауга алу тиештер ки, наданлык, намазсызлык белән ислам галәме эчендә Бохара мисал итеп китерелер дәрәҗәгә килгән. Боларны яхшы укыту, яхшы тәрбия итү, әлбәттә, кирәкле. Болар өчен булган мәктәпләрне дә яхшырту һәм боларның олылары өчен вәгазь мәҗлесләре төзү кирәк. Кимендә атнага бер мәртәбә гыйлем бирү кирәк. Бер карт галим берәр җомгада вәгазь мәҗлесе ачса, пәрдә астында булып, кыз һәм хатын тыңласалар, һичбер төрле зарар булмыйча, дингә файда һәм ярдәм хасил булыр. Бу реформа бабында башта падишаһ, соңра галимнәр җаваплы. Болар өммәтнең төзеклеге, яхшылыгы өчен кайгыртырга тиеш. Бер дәрәҗәдә генә пәйгамбәрнең тормыш юлына карасыннар, хөрмәтле сәхабәләр һәм табигыйн (ридъвәнүллаһи галәйһим) гамәлләренә мөрәҗәгать итсеннәр – кайсы эшләрен муафикъ күрерләр. Бу минем язганнарымны да сира һәм сәхабәләр тарихларына яраклы итеп күрсеннәр, иншалла, муафикъ табарлар. Иннә үриду илләл-исъләхү мә истәтагтү вә мә тәүфикый илләә билләһ (Чынлыкта, мин реформа телим, тик булдыра алмыйм. Ярдәм Аллаһтан гына – *А.Г.*).

## Милли эшләр комиссариаты әгъзасы

Якшәмбе көн беренче августта Мирсәет Солтангалиев белән очрашу булды. Бу кеше Шура хөкүмәтендә игътибарлы комиссар: 1) милли эшләр комиссариаты коллегиясендә әгъза, мөселман комиссары; 2) шәрык халыклары коммунистларының Мәркәз бюросы рәисе; 3) Мәркәз мөселман хәрби комиссиясенең рәисе. Бу кешегә шәрык мәсьәләсенең мөселманнар карашында да әһәмияте барлыгы, Исламбул һәм хәлифәлек урыннары изге җирләренең инглиз, юнан һәм башка Антанта дәүләтләренең кулларында булуы мөселманнарны кайгыртканлыгын, шунлыктан Шура хөкүмәте бу бабта мөселманнарга ярдәм итәргә тиешлеген, мөселманнарның да хөкүмәт белән дустанә һәм хәерле мөгамәләдә булырга кирәклеген сөйләдем. Бу теләк өчен 3–4 маддәне мөһим күрсәттем:

1. Шура тарафыннан олы һәм кече идарәләрдән мөселманнарның диннәренә әдәпсезләрчә һөҗүм һәм протест булмаска, аларның дини хисләрен кайгыртырга тиеш.

2. Мөселманнарның үз акчаларына салынган мәктәп һәм мәдрәсәләре диннәрен укытыр өчен ихтыярлы булырга, дин укытуга һичбер юл белән кысылмаска тиеш.

3. мөселманнарның үз суммалары белән төзелгән Диния нәзарәте бинасы бөтен әсбаплары белән мөселманарның үз кулларында булырга, хөкүмәтнең һичкайсы идарәсе өчен алынмаска тиеш. Бу бинаның – кирәк гаскәри идарәләр өчен, кирәк музей өчен – бер бүлеге булса да, алынуы мөселманнарның дини хисләрен кузгата, борчый.

4. Мөселманнарның барча рухани бүлекләре – ызанчыдан башлап мөфтилеккә кадәр булган кемсәнәләр – бар да халыкның йөздә туксан тугыз крестьян һәм эшче булу сыйфаты белән сайлап куелган хезмәтчеләре. Шунлыктан боларны хөкүмәттә халык хезмәтчеләре [итеп] танып, гаскәри һәм башка хезмәтләрдән гафу ителүе тиешле.

5. Мөселман гаскәрләрен күбрәк Шәрыкне коткаруда инглизгә каршы куюю тиешле, Истамбулны коткару бабында мөселманнар җитди хәрәкәт итәчәкләр.

6. «Кызыл муллалар» дигән оешма хөкүмәт сәясәте өчен зарур. Бу оештыру муллаларны икегә аерып, күбрәк өлешен хөкүмәттән ераклаштырырга хезмәт итәчәк. Бу исә хөкүмәтнең таләбе түгел, хөкүмәт һәр кайсы мулланы үз кешесе, үз гражданы итеп күрергә тиеш.

7. Дәүләт никях, талак кебек вакыйгаларны язуда һәм волостьларда язу халык өчен бик кулайлы. Бу эш яраштыру мөмкин булуын уйламыйча куелган. Һәр авылның үзендә язу тиешле. Бу эшне дә муллаларның үзләренә тапшырып, атнага яки унбиш көнгә бер мәртәбә волостька ведомость бирү ысулын тоту тиешле, бу рәвеш белән муллаларны эшкә кертү һәм аларны җәлеп итү халыкка байтак җиңеллек булыр.

8. Шура хөкүмәте өчен көрәш заманында, сәясәтләр тәмам урнашып җитмәгән вакытта кечкенә нәрсәләр белән маташу, аз файда өчен халыкны шикләндерү тиеш түгел икәнен дә бәян иттем. Бу мәсьәләләр байтак озын бәян ителгәнгә, Мирсәет иптәш язып бирүне аңлатты, мин дә язып бирәчәк булдым.

Сүз сентябрьдә булуы уйланылган киңәшмәгә күчеп, кайбер гади адәмнәр сәясәт бабына кереп, Шура хөкүмәтенә каршы сүз һәм хәрәкәт булудан куркуын бәян итте, хөкүмәтнең кайбер мөселман булмаган әгъзалары мөселманнарда күренгән аз гаепне бик

күбәйтергә торуларын, хөкүмәт алдында мөселман җәмәгатен пычратырга ниятләүләрен, омтылышларын сөйләп үткәрде. Рәшит әфәндене дә кайбер мөгамәләләре белән хөкүмәт шактый шөбһәгә калганын, хәтта аның сәбәпле, Бәрәкәтулла һәм Муса әфәнделәр хакында да шөбһә беләнрәк каравын аңлатты. Муса әфәнденең митингтагы мөгамәләсен дә әйтеп үтте.

Минем аңлавыма күрә, бу кемсәнә коммунист булса да, мөселманнар мәсьәләсендә туры фикерле, яхшы теләк итүче булып күренде. Хәер, сәяси адәмнәрне аңлау да – авыр эш. Минем кебек гади адәмнәргә ялгыш аңлау һәм алдану бик мөмкин. Ләкин күп халык бу кеше хакында яхшы фикердә һәм яхшы уйлауда. Хөкүмәт хезмәтендә шундый адәмнәрнең булуы мөселманнар өчен файдалы. Әлбәттә, болар хөкүмәтенең сәясәтен һәм канунын кайгыртуга мәҗбүр – вазыйфалары. Шулай да, аларның ул даирәләрдә булулары, күбәюләре тиеш.

Мин һәрвакытта Мулланур Вахитов мескенне кызганам, кызгануымны халыкка белдерәм. Минем аңлавыма күрә ул адәмне үтерү тиеш түгел иде, вөҗданлы, мәрхәмәтле егет иде. Мәгърифәте, хезмәте, әманәте яхшы булганга, хөкүмәттә зур урын тотуы мөмкин һәм мөселманнарга да бөек юлбашчы булуы өметле иде. Мөселманнарга, аеруча муллаларга арага кереп, чех-славян хөкүмәтеннән сорарга һәм сәламәт калдыртырга тырышырга иде. Шулай ук кызылларның мулла Габдулла Апанайны үтерүләре хата эш булган, хөкүмәтнең сәяси хатасы булган ки, югарыда әйтелгән [зат] хәзер дә Шура хөкүмәте тарафлы адәм булмаса да, затында инкыйлабчы, буржуазиягә каршы, тугры мантыйклы, икейөзле булмаган, риясыз бер адәм иде. Ахмак дустан акыллы дошман артык икәне тәҗрибә һәм мантыйк белән ачык мәсьәлә. Икенчедән, бу адәмнең алдагы көндә Шура хөкүмәте өчен файдалы адәм булып чыгуы бик ихтимал иде. Кайгырдылар, мөселманнар да бик кирәкле адәмен югалттылар.

Менә бу ике адәмнең югалуына мин кайгырам, башка коммунистларга сөйләгән кебек, Мирсәет әфәндегә дә бу мәсьәләне сөйләдем. «Ашыгыч булган, мин кайтып җитмәгән идем. Кайткач, күп адәмнәрне һәлак итү списогыннан чыгарттым», – диде.

Кыскасы, бу адәм белән бер сәгать кадәр яхшы, аулактагы сөйләшүебездән соң, чәй мәҗлесебез булып, Салих Ирзин йортында йорт хуҗасы бәян итүче Сәлимзадә әфәнденең ихтирамын кабул

итеп, төнге сәгать 12 узгач, Мирсәет әфәнде хатыны Фатыйма бинте Әхмәд бине Ирзин белән кайтып китте.

Без дә төн уртасында төп йортыбызга кайтуны авырсынып, өй хуҗасы тәкъдиме, хәтта үтенүе һәм кыставы буенча, кичкә шул йортта калдык. Ләкин 3–4 сәгатьтән артык йоклау мөмкин булмады. Куе чәй күп эчелгән, фикер кузгалган, чын йокының табигый вакыты булган ул төн үткәч, табигый булган йокы теләге азайган. Йокы да, минем теләгән вакытта рөхсәт итмәдең, дип үпкәләп, инде мин теләмим, дигән кебек качкан була. Чыннан да, сәламәтлек саклау һәм табигать канунын саклау өчен йокы ул төндә булу кирәк. Кичексә, бары ул вакытында ястүне үтәр кадәрле кичегеп, соңра ул бу фикер кузгатырдай сүздән юк булып, тиз йокы ятагына ашыгу белән бәдәннең югалган куәтләрен кайтару тиешле. Хикмәт һәм фәлсәфә буенча бәдәндә һәм тамакта уяулык һәм куәт, һәртөрле хәрәкәтләргә ярдәм бирүче нәрсә кояш белән булганлыктан, йокы вакытының иң кадерлесе һәм яхшысы – кояшның ераграк киткән вакыты яки кояштан ераграк узган вакыты. Шунлыктан сәламәтлек саклау галимнәре йокы вакытының яртысы ярты төнгә туры килергә тиеш, дигәннәр. Шул вакытта гына йокы тулы һәм саф йокы була. Бу вакыттагы йокыда рух аны-моны күреп чуалмыйча, ваемсызлык белән рәхәт күрә. Башка вакытта исә саф йокы булмый, ярым йокы, ярым уяулык, төрле төш белән чуалып, киселеп, башка файда китерми. Төшлек чорларындагы аз вакытта гына булган бер ялдан башка вакыттагы йокыларда бу хәл тәҗрибә ителә. Ни булса да, бу кичә шулай үтте. Һәрвакытта да йокым бик зәгыйфь булганлыктан, аз гына хәрәкәт сәбәпле, бөтенләй югала торган булганлыктан, кичке әңгәмәләрдән качу гадәтем булса да, бу сөйләшү зарур булганлыктан, үтәдем. Аллаһ ахырын хәерле итсә иде! Файдалы нәтиҗәләр туса, берничә кичне дә фида итү бик зыян түгел. Иншалла, хәерле булыр. Көндез сәгать 10 да торагым булган Карамышевлар йортына кайтып, бу сөйләшү нәтиҗәсен яздым. Вәс-сәлам!

Дүшәмбе көн икенде вакытында Мәскәүнең гыйлем һәм фикер ияләреннән, сәүдәгәрләреннән Гариф бине Хөсәен Бурнаш торагыбызга килеп, берәр сәгать кадәрле сөйләшеп утырдык. Бу кемсә Бохара һәм Төркестан малы белән сәүдә итеп, ул тараф халкы һәм холкы белән дус. Тәҗрибәле, ихтирамлы кеше булып, Мәскәү кешеләре арасында игътибары куәтле. Бохаралылар өчен күп кайгыртып, һичбер юл белән яхшылык тарафына төшмәүләрен һәм бу килгән вәкилләрдән һич нәрсә тумаячагын ачынып сөйләде. Юга-

рыда язылган Бохараны үзгәртү турындагы фикерләремне җиткереп, болар белән әмиргә тәкъдим итү бабында фикерен сорагач, алып китмәсләр, әмир үтерер, дип куркырлар, диде. Хива ханы Әсфәндияр хан атасы гасырында солых вәлие икән, бездән ысуле җәдид мөгаллиме соратып, Тәүфикъ бине Сафа Чирмешанины җибәргән идек. Хан булганнан соң да байтак туры хәрәкәтләр булды. Ләкин чиктән артык сәләтлелеккә ия булмады булса кирәк, мәмләкәтне яхшы сыйфатлы итә алмады. Төрекмәннәргә каршы яхшы мөгамәлә дә була алмыйча, Җәнид хан белән байтак орышып, ахырда һәлак булды.

## Бер кабардин белән сөйләшү

3 август көнендә кичке сәгать 5 тә Мирсәет Солтангалиев баҗалык мөнәсәбәте белән кунакка чакырган иде. Өч сәгать булдык. Хатыны Фатыйма бинте Әхмәд бине Салих Ирзин булып, хатыныма атасы белән бертуган кыз кардәшенең оныгы була. Бу мәҗлестә әһәмиятле эш һәм сүз булмаса да, югарыда искә алынган затта йомышыбыз да булганлыктан, күркәм мөгамәлә иттек һәм дуслаштык. Монда Кавказ гражданнарыннан кабардин Нәзир бине Гаделгәрәй исемле бер укымышлы шәкерт очрады. Яхшы гарәпчә һәм русча сөйли, мәмләкәтләре кулдан кулга күчү белән төрле авырлыклар күргән, кайберләрен аклар, кайберләрен кызыллар үтергән. Инде бу адәм: «Сәясәтем, эшчәнлегем белән коммунистмын, динем һәм шәригатем буенча мөселманмын, динне һичбер рәвеш белән киметергә һәм зәгыйфьлек китерергә ярамый, шәригать өчен үлү тиешле», – ди. Солтангали гаиләсе дә мөселман мулла коммунист дип тәкъдим иткән иде. Бу халыкның тормышына күрә, тормышның һәм сәясәтнең коммунизмы бик ерак түгел икән. Чөнки өлкәсендә сәүдә юк, сәнәгать юк. Тик игенчелек белән яшиләр икән. Күбесе фәкыйрь, үз көче белән тормыш итә торган халыклар. Тик юллары буенча большевиктан бигрәк меньшевикка якынрак булуларын да сөйләде. Мәсәлән, җир мәсьәләсендә иске хуҗаларыннан бөтенләй алмыйча, иясенә һәм башкаларга бүлү юлын яхшы таба. Боларның, җир хуҗасына бер дә бирмичә, халыкка бирүләре бер дә урынлы түгел.

Җирне иске хуҗаларыннан алуны шәригатькә яраклаштыруда әйтә: «Күпчелеккә күрә, асылында, шәригатьтән ерак булган,

тартып алынган җирләр. Форсат һәм кодрәт булганда кайтарылып, иске хуҗаларына яки мөселманнарның казнасына тапшырылырга тиеш. Шул юл белән алардан алынып, мөселманнарга бүлеп бирелүе шәригать буенча дөрес булса кирәк, ләкин үзенә дә өлеш чыгарырга тиеш». Ни булса да, ышанулы, иманлы, тартынып кына булса да шәригатькә яраклы итәргә тырышуы яхшы. «Халкыбызның динилеге яхшы һәм котлы, имамнарның гарәпчә белмәгәне, сөйләшмәгәне юк», – ди. Нигездә, көньяк халкы – зирәк, сәләтле, кызу канлы, йөгерек зиһенле халык. Безнең Бохара галимнәренә карaганда мактау һәм туры юл әсәрләреннән хәбәрләре аз булса да, кирәкле урыннарда бохаралылардан дәрәҗәләре югары. Бу сәясәт бабында да байтак мәгълүматы бар. Бохара вәкилләреннән берәр сүз дә ишетә алмадык. Бу Нәзир әфәнденең бер галиҗәнаблеген соңра ишеттем: Мәскәүдә бер рус кызын никяхлап, исламга керткән икән. Бер көнне татар театрына барырга җыенганда, хатыны кәефсезлек күрсәтеп, өйдә калган. Бу да бераз вакыттан өенә кайтса, хатынның кәефе төзәлгән булса кирәк ки, өендә булмыйча башка берәүнең торагында булган. Нәзир гайрәтен тыя алмыйча, аны шунда ук үтерү нияте туа, хатынны аткан, хастаханәгә китергәннәр. Нәзирне дә тоткын итеп, бер кичә үткәреп, янә рөхсәт алган, чыккан. Күбрәк ирлек гайрәте белән бәйле үтерүләр элек тә гафу ителә иде, бәлки, бу хөкүмәттә кан бик арзан вакытларда бигрәк тә, аеруча коммуннардан гафу ителсә кирәк. Сөйләшүендә җаны тыныч кебек күренә, әлбәттә, имин. Нигездә, андый-мондый эшләрдә борчылмый торган, һәртөрле вакыйгаларда салкын кан белән каршы тора торган йөрәкле адәмнәр, ягъни кеше әхлагындагы кешеләр.

Хатын-кыз бабында гайрәт – ирләрнең табигый һәм фитри (туганда ук Аллаһтан бирелгән нәрсә – *А.Г.*) булган вазыйфасы. Хәтта хайваннар да бу бабта көнче һәм гайрәтле була. Ләкин соңгы заманнарда христиан һәм яһүд халкында, ягъни, гомумән, Аурупа халкында бу гүзәл холык бетеп бара, бу мактаулы булган гайрәт югалып бара. Ир хатынын, хатын ирен күп көнләми һәм сакламый, тәрбияле адәмнәрдә каты әхлак булмый, үзләрен яхшы тоталар, дигән сүз йөртәләр һәм алданалар. Бу бозык тормышка Аурупаның Румнан калган бу бозык әхлагына безнең мөселманнар теләге дә, икенче төрле әйткәндә, маймыллыктан чыгып җитмәгән яки үзләре сизмичә маймыллыкка кайтырга тырышучылар да бу ысулга ияреп бaралар. Нәсел катнашуына, кан бозылышына һәм башка гаилә

бозыклыгына, тормыш низамсызлыгына караган һәм сәбәп булырдай күп эшләрне юлга салалар.

Бер шарт: элекке вакытта җитмешенче елгы сугышлардан элек Солтан Габделгазиз гасырында, Франция императоры икенче Наполеонның Солтан белән котлы мөнәсәбәтле вакытларында әзер җаваплылык белән билгеле Фуад паша Парижда булганда, Наполеонның хатыны бер сөйләшүдә Фуад пашадан: «Ислам хатыннары ни өчен ирләрдән качалар, аралашмыйлар», – дип мәҗлестә кызартырга теләгән. Фуад паша төреклек осталыгы, иман һәм ислам гайрәте белән җавабында бер җөмлә әйтә, җөмләсе дә хатынның гомере буенча онытылмаслык ядкяр булган: «Нәсел-нәсәп мәгълүм булмый», – дигән. Мәҗлес әһелләре көлешкәннәр.

Гәрчә Аурупа хатыннарында оялу аз булса да, хатын байтак оялган. Наполеон әйткән ки: «Әйттем сиңа, сорама, Фуад тиз җаваплы һәм яман телле адәм, оялтыр, дидем». Вакыйга Фуад паша мәрхүмнең җавабы зур дини фәлсәфәне һәм ислам гүзәллекләреннән олы бер әхлак кагыйдәсен аңлатырлык җавап. Гафәраллаһү ләһ (Аллаһ аны гафу итсен – *А.Г.*)! Искә алынган хатын исламның зарарында күп хәрәкәтләр кылган, яшәр булса, янә күп кылачак хатын булган. Хәерлелек белән Аллаһ дәүләтләренең гомерен кыска кылган. Безнең Николай кебек, Пруссиядән җиңелеп, зур инкыйлаб сәбәпле, югалганнар.

Искә алынган сугыш алдында да Исламбулга килгәч, олы йөрәк беләнме, башкасы беләнме бер сөйләшүендә һәркайсы динсезләр кебек эче пошып: «Мөселман хатыннарыннан ничек бу хиҗабны бетермисез, хатыннарны мәйданга чыгарырлык прогресс һәм яраклылык (үзенең бозык фикеренчә, әлбәттә) юлына куймыйсыз?» – дигәч, искә алынган вәзир, сүз озайтасы килмәгәнлектән булса кирәк: «Галимнәр риза булмаслар», – дигән. «Алай булса, андый галимнәрне бетерергә кирәк, мәдәнияткә (Франция мәдәнияте, кешелеккә афәтле һәм зарарлы булган мәдәниятне әйтә) каршы һәм зарарлы булган дин галимнәре ник кирәк», – дип бер зур бозыклык һәм зур фетнәнең орлыгын игү ниятенә керешкән икән. Шул арада ук Париждан: «Пруссия белән сугыш ачыла, тиз кайт», – дигән телеграмма хәбәрен алып, кирегә әйләнеп һәм каһәрләнгән [хатын] чаба-чаба игелексез мәмләкәтенә китәргә мәҗбүр булган, ислам галимнәренең дә «әлхәмдү лилләһ» (Аллаһка мактау – *А.Г.*) диюләренә сәбәпче булган. Шул сугыш 1870 елда булу сәбәбе белән, «70 нче сугыш» исемендә телгә алына. Шул сугышта Фран-

ция Пруссиядән нык җиңелеп, императорлык асты-өстенә килеп, җөмһүрият төзелде. Ислам галәме бераз сулыш алды. Юкса, болар солтан Габделгазизне Парижда кунак итеп, тәмам аның белән идарә иткәннәр, чөнки солтанлыкларына тәмам кертә язганнар иде. Аллаһның ислам галәменә мәрхәмәте һәрвакыт файда итүдә. Иншалла, бу заманда да файда итәр. Иман һәм тәүхид ияләрен хур итмәс.

## Төрек вәкилләре белән сөйләшү

Чәршәмбе көн 4 августта Сәлахетдин, Сәйфетдин исемле итчеләрдә мәҗлес булып, төрек вәкилләре белән озын сөйләшү булды. Солтан Вахидеддин бине Габделмәҗиднең муафикъ һавасы кабинет тәшкил итеп, Антанта белән солых, аларның тәртип һәм тәкъдим иткәне, бөтен ислам милләте өчен мәҗбүрләү булган килешүгә имза куячагы зур кайгы белән сөйләнде. Хәзер кабинетта элекке кияве Фәрид паша олы йөрәклектә калып, хәрби батырлыгы өстәлгән.

Бу вәкилләрнең фикерләре исә: «Солтан Вахидеддин лаеклы ислам хәлифәсе түгел, мөселманнарның дини, дөньяви һәм сәяси мәнфәгатьләренә карамас, җитмеш яшенә килгән хәлдә, тик үз шәхси мәнфәгатьләренә карап, шәһвәт ләззәтләрен кайгыртып, милләт эшләреннән ваемсыз. Мондый адәм хәлифәлек чылбырында утырырга лаек булмас», – диделәр. «Хәлифәлек мәсьәләсе – тик Төркия мөселманнары өчен түгел, гомумән, җир йөзендә булган мөселманнарның уртак мәсьәләсе. Шуңа күрә һәммә мөселманнарга бу бабта кайгырырту һәм уртак мәсьәлә итеп, шәригать йөзе белән хәл итүдә нык тырышу тиешле. Төркия хәлифәлеге падишаһы – һәммә мөселманнарның хәлифәсе. Шуның өчен һәр җир мөселманнарының төрле сыйныф вәкилләре Анатольдә тупланып, сөйләшеп, бер карарга килсәләр, бер дини вазыйфаларын үтәгән булырлар, ди», – диярләр.

## Хәлифәлек мәсьәләсе

Миннән дә сөйләшү вакытында хәлифәлек мәсьәләсе, аның дини вазыйфалары һәм башкаларын сорасалар да, мәсьәлә зур һәм әһәмиятле булганлыктан, аз арада хәл итү мөмкин түгел, һәр яклап тикшерү һәм өйрәнүгә мохтаҗ булганын бәян белән аңлаткан идем.

Бу хәлифәлек мәсьәләсенең тиешенчә хәл [итү] өчен бу олы мәсьәләләрдә тиешенчә карау тиешле:

1) хәлифәләр нәрсә ул;

2) Аллаһ рәсүле салләллаһү галәйһи вә сәлләмнән килгән хәлифәлекне утыз елга билгеләвенең мәгънәсе;

3) Габбаси хәлифәләре ничек хәлифәләр дип аталдылар;

4) Госман солтаннары, кораеш [кабиләсеннән] булмаган хәлдә, ничек хәлифә дип аталдылар;

5) хәлифә дип аталган һәм куелган кемсәнә урыныннан төшерелерме;

6) ни кебек сәбәпләр белән урыныннан төшерелер;

7) хәлифәлек исемен күтәргән Госман солтаны Вахидеддин бине Габделмәҗид хакыйкать белән (ягъни соңгы атама белән) хәлифә идеме;

8) бу адәм урыныннан төшү һәм чыгарылу күрсә, ни кебек сәбәпләр бар;

9) инглиз боерган килешүнең хакыйкате ни;

10) аның зарарлары фәкать сәясиме яки дини дә, сәяси дә;

11) Вахидеддинне урыныннан алып, аннан хаклырак бер зат булып, аны кую мөселманнарның көчендәме;

12) бу мәсьәләдә Төркия мөселманнары, төрек һәм гарәп – барысы да берләшә алырмы;

13) боларга Русия, һинд һәм башка мөселманнар кушыла алырмы;

Беренче, икенче мәсьәлә – хәлифәлекнең мәгънәсе, утыз елга билгеләнүе[19]:

Ислам хәлифәлеге хакыйкате буенча, пәйгамбәрлекнең Аллаһ вәхиеннән башка, туры юл вазыйфаларын һәм сәясәтен үтәү, аннан калган туры юл, бирелеп китү сәбәпләре һәм мәмләкәтнең уйлап эшләвен тиешле рәвештә күндерү. Бу хәләт өчен пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вә сәлләм кебек дөнья ләззәтләреннән баш тартулар, дини һәм милли мәнфәгатьләрдә фидакарьлек тиештер ки, тәҗрибә белән изге хәлифәләр радыяллааһү ганһүмнән башкада бу хәләт күренмәгән, тик Гомәр бине Габделгазиз радыяллаһү ганһү. Аллаһ рәсүле салләлллаһү галәйһи вә сәлләмнән: «Хәлифәлек миннән соң утыз ел, соңыннан патшалык булыр,» – дигәне ачык бер могҗиза ки, утыз ел тәмамланудан соң никадәр дини әдәп һәм

[19] Хәлифәлек һәм әмирлек турында килгән кайбер риваятьләр. [...].

ислам әхлагы саклансада, хәлифәлек патшалык сортына алмаштырылган. Бу тарихта билгеле.

3 нче мәсьәлә габбаси хәлифәләре һәм алардан элек Бәни Үмәйя хәлифә [дип] аталдылар. Тик Бәни Үмәйя төркеменә ислам милләтенең карашлары салкын була килгәнлектән, аларга хәлифәлек чылбыры бик тоташмаса да, габбасиларга һичшиксез тоташа иде. Аеруча боларның кулларында сәясәт һәм мәмләкәтләр белән идарә итү урыннарын саклау өчен әмирләр һәм солтаннар төрекләр тарафыннан тартып алынгач, солтаннарның да авторитетын арттыру өчен хәлифәлек исеме белән аталып, бу исемне бөекләндерделәр, үзләренең солтанлыгын һәм бөеклекләрен саклау өчен хәлифәлекне сәясәттән башка бер дини урын хөкеменә керттеләр. Асыл шәригать тарафыннан танылган хәлифәлек вакыты узса да, мөселманнарның сәяси идарәләре дә дини идарә һәм динне саклауга ияреп, игътибар ителгәнлектән, бер дини идарә саклануы, ислам галәменең тәртибе һәм саклануы тиешле күрелеп, бу урынның исемен булса да дәвам иттерү, искә алынган солтаннар һәм кешеләр тарафыннан тиешле күрелеп, бу урынның исемен булса да, дәвам иттерү искә алынган солтанлыкны һәм кешеләре тарафыннан тиеш күрелгән. Димәк, хакыйкый хәлифәлек булмаса да, хакыйкый хәлифәлек кебек мөселманнар өчен, бер яктан, бер дини берләшү булып торган. Ләкин бу хәлифәлек чын имамлык мәгънәсенә кабул ителгәнлектән (имамнар Кораеш [кабиләсеннән]), башлангыч вакытында ук сәхабәләрнең бердәм карашы белән хупланган һәм шуңа таянып, ансарларның (Мәдинә шәһәре кешеләренең – *А.Г.*) имамлыгы һәм хәлифәлеге кире кагылган иде. Бу як ки карау белән дә хакыйкый хәлифәлек тә һәм аңа охшаган рәсми хәлифәлек тә Корәеш [кабиләсеннән булмаган] башка кешедә булмаска тиеш иде. Ләкин югарыдагы бер сәяси тиешле чара өчен, госманлы солтаннарның хәлифә дип кандидат ителеп, солтан Сәлим мәрхүм Мисырны басып алганда, хәлифә буларак танылган Габбаси хәлифә Габделгазиз бине Ягкубның һәммә сәяси эшләре искә алынган солтан кулына күчкәндә, хәлифәлекне дә, үз малы, үз халкы итеп, солтан Сәлимгә тапшырган иде. Гүяки, шул тапшыру белән солтан Сәлим мөселманнар хәлифәсе булды һәм мөселманнар тарафыннан хәлифә дип танылды. Аннан соң килүчеләр дә, падишаһ булу белән, хәлифә исемен күтәреп килделәр. Болар, хакыйкатьтә, бер солтан иделәр. Күпчелегендә мөселманнар мәнфәгате һәм кайгысы булды. Исламга байтак хезмәт иттеләр. Шул мөнәсәбәт белән мөселманнар

боларның хәлифә исемен күтәрүләренә яхшы күз белән карадылар. Тәмам лаеклы бер исем булмаса да, үзләренә үзләре бер юаныч биреп, бу исемне йөртеп килделәр. Ләкин бу эш өчен дә яраклы булу кирәк. Иң мөһиме исә диндарлык, дин юлында фидакярлек, намуслылык зарур. Мөселманнарның дини хисләре, котлы ихласлылыгы аның тарафына күңел куйсын: габбаси хәлифәләре вакытында күп мөселманнарның Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән чыккан имамнар тарафларына мәхәббәтләре, хәтта имам Әбү Хәнифә вакытындагы имамны, Мансур димичә, Зәед бине Гали бине Хөсәен радыяллаһү ганһүмне тануы бу дини рух, намуслылык һәм динне ихтирам итү сәбәпле булса кирәк.

Бу кадәренчә бәян белән 4 нче мәсьәлә дә хәл ителгән булса кирәк.

5–6 нчы мәсьәләләр – имам һәм хәлифәнең нинди эш белән булса да туры килмәве билгеле булса, мөселманнарның дини һәм сәяси эшләрендә көчсезлеге яки мәнфәгате бәясендә, зарар ихтимал тотылса, урыныннан алына белер. Габбаси хәлифәләреннән күпсанлы хәлифәләр урыннанрыннан алынганнар иде. Мөселманнарның гомуми мәнфәгате һәр бүлектә кагыйдә булып, күрелергә тиеш булуы кебек, бу бүлектә дә мөһим булып кала.

7 нче мәсьәлә – Вахидеддин хәлифәме? Госманлы солтаннарына әйтелә торган мәгънә белән, ягъни бер ясалма мәгънә белән хәлифә. Ләкин хәлифәлек вазыйфаларын үтәүдә падишаһлыктан артык эше юк. Бу падишаһларда үзләрен саклау, рәсми падишаһлык гадәтен үтәүдә артык куәт, гайрәт һәм дәрт юк. Башка җирләрдә булган мөселманнарны кайгырту кайда, үзенә буйсынучы булган Төркиядә дә дини һәм әхлак кайгыларын кайгырту юк. Шунлыктан боларда охшату һәм күчерелмә мәгънә белән дә хәлифәлек, Аллаһ ахырын яхшырак белүче, юк. Хәлифә исемен бирү бары коры бер куаныч. Гарәпләрнең тәртибе өчен, мәмләкәттән читтә булган мөселманнарның күңелләрен җәлеп итәр өчен бер тиешле чара.

Гарәпләрдә байтактан бирле яшерен бер фикер йөри: госманлы падишаһларыннан эшлекле бер адәм, сәләтле бер көч иясе тугач, искергән агачны ашлап куәтләндергән шикелле, ислам солтанлыгында бер яңару булса, хәерле нәтиҗә тумасмы, дип, гарәптән, Бәни Һашимнән бер хәлифә торгызу, исламның башы да гарәп тырышлыгы, гарәп зирәклеге белән калыккан иде, янә бер гарәп хөкүмәте белән яхшылык күрмәсме, өмете белән фикри хәрәкәт йөрер иде. Ләкин бу мәсьләгә бердәмме, төптән үкме инглиз мәкере

кушылганлыктан, тарафы югалып, күбесенең чигенүен җәлеп итә иде. Әлбәттә, инглизнең бу фикере күп еллардан бирле мәйданда йөри. Инглиз бу эшне ислам галәменә хәерлелек белән эшләми. Фикере һәм бар сәясәте үз файдасына гына булган бу дәүләт сәясәттә өстен. Әлбәттә, шулай булачак. Аныңча, бу гарәп дәүләте – гарәп хәлифәсен үз мактанычы белән торгызып, үз яклавына алып, бөтен Гарәбстанның зур өлешләрен үз яклавында итеп, Мисыр һәм Һиндны тәэмин итәчәк. Инглизнең бу фикер һәм сәясәте мөселманнарны, аеруча гарәпләрнең шөбһәгә калуларыннан, бу фикер алга сөрелми килде. Бу соңгы сугышта Мәккә шәрифнең Төркиядән аерылуы (аның белән бергә сугышка катнашмавы) да инглиз тарафыннан булган сәясәткә нигезләнгән булды, диючеләр булды. Шулай булдымы яки кешеләре белән киңәшмичә, галимнәргә мөрәҗәгатьсез берләшү һәм прогресс әгъзаларының Германиягә яраклы итүе зур хатирәле эш булганлыктан, нәтиҗәсе матур булмаганда, бергә алып, бер ысул белән битарафлыгы күренә торып катышмавы идеме? Һәр тарафы ихтимал.

Шәриф Хөсәенгә килсәк, яхшы галим, дәрәҗәле һәм акыллы күренә. Дин һәм милләт өчен яхшылык итә иде. Хәтта өендә бер сөйләшүдә үзсүзләнеп, Мәккә кешеләренең төрле бозыклыкларга сәләтен, аеруча Хәрам (Мәккәдәге мәчет – *А.Г.*) эчендә дә кайбер мәчет әдәпләренә тап төшерә торган хәрәкәтләр күренүен сөйләдем һәм әйттем: «Мәккәнең уллары Хәрам шәрифкә әзер булсалар да, халыктан аерым намаз укыганлыктан, шәригатьчә булмаган эшләрне, бидгать әмерләрне күрмиләр, шунлыктан яхшыруына чалышмыйлар», – дигәч, аулакта укучыларны бәян итеп сөйләүдәге җөмләне раслап: «Килешәм, мин дә алардан», – дигән иде. Шуны да әйткән иде: «Мин күрмәгәнне сез күрерсез, Хәрамдамы, аның тышындамы ярамаган эш күрсәгез, миңа ирештерерсез. Әгәр игътибар итмәсәгез, миңа әйтмәсәгез, кыяматтә сездән дәгъва итәрмен». Бер әмирдән бу сүз байтак беленде – мөһим сүз. Күңелендә дөреслек булмаган кемсәнә болай мөгамалә итмәс һәм мондый сүзләр дә әйтмәс иде.

Гарәпләрдә сәясәтчә берләшү һәм реформа ияләренә, солтан Габделхәмиднең хәлифәлегенә уңыш елмайды. Ләкин гарәпләрдә, гомумән, дин рухы куәтле, һәр эшкә дин һәм ислам күзлеге аркылы карап, бу бүлектә зур шөбһәләре, канәгатьсезлекләре бар иде. Зур кешеләр мәҗлесләрендә булдым, аеруча Мәдинә-мөнәвәрәдә озак торганлыктан, күп кешеләр белән очраштым. Сәясәттән бәхәс куз-

галса да, яшьләр турында бер шөбһәне мәйданга куярлар иде. Күп вакытта белер-белмәс сәясәт ишегеннән керүчеләрне, аларны кызганып, түбән фикерлелектән үстереп, алга таба үсешләрендә ярдәм итәргә туры килде, ләкин күп көч белән башкарылды. Госманлы дәүләте һәммә мөселманнарча, аеруча гарәпләрчә, ислам дәүләте булуы һәм исламның рәсми йола-гадәтләрен саклау-яклау вазыйфаларын тиешенчә үтәве көтелә һәм өмет ителә иде. Солтан Габделхәмид алай итте, болай итте, ислам җәмагатен сакларга тырышты яки шул төсне күрсәтте, дин тарафында булган күп кешеләрне үзенә җәлеп итте.

Фикердәшләр мәйданга чыктылар, сәяси өстенлеккә ирештеләр, халык дүрт күз белән болардан реформа көтте, һәркем үз үлчәвенчә, үз күңелендәге хасиятчә үзгәреш күзәтте. Гарәпләр, дин әһелләре булган галим-шәехләр, Госман дәүләтенең фәкать Төркия дәүләте буларак эшчәнлеген-үзгәрешен көтмичә, бәлки, ислам дәүләте буларак яңарышын көттеләр. Яшьләр исә дәүләтнең Ауропа дәүләтләре ысулына куелып, һәртөрле бозык һәм башка ислам булса, болай ауропачылыкның Истамбулда, башка шәһәрләрдә, хәтта авылларда күренүен теләделәр. Боларның бер дәрәҗәдә теләкләре, көтүләре хасил була да башлады. Ләкин зур милләтнең, башлыкларның көткән, ислам дәүләте булып яңаруы һәм яхшыруы бер җирдә дә күзгә чагылмады, колакка ишетелмәде. Бу хәл исә һәр җирдәге мөселманнарга көтелмәгән бер рух бирде, бер фикер тудырды, тышка чыкмаса да, эчләрендә яшәп ташыды, балалады, тамырланды, менә бу сугышның башында-ахырында да ачык булды. Кечкенә сугыш игълан ителүгә үк, ысулсыз, изүчеләрчә, галимнәр, башлыклар мәҗлесе белән киңәшмичә, Алмания тарафыннан, икенче төрле әйткәндә, кайгыга батучылар фикеренә бирелеп, Әнвәр паша тарафыннан игълан ителде. Халкы риза булмаса да, тел кыймылдату мөмкин булмады. Башында һәм урталарында Төркия бер җәһәттән җиңелсә (аста калса) да, гомумән, җиңүче Германия тарафында булып килүендә, ахырдан Төркиянең хәерле булуы өметле икән, кинәттән кире хәл килеп чыгуы халыкны, мөселманнарны шашындырды. Эш җиңү белән тәмам булса, бү хәлләр тыначак иде, ләкин алай булмады, җиңелү белән эш төгәлләнде. Кешеләренең күңелләрендә булган, күпме вакыт саклаган хасиятләрне чыгарырга мәйдан булды. Һәр җирдә фикердәшләргә һөҗүмнәр башланды, милләт эчендә каршылыклар, үзара килешмәүчәнлек башланды. Союздашларга җиңелеп, сугыш игълан иткән

солтан Рашад дөньядан китте. Аннан соң килүче кардәше солтан Вахидеддин җаваплылыкны үз өстенә алмады, Төркиягә авыр мәсьәлә тәкъдим итте, кабул итү-итмәүдә каршылыклар туды. Мәҗлес депутатларының күпчелеге Анатолийга чикләде, Мостафа Кәмаль паша каһарманнарча гаскәр туплап, Антантага каршы Истамбулны коткару нияте белән сугышка керешә. Табигый, ике фирка арасында төрле сүзләр булачак, төрле фикер туачак, солтанга зыянлы фикерләр тупланачагы ачык иде, ләкин эшнең эченә кермичә, бер тарафның гына авызына карап, сүзен тыңлап хөкем ителмәячәк, фәтва бирелмәячәк – бу да табигый.

7–8 нче мәсьәләләрдә артык җавап язылмаячак һәм соңгы мәсьәләләргә даирәсезләр өчен дә вакыт та юк. Вәс-сәләмү галә мән итбәгаль-һүдә (Туры юлга ияручеләргә Аллаһның сәламе булсын – *А.Г.*)!

Җомга көн 6 августта Кәшшаф Мәүлиханов исемле бер дин таратучыда булып, төрекләр белән әңгәмә булды. Болар белән һинд адәмнәреннән доктор Мансур исемле берәү бар иде. Балкан сугышында «Кызыл ай» иганәсенә, һинд җәмгыятенә килгән табиб. Хәзер Берлиннан фронтны аэропланда кичеп, Русиягә килгән, Мәскәүдә булган милләтләр конгрессында да әгъза булып хезмәт итә икән. Гарәпчә, фарсыча, төрекчә дә сөйли, Аурупа телләреннән инглизчәдән башканы белмәгәне аңлашылды. Һиндта Әхмәдхан мәдрәсәсендә гыйлем алып, инглиз мәктәпләрендә укыган икән. Коммунизм юлында булса кирәк. Гарәп гыйлемен укуын әйтсә дә, шәех Бәрәкәтуллаһ мөнәсәбәтен аңларлык дәрәҗдә озын сөйләшү булмады. Шимбә көн сәгать 6 да өебезгә килергә тиеш булса да, килмәде. Төрекләр белән бергә хәрәкәт иткәнлектән, аларга хәерхаһлы булуы ачыкланды. Милләтләр конгрессында булуы да моңа дәлил. Читтән килгән кешеләр өчен Мәскәүдә эш күрүчеләргә җайсыз, шәрык эшләре идарәсенә үтенечләр русча язылырга тиеш булганлыктан, яздыру өчен байтак вакыт китте. Язучының хокук галиме булуы кирәк булганлыктан, таныш кеше Заһид бәк Шамилгә бу хезмәт йөкләнсә дә, ул Петроградта йомышы чыгып, анда сәфәр китте. Көтеп зар булдык, мөрәҗәгать итәргә кеше аз, хокук галимнәре үзләре дә азайган: кайсы киткән, кайсы төрмәдә, кайсы җәйләүдә һ.б. Яздырып биреп тә эш чыгамы-юкмы, бар да нервыга тәэсир итә торган эшләр. Аллаһы Тәгалә ахырын хәерле кылса иде!

## Мөхтәсиб Лотфулла Исхакый белән сөйләшү

Лотфулла Исхак белән әңгәмә: Петерградтан мөхтәсиб Лотфулла әфәнде белән шимбә көн 7 августта килеп сөйләшү булды. Петроград хәленнән: яңа мәчетне алулары ихтимал булганлыктан, ашыгыч ачып, җомгаларны анда укый башлаганнар. Өченче мәхәллә – касыймилар мәхәлләсе – тәмам беткән. Икенче гаскәри мәхәллә дә зәгыйфьләнгән. Гәрәй мулла вафат булып, аның урынына мулла Якуп әфәнде урнашкан. Бу рамазан аенда генерал Габделгазиз бине Габдулла бине шәех Дәүләтша Дәүләтшин вафат булган. Бичара, әхлагы саф, пакъ вөҗданлы кеше иде. Бабалары юлында булса, чын, яхшы ишан булырдай кеше иде. Бер җирдә имам булган булса да, халыкның дин һәм әхлагына файда бирерлек яхшы имам булып гомер иткән булыр иде, ачлыктан үлмәгән булыр иде. Атасы Габдулла кантон эшләрендә оста, акыллы адәм булып, бу газиз баласын да әлеге юлга салган. Әлбәттә, тәкъдир беленми, олы абруе белән укып, шәрык мәктәбен тәмамлап, күп телләр өйрәнеп, Бохара әмиренә хезмәт итеп яшәде. Ләкин саф вөҗданлы, иманлы кеше булганлыктан, дөньясын төзәтә алмаган, фәкыйрьлеккә төшкән, тормышын бу соңгы тормышка яраклаштыра алмаган. Гаиләсе дә рус кызы, уллары-кызлары да рус. Икътисад белмәс, атаны оялтучы булып, исламны белмәгән алмаш. Лотфулла әфәндедән: «Нинди авыру белән үлде», – дигәч, бераз тукталып, соңыннан авырсынып кына: «Бичара, сызып, ачлык җәфасыннан үлде», – дип куйды. Мөхтәсибнең фикеренә караганда, бу сәясәттә мөселманнар барчасы – руханилар һәм башкалар – битараф торырга тиеш. Ни күрсә дә, чыдарга, болардан соранып, хәлне аңлатып биреп йөрмәскә тиеш. Боларның асыл һәм кагыйдәләренчә, руханиларга кайсы дин булса да, һич игътибар юк, кадер-хөрмәт юк, динле кеше динле булганы өчен гаепле кебек. Һәр җирдә динне, дин әһелен мыскыллаган игъланнары бар, шунлыктан болардан сорап йөрү – гаеп эш.

Аңа әйткән сүзем: «Бирмәсәләр бирмәсләр, безне милләт сорарга, бер дәрәҗәдә мөнәсәбәт ясарга, үзебезне танытырга йөкли, милләтнең Диния бинасы китеп бара, музей итеп игълан иттеләр, Диния әгъзаларын аннан чыгарачаклар. Мәктәпләрдә дин дәресләрен укытуны ясак иттеләр. Бу мәсьәләләрне хәл иттерүне, милләтнең хокукын саклауны милләт бездән көтә. Көтүләре хаклымы-хаксызмы, без бер дәрәҗәдә аларның таләпләренә колак

салырга, хәерле нәтиҗә буламы-юкмы, элекке тәртипне ясау һәм, бераз гына булса да, шулай яшәү – безнең вазыйфабыз. Алдыбызда мөхтәсибләр киңәшмәсе тора – бер җавабыбыз булыр, гозерләребез күренер. Бөтенләй өметебезне кисмик, бәлки, бер дәрәҗәдә уңайланыр, вакытлы булса да йомшаклык күрсәтерләр», – дидем.

Аның фикеренчә, бөтен эшне кызыл муллаларга тапшырып, эштән һәм хезмәттән чигенергә кирәк. Үзләре эшләсеннәр, милләт билгеле вакытта зур дини зарарларга очрый икән, очрасын, тәмам төшенкелек хәленә килсен. Әлеге эштә мондый рәвештә соңгы көндә бер хәерле хәл туар, милләттә зур бер уяну хасил булыр. Иншалла, эшләр төзәлер, тиешле урынына урнашыр. Ләкин бу эшне эшләүдә милләт белән киңәшләшү кирәк. Булса булсын, руханилар киңәшмәсеннән соң гына мөмкин. Күренер, әгәр милләтнең теләгенчә хәрәкәткә ярдәм итмәсәләр, руханилар дини хөррият-ләренчә ихтыярлы куелмасалар, шунда киңәшеп, бу хәлне игълан итә, инде без бу хезмәттә дәвам итә алмыйбыз, эш үтәрлек кешеләр билгеләгез, дип кызыл муллаларга, Шура идарәсенә тапшыру вакыты килер. Аллаһ хәерле кылсын! Югарыда искә алынган затның сәясәт галәмендә Төркия һәм инглизләр мәсьәләсендә дә фикере башка.

## Мөхтәсибләр җыелышы ни өчен кирәк?

Мөхтәсибләр җыелышын югарыда күрсәтелгән заттан башка кешеләрдән яхшы күрмәүчеләр бар. Үзебезнең казый Ризаэддин әфәнде дә шөбһә белән карый. Курыккан кешеләрнең куркы-нычларының иң зурысы –коммунистларның мактаулары белән теләкләренә каршы бер карар чыгармагайлары, дип уйлауда иде. Уфа коммунистлары баштан ук съездның булуын теләделәр, тизрәк ясауны кирәксенделәр, тәкъдимнәре булу да ихтимал. Сәбәпләренең иң күренгәне Мәхкәмә әгъзасының гафу үтенеп, урыннарына янә кызылрак әгъза сайлату фикере булу беленә иде. Ни булса да, мондый зыянлы ихтималлар юк түгел. Тиешле булмаган кешеләр сайланып, эштән китүчеләр милләтнең каргышына очрауларында зур ихтимал бар.

Киңәшмә хакында уйларыбыз:

1. Өч елдан бирле рәтле сөйләшү булмау, милләт белән, мөхтәсибләр белән киңәшү, ике тарафның да хәле белән танышлыгыбыз аз иде.

2. Өч еллык эшләребезне дә тәфсилле рәвештә милләткә күрсәтү, яхшы хисап бирү тиешле иде.

3. Сәясәтләр алмашынды, дин укытулар авырлыкка калды, аны хәл итү чаралары турында фикер алышуга ихтыяҗ бар иде.

4. Диния нәзарәте мәхәллә идарәләре тарафыннан акрынлап кысыла бара. Алда ниләр булачагын белеп булмый. Бу хәлне дә милләткә белдерү, безнең кулыбызда булган Мәхкәмә бинасы, әйберләре турында күрешеп сөйләшү тиеш күрелде.

5. Шура хөкүмәте белән һәрнәрсәдә битараф торып булмады, бер дәрәҗәдә мөнәсәбәттә булу кирәк иде. Кадерле мөнәсәбәт кирәк, Мәхкәмәнең чын хуҗалары, мөселманнарның гомуми сайланган вәкилләре белән киңәшеп, хат әзерләү мөмкинлеге булуда өмет бар иде.

6. Һәркайсы милләт мондый авыр көннәрдә дә үз кайгыларын күреп торганда, мөселманнарның Нәзарәтләре һәм халкы рухсыз ятулары бигрәк зәгыйфьлеккә һәм югалуга сәбәп булыр, дип фикер ителде. Гомумән, шундыйларны уйлап бу эшкә керешү иде. Хәерле булып чыкса – Аллаһ рәхмәте һәм юмартлыгы; хаталы булса – эшләүче әгъзаларының кимчелеге. Аллаһы Тәгалә ярдәм итеп һәм рәхим кылып, хәерле эшләр насыйп итсә иде, куркынычлы эшләрдән үзе сакласа иде!

## Мәскәүдә ислам мәмләкәтләре вәкилләре

Бу көннәрдә әзәрбайҗан вәкилләре килде. Әзәрбайҗан, Төркия, Хәрәзем, Бохара вәкилләре тупланды. Һәркайсының йомышлары бар. Төркиянең йомышы билгеле. Инглиз һәм Юнанга каршы хәрәкәт һәм сәясәтләрендә ярдәм, алтынга ихтыяҗлары бар.

Әзәрбайҗан Шура кулына кергән, коммунизм төзелергә тора. Бу юлда якынлыкка ниятләре булса кирәк. Хәрәземлеләр исә янә Шура ысулын кабул иткәннәр, боларның идарәсенә кергәннәр, төрле кагыйдәләр өйрәнер өчен килгәннәр. Петроградка барып, барысын күрделәр; газетада кечкенә генә күңелсез мәкалә булып узды. Гүяки, коммунистлар мәчетләрне ватканнар, бетергәннәр, дип

ишетеп, Петроградка барып, яхшы сәламәт хәлдә булуын күреп, куанып, коммунистларның мәчетне саклауларына рәхмәтләрен әйтүләрен, Петроград газетасына хәбәрләр язган булганнар. Бу әфәнделәр моны ишетеп, үзләрен җамигъ (төп мәчет – *А.Г.*) күрер өчен килгәннәр, дип уйламасыннар, коммунистларның хәтерләре калмасын дип, газетадагы хәбәргә җавап яздылар: «Мәчет күрер өчен килмәдек, безнең өчен мәчетнең әһәмияте юк. Без, ягъни Шура хөкүмәтендә булганга, коммун ысулларын һәм тәртипләрен күрер һәм өйрәнер өчен килдек, шул арада гына мәчетне күреп уздык», – диделәр. Тәһарәтләр яңартып, мәчеттә намаз укып чыктылар. Бу җавапларына Хәрәзем вәкиллеге рәисе Баба ахун, мулла Ура, мулла Нурмөхәммәд дип имзаларын куйдылар. Бу мәкалә халыкка бераз сүзгә бәхәс булды. Дингә мөнәсәбәтләрен, мәчеткә мәхәббәтләрен коммунистлардан яшергәннәр, коммунистларга мәхәббәтләрен ачык күрсәткәннәр, дип сөйләделәр.

Мәварәэннәһер халкы – кирәк Бохара, кирәк Хәрәзем – бар да күңелгә хуш, уллары да чамасыз дәрәҗәдә ихтирам итүчән, аларга каршы ни кадәрле тугры һәм кирәкле сүз булса да, дәшми кала алалар. Шунлыктан араларында әмирләре теләгән һәм тоткан юлдан башка бер фикер һәм хәрәкәт тумый. Дини, гыйльми, тормыш эшчәнлегендә тукталып калулары да шул сәбәптән. Кайбер тарафның фикеренчә, бу мәмләкәтләргә коммунизм кереп урнашып, асты өстенә килсә, иске фикерләр, хәлләр җимерелсә, уянулары, фикри хәрәкәтләр башлану ихтимал.

Тәҗрибәләрдә, тарихи вакыйгаларда мисаллары булгалаган, ләкин Багдад кебек җирләр дә бар. Һәлякү гаскәре Багдадны җимергәч, хәлифәне, дәүләтне, галимнәрне үтергәч, китапханәдәге барлык гарәп һәм ислам китапларын Диҗләгә салып, суның агышын туктатыр дәрәҗәгә китергәч, шәһәр хәрабә хәленә килеп, соңыннан да гүзәл хәлгә килә алмады, бер кечкенә шәһәр булып кына калды, иске шөһрәте дә колакларда гына калды. Әмма Бохара һәм Хәрәзем Һәлякүнең бабасы карт мәҗүсинең басып алуында зур хәсрәт, зыянга очрасалар да, соңыннан төзәлеп, әһәмиятләрен югалтмаганнар. Бәлки, заманаларына күрә төзек булып, тәртип юлына кергәннәр. Бу мөмкин эш. Яхшы юлбашчыга очрасалар, яхшы фикерле, дин танырдай кеше булса, Аллаһның киң рәхмәтендә булырдай эш. Ләкин адәм – кирәкле адәм. Вәс-сәлам. Ишетелгәненә күрә, Бохара вәкилләре Петроградта җомга намазына искә алынган мәчеткә барганнар, ләкин имам Лотфулла әфәнде

Мәскәү юлында булган, икенче мәхәллә имамы Якуп әфәнде дә ни өчендер әзер булмаган. Бер суфи хөтбә укыган, вәкилләрдә Мәхмүд хуҗа имамлык иткән. Мәчет хезмәткәрләренең берсе дә әзер булмаулары белән бәйле бер эш күренгән. Бохара әмире торгызышкан мәчеттә, аның вәкилләре әзер булачак булгач, имамнар барча тормышлары белән әзер булырга тиеш иделәр. Мәхмүд хуҗа гыйлемле адәм булса да, рәсми хатыйб булмаганлыктан, янында вәгазе булмау сәбәпле, хөтбәне башка бер суфи әйтеп, имамлыкны Мәхмүд хуҗа үтәве, хәнәфиләр буенча, дөрес, ләкин мәкруһ (хупланмаучы гамәл – *А.Г.*), сөннәткә каршы эш һәм кайбер мәзһәбләр буенча бөтенләй дөрес булмаган намаз булган. Болар да, үз гадәтләренчә, кайбер җитәкчеләргә киемнәрен кидереп киткәннәр.

Төрекләрнең инглизләргә каршы хәрәкәттә булуларына, Шура хөкүмәтенә мөрәҗәгать белән файда итә алуларына, соңра бер өстенлеккә ия булуларына фикер иткәннәре дә бар. Инглизгә каршы өстенлек мөмкин түгел, вакыт белән бәйле торса да, ахырда инглиз җиңүче булыр, үз сүзен мәйданга чыгарыр, аның сәясәте өстен булыр, диләр. Анатольдә Мостафа Кәмальнең хәрәкәтләре дә бер хәерле нәтиҗәгә ирешмәс, Истамбулдан Төркия дошманнарын чыгара алмас, Истамбулны чорнап алган флотка каршы бер хәрәкәт тә кыла алмас, диләр. Анатоль эченә таба инглизнең коралы, Юнанның гаскәре керә бара, хәрәкәт тә дәвам итә. Боларның артлары иркен, төзек, әмма төрекләрнең исә җитәрлек акчалары да, кораллары да юк, булса да, Шура хөкүмәтеннән файда итсәләр дә, әлбәттә, вакытлы һәм үлчәүле булачак. Диңгездә куәте юк, шунлыктан диңгез кырында булган шәһәрләрне басып алырга мөмкин түгел, ни кадәр сузылса да, төрекләрнең Анатоль хәрәкәтләреннән бернинди нәтиҗә чыга торган түгел, диләр. Бу төркем фикеренчә, ни кадәр хурлык булса да, ислам дәрәҗәсенә һәм Төркия дәүләтенең хөрмәтенә каршы булса да, инглиз белән килешү һәм аның сәясәтенә муафикъ [булу] тиешле. Мәмләкәтләрнең җиңүләре, халыкларның тынычлыгы шунда гына мөмкин. Кыскасы, бу юл – яманлыктан курку. Болар Шура хөкүмәтендә дә, бара-бара инглизгә көче калмас, әлбәттә, җиңелер, инглиз өстенлек табар, диярләр. Вә лилләһи гакыйбәтүл-үмүр (Эшләрнең ахыры Аллаһ кулында – *А.Г.*). Инглизнең яхшы сәясәте, һәр бабта осталыгы һәм көче, бер дәрәҗәдә, халыкны алдарлык һәм юатырлык хөррияте бу фикергә азрак куәт бирә. Кем белер, Аллаһның хәзинәсендә һәм

аның тәкъдирендә, теләгендә ниләр барлыкка килер. Хәзерге көндә Германия, читтә торып, Антантаның килешүе белән тәмам хәрәкәттән туктап, ял иткән бу Германиядә ни фикер бар? Антантаның йөкләүләре буенча, алар тарафына кушылып, Шурага каршы хәрәкәттә булса, Шура өчен күп өмет калмый, Антантаның җиңүе мәйданга чыгачак. Төркия өчен дә, хурлык булса да, ялгыз аларга сыену чарасы калачак. Әгәр, киресенчә, бу тарафка кушылса, янә Төркия, Болгария, Русия белән аңа кушылып, зур бер сугыш башланачак. Ихтимал, озакка сузылуына күрә, Русиянең тәмам бетүе, ачлыктан һәлак булуы, һәртөрле коткыларга дучар булуы туачак. Ахыры ни булыр? Бу тәкъдирдә, бөек фидакарьлектән соң, Антантага җиңелүләре дә ихтималдан ерак түгел. Ләкин ул мәртәбәгә ирешкәнче күп нәрсәләр таләп ителә. Һәрхәлдә, без мөселманнар өчен сәясәттә битарафлыгыбыз исемендә булса да, янә Шура хөкүмәте белән яхшы мөнәсәбәттә булу тиешле. Гәрчә болар коммунистлар, динсезлек шигарьләре, һәркайсы динне хурлау, дин әһелен хөрмәт итмәү гадәтләре аларның кануннары [булса да]. Аеруча руханилар, дини идарәләр олыны да, кечене дә хөрмәт итәргә тиешләр. Төркиягә гүзәл могамәлә сәясәтләре дә – бу хәл күрсәткече. Романовлар барчасы да ислам өчен файдалы түгел иделәр. Бәлки, миссионерлык рухы тәэсире астында начарлыкта булдылар. Ислам эшләренә дә, хуҗалыклары сәбәпле, мәчет һәм мәктәпләрнең биналары мәсьәләсендә төрле кысынкылыкларда булдылар. Дин дошманнары икәннәре мәйданда булса да, буйсындык, яхшы мөгамәләдә булдык, тугрылык күрсәттек. Бу хәлләргә мәҗбүрилек күрдек, янә Аллаһның рәхмәте, ярдәме астында динебезне бер дәрәҗәдә сакладык. «Кешеләр патшалары динендә булыр» дигәнчә, начар тәэсирләре булды, күп булды. Боларның да шулай булачак, ләкин араларында аерма бар. Кешенең динне кирәксенүе – табигый бер хәл. Динсезләр никадәр үзләренең бозык фикерләрен таратырга тырышсалар да, артык таралачак түгел. Әмма христианлыкның үзенә каратуы, асылы күктән иңгән бер дин булганлыктан, дәгъвасы да күп күренгәнлектән, ислам өчен хәтәррәк һәм хәвефлерәк. Романовлар вакытында дәвам итеп, болар вакытында нигездән җимерелүе, тормышларның бөтенләй алмашынуы, яхшымы-яманмы – һаман фикердә һәм уйлауда. Кайсы халык өчен хәерле? Ихтимал, бу рәвештән дини бер туры фикер һәм яхшы тормыш туып, ислам галәме өчен, гомумән, кайбер мәсьәләләрдән өзелү уе белән бер алга китү күренер, төзүлү туар,

тормышта, гамәлләрдә, ышануда чамасызлыклар һәм салкын караулар бетеп, Аллаһ ярдәме белән, изге галимнәр туры юлга күндереп, ис җыярлар, фикерләрен төзәтерләр, бөек дини инкыйлаб барлыкка килеп, хакыйкый ислам юлына керерләр, би-изнилләһи вә кәрамиһ. Лә тәкънәтү мир-рахмәтилләһ, иннәллааһә йәгъфируз-зүнүбә җәмига (Аллаһ Тәгалә ярдәме һәм юмартлыгы белән. Аллаһ рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чынлыкта, Аллаһ бөтен гөнаһларны кичерә – *А.Г.*).

Бу арада Сергач өлкәсе Пожар авылыннан хаҗи Хөсәен исемле таныш адәмебездән һәм искә алынган өлкә, Кормаш өлкәсе имамнары исеменнән мулла Лотфулла Шәриф әфәндедән чакыру килде. Форсат булганда, кайтканда ике-өч көнгә кереп, муллаларның дини эшләрен күзәтеп, Мәхкәмә белән таныштырып, мөмкин булса, азрак рух биреп чыгу – ярый торган эш.

**Шимбә көн, 10 август.**

Ташкентта Бохара яшьләре – «Яңа коммунистлар» – тарафыннан 15 апрельдә «Таң» исемле әдәби-сәяси журнал чыгып, өч сан чыкканнан соң эшләре күп, хәрефләре аз булу сәбәпле, тукталып торырга мәҗбүр булган икән. Моның белән бергә, 28 июньдә «Котылыш» исемле атнага ике сан газета нәшер итү башланды. Үзбәк телендә, яңа хәрефле хәрәкәт, рәсем-язуында. Газетаның ике санын күрдем. Баш мәкаләләре Габделкадыйр бине Мөхетдин исеме астында. Элек мирза Мөхетдин Мансуров исемле бер бай уллары белән яңарап, фикерле булып, Бохара әмиренең сәүдә эшләрендә вәкил булып йөргән булса да, Бохарага сыймыйча, рус Бохарасында тора башлаган иде. Улларыннан Габделкадыйр яхшы фикерле егет иде. Бохара җире боларга тар булганлыктан, иптәшләре белән Ташкентка килгәннәр, Бохарада яңару һәм инкыйлаб торгызу нияте белән төрле хәрәкәттә булалар. Газета һәм журналлар чыгарып, фикерләр тараталар икән. Газеталарында Бохарага караган мәкаләләреннән башка бернәрсә дә юк, дияргә мөмкин. Яхшы тәэсир итәрлек мәкаләләр. Әмирнең золымнарын ачык язган, әмирне торткын итәргә халыкны, гаскәрне чакыра. Бер мәкаләсендә әмирнең ике йөз дөя белән инглиз банкына каракүл, алтын һәм башкаларны озатуын язган, мөселманнарның казнасын үз малы кебек озатуын халыкка белдерә. Гомумән, Төркестанда Шура ысулы мәйдан алуына, коммунизм таралуына куанып, Бохарада да аның таралуын тели. Халыкны бар көче белән шуңа чакыра.

## Мирза Бидел тәрҗемәи хәле

«Таң» журналында шәрыкның мәшһүр шагыйре философ Мирза Бидел исеме белән танылган шәех Габделкадыйрның тәрҗемәи хәлен язып, хөррият һәм тигезлеккә караган, аскетизмга кагылышлы кайбер бәетләрен тәрҗемә итеп сөйләнелгән. Бу журналның бәян итүенә күрә, Мирза Бидел хәзрәтләренең Бохара янындагы әмир Тимурның тууы һәм чыгышы гарәп тарихларында сөйләнә торган Себез шәһәреннән, барлас дигән кабиләдән. Габделкадыйр Зур абад өлкәсендә 1054 елда туып, Бангалә шәһәрендә яши, соңра төрекләрнең пайтәхетләре Шаһҗиһан абад шәһәрендә 1133 елда вафат була. Яшь килеш атадан ятим калып, алты яшендәге баланы мәктәпкә тапшырып, алты ай укып, Коръәнне [укып] тәмамлаган. Соңра мәдрәсәгә кереп, гарәп һәм фарсы әдәбияты гыйлеменә керешеп, ун яшендә чагында, матди хәле мөмкинлек бирмәү сәбәпле, мәдрәсәдән чыгарга мәҗбүр булган. Соңра суфи шәехләр тирәсендә тәрбияләнеп, фикер дәрьясына бирелә. (югарыда әйтелгәннәр «Таң»нан китерелә).

Мирза Бидел шагыйранә табигатьле, шигырьләр сөйләргә ярата. Фикерләве шәрык гыйлеменә мөнәсәбәтле, шигырьләре бик нечкә, фәлсәфи рухы һәм зиһенлелеге белән шөһрәт казанган. Ләкин билгеле булганча, сәләтлелеге зур кешеләр күп вакытта озак укырга яратмыйлар. Үз фикерләренә таянып, югарыга күтәреләләр, күп китап укып, башка кешеләрнең, төрле галимнәрнең бәхәсле фикерләре белән табигый сәләтләрен чуалтмыйлар һәм бозмыйлар. Китапларны күп уку, шул китапларның фикерләрен үзендә урнаштыра, сизмичә иярүчәнлеккә этәрә. Бер дәрәҗәдә кагыйдәләр үзләштерелгәч, һәр кайсы фәннең ысулы аңлангач, кеше үз фикеренә таянып, юк-бар нәрсәләр белән бозылмыйча, чын күңелдән гыйлем эченә бирелсә, фикер дәрьясына чумса, хакыйкый гыйлемгә муафикъ булуы өметлерәк. Чын галим шушы рәвештә генә булырга тиеш, юкса аның гыйлеме тәрҗемәи хәлен бизәүче бер гыйлем булып кына кала. «Гыйлем мәгълүмат күплегеннән килми, чынлыкта, гыйлем – Аллаһ тарафыннан мөэмин колына бүләк ителгән нур» мәгънәсендәге хәдис шәриф хикмәт һәм чын хакыйкать булса кирәк. Безнең Мирза Бидел хәзрәтләре дә шундый ирләр рәтендә булган. Искә алынган «Таң» журналының сөйләвенә таянып үз тәҗрибә хәлендә бу бәетне язган:

[...].

Минем бәеттә данлыгым, шигырь һәвәслегем юк. Табигатемдә шагыйрьлек юклыктанмы, Бохарада вакытымда да фарсы бәетләренә күп күңел куя алмадым. Күңел куйсам да, шөгыльләнүгә форсат таба алмадым. Нәзек бәетләрдән Мирза Бидел әсәрләренә, аңлаешлы җиңел бәетләрдән Шәех Сәгъди һәм Мәүләви Җами әсәрләренә мәхәббәтем бар иде. Мәснәви шәрифкә дә шулай ук иде. Ләкин шөгыльләнә алмадым. Мирза Бидел мәрхүмнең диванының башы хәтеремә килә, хәтта нәзеклегеннән хушымны ала иде. Диваны бу мөбарәк бәет белән башлана:

[...].

Бу җиңел аңлаешлы бәет тә югарыда искә алынган хәзрәтләренә карый:

[...].

Мирза хәзрәтләренең күп бәетләре чын аскетизм һәм тәвәккәллек, кылануны кире кагу, тормыш әйберләренә артык бирелмәү, риялык һәм ясалмалылык бабларында, бар булуның берлеге бабында бик җитди сөйләр, рәсми кәлям әһелләрен, фәлсәфә ияләрен сөймәс. Фикер хөррияте, нәфескә таяну мад- дәләрен дә аңлатыр. Язган әсәрләре күп. «Диван», «Җар гансар», «Мохит әгъзам», «Гыйрфан» исемле әсәрләре басылган. Диваны Бохара мәктәпләрендә безнең яшь балаларга «Мөхәммәдия» укыткан кебек укытыла. Күбесенчә язу белән язылганлыктан, язу тану файдасын бирсә дә, аң файдасын бирми. Шул мәктәптә вакытларында Бидел диванын укып чыккан сартлар (Урта Азия халкы – *А.Г.*), беркадәр өйрәнгәч, өйрәтеп йөриләр, яхшы аңлаучылары өстен, макталган гыйлем алучылар була.

Ташкент шәкертләре арасында да шагыйрьлек игътибарда булганлыктан, моның әсәрләре белән шөгыльләнүчеләр бар. Бу соңгы елларда башка файдалы китаплар бастырганнары кебек, һинд басмаларына күрә дә, күркәм рәвештә эшләп, Мирзаның диванын да гүзәл язу белән Ташкентта басканнар иде.

Соңгы елларда ташбасма һөнәре, үз типографияләре булмаса да, шактый прогресс юлына кергән, араларында матур язу адәмнәре булганлыктан, гүзәл ташбасма белән басылган китаплар барлыкка китерелгән иде. Инде бу төшенкелекләр сәбәпле туктауга очраган. Әлбәттә, ахыры хәерле була.

Искә алынган «Таң» журналында бер сүз күрдем: «кайдан беләм» урынына «кайдам» сүзен кулланган. Астында язган: «Бу сүз

«кайдан беләмен» сүзенең җиңелләшкәне, халкыбыз күп сөйләр, җиңел һәм чырайлык бер сүз.

«Таң» иясе Мирза Биделнең китапларыннан барлыкның берлегенә караган кайбер бәетләрне сайлап алган:

[...].

## Гомеопатия ысулынча табиб

Чәршәмбе көн 11 августта Федор Лаврентевич Брушнин исемле табибка очрадым. Бу адәм – ефәк материаллар фабрикачысы, зур мал иясе, йөз елдан бирле ата-бабалары бай булып килгәннәр. Бу адәм сәүдә өлкәсендә булса да, гомеопатия ысулынча[20] медицина өйрәнеп, халыкка бушка дару бирә. Аллаһка

[20] Медицина фәнендә һәм дәвалауда электән бирле ике ысул бар. Берсе – киресе белән дәвалау. Эсселекне салкынлык белән һәм киресенчә, дымлылыкны корылык белән һәм киресенчә итеп дәвалыйлар. Мәшһүр һәм тормышта кулланыла торган ысулдыр. Икенчесе – үзе кебек нәрсә белән дәвалау. Өшегәнне кар белән уып кыздыру, пешкәнне кайнар су яки бал белән эсселеген арттыру кебек рәвеш. Бу гомеопатия табиблары бу соңгы юл ияләреннән икән. Боларда авыру урынын үзләре карау юк. Бәлки, хастаның үз бәяненнән авыруны аңлап, дәва бирәләр. Операция дә юк икән. Бу адәм дә: «Медицина югары уку йортына керергә булганда адәм кисү, кан күрү хәлләренә чыдамлыгым булмаганлыктан, ташладым», – диде. Иске юнан медицинасында да хастаның үзеннән сорашып, дәва бирәләр. Кайвакыт тамырдан карап, авыруны билгелиләр. Хәер, ибне Синадан, күз күрүе белән авыруны белер, дәвасын бирер иде, дигән сүз бар. Моңа нисбәтле бер гаҗәеп хикәя риваять итәләр. Караган вакытында, хасталарны тезеп, тәкъдим итәләр, һәркайсын күздән кичереп, дәвасын сөйләр икән. Дәва сөйләмәсә, иптәшләренә дәвасыз, өметсез хаста икән, дип ышануы хасил булыр икән. Беркөн бер киселгән яки параличланган кешене тәкъдим иткәндә һич дәва бәян итмәгән. Хастаның якыннары, өметләрен кисеп, киселгән кешедән качканнары өчен, хастаны бер хәрәбәгә куеп, бер савыт белән сөт куйганнар, тиз үләчәк, дип үзләре киткәннәр. Бу бичара хаста тормышыннан өметсез һәм бизәр булып яткан. Очраклы рәвештә, Аллаһның әмере һәм ярдәме белән, бер тишектән бер елан чыгып, моның сөтен эчкән. Күбрәк эчкәнме, сөт савытына коскан да югалган. Тормыштан бизәр булып, дүрт күз белән үлем көткән хаста, тизрәк дөньядан китим, шул еланның агулы косыгын эчим, дип алып, шул савыттагы косыкны эчкән. Бу хаста, инде дөньядан китәм, әлхәмделиллә,

вәгъдә иткән икән: кем килсә дә, кайдан булса да, бушка карап, үз кесәсеннән бушка дару бирәчәк булган һәм шулай вәгъдәсен үтәп, гомер итә икән. Соңгы инкыйлабта йортыннан һәм җиһазларыннан аерганнар, күренгән малын талаганнар, алганнар. Алай да, шул вәгъдәсенә тугрылык күрсәтеп гомер кичерә. 58 яшендә аксакал, ләкин таза бер философ табигатьле адәм. Сүзгә юмарт, үзенең тәрбиясен, башыннан үткәннәрен, юлын, тормышын байтак сөйләде, байтак әһәмиятле адәм [булып] күренде. 14 яшь вакытында, теше авыртып, табибка мөрәҗәгать иткән. Авыруының сәбәбен соравында, татлы ашаганнан, дигәч, шул вакыттан ук татлыны ташлаган, икенче кат теш авыруы күрмәгән. Балсыз чәй авызын бөрештергәнлектән, чәйне дә ташлаган, каһвә эчә икән. Төрле җиләк һәм кишер чәйләрен хуш күрә. Сигез елдан бирле, гомумән,

---

дип әҗәл көтеп торганда акрын-акрын тормыш әсәре һәм сихәт галәмәте пәйда була башлаган. Аз вакытта савыгып, үз аягы белән якыннары янына кайткан. Хәким ибне Синага да, Аллаһның хикмәтен һәм киң рәхмәтен белдерү өчендер, күренгән. Ибне Сина күрү белән, елан косыгын кайдан таптың, соравын бирүенә баягы хаста вакыйганы бәян иткән. Ибне Сина: «Мин күрдем, синең дәваң фәкать елан косыгы иде, ул исә табылуы бик мөшкел бер дарудыр, шуның өчен сиңа сөйләп тә тормаган идем. Аллаһның рәхмәте булган», – дигән.

Ит ашамауны яки бик аз һәм сирәк ашауны пәйгамбәр һәм ислам медицинасы, башка табиблар да сөйлиләр. Кайберәүләр, итсез куәт ким була, бәдән зәгыйфьлегенә сәбәп була, дисәләр дә, дөрес сүз түгелдер. Шәрык халкы, гомумән, итне аз ашаучы халыклардыр. Бездә дә авыл халкы итне аз ашыйлар. Аеруча яз көннәрендә, эшләрнең иң куәтле вакытларында итсез, икмәк, сөтле такта чәй булса, буш шулпа белән канәгатьләнәләр. Куәтләрендә кимчелек күренми, бәдәннәрдә зәгыйфьлек беленми. Төрекләрнең бу кадәр авыр хезмәттә булганнары унар потны күтәреп ташу хезмәтендә булган йөк ташучылары сыр белән бодай икмәген ашыйлар, бардак-бардак су эчәләр дә хезмәтләренә китәләр, тиешенчә кимчелексез үтиләр. Безнең ялгыш уйлар бар да гадәткә әсир булганлыктан, чын тәҗрибәгә керешмичә, сукырларча иярүгә артык бирелүче булганлыктандыр. Бәйрүттә гомуми Диван мөдире намуслы кешеләрдән шәех Габделхәлим әфәнде белән күп сөйләштем. Шамнан Мәдинәгә кадәрле булган сәфәрдә булдым. Һәрвакыт даими рәвештә ураза тота, нигездә, ит ашамый, үзе нык, куәтле, гыйбадәте һәм Коръән укуы күп булган бер мөбарәк адәм иде. Хафизаһүллаһ (Аллаһ аны сакласын)! Әлеге кеше ит ашамаса да, үзен куәтле хис иткәнен, зәгыйфьлек әсәрләрен күрмәвен сөйлидер.

ит затыннан саклана икән. Күбрәк гөмбә шулпасын эчкәнен, гөмбәдә каннарның юлларын чистартуда, каннарның яхшы йөрешләрендә файда барлыгын, кан юлларында җыелган һәм, юлларны тоташтырып, подаграга сәбәп булган тозларны чистартуын сөйли. Кулымда, бармакларымда подагра (буыннар сызлавы) хасталыгы, күкрәгемдә йөрәк кызуы (одышка) барлыгын әйттем. Ит затыннан сакланырга киңәш бирде. Тавык затының зарары азрак булса да, саклану яхшы, диде.

Бу адәмнең фикерендә һәм акылында бераз тынлык күренә, шулай да халык файдасын тели, акчасыз, бушка файда ирештерә, аларга вакытын сарыф итә. Максаты – матур итеп искә алу: «Мине хәерлелек белән искә алсалар иде», – ди. «Миллионны алып барып булмый, ахыргы урыныбыз өч аршин җир, бәндәләргә файда китерсәк, безнең белән барыр», – ди. Шәраб, исерткеч эчүгә бик дошман. «Күп адәм авыруны үзе таба, үзе ала, күбрәгенә эчке сәбәп була,» – ди. Ике сәгать сөйләшүендә, күбрәк шәраб эчүне хурлап, аның зарарларын бәян [итү] белән үткәрде. Шул сәбәпле, фәкыйрьләргә акча ярдәмен күрсәтмәвен дә сөйләде: «Акча алып китеп, эчәләр иде», – ди. «Хәзерге хөкүмәт, хыянәтче дип малларны тартып алу һәм талау өчен төзелгән. Халык өчен демократия хөкүмәте кирәк, искечә ысул ярамый, ысуллы һәм үлчәүле хөррият һәм гаделлек тиеш», – ди. Мөселманнардан хөкүмәт хадимнәре – коммунист һәм комиссар – бу адәмгә аз күренә икән. «Рус һәм яһүдтән бик күп, мөселманнардан аз, ни сәбәп?» – ди.

Моның тикшерүендә кимчелек булганмы яки яһүдләргә караганда азлыгын әйтәме – ни булса да, мин дә, күп, димәдем. «Мөселманнар диннәренә ихласлы, дини тәрбияләре яхшырак, руханиларына ышанучанраклар», – дип җавап биргәч, канәгатьләнгәндәй туктады. Үзе бик диндар һәм иманлы руска охшый, дин бабында дөрес фикергә муафикъ була алмаган күпчелек ышануынча саташмаган фикердә. Толстой турында яхшы фикере юк: «Үз-үзен яратуы белән саташты», – ди. Аның хатынына чыдамавын, аннан качып, читтә үлгәнен гаеп саный. «Кеше түзем булырга тиеш, зәвыгына һәм фикеренә каршы булса да, кеше файдасына авырлык йөкләү тиеш иде», – ди. Коммунистлыкның таралуына Толстойның хезмәте булган [дип] хисаплап: «Бу хәлне күрсә, ни әйтер иде», – ди. Ләкин Толстой хөррият һәм гаделлек таләп итүче булса да, христианлыкка фанатизм белән ышанган иде, коммунизмнан бик ерак иде. Шулай да иясе булмаган, яхшы тәрбия күрмәгән халыкка

хөррият бирелсә, дин һәм әхлак бабында да иркенәеп, коммунизмга якынаеп китүләре була, һәм булды. Бу хәлләр хөрриятне үлчи белмәгәннән туган.

## Үлемне истә тотуның файдалары

Нервылары бик сәламәт, бәдәне нык кешенең нервный булуы үз-үзен яратудан туган афәт итебрәк күрсәтә. «Нервыны җибәрү өчен үлемне искә алу кирәк», – ди. «Үлемне күбрәк уйларга кирәк, адәмне төзәтә», – ди. Бу сүзе дә дөрес, үлемне искә алу дөньяның һәм дөньяда булган нәрсәләрнең әһәмиятен киметә, үлемдәге хәвеф-хәтәр алдында дөньяви куркулар һәм хәсрәтләр – бар да юк дәрәҗәсенә төшәләр. Шунлыктан алар сәбәпле нервылар артык йогынты алган булмый. Нервылык, дөрестән дә, зирәклекнең һәм хиснең куәтле булып, һәрнәрсәдәге яхшы һәм начарны тиз аңлавыннан, рухның каты тәэсирләнүеннән туа. Надан, хисе зәгыйфь, тәэсирләнүе ким адәмнәрдә нервылык булмый, алар юк-бар нәрсәләргә карамыйлар, «арба уалса – утын була, үгез үлсә – ит була» дигәндәй, һәрнәрсәгә җиңел күз белән карыйлар, дөньяда тыныч яшиләр. Ләкин бу хәл кызыгырлык күркәм хәл түгел. Мондый нервылары йоклаган, эче пошулардан азат адәмнәрдә бер дәрт тә булмый. Үзен төзәтү, дөньясы өчен кайгыртмаган кебек, дине һәм ахирәте өчен дә кайгырту булмый, хайваннар яшәве белән яшиләр, дөньяда ашау-эчү өчен генә торалар. Бохарада ягымлы галимнәрдән мулла Исмәгыйль бине Хәмид Минзәләви Тегермәни: «Ахмаклык – яхшы дәүләт», – дияр иде. Хәсән Гата бине Мөхәммәд Габәши: «Тынычлык наданлыкта, белдеңме – башың бәлагә керә», – ди. Садыйк бине Сафа Галикәй: «Һай, бәхетле Мортаза булып яшәсәң иде», – дияр иде. Искә алынган Мортаза тыныч җанлы адәм иде. Фәкать бу адәмнәр бәхетле адәмнәр түгел, үзләре өчен дә, башкалар өчен дә мондый адәмнәрдән хәерлелек бик сирәк туа.

Инде бер шөбһә туа ки: нервылы булган адәмнәр холыксыз, хаста һәм кәефсез булалар, нервылы булмаганнар хиссез надан булалар. Чын кеше, яхшы әхлаклы, нык бәдәнле һәм сәламәт рухлы, файдалы адәм кайда була һәм кем була?

Бу шөбһәнең хәле шул: чын адәм үзе өчен һәм башкалар өчен файдалы һәм әхлаклы булыр. Тәрбия һәм әхлак төзәтү белән хисендә куәт, рухында сәламәт һәм саулык, акылында яхшы

ныклык булыр, төрле борчуларга каршы тәрбиясе һәм әхлак төзәтү бабындагы файдалы мәгълүматлары белән каршы торыр. Ни куәтле шатлык һәм сөенүгә бирелеп, чиктән ашыр, ни дә борчу һәм кайгы һөҗүмендә һәм килүендә изелер, үзен югалтыр. Бәлки, ике әсәрләнү төренә һәм тәэсиренә каршы сабыр һәм түземлек белән мөгамәлә итәр, сабыр һәм түземлек белән ләззәтләнер. Алар белән яхшы ышануы, иман куәте кадерендә диндарлык итәр. Баягы үлемне, дөньяның фанилыгын, әһәмияте азлыгын искә алып, үзен һәрвакытта тынычлыкта сакларга, Аллаһ Тәгаләнең туры юлга кертүе белән, уңышлы булыр.

Үлемне искә төшерү мәсьәләсендә яңа чыккан язучылар һәм сөйләүчеләр үз белемнәренә канәгать иткән әдипләр башка фикердә: «Үлемне искә алу рухны сүндерә, гайрәтне зәгыйфьләндерә, дәртне югалта, шунлыктан тормыш өчен һәм башка тормыш хәҗәтләре, галәм тәртибе һәм милләт төзеклеге өчен куркыныч», – диярләр. Ләкин боларның бу фикерләре дөрес фикер түгел. Беренчедән, бу фикер һәм бу сүз иманлы мөселман авызыннан һәм каләменнән туарга тиеш түгел. Аллаһ илчесе салләллаһү галәйһи вә сәлләмнең катгый дәлил булган сахих (дөрес – *А.Г.*) хәдисендә килгән. Димәк, хатасыз булган хикмәтле Рәсүл тәгълиматында һәм аның милләтне төзекләндерү, галәмнең тәртибе өчен булган кисәтүләрендә үлемне искә төшерү файдалы күренгән. Икенчедән, боларның акыл һәм фикерләренә каршы чыгабыз: һәртөрле хәрәкәт һәм хәерлелек өчен, хәтта сирәк була торган фидакарьлекләр өчен, әлбәттә, бөек максатка һәм кыйммәтле файдага ышанырга кирәк. Шундый бөек һәм кыйммәтле максатлар адәмнең алга баруына һәм батырлыгына, малын һәм җанын аямыйча, төрле хәрәкәтенә сәбәп булалар. Мондый кыйммәтле һәм бөек максатлар һәм файдалар үлемнән соң булган мәңгелек тормышта гына булачак. Чикләнгән тормышта булган файда һәм ләззәтләрнең акыл каршында кыйммәте юк. Мең мәшәкать һәм җәфа белән юнәтелгән малны һәм иң кадерле, кыйммәтле булган тормыш, җанны фида кылыр өчен арзанаймый. Бер кемсә үлем һәм үлем соңын чын иман белән хәтерендә тотса, андагы нәтиҗә һәм ләззәтләргә ышануы булганлыктан, аның янында һәрнәрсәне багышларга һәм фида итәргә әзер булалар. Шул нәтиҗәләргә ирешү өчен мал кирәкме, башкача хезмәт вә каһарманлык кирәкме – һәммәсенә тырышачак, кулга алырга тырышачак.

Үлемнең соңыннан катгый караш белән дә искә алуда (ничек икәне хәдистән дә аңлашыла) да зур файдалар бар ки, дөньяның фанилыгын, гомернең кыскалыгын искә алганлыктан, әһәмиятенең азлыгын белдерә һәм аңа алданып, әхлакны бозмаска, урталыктан чыкмаска юл бирә. Бу юл белән искә алынган хәдисне нервыларны саклау һәм яхшыландыру бабында зур бер файдалы кагыйдә дип аңлау мөмкин.

Нәтиҗә: мөселман үлемне күп искә төшерсен ки, фани ләззәтләргә әһәмият биреп, үзенең кешелеклелеген, исламын югалтмасын, вак-төяк кайгы һәм куркулар белән артык борчылып, әхлагын һәм әгъзасын бозмасын, барчасы вакытлы, үтәр. Үлемнең соңын күп искә алсын ки, андагы зур нәтиҗәләр һәм зур файдалар кыйммәтле, чын-чын әһәмиятле. Кешенең бөеклегенә, мөселманның дөрес иманына туры килә. Шулар өчен дөньяда яшәсен, шуларны кулга алу өчен һәртөрле фидакарьлекләрне булдырсын.

Нәтиҗәнең нәтиҗәсе: әхлакны саклау, хәерлелеккә омтылу, хәрам нәрсәләргә нәфрәт өчен үлемне искә төшерү – иң зур чара.

[...].

## Милли эшләр мәсьәләсе буенча бирелгән гариза

Җомга көн 13 августта Милли эшләр халык комиссариаты коллегиясенә докладная записка җибәрдем, Мирсәет Солтангалиев кулына. Запискаsuccessfulның эчтәлеге:

Шәрык халкы Антанта (Аурона) хөкүмәтләре тарафларыннан аерылган булганлыктан, аларны иркенлеккә чыгарырга кирәк. Аларга ярдәм, һәркайсы милләткә хөррият бирү фикерендә һәм вәгъдәсендә булган Шура хөкүмәтеннән көтелә. Бу теләк өчен хөкүмәтнең мөселманнарга яхшы караулары, бөек ислам диненә (зарарына) Мәркәз һәм түбәндәге идарәләр тарафыннан хәрәкәттә булмау, ихтирамсыз мөгамәләләр итмәү тиеш күренә. Бу хәл өчен бу маддәләргә Шура хөкүмәтенең карашын җәлеп итәмен:

1. Мөселманнарның диннәре өчен хәҗәт булган сборларга, җыеннарга түзәргә, ярдәм итәлергә тиеш.

2. Халыкның дини һәм әхлакый тәрбияләре өчен кирәкле булган имамнар, мөәзиннәр һәм Диния нәзарәтенең әгъзалары гаскәри хезмәттән азат итәлергә тиеш.

3. Уфадагы халыкның үз суммасы белән торгызылган Диния нәзарәте бинасы халыкның үз милке булып танылырга тиеш.

4. Искә алынган бина Уфада Воскресенская урамында 5 нче номерда үзе һәм бөтен әсбаблары белән мөселманнарның дини һәм милли милекләре булганга, хөкүмәт тарафыннан бер эшкә дә һәм бер идарәгә дә алынмаска тиеш иде. Ләкин, кызганычка каршы, ул бина музей [итеп] игълан ителде. Акрынлап бинаны алырга да керештеләр. Бу хәл мөселманнарның милли һәм дини хисләренә каты бәрелә торган хәл булганга, бу бинаны мондый эшләрдән котылдырырга тиеш.

5. Диния нәзарәте сәяси эшләрдән үзен читтә тота. Шулай да шәригать сыйдырган кадәрлек белән Шура хөкүмәтенә ярдәмнән кире тормый. Шунлыктан Диния нәзарәтенең әгъзалары, шәхесләре һәм маллары һәртөрле тыкшынулардан сакланган булсыннар иде.

6. Диния нәзарәтенең дини эшләрне торгызуда булган хезмәтләрендә типографияләр һәм почталар белән файдалануына иркенлек бирелергә тиеш. Бик таләп ителгән иде: Уфада булачак җыелышка килер-китәр өчен, вәкилләргә юлда йөрер өчен рәсми ярдәм булсын иде.

7. Мөселманнарның үз суммалары белән салынган дини мәктәп һәм мәдрәсәләре аларның кулларыннан алынмаска һәм аларда дин укыту тыелмаска тиеш. Алынганнары бар да үзләренә кайтарылырга тиеш.

8. Мөселманнар дини мәктәп һәм мәдрәсәләрендә диннәрен укыту бабында һәртөрле иркенлеккә ирешергә тиеш. Кирәгенчә киңәшләр, акча җыюлар, тәртипләр төзүләр кебек эшләрендә хөррияттә булырга тиеш.

9. Кайбер җирләрдә (шәһәрләрдә һәм авылларда) Шура хөкүмәте идарәләре халыкның муллалык эшенә катышып, фәрман бирүләре һәм мулла билгеләүләре ишетелә һәм күренә. Диния нәзарәтенең рөхсәтеннән башка мондый эшләр булмаска тиеш. Советлар бу дини эшкә катышмаска тиеш.

10. Күп була ки, волостной советлар хатыннарның никях һәм талак мәсьәләләренә катышып, регистрация ясауларында үзләре кылган никях һәм талакны дини һәм шәригать буенча дип танытыр өчен муллаларга фәрман җибәрәләр. Дин һәм шәригать буенча бу никях һәм талакның ярамаганы һәм дөрес булмаганы күп булганга, мулла моңа имза куя алмый. Бу мәсьәләләр дә игътибарга алынсын иде.

Бу язылган маддәләрне, мөселманнарның диннәре буенча кирәк күренгән мәсьәләләр булганлыктан, Русия социализм кушма җөмһүрият ысуллы Шура хөкүмәте игътибарсыз калдырмас, дип ышанып калдым. Язма ахырына мөфти фәлән бине фәлән дип имза куелды. Исемендә хат, Оренбургский мөфти Духовное собрание дип басылган булганлыктан, әзерләнмәде. Бу язуны русча яздыру күп вакытлар сорады, дәгъва вәкилләре күзеннән кичүе тиеш, диделәр. Аларның исә кайберләре үз өстенә алмый, кайберләре җәйдә, кайберләре төрмәдә; шунлыктан күп кичектерү белән бары 16 августта Заһид бине Шәфигъ Шамвил тырышлыгы белән өлгереп, 13 ндә Мирсәет Солтангалиевның йортына җибәрелде. Аллаһ ахырын хәерле кылсын!

## «Сөбател-гаҗизин» китабы турында

Буш араларда хатыным Гайшә «Сөбател-гаҗизин» китабын укып тыңлата. Бу арада хәрамлыкмы, хәләллекме бабында кичкән кайбер бәетләре бик хисле һәм бик матур булганлыктан, монда беразын сайлап язарга булдым:

[...].

Искә алынган китапның чыгтай төркисендәге әдәбият һәм тәсаввыф китапларының иң гүзәл, хикмәтле һәм иң матуры. Элек мәктәптә балаларга укытып, дәрәҗәсен төшерсәләр дә, зурлар өчен имтихан нөсхәсе. Кирәгенчә аңлаучылар ирләр арасында да күп түгел. Балалар, аеруча кызлар аңлап укымасалар да, ярым-йорты бәетләре файдалы рух биргән, кайбер бәетләре хәтерләрендә калып, олыгайгач, файдаланганнары булган. Олырак шәкертләргә дәрес биреп, яхшы аңлатып укытылса, яман булмас иде. Эстәрлебаш шәех Нигъмәтулла бине Биктимер җәнабләре шәкертләргә укыткан икән, диләр. Безнең хәзрәт остаз ахун мулла Ихтиярхан Бохари хәзрәтләре туры килгәндә дәресләрдә: «Ишан суфи һәмтү гүфтә сит», – дип кайбер бәетләрен укыр иде, бик килешле булып ишетелер иде. Бу китапның һәр бәетендә бер хикмәт бар, фикер һәм игътибар белән укыганда бер тәэсир төре бар. Үзе хуш табигатьле шагыйрь, суфи, заһид, дөрес ният иясе, тәкъва адәм. Рахимәһүллаһү Тәгалә (Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын – *А.Г.*)! Бу китапны күп сәфәрләремдә янымда йөртәм, буш вакытларда укыйм, файда алам, кайбер иптәшләргә укыйм, гыйбрәтләндерәм. Әүвәлге хатыным

Бибимаһруй бинте Исхак бу китапка мәхәббәтле иде, яхшы аңлый иде. Бәетләренең башы әйтелсә, бөтен бәетен хәтереннән укыр иде: «Минем шәехем – «Сөбател-гаҗизин»«, – дияр иде. Кайвакытта мулла Таҗетдин Ялчыгол укуына күрә, укуы туры чыга иде. Гафәраллаһә (Аллаһ аны гафу итсен – *А.Г.*)!

Бу 13 август җомганы элекке җомга кебек мин укыттым. Мулла Габдулла бине Хәсән бине Шәмсетдин Пәрәви Мәскәүнең кытлыгыннан һәм кыйммәтлегеннән куркып, Алабуга төбәгендә Тирсә исемле мәшһүр авылга күчеп, анда билгеле бер вакытка имамлык итүдә. Кайбер адәмнәр аны гаеп итсәләр дә, гафу ителмәслек түгел. Кайбер ашыгыч һәм фикерсез кавемнәр имам алу фикеренә төшеп, Муса әфәндегә дә тәкъдим иткәннәр икән. Галәмдә ахмаклык төрләре күп, Муса әфәнде – Петроград имамы, мәхәлләсе һәм Финляндия сәүдәгәрләре тарафларыннан мәхәлләсендә намуслылык итсә-итмәсә, миллионлы иганәләрен күрсәтеп торалар, бер губернатор тормышы белән торгызалар икән. Ач-ялангач торыр өчен Петроградны һәм шул кадәр әһәмиятле һәм ихласлы тәрбияне ташлап, Мәскәүгә килсен; кайгыртып сөйләүче адәмне җомга намазында да күренми, диләр. Гади халкының эше – ахмаклык өстенә ахмаклык. Мәхәлләсенә яхшы мулла килсен, ачмы, ялангачмы – канәгать булсын, халыкның аңа тамгаларын салуларына шат булып, шул куаныч белән күченсен. Хәзерге көндә Мәскәүдә аз гына гаиләле кеше икътисад белән генә торыр өчен айга кимендә ике йөз мең сумга мохтаҗ. Беренче мәхәлләдә кавем бик аз, хәзер бигрәк азайган. Әйтелгән сумманың яртысы, хәтта дүрттән бере дә булачак түгел. Мулла Габдулла моны сизенгән, җиңелрәк тормышлы җиргә күчкән. Әлбәттә, гозерле. Мөәзин хезмәтен үтәп тора.

13 августта Мәскәүдә трамвайлар туктадылар. Зур типография – Сытин типографиясе дә эштән туктаган. Өч-дүрт көннән бирле көн саен бирелә торган икмәк бирелмәде. Халык ачыкты, базарлар бетте. Ипи табылмады, табылса да, кадагы җиде-сигез йөз сум. Петроградта да шулай нык ачлык иде. Кара икмәк бирү биш йөз сумга чыккан икән. Сөйләнелә: гаскәрнең дә берар атналык кына ашавы калган, эшләрдә азаплану беленә, Антанта көчле рәвештә сугышка әзерләнә, диләр. Хәтта Балтыйк диңгезенә Англиянең чыкканы ничә көннән бирле сөйләнә. Петроградтан күчү башлана яки башланган хәбәрен сөйлиләр. Диңгездән Англия, корыдан Финляндиянең һөҗүмнәре ихтимал тотыла икән. Хәбәрләргә күрә,

Курский тимер юлы да эшләми икән. Гомуми забастовка башланса, куркыныч хәл булыр. 14 августта янә трамвай күренми, ни булыр?

Юлларның киселү ихтималы безнең өчен дә хәтәрле, эшебез бетмәгән, берәр җавап көтәбез. Көтсәк, юл бетү хәтәре. Аллаһ хәерле кылса иде! Хәерлелек өмете өлешчә зарарны җиңеләйтә, иншалла.

## Пәйгамбәр нәселеннән булган имамнардан имам Мөтәвәккил Гали хәлифәнең вәгазьдә матур шигырьләре

Дөньяның гади, гади булмаган инкыйлабларын фикерләп утырганда, пәйгамбәр нәселеннән булган имамнардан[21] Әбелхәсән Гали Мәһди Мөнтәзыйр абыйсы бине Мөхәммәд әл-Җәвад бине әр-Рида бине Муса әл-Кәзыйм бине Җәгъфәр әс-Садыйк бине Мөхәммәд әл-Бакыйр бине Гали Зәйнел-габидин бине әл-Хөсәен бине Гали галәйһиссәламнең Габбаси хәлифәләреннән Мөтәвәккил Галиулла янында сөйләгән касыйдәсе хәтеремә төште. Казый Ибне Хәлләкәннең бәян итүенә күрә, искә алынган хәлифә бер кичәдә ашау-эчү мәҗлесе арасында бу имамны чакырткан. Килгәндә габбасиларның гадәтләренчә, [сугыш белән] чыгу һәм җәберләү белән гаепләп куркытмакчы булса да, имам пакъ булганлыктан,

---

[21] Пәйгамбәр нәселеннән булган бу имамнарын һәркайсы мөселман ихтирам итәргә һәм яратырга тиештер ки, боларны унике имам диярләр. Шулардан: 1) әмирел-мөэминин Гали бине Әбү Талиб, 2) Хәсән, 3) Хөсәен, 4) Хөсәен улы Гали Зәйнел-габидин, 5) аның улы Мөхәммәд әл-Бакыйр, 6) аның улы Җәгъфәр әс-Садыйк, 7) аның улы Муса әл-Кәзыйм, 8) аның улы Гали әр-Рида, 9) аның улы Мөхәммәд әл-Җәвад, 10) аның улы Гали әл-Һади, 11) аның улы Хәсән Гаскәри, 12) аның улы Мөхәммәд Мәһди Мөнтазыйр. Шигый-имамилар боларны гөнаһсыз дип тоталар, исемнәренә «галәйһиссәлам» дога-җөмләсен кушалар, кайбер сөннәт әһелләре дә «сәлам» белән искә алучылар бар. Имам Бохари һәм байтак хәдис белгечләре әмирел-мөэминин Галине «галәйһиссәлам» белән ихтирам итәләр. Мөхәммәд Мәһди Мөнтазыйр уникенче имамдыр. Шигый-имамилар ышануынча, яшьлегендә төрбәгә кереп югалган. Имам Мөнтазыйрны Мәһди Мөнтазыйр диярләр, кыямәт көне якынлашкач, чыгачак Мәһди бу имам, диярләр. Сөннәт һәм җәмәгать әһелләреннән шәех Мөхеддин ибне Гарәби һәм иярченнәре дә болай уйлаудадыр. Вәллаһү әгъләм (Аллаһ белүчерәк).

дөрес җавабын кыюлык белән канәгатьләнерлек [итеп] бәян иткәч, мөэминнәр әмире ачылып имамга ашау-эчү һәм махсус кунаклыкны тәкъдим иткән. Имам ул хәлдән акланган һәм ялынган. Әмирелмөэминин мәҗлескә караган кайбер шигырьләр укуын теләгән. Имам моннан да хәрәкәт иткән, соңра артык йөдәтүенә каршы түбәндәге шигырьләрне укыган:

[...].

Искә алынган шигырьләрне сөйләгәннән соң, мөэминнәр әмире тәэсирләнеп, елаган, мәҗлес ашау-эчүен туздырган, имамны ихтирам белән өенә озаткан. Менә гыйбрәт: изгеләрнең нинди куркынычлы урында да диннәрен саклаулары һәм аның өстенә мөэминнәр әмире кебек кулында кылыч булган, ни кылса да, дөньяда һичкем тарафыннан соралмаган падишаһка кәефен бозарлык, рәхәтлеген җибәрерлек, җанына үтәрлек шигырьләр укуы – никадәр бөек дини гыйбрәт белән изгелеккә өндәү һәм хәрамнан тыю. Падишаһларда да дин бар, никадәр кәефләнүле булсалар да, золымнан качмасалар да, ышанулары нык, иманнары сәламәт булып, туры сүздән, үткер нәсыйхәттән тәэсирләнгәннәр. Хәлләрен, вакытлы рәвештә булса да, алмаштырганнар. Габбаси хәлифәләренең һәркайсында да мондый хәлләр күренгән. Аллаһ Тәгалә пәйгамбәр нәселеннән булган имамнардан риза булсын, дәрәҗәләрен арттырсын! Мондый исламның элекке әмирләрен дә рәхмәте һәм юмартлыгы белән кичерсен! Искә алынган Мөтәвәккил Галиулла вакыйгасының мисаллары зур габбаси хәлифәләреннән Мансур, Мәһди, Рашидләрдә дә бөеклекләре һәм көчләре белән яхшы булган хәлдә, янә мондый тугры сүзләргә очраганда түбәнчелек иткәннәре, савап һәм хаклыкка муен игәннәре тарихта билгеле. Рахимәһүллаһ (Аллаһ аларны рәхим кылсын – *А.Г.*)!

Бүген 14 август төштән соң трамвайлар кузгалдылар. Ләкин вак базарда бер нәрсә дә калмаган, сәүдә беткән, бетерелгән. Кәбестә, кыяр, алма бар, диделәр. Гаҗәеп эшләрдән берсе: бер данә кечкенә баш кәбестә өч мең сум икән. Алма данәсе утыз-кырык сум һ.б.

## «Рухел-бәян» тәфсире турында

Кайбер буш вакытларымда «Рухел-бәян» тәфсирен укыдым. Бу китапны яшь көннәремдә синтаксис һәм мантыйк укыган заманнарымда укыштыра һәм байтак файдалана идем. Яңарак китап укырга өйрәнер өчен шундый кыйссалы китаплар яхшырак була[22]. Бу заманда әхлак бозгыч романнар, төрле газета укып утырырга өйрәнәләр. Бу тәфсирне укуны соңгы заманнарда куйган идем. Бу китапның тәфсирлегеннән бигрәк кыйссачылыгы өстен. Язган хәдисләре, хәдис белгечләреннән берсе буенча, иснадсыз (тоташу чылбыры юк – *А.Г.*). Иясе үзе Җәлвәтия тарикатенә караган, суфи, тәкъва, яхшы вәгазьче адәм булган булса кирәк. Шәехе Сәед Госман әфәнде тарафыннан Брусәгә күндерелгән, анда Зур җамигъта (мәчеттә – *А.Г.*) вәгазь белән шөгыльләнгән. Шәех Исмәгыйль Хәкый Брусәви дип билгеле. Брусәдә үзенә караган мәчете бар. Мәчете эчендә китапханә бүлмәсендә тәфсиренең үз язуы, үз нөсхәсе саклана. 1326 елда Брусә сәфәремдә кереп чыккан идем. Кабере дә шул мәчете янында. Кайбер адәмнәр бу затны тәфсирендә «хатыйбе ләйл»лек[23] кылган дисәләр дә, байтак файдаларны җыйган, халыкка, аеруча имамнарга һәм вәгазьчеләргә файдалы итеп язган. Фарсыдан Мәснәви, Сәгъди, Җами бәетләреннән күп нәрсәләр язган, зәгыйфь һәм асылсыз сүзләр дә байтак кергән. Гафияллаһү ганни вә ганһ (Аллаһ мине һәм аны гафу итсен – *А.Г.*)! Бу кешенең башка әсәрләре дә – бер дәрәҗәдә файдалы нөсхәләр. Киң мәгълүматлы адәм. Аллаһ рәхим кылсын, 1127 елда вафат.

Асрау аятьләре тәфсирендә Хафиз Ширази диваныннан түбәндәге хикмәтле бәетне күчерә:

---

[22] Минем бу китапка мөнәсәбәтем башлануының сәбәбе : «Исагуҗи» укыган вакытларымда гарәп китапларын аңлый башлаган идем, укырга теләгем бар иде. Атам мәрхүм яңарак Хиҗаз сәфәреннән «Рухел-бәян» һәм «Шәрхе тарикахадиме» нөсхәләрен китергән. Китапханәдә артык гарәп китабы да аз иде. Шунлыктан көндәлек дәресләрдән бушаганда өйдә бу тәфсирне дә, «Хадим»не дә укый идем. Һәр ике китап иясенә Аллаһ рәхмәт кылса иде!

[23] Хатыйбе ләйл – кичтә утынчы дигән сүз. Гарәпләрдә утын, чыбык каты үлән затларыннан булганга, чәчелгән, корып, ботагыннан төшкән агач кисәкләре җыела. Караңгыда җыелса, яхшысы, яманы аермыйча җыела. Шунлыктан һәртөрле сүзне аермыйча язучыны «хатыйбе ләйл» диләр.

[...].

Фарсы императоры янына өч хикмәт иясе иң авыр хәлләрнең нидән гыйбарәт икәне хакында сөйләшкәндә, берсе (Һинд хикмәт иясе): «Кайгы белән катыш хасталык», икенчесе (Рум хикмәт иясе): «Картлыктагы фәкыйрьлек», – дигән, өченчесе (фарсы хикмәт иясе вәзир Нәүширван) әйткән: «Начар гамәл кылганда килгән әҗәл». Ахырда моның сүзен өстен иткәннәр.

[...].

## М. Солтангалиев белән сөйләшү

15 август кичәсендә Мирсәет Солтангалиев белән утырып, ниятләнгән докладлар турында сорадым. Иптәшләре белән кайбер маддәләрендә киңәшләшү булганын, Нәзарәт бинасы турында, тимәскә карар бирүләрен сөйләде. Хәтта Уфага телеграмма бирәчәге өстенә үз кулыма да язу бирәчәген белдерде. Сүз арасында, Мәхкәмәи-шәргыянең ике данә язу машинасы Уфада Шура комитеты тарафыннан алынуын һәм бу эшнең үзен диннән аерым тоткан Шура хөкүмәтенең хөрмәтенә яраклы булмаган бер эш икәнен сөйләгәч, мәсьәләгә гаҗәпләнеп, байтак тәэсирләнде.

Йорт хуҗасы Мөбин бине Сәлим Паршавига, озаткан вакытында, машиналарның кайтарылуы турында язачагын сөйләгән. Ахыры хәерле булса иде!

Сәфәр билетын (пропускны) да бирәчәк булды. Иншалла, бирер.

Югарыда искә алынган заттан ишеткәнемә күрә, Мәркәздә митрополит Тихин тарафыннан кызыл руханилардан тәшкил иткән «Исполком рух» исемен биреп йөриләр икән икән. Вәкилләре – чукынган бер яһүд – килеп, боларга кайбер мәсьәләләрдә мөрәҗәгать иткән. Болар үзләренең дини һәм сәяси кайбер хокукларын саклау өчен бу эшне үзләренә йөкләгәннәр булса кирәк.

Мәктәп һәм мәчетләр кебек кайбер дини чыганаклар өчен утын һәм агач табу да дин исеме белән түгел, халык хәҗәтләре исеме белән юл табу мөмкин.

Вакытның сәясәтенчә, шәхси һәм милли дәрәҗәне саклау, якында һәр җирдән файда ала белү – яхшы чара. Кайбер файдалар, каравы белән тышкы яктан түбәнлек кебек күренгән чаралар да, ахыры яхшы булу ихтималы булганда, эшләнә. Ходайбиянең олы

вакыйгасы – моның зур гадел шаһите, Мәккә кәферләренең теләкләре, тыштан күренгәндә ислам дәрәҗәсенә зыянлы һәм бер бәхетсезлек кебек күренеп, кайбер сәхабәләрнең хурлануларына һәм кулайсыз сүзләренә сәбәпче булган. Ахырдан, Аллаһ илчесе салләллаһү галәйһи вә сәлләмнең мөбарәк фикере зур-зур хәерле нәтиҗәләрне, тышкы якта күренгән төрле кадерле эшләр, гадәттән тыш зур хөрмәтләрне тудырган, искә алынган сәхабәләрнең кадерләренә сәбәпче булган. Бу христиан чиркәүләренең бу бабтагы программаларын күрәчәк булдым. Бәлки, кайбер файдалы юллар күрергә мөмкин булыр.

Казакълар хәленнән бераз сүз булып, хәзер казакълар өчен бер җөмһүрият төзелгәнен, эшкә карар бирелгәнен сөйләде. Тик даирә бик зур, вилаяте бик озын булганлыктан, казакъларның үзләреннән адәм җитешмәгәнлектән, вакытлы сурәттә өч җирдән идарә ителәчәк икән. Оренбург, Омск, Ташкент шәһәрләрендә исполкомнар төзелеп, Акмулла даирәсенә кадәрлене Оренбургта казакъ исполкомы төзелеп, үзе хөкүмәт идарә итәчәк. Акмулла, Семипулат областен Омсктагы исполком, казакълардан да кайбер әгъза кергән булган хәлдә, идарә итәчәк. Йитесу вилаяте (Семиреченский) Ташкентта күзәтеләчәк икән. Казакъларның үз адәмнәре җитешә, үзләре идарә көченә килсәләр, бу ике вилаять идарәсе дә үзләренә тапшырылачак икән. Бу җөмһүрият, мөхтәриятле идарә исемендә дә, рәсми рәвештә дә яхшы. Ләкин идарә ысулы һаман Шура хөкүмәте ысулынча булачак. Бу турыда халыкның карашы ничек булыр? Шулай да, яхшы каршы алырга тиешле.

## «Мәснәви-шәриф»тән кайбер шигырьләр

Искә алынган Мөбин бине Сәлим китапханәсеннән бер Рөсухи нөсхәсен – шәех Исмәгыйль Әнкарави хәзрәтләренең «Мәснәви шәрехе»н – китердем. Югарыда искә алынган затның атасы Сәлим агай Казан вилаяте Җәбәлстанында (Тау ягында – *А.Г.*) Мулла илендә шәех Мәзһар хәзрәтләре хәлифәләреннән хаҗи Хөсәен әфәндедән тарикать алган, яхшы гына намуслылык иясе булып, Мәскәүдә торып, кайбер китаплар укып, дөньядан кайткан. Аннан калган китаплар җөмләсеннән бөтен «Мәснәви шәрехе» нөсхәсе.

«Мәснәви» китабы ислам галәмендә бөек әхлак һәм тәсаувыф китапларыннан санала. Алты томда язылган, фәлсәфи, гаять

тәэсирләндерүче һәм нәзек табигатьле мөбарәк китап. Язучысы Мәүләви Руми дип танылган шәех Җәләледдин Мөхәммәд бине Баһаведдин Мөхәммәд бине Хөсәен әл-Бәлхи әл-Каунәви. Нәселе олы туры сүзле мөэминнәр әмире Әбү Бәкер хәзрәтләренә тоташа. Шулай ки: искә алынган Хөсәен бине Әхмәд бине Мәхмүд бине Мәүдүд бине Сабит бине Мөсәййиб бине Мотаһһир бине Хәммад бине Габдрахман бине Әбү Бәкер әс-Сиддыйк радыяллаһү ганһү. Бәлехтә [һиҗри] 604 елның 6 рабигыль-әүвәлендә туган, Каунәиядә [һиҗри] 662 елның 5 җөмадиәл-ахирендә дөньядан кайткан. Рәхимәһүллаһү Тәгалә (Аллаһ Тәгалә аны рәхим кылсын – *А.Г.*)! Тәрҗемәи хәле Гариф Җами Мәүләнә Габдрахман ән-Нәкышбәнди хәзрәтләренең «Нөфхат әл-әнси фи әхвали хәзрәт әл-коддүс» китабында ихтирам белән искә алынган.

[...].

## Әнвәр паша белән сөйләшүләр һәм аның фикерләре

Бүген (шимбә көн 17 августта) Төркиянең хәрби министры Әнвәр пашаны йортына бардым. Ике көн элек Берлиннан килгән икән, яхшы, түбәнчелек белән каршы алды. Яшь, рухлы, нык, каһарман кыяфәтле, кыланышлары һәм хәрәкәте акыл һәм батырлык күрсәтеп тора. Тулы әгъзалы, эре борынлы, зур күзле, таза гәүдәле адәм.

«Төньяк төрекләре, Төркиягә күңел һәм рух белән бәйләнешләре һәм мәхәббәтләре булганлыктан, сезнең дә Төркиянең бер ислам каһарман милләтенең бөек хадиме булганлыктан, күңелләрендә хакыгызда зур ихтирам саклыйлар, исемегезне дә ихтирам итәләр, балаларына Әнвәр исемен бирәләр. Аллаһ даими рәвештә ярдәмчегез булсын! Сәяси хәлләр диңгез кебек кайчак тыныч, кайвакыт дулкынлана, куркыныч хәл күрсәтә, өметсез булмыйча, хәерле ахырын көтүдә», – дидем. Ул да сүзләремә рәхмәтле булып, хезмәтләрендә вазыйфасын үтәргә тырышуын, хәзер җиңелү тарафында булсалар да, Аллаһтан өметен кисмәвен, Аллаһның ярдәме белән бер җиңүгә ирешәчәген сөйләде. «Исламбулның хәле аяныч, әсирлек хәлендәге кебек яшәүдә, Анатолийда бер дәрәҗәдә яхшы хәрәкәт барлыгын сөйләп, яхшы үлемнән курыкмауда», – диде. «Әҗәл, кайчан булса да, бер киләчәк, курку файдасыз, бәлки, зарар

гына, курыкмасак, иншалла, эшләр барып чыгар», – дип рухка ныклык бирердәй сүзләр бәян итте. Бездәге ислам әһелләренең хәлләрен, иске хөкүмәткә караганда боларның дингә крашлары һәм мөгамәләләре ничек икәнлеген сорагач, аерым хөррияттә куйганлыкларын, ләкин кайбер ярашканлыклары булмавын, шул сәбәпле килгәнемне белдердем. Тышкы эшләр комиссары Чечериннан, мөселманнарның диннәренә һәм гадәтләренә каршы бармау, дини хисләренә бәрелмәү тиеш икәнен сөйләде. Мин дә элекке Төркия илчесе өстенлекле Кәмаль бәк белән байтак сөйләшкәнлегемне һәм кайбер дини һәм милли киңәшүләрдә булып, безнең бу тараф мөселманнары өчен хөкүмәт янында да хәерлелектә булачак вәгъдәсе булганын сөйләдем һәм: «Сездән дә, җае чыкса, мөселманнарның вәзгыятьләре турында хөкүмәт башлыкларының зурларына бер-ике авыз сүз сөйләвегез өмет ителәә», – дидем. Кабул итеп, вәгъдә бирде. Соңра артык утырмыйча, ярдәм алып чыктым. Тышкача озатып, әдәплелек күрсәтеп калдылар.

Бу адәм хәзерге хәлнең авырлыгын яхшы белә торган кеше. Каршыбыздагы дошман куәтле дип үзе дә әйтә. Германиядән, әлбәттә, бер фикер белән килгән. Моннан Кавказга, аннан Анатольгә барачак. Һаман да Антантага Исламбулга каршы хәрәкәтләреннән өметсез булмаганга охшый. Инглизләр һәм иптәшләре Исламбул хөкүмәтен куркытсалар да, Анатольдәге Төркия гаскәрләренең әһәмияте юк түгел, бөтен Төркия вилаятьләре аларның кулларында булганлыктан, килешүдә алар белән хисаплашырга мәҗбүр булсалар кирәк.

Чәршәмбе көн, 18 август көн, сәгать бердә Әнвәр паша иптәшләре һәм адъютантлары белән йортыбызга килеп китте. Чәй мәҗлесе корганлыктан, бер сәгатьтән артык утырдык. Чәйне яратуы аз икән. Шундый төтен эчмәс, шәригать тыйган шәраблардән дә сәламәт икән. Күбрәк су белән канәгать булуын сөйләде. Сәламәт фикерле, нык, әгъзалы, көчле, мәшәкатьләргә, киртәләргә каршы чыдамлы булуының сәбәпчесе һәм сәбәбе дә, шаять, шул. Русия мөселманнары өчен, аеруча галимнәр өчен Шура хөкүмәтенә ничек мөнәсәбәт тиеш булыр, нинди сәясәт куллану файдалы булыр, соравын бирдем. Ул түбәндәгеләрне аңлатты:

«Галимнәр өчен сәясәтчә битарафлыкны саклау өстенә, яхшы мөгамәләдә булу, дустанә сәясәт тоту, арадан кайбер яшьләрнең хөкүмәт хезмәтендә булуларына ярдәм итү, ул яшьләр белән дә яхшы мөгамәләдә булу тиешле, мөселманнар хөкүмәтнең ыша-

нычлы карашын җәлеп итсеннәр дә диннәрен үзләре саклап, сәяси һәм икътисади эшләрдә файда итсеннәр, алдагы көннәре өчен әзерлек күрсеннәр. Кайбер яшьләрнең коммунизмга язылулары, минемчә, гаеп һәм хата эш түгел», – ди. «Алар, иншалла, исламнарын һәм иманнарын югалтмаслар. Югалтса да, бик азы югалтыр, ләкин гомуммилләт боларның коммунист булып, хөкүмәт хезмәтендә булуларыннан файда алыр. Шунлыктан бу рәвеш хисапланыр. Бу турыда төрле җирләрдә һәм төрле мәҗлесләрдә булу белән адәмнең дини ышануы бозылмый, бәндә хисләрен югалтмаса, зыян күрмәс, бары хисләрен югалтмаска кирәк. Мин дә Берлинда тордым һәм башка күп җирләрдә булдым. Исерткеч һәм сигара эчмәдем, хәтта каһвә һәм чәй дә бик аз эчтем. Икмәк, су белән канәгатьләнәм. Динем һәм иманым, әлхәмдү лилләһ (Аллаһка мактау булсын – *А.Г.*), әүвәлгедән куәтлерәк булды, исламга ихласлыгым артты», – диде. Кайбер дини зарарлары һәм ризасызлыклары була икән, халык үзе аңа каршы диннәрендә ныклык күрсәтеп, дин укуны, кайсы урында һәм нинди бинада булса да, туктатмасыннар, укытсыннар. Мәктәпләренең алынулары укытмаска сәбәп булырга тиеш түгел, бу бабта артык тарткалашмыйча, табылган урында һәм мөмкинлеге булган рәвештә укыта бирү кирәк», – диде.

Сүз арасында элекке сүз кебек: адәм баласы ни кадәр авырлык күрсә дә, Аллаһтан өметен өзмәскә тиеш. Ахыр чиккә килеп тә, уңыш табулар була. Алдагы көндә ислам галәме өметле, киләчәге яхшы, соң булса да, бер төзеклек хәленә ирешер, без күрмәсәк, бездән яшьләр күрер, үз рәхәтебез, үз мәнфәгатебез өчен эш күрү тиеш түгел, бәлки, эшне эш булсын өчен эшләү, файдасын кем күрсә дә күрсен, ышануы белән эшләү тиеш. Юллы хәрәкәт итеп, эш күрелсә, нәтиҗә булса-булмаса да, җанга рәхәтлек хасил булыр.

Бу мәгънәдәге киңәшләр һәм ләззәтле бәяннәреннән соң чәй мәҗлесен үткәреп, ике һәм чирек (14:30) сәгатьтә саубуллашып, йортыбыздан чыктылар һәм киттеләр, фи әмәниллән (Аллаһ иминлегендә – *А.Г.*).

Алманиянең Шурага һәм Төркиягә кушылып, Антантага каршы сугыш ихтималыннан сорагач, хәзер андый галәмәтләр ачык түгел, ләкин алда ихтималлар булганын кыска гына әйтеп, бик эчкә кермичә, канәгатьләнде. Әлбәттә, сәясәт иясе сәясәттән күп сөйләмәс, һәр җирдә шалтырамас. Вәс-сәлам!

Әфганстан пайтәхете Кабул шәһәрендә «Әман Әфган» исемле фарсы телендә ташбасмада рәсемле журнал чыга башлаган, 3–4 саннарын Мәскәү имамы ахун Габделвәдүд кулында күрдем. Әфган илчесе һәм вәзире Мохтари Вәлихан китергән. Бер нөсхәсендә искә алынган ахунның элек килгән әфган вәкилләре алдында булган җомгада кайбер сәяхәт файдаларын кушып, сөйләгән вәгазен фарсыга тәрҗемә итеп, бастырганнар. Аның улы белән алынган рәсемен төшергәннәр. Бу вакытта вәзир бу ахунга, хатынына һәм баласына киемнәр китергән. Искә алынган журналны күздән кичердем. Әдәби һәм сәяси мәкаләләре бар. Ауропа сәяси хәлләреннән кыскача байтак нәрсә язылган. Һиндстан мөселманнарының Калькуттада һәммә базарларны бикләп, эшләрне туктатып, җамигъта (төп мәчеттә – *А.Г.*) тупланып, инглизләрнең Исламбулга хакимлек итү һәм солтан зарарына, хәрәкәтләренә каршы нәфрәт игълан итүләрен теркәгән.

Сүриядә, Шамда әмир Фәйсалның Шам вилаяте таҗын кигәне бәян ителгән. Болар Шамда Франция яклавында, Гыйракта инглиз яклавында мохтариятле бер хөкүмәт булып, янә бу хөкүмәтләр тарафыннан куелган комиссия Тәхет идарәсендә эш күрәчәкләр икән.

Әмир Фәйсал, әмир Габдулла, Шәриф Мәккәдән Сәед Хөсәеннең уллары булса кирәк. Югарыда искә алынган затның сугыш вакытында Төркиядән аерылып, инглиз фикерләре һәм сәясәтенең тәэсиренә бирелгән нәтиҗәсе булган. Югарыда бу мәсьәлә кыскача искә алынган иде. Аллаһ мөселманнар өчен хәерле хәлләр насыйп итсә иде!

[...].

Әнвәр паша белән өченче сөйләшү Төркиянең башка түрәләре белән берлектә бер кунакта булды. Озын сөйләшүдә бер зат, үткән эшләр җөмләсеннән Төркиянең үткән сугышта читтә калуына күрә, Германиягә кушылып сугышны өстен күрүнең сәбәбен сорагач, бераз авырлык белән бәян итте. Әйтсә дә, бик аңларлык һәм канәгать итәрлек җавап булып чыкмады. Шулай аның әйтүенчә: «Төркиянең Германия тарафыннан сугышка катышуы, Төркиянең бик олы дошманы булган Русияне тар-мар итте. Романов династиясенең бөтенләй югалуына сәбәпче булды. (Төркия Германиягә кушылмаганда, Русия сугыштан тизрәк файдалы чыгып, бөек инкыйлаб тумас иде). Аның урынына большевизм туып, өлешчә кешеләренә, байларга зарарлы булса да, гомумхалыкка файдалы, ислам

өчен ирекле бер хөкүмәт туды. Аның карашынча, коммунизм – мөселманнар үз диннәрен яхшы саклау шарты белән гомум тормышны яхшырту өчен файдалы, мөселманнар үз кирәкләрен юнәтү өчен уңайлы. (Ләкин бу сүзе аңлашылмас бер табышмак кебек пункт, бәлки, сәясәт карашы белән әйтә торгандыр).

Төркия хәзер авыр хәлдә, ләкин бу хәл, Германия җиңүче килсә дә, булачак иде.

Англия урынына Германия тәхет алуга керәчәк иде. Бәлки, бу хәлебез, сугышыбыз астында, Аллаһның ярдәме белән, килешүне кулайлатыр, җиңеләйтер. Безнең үз өстебезгә алуыбыз җиңелрәк зарар булып калыр. Читтә калсак, янә безне бүлгәләячәкләр, Русия, Франция, Англия, Италия дүрт тарафтан кирәк җирләренә йогынтыларын эшләтәчәк, бәйсезлегебезне бетерәчәк иделәр», – диде. Ләкин, билгеле ки, бу соңгы пунктында зур шөбһә бар. Читтә калса, бәлки игътибарлары артыр, бәйсезлекләрен саклауга ярдәм итәр иделәр. Вәллаһү әгъләм бис-саваб (Аллаһ белүчерәк – *А.Г.*)!

Йосыф Акчура да: «Төркия сугышка кушылмаса, бүлгәләнәчәк, бетереләчәк иде», – ди. Бәлки, сәясәт башлыклары бу мәсьәләне анык белгәнлектән, катышуны тиеш күргәннәрдер. Халык мондый сәясәтләрдән ваемсыз булганлыктан, ачык күренгән авырлыкларга карап хөкем итә торганнардыр.

Яңа хәбәрләр һәм фикерләр тумаса да, үткән хәлләрдән фикер алышынды. Муса әфәнде Казан мөселманнарының (Русия мөселманнарының) Төркиягә каршы яхшылык күтәреп баруларын начар санап, кыскача нотык сөйләде. Әнвәр паша: «Каршысында начар саналмас гозерләре ачык. Яхшы ихтыярлары белән Төркиягә каршы яхшылык күтәрәчәк түгеллекләрен һәммәбез беләбез. Шуңа күрә Муса әфәндедән Казан мөселманнарының бу мәҗбүри хәлләрен кабәхәт димәсен, кабул итмәбез», – дип җавап бирде. Мин дә ахырда утырган хәлемдә генә: «Русия мөселманнарының ихтыярлары белән Төркия гаскәренә атарга риза булмауларын бәян итеп, мисал буларак, бу гомуми сугышта Хаҗитарханда беренчелектә булган бер мисалны сөйләдем:

«Бер мөселман егет гаскәри хезмәткә алынганнан соң Кавказ җиренә төрекләргә каршы барырга боерылган. Гаскәр рәисләренә тәкъдим иткән: «Мине башка тарафка, ни җиргә җибәрсәгез дә, китәрмен, хезмәт итәрмен, ләкин Төркиягә каршы җибәрмәсәгез иде», – дип үтенгән. Ләкин гаскәри идарә моның үтенечен баш тарту [дип] санап, асарга хөкем иткән, һәм асканнар. Дине һәм

вөжданы өчен җанын фида кылган». Рәхимәһүллаһ (Аллаһ аны рәхим кылсын – *А.Г.*)! Мөселманнарыбызда шундый сәламәт хис бар икәнен бәян иттем. Соңра – кирәк Әнвәр паша, кирәк башкалары – безгә сезнең Русия мөселманнары хакында мондый шөбһәбез юк. Аларның бу мәсьәләдә кимчелекле булмаулары хәтеребезгә бәйләнер, мәгънәсен әйтешеп, әдәплелек күрсәтеп, мәҗлес тәмамланды.

Пәнҗешәмбе 19 августта Төхфәтулла исемле Төркия гражданы, сәүдәгәрдә мәҗлес булып, Әнвәр паша, Мирсәет Солтангалиев, Муса әфәнде һәм башкалар булып, зур кунаклык тәкъдим итте. Әнвәр паша Кавказда һәм Берлинда калган кайбер иптәшләрен (Габделгазиз Чавыш Туниси кебекләрне) чакырып, Мәскәүдә Мәркәздә кайбер сәяси эшләр турысында киңәшләшәчәген миңа сөйләде: «Башка җирдә җыелсак, бу хөкүмәт берәр төрле шикле уйга төшмәсен өчен җыелабыз». Соңра Кавказга, соңра Төркестанга китәчәк икән. Казан, Хаҗитархан мөселманнарын күреп китү турында сүз булып, хөкүмәтнең карашына карый торган план икәнен сөйләде. Хөкүмәтнең, бәлки, болай йөрүгә яхшы карамавы ихтимал тотыладыр, Җамал пашаны да Төркестанга туры күндергәннәр. Хөкүмәт һәрничек болар белән яхшы мөгамәләдә булса да, үзенең саклыгын, ислам союзы мәсьәләсен исендә тота һәм аннан курка.

## Татар-башкорт җөмһүриятләре

Бу мәҗлестән чыккач, Мирсәет Солтангалиев йортына чакырылып, ике сәгать кадәр утырдык. Иске заманнардан бераз бәхәсләшеп үткәрде. Җөмләсеннән: башкортларның хокуклары киметелүе, үзләренең кайбер уйлап эшләмәүләре булуын бәян итте. «Аларга идарә итеп торыр өчен билгеләнгән Преображенский исемле рус аларның зарарларына хәрәкәттә булып торган хәлдә, хезмәттән русларны чыгарып, мөселманнарны гына сайлаулары шөбһәгә сәбәп булды. Зәки Вәлиди һәм иярченнәренең Татар-башкорт җөмһүриятенә бар көчләре белән каршы торулары ул Җөмһүрият тарафлы коммунистларның да байтак начар күрүләрен җәлеп итте. Бара-бара Зәкине Мәркәзгә алдырдылар, урынына башканы куеп, идарәне башка төрлерәк төзеделәр», – дигән мәгънәдә аңлатты.

Татар-башкорт җөмһүрияте төзү турында бу Мирсәет һәм башка фикерлерәк мөселман коммунистлары яхшы тырышуда булганнар. Җөмһүриятне киң чикле, киң хокуклы итәр өчен күп тырышканнар. Хәтта кечкенә булганда хезмәтен кабул итмәячәкләрен игълан итүгә кадәр барганнар. Казан һәм Мәркәздә булган әһәмиятле коммунистлар бар да шул фикердә булып, эш карарга якынлашканда башкортларның кире кагуларына Шәмиголов кебек асыл җөмһүрият каршылыгында булганнарның котыртуы, башкорт җөмһүриятенә шөбһә белән караучыларның һәм рус Преображенскийның доносы, Сәетгалиевның да бердәмлектән чыгып, үзе генә кечкенә даирәдәге татар җөмһүриятенә ризалык сиздерүе кебек нәрсәләр җыелып, зур Татар-башкорт җөмһүрияте туар урынга кечкенә генә Татар җөмһүрияте туып куйган. Башта бу җөмһүрият башына Солтангалиев билгеләнебрәп торса да, бу кечкенә туган җөмһүриятне ул кабул итмәгән. Шунлыктан баштан ук ризалык күрсәтүче Сәетгалиев куелган икән. Бу кадәр – Солтангалиевның аңлатуларыннан файдаланган нәрсәләр.

Үз максатларына килгәндә, бина турында, гомуми биналарны карау вазыйфасында булган зур даирәгә мөрәҗәгать тиешле булганга: «Тиздән хәл итеп булмый», – дисә дә, «Анда мөрәҗәгатьне тиз әйләндереп булмасмы», – диюемә тырышып карауны вәгъдә итте. Башкалары турында да вәгъдәләре кат-кат булды. Ялган вәгъдә җөмләсеннән булмаса, ярар иде. «Ялган вәгъдә булды һәм ялганнан башка вәгъдәсе юк» – [дигән] шигырьне уку башыма килмәсә, яхшы иде.

Якшәмбе китәчәгемне әйттем, «Бер ай торып, рәсми бер язусыз, коры сүз вәгъдәсе белән генә кайтуны авыр күрәм», – дидем. «Язу әзерләрмен», – дип вәгъдәсен янә яңартты. Ахыры ни булыр?

Икенде [намазы] вакыты тарайганнан, «Намаз укып чыгам, сез – коммунистларның намазлыкларыгыз да юктыр», – дип хатынына әйткәч, «Мирсәет хәзер табып бирер», – диде. Чыннан да, икенче бүлмәдә Мирсәет намазлыкны кыйблага юнәлтеп җәйгән иде. Икенде [намазын] укып, кайбер йомышларны сөйләп, саубуллашып чыктым.

Җомга көн 20 августта кара икмәкнең кадагы ике йөз, бер пот печән унике мең сум, дип ишетелде. Аллаһүммәр-хәм гыйбәдик (Аллаһым, колларыңны рәхим кыл – *А.Г.*)!

## Җомга хатирәләре

Җомганы янә беренче мәчеттә укыдым. Кыскача вәгазь һәм хөтбә белән канәгатьләндем. «Көнләшмәгез, кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, ачуланышмагыз, бер-берегезне ташламагыз, Аллаһның коллары булган хәлдә, бер-берегезгә кардәшләр булыгыз... Бер мөселманның икенче мөселманга абруе да, малы да, каны да хәрам» дигән сахих (дөрес – *А.Г.*) хәдисне укып, тәрҗемә иттем.

Хөтбәнең кыскалыгы, намазның озынлыгы тиешле булу, «ахырзаманда хөтбәләре озын, намазлары кыска булган адәмнәр килер» җөмләсе кисәтү сурәтендәрәк искә алынуы хәдис-шәрифләрдә килгән. Бу бабта үзем дә сакланып, сөннәткә игътибар итеп укырга тырышсам да, төркичә вәгазьләр озынрак булып, сөннәт даирәсеннән чыкмыймы икән, [дигән] шөбһә һәрвакыт эчемне пошыра. Башкаларга да бу мәсьәләне искәрттем. Ләкин игътибар иткәннәр күп булмый.

## Әфган вәзире һәм вәкиле белән сөйләшү

Шимбә көн 21 август кичке сәгать җидедә Мәскәү имамы ахун Габделвәдүд бине мулла Фәттахетдин йортында Әфган дәүләте вәзире Мохтари Вәлихан белән очрашу булды. Янында Шура дәүләтендә дәүләт вәкиле булып торачак илчесе Мирза Мөхәммәдхан, сәркятибләре, адьютантлары һәм тәрҗемәчеләре бар иде. Вәзир минем белән танышу морадында булганын искә алынган ахунга аңлатканлыктан, югарыда искә алынган зат үз йортында кечкенә генә пылау һәм чәй мәҗлесе ясап, чакырган иде. Бер сәгать кадәр сөйләшеп утырдык. Акыллы, сәяси адәм, Бохара, Хәрәзем түрәләре кебек түгел, мәгълүматлы, Аурупа дәүләтләрендә дә үзен яхшы тотарлык вәзир икән. Аллаһ Тәгалә ислам дәүләтләрендә мондый түрәләрнең мисалларын күбәйтсен! Үткән ел Бохарада Кабул галимнәреннән Сәйфрахманхан һәм Мансурхан исемле бөек адәмнәре белән булганнар, аларның хәлләрен әйтеп, кайгырды. Ислам галәменең хәзерге сәясәт карашынча күренгән киләчәген сорагач, бик куркыныч икәнен сөйләде. Хәзерге сәясәт башлыклары турында түбәндәге җавап кыскалыгы белән канәгатьләнүне үзенә кагыйдә итеп тоткан: «Мөселманга фәкать мөселманлык кирәк, шул җитә».

Сүзнең баруыннан һәм башка сөйләшүләрдән аңлашуына күрә, искә алынган җөмләнең аңлатмасы һәм аңлатуы коммунизмның кайбер кагыйдәләре мөселманлыкка муафикъ икән, кабул итүенә киртә юк, кайбер кагыйдәләре каршы булса, мөселман тик үз диненә карасын, шул ышануы буенча хәрәкәт итсен. Кыскасы, ни тулысынча кабул итү, ни тулысынча инкяр итү, бәлки, өлешчә кабул итү һәм өлешчә инкяр итү юлында. Вәс-сәлам!

18 айлык падишаһлары әмир Әмануллахан бине Хәбибуллахан бине әмир Габдрахманхан бине Дустмөхәммәдханның диндар, шәригатьне саклау һәм үтәүдә тырышучы икәнен, Төркия дәүләтенең хәзерге җиңелүе һәм инглизләрнең җәберләү куәте астында калулары өчен артык хәсрәттә, хәтта Төркия эчендәге адәмнәрдән дә артык кайгыруы хакында сөйләде. Бу Әфган дәүләте вәкилләрендә байтак өмет бар, болар Аурова гыйлемнәрен һәм гаскәрләр төзү ысулларын акрынлап үзләрендә кабул иткән хәлдә, диннәрен кулларыннан бирмәгәннәр, ислам өчен иң файдалы рәвеш һәм файдалы юл – бу.

## Милли эшләр комиссариатыннан җавап

Шимбә көн 21 августта Мәскәүдән чыгар өчен әзерлек күрелде. Шул көн ахшам [намазыннан] соң гына Шәрык бүлеге идарәсеннән – Милли эшләр комиссариаты коллегиясеннән – Мирсәет Солтангалиевкә бирелгән кәгаземә яхшы җавап һәм юл өчен рөхсәт язуы кулыма иреште. Әлхәмдү лилләһи галә зәлик (Аның өчен Аллаһка мактау – *А.Г.*)! Җавабында Диния нәзарәтенең дәвам итүе, бинасының да тартып алынмавы, дини мәктәп мәсьәләсе халык тарафыннан торгызылып, дин укыту өчен булганлыгында халыкның үзенә кайтарылуларының мөмкин булуы, кабул иткән сурәттә хәл ителә. Башка маддәләр исә декретлар белән электән үк хәл кылынулары, шул декретлар буенча мөгамәлә итәчәкләре әйтелгән. Мәдрәсәләр мәсьәләсе, Казан һәм башкорт җөмһүриятләре эше булганлыктан, аларга тапшырылган. Мәдрәсәләрнең күбесе Казанда булганлыктан, бу рәвеш ихтыяр ителгән. Ни булса да, бер ай кадәр Мәскәүдә торуым авыр эш булса да, хәзерге күренештә нәтиҗәсез булмады. Иншалла, ахыры хәерле булыр. Бу вакытта тормышыбыз Карамышевлар сәүдәгәрләр йорты әгъзасыннан Ибраһим Карамышев Кирмәни, Зыятдин бине Хәмид Фәез әфәнделәрдә мосафир

булып, ихтирам күреп тордык. Номерда һәм башка җирдә торып, бер йөз мең сум кадәр акча тотуыбыз тиешле икән. Бу адәмнәр бушка, милләткә ихтирамнары өчен без – ике адәмне – ихтирам иттеләр. Хакы урынына рәхмәт һәм хәер-догадан башка бер эш кабул итмәячәкләрен ачык белдерделәр. Җәзәһүмүллаһү хайра (Аллаһ аларга хәерле әҗерен бирсен – *А.Г.*)! Үзләре һәм гаиләләре хезмәтебездә һәм ихтирамыбызда кимчелек эшләмәделәр. Аллаһ барчасының дин һәм дөнья якларын төзек һәм мәңге итсә иде! Бичаралар элекке заманда Карамышевлар исеме астында каракүл белән зур сәүдә итеп, зур байлыкка ирешкәннәр иде. Элекке баруыбызда 1918 елда да аларда мосафир булган идек, уңышлы сатылу һәм муллыклары вакытында иде. Бу соңгы елларда сәүдә малларына әйләндерелгән бөтен милекләре диярлек, байлыклары конфискацияләнгән. Калса да, кулларында аз нәрсәләре калган. Өйләре, җиһазлары сәламәт, заводлары хөкүмәт исемендәге эшчеләр ширкәтенә әйләндерелгән, үзләре дә шунда кара эшчеләр белән бергә эшләп, көн күрәләр. Олы бертуган абыйлары Әхмәд әфәнде Карамышев быел кышта вафат булган. Бер иптәшләре – минем элекке кунак өем Госман бине Фазыл Альбитков – Буада эшчеләр ширкәтеннән гыйбарәт [булган] күн заводларында эшли икән. Әхмәд тормышында да бу ике иптәш тә Буада яшәгәннәр. Хәзер Мәскәү заводында Зыя калып, Ибраһим янә Буага китәчәк булып калды.

**Гыйбрәт.** Үткән кышта Ибраһим, Госман, Зыя Буада зур гаиләләре белән җиде йөз мең сум акча тоткан хәлдә, Мәскәүдә агалары Әхмәд тик гаиләсе белән үзенә миллион өч йөз мең сум акча тоткан. Һәркайсы икътисад әһеле булулары белән бергә, урыннарының чиктән чыккан төрлелектән килгән аерма зур. Аллаһ бәрәкәтләрен алмасын иде! Бу көннәрдә кечкенә бер гаиләгә исрафсыз, тартынусыз гына тормыш өчен дә аена өч йөз мең сум кадәр хәҗәт икән. Янә Аллаһның ярдәме һәм рәхмәте [белән], мөселманнар ач түгел. Аллаһ җүн бирә, яхшы торалар, диләр. Аллаһ кемне тели – шуны хисапсыз ризыкландыра.

Мәскәүдә хөкүмәт белән мөгамәләмдә мәшһүр милләт хадиме Заһидбәк бине Мөхәммәдшафикъ бине Шәех Имам Шамвил җәнабләренең күп файдасы иреште. Бу адәм – һәркем хакында иганәле, хезмәтле, һәркемнең яхшы ризалыгын җәлеп итә, гомуми һәм милли эшләр булса, бигрәк тырышучан һәм ярдәмле. Күп заманнардан бирле шул күркәм холыгы белән танылып килә. Биреләчәк

гаризамны күп дәгъва вәкилләренә йөреп, мәшәкать белән яздырып, әзерләп бирде. Хезмәт хакы тәкъдим ителүне дә кабул итмәде. Ахырда Ибраһим әфәнде Карамышевка, дәгъва вәкиленә һәм ямщикка тоткан чыгымына каратып, ун мең сум биреп калдырдым. «Кабул итәрме, юкмы», – дип шөбһәдә калдылар. «Миннән соң бирерсең, кайтарып алмыйбыз, диярсез», – дидем.

Янә бу бабта Мөбин бине Сәлим Паршави исемле егетнең хезмәте күп булды. Солтангалиев белән яхшы танышлыгы булганлыктан, яхшы арадашчы булды, чын хезмәт итте. Үзе дә сәүдәдән бай булып киткән, тыныч кына тора икән. Аллаһ барчасына хәерлесен бирсен!

## Мәскәүдән Казанга юнәлү

Торагыбыздан, аның хуҗасының Мәскәү ысулынча сикертмәле эш арбаларына әйберләребез белән, йорт хуҗасы белән икәү һәм арбачы утырып, вокзалга бардык. Ямщикка алты-җиде сум тоттыруыбызны кабул итмәде. Вакытына күрә, мондый арбада бару зыянлы түгел дип, тәкъдимнәренә күрә бардык. Ике сәгатьтән вокзалда булып, билетларыбыз да шәһәрдән янә йорт хуҗасының ярдәме буларак алынган иде. Сәгать ярым кадәр көткәч, вокзалга керергә ярдәм итеп, саубуллашып, вагонга юнәлеп, хәзер икенче дәрәҗәдә хисаплана торган борынгы спальный, өченче дәрәҗәдәге вагонга урнаштык. Урыннар номерлы, хөрмәтле булганлыктан, тыныч иде. Такта өстендә катырак булса да, шикаять итәрлек түгел иде, икебез ике сәкедә ятып кайттык. Өч сәгатьтән поезд кузгалды. Тиз йөри торган поезд булгач, тиз кайтты. Арадагы станцияләрдә аз туктады. Туктаган җирләрендә утын-су алырлык кына туктап уза, алма, йомыркалар саталар, башка нәрсә юк. Йомырканың иң арзаны Төрләмәдә булды, дистәсе биш йөз сум иде. Мин дә бер карт чуаш кулында кәрҗинле йомырка күреп, сатулаштым. «110 йомырка – 5500 сум, бүлеп сатмыйм», – дигәч, алырга булдым. Урыныбызга кертеп санадым, чуаш карап торса да, өч данә ким чыкканын кабул итмичә, минем кулыма, үзенең күзенә ышанмыйча: «Саналган, дөрес иде» – дип, кире алып китәчәк булды. Бәлки, хата үземдә булгандыр, дип, акча бирдем. «Иске генә кәрҗинне ал», – дип тәкъдим итте. «Биш йөз сум бирәләр иде, сиңа ике йөз сумга бирәм», – дигәнгә: «Хәергә йөз сум өстәп бирәм», – дигәч, кабул

итте. Чуашлар искечә хәлләрен бетермиләр, беркатлылыклары гомерлек, тугрылыклары да күренә. Ышанырлык кайбер хаталары булса да, тугрылыклары алга чыга. Хәзерге мәдәният хыянәтеннән сәламәт күренәләр. Сирәк кенә кайбер җирләрдә май күренде, 1800 сумга алгалыйлар. Күбрәк ике мең сумнан сатыла. Без дә ике меңнән җиде ярым кадак май алдык. Мәскәүдә биш мең сум иде, аңа да табып булмый. Кирәгеннән артык булса да, тоташ булгач, шулай алдык. Шулай кайта торгач, җиде ярым сәгатьтә Казанга кайтып иреште. Ләкин чыгар көн тикшерүче әйберләребезне күп күреп, тишерделәр, йомыркага бәйләнделәр.

Мәскәүдән бирелгән ихтирамлы тәүсыянәмәне (документны) комендантка күрсәткәч, өстән генә карап: «Үткәрегез», – дип фәрман бирде. Сәламәт чыктык, әлхәмдү лилләһ (Аллаһка мактау булсын – *А.Г.*). Чыктык, ләкин арба юк, алдан чыккан кешеләр барысын алып бетергәннәр. Гыйлаҗ әфәнде Альметов та кайта икән. Ул да әйберләрен куеп, телефон аша өйдән ат соратып, көтәргә калды. Безнең әйберләребезне дә китерәчәк булып, безне җәяү озатты. Сәламәтлектә, исән-сау өебезгә кайтып җиткәндә, әйберләребезне тапшырдылар. Һичбер әйберебез югалмыйча, җиңеллек белән сәфәрдән кайттык. Аллаһка шөкер!

Кайткач, Сергач өязендә төшеп, муллалар белән танышу фикере бик куәтле иде. Ләкин гаетне Казанда үткәрү мәҗбүри һәм тиеш булганга, моны эшләү мөмкин булмады. Сергачта өч-дүрт хатын очрап, хәлләрне сораштык. Аларда гает сишәмбе көн икән. Муса әфәнде шул якларда йөреп, Мәскәүдән Петроградка килешендә, үзеннән һәм Диния нәзарәтеннән сишәмбе көн укуны сөйләгән булса кирәк. Аның фикеренчә, шулай сишәмбе көн булырга тиеш. Петроград мөхтәсибе Лотфый әфәнде дә шулай, ди. Ләкин Мәскәүдә чәршәмбе көн укыячак булып калуларын, Казанга кайткач, хәбәр итте. Диния нәзарәте сишәмбе көн укуны ихтыяр иткән икән. Казанлылар чәршәмбе көнгә карар биргәннәр. Муса әфәнде обсерваториядән хәбәр алып, ягъни андагы караштан хәбәр алып, айның тәмамлануыннан күчеп, күрү урынына килгән, айны баш көн [итеп] игътибар итә. Обсерватория кешеләре хәбәрләренә күрә, зөлхиҗҗә ае шимбә көн 14 августта иртәнге җиде сәгать кырык дүрт минутта туган икән. Кичәсе якшәмбегә каршы яңа ай дәрәҗәсенә килә. Шунлыктан якшәмбе ай башы булып, дүшәмбе Гарәфә, сишәмбе гает булырга тиеш була. Диния нәзарәте моны да

игътибарга алган. Ләкин аның үз календарендә рамазаннан бирле айлар берәр көн соң игътибар ителә.

## Обсерватория хисаплары

Бу 1920 елның Казан обсерваториясеннән алынган календарен монда язам, шаять, файдасы булыр. Яңа сәгать һәм яңа ай хисабы белән айның тууы (яңа сәгать кояш сәгатеннән ике сәгать элек):

Җөмадиәл-әүвәл 21 гыйнварда, чәршәмбе көн иртә 8 сәгать 27 минутта туар, пәнҗешәмбе.

Җөмадиәл-ахир 20 февраль, җомгага каршы төн, 12 с. 35 м., ай башы – шимбә.

Рәҗәб 20 март, шимбә көн, 1 с. 56 м., ай башы – якшәмбе.

Шәгъбән 19 апрель, шимбәгә каршы төн, 12 с. 43 м., ай башы – сишәмбе.

Рамазан, 18 май, сишәмбе иртә, 9 с. 25м., ай башы – чәршәмбе.

Шәүвәл, 11 июнь, чәршәмбе көндез, 4 с. 41 м., пәнҗешәмбе.

Зөлкагъдә, 15 июль, пәнҗешәмбе, 11 с. 25 м., шимбә.

Зөлхиҗҗә, 14 август, шимбә иртә, 6 с. 44 м., якшәмбе.

Мөхәррәм, 12 сентябрь, якшәмбе көндез, 3 с. 52 м., дүшәмбе, сишәмбе тиеш.

Сәфәр, 12 октябрь, сишәмбе иртә, 3 с. 50 м., чәршәмбе.

Рабигыль-әүвәл, 10 ноябрь, чәршәмбе кич, 7 с. 5 м., җомга.

Рабигыс-сани, 10 декабрь, җомга көндез, 1 с. 4 м., якшәмбе.

12 сентябрьдә якшәмбе, 10 декабрьдә җомга көндезләрендә туган ай кояш бату һәм ай тизлекләреннән ул көннәрдә яңа ай дәрәҗәсенә килеп җитми. Шунлыктан ул кичәләрне ай башы итеп хисаплау тиеш түгел. 27 октябрь чәршәмбе көнне кич 5 сәгатьтән соң ай тотылды, 2 сәгатьтән артыкка барды. Сишәмбе иртәнге 3 сәгать 25 минутта яңа ай туганда 21 октябрьдә сишәмбе көн кич ай тотылган булса кирәк. 1921 ел өчен обсерваториясеннән алынган хәбәр буенча тәкъдим 1340(39) ел һиҗри өчен:

9 гыйнвар, якшәмбе, җөмадиәл-әүвәл, 9 с. 10 м., иртә, дүшәмбе.

8 февраль, сишәмбе, җөмадиәл-ахир, 4 с. 20 м., чәршәмбе.

9 март, чәршәмбе, рәҗәб, 9 с. 53 м., кич, җомга.

8 апрель, җомга, шәгъбән, 12 с. 49 м., көндез, шимбә.

8 май, якшәмбе, рамазан, 12 с., төн, дүшәмбе.

6 июнь, дүшәмбе, шәүвәл, 9 с. 58 м., иртә, сишәмбе.

5 июль, сишәмбе, зөлькагъдә. 5 с. 20 м., көндез, пәнҗешәмбе.

4 август, пәнҗешәмбе, зөлхиҗҗә, 12 с. 1 м., төн, җомга.

2 сентябрь, җомга, мөхәррәм, 7 с. 16 м., иртә, шимбә.

1 октябрь, шимбә, сәфәр, 4 с. 10 м., көндез, дүшәмбе.

31 октябрь, дүшәмбе, рәбигыль-әүвәл, 3 с. 22 м., төн, сишәмбе.

29 ноябрь, сишәмбе, рәбигыль-сани, 5 с. 9 м., көндез, пәнҗешәмбе.

29 декабрь, пәнҗешәмбе, җөмадиәл-үлә, 9 с. 23 м., иртә, җомга.

[Һиҗри] 1339–1340 елларның хисаплары Диния нәзарәте тәкъдиме буенча, әлеге обсерватория хисабына туры килә. Ләкин рәҗәб пәнҗешәмбе, рамазан якшәмбе, зөлькагъдә чәршәмбе башлары бу хисаптан берәр көн элек куелган, ләкин гомуми көн бер. Яңа ай күрү хәл итәр, иншалла.

## Гает хөтбәсе һәм Корбан хикмәтләре

Аллаһ Тәгалә ярдәме белән, чәршәмбе 25 августта Казанда Корбан гаете укылды. Гаетне үз халкым янымда имамлык итеп үтәдем. Халык бик күп, мәчет эче тәмам тулы, әйләнә-тирәсе дә тулган иде. Һава салкын булу сәбәпле, кыскарак үтәүне тиеш күреп, хөтбәнең вәгазь өлешен кыскарак тоттым. Хөтбә вәгазендә: «Йә әййүһәлләзинә әмәнү... Үләикә һүмүл-фәсикун» аятен укып, тәрҗемә иттем, ачыклык керттем. Икенче хөтбәне, башында мактау һәм салаваттан соң, ахырда өчәр кат тәкбир белән тәмам иттем. Коръән укылып, аягүрә басып, кычкырып, төркичә, күз яше белән дога кылдым. Халык байтак вакыт шул тәэсирдә булдылар. Аллаһ Тәгалә киң рәхмәте белән мең кимчелекле гыйбадәтләребезне кабул итсә иде!

Хайван ни кадәр кыйммәтле булса да,ияләрендә дини гадәтләргә ихласлылык бар. Һәркайсы мәхәлләдә байтак Корбан бугазлаганнар. Хайваннар базарларда күп булмаса да, авыллардан җыеп китереп, бүлгәләгәннәр. Егерме-егерме биш мең сумнарга бер дәрәҗәдә сарык алынган. Корбан мәсьәләсе исламда күпчелек галимнәр каршында, имам Әбү Хәнифә иҗтиһадына күрә, ваҗиб. Бу бабта халыкның башка ваҗиб һәм сөннәтләргә дә тырышлыклары бар. Бу тырышлыкта мәхәллә имамнарының күрсәтүләре, кызыктырулары тәэсирсез булмаган. Дәвам итүе һәм таралуы таләп ителә һәм кирәкле. Фәкыйрьләр аз булса да файдалана, кунак итүләр

сәбәпле, дус-иш арасында үзара сөйләшүләр туа, уяу имамнар булса, файдалы әңгәмә була, алар өчен икътисади файдалар да була, бу да – иҗтимагый файда, шәригать буенча дөрес.

Кайбер динсезләр тарафыннан: «Хайван бугазлап, кан агызып гыйбадәт кылу булмаска тиеш, бер мәхлукны рәнҗетеп, канын агызып гыйбадәт кылу тиеш түгел, бу гыйбадәт кирәк икән, бәясен, кыйммәтен фәкыйрьләргә сәдака итсен», – диючеләр бар. Ләкин бу мәсьәлә әйтүче тарафыннан шәригатьне дөрес вәхи (Аллаһның җиткерүе – *А.Г.*) буенча, өммәтләргә ирештергән пәйгамбәрләр тарафыннан хәл ителгән. «Һүвәлләзи халәка ләкүм мә фил-әрдый җәмига» аяте бәяненчә, хәйваннар кешеләрнең файдалануы өчен барлыкка китерелгән. Бер хайванны корбан итеп бугазлауда дин хикмәте һәм файдасы бар:

1) нәфесен буйсындырып, үсүе таләп ителгән бер хайванын киметә;

2) кешеләр җәмгыятенә файда итеп, ите һәм тиресе белән фәкыйрьләргә файда итә;

3) халыкка, гаиләсенә таләп ителгәнчә иркенлек итә;

4) шул вакытта, бәлки, элек имансыз, гайрәтсез бәндә: «Йа, Рабби, синең әмерең булса, синең юлыңда үземне корбан итәр идем. Рәхмәтеңнән, бер хайванны үзебез өчен фида итәргә рөхсәт бирүеңнән, бу хайванны бугазлыйм, кабул итсәң иде», – [дигән] җөмләләре белән мөрәҗәгать әйтеп, байтак ләззәт, руханият табып, Аллаһка якынлык хасил итә. Шунлыктан Адәм пәйгамбәрдән бу гыйбадәт башланып, Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссләләм вакытында кайбер хикмәтләре аңлатылып, адәм баласыннан фида булуы күрсәтелеп расланган. Рәсүлүллаһ салләллаһү галәйһи вә сәлләм вакытына килсәк, аның изге шәригатендә карар бирелеп, бу эшкә халыкны үзенең гамәле һәм кулы белән ишарә итеп, һәммә иманлы халык канәгать итәрлек дәрәҗәдә бәян итә. Шунлыктан бу мәсьәләдә алай-болай сүзгә, юк-барга һәм динсезлеккә бирелгән акыл белән үзгәртүләргә юл юк. Элекке заманнарда мондый динсезләр булгалап, иманы зәгыйфь адәмнәргә төрле котыртулар салгалаган булсалар да, Аллаһ Тәгаләнең рәхмәте белән, мцселманнарны андый бозыклардан саклап, мөселманнарга ярдәмен дәвам иттерде. Ул динсезләр дөньяда ук җәзаларын таптылар. Моннан соң да өметебез: Аллаһ Тәгалә үзенең динен саклар, мөселманнарга мәрхәмәт итәр. Мондый динсезләрнең җәзаларын

бирер, би-гадлиһи вә фәдълиһ (Аллаһның гаделлеге һәм хөрмәте белән – *А.Г.*).

## Һәвел намазы, хатыннар вәгазе хакында сорау-җаваплар

Бер көндә Чистай кешеләреннән берсе, безнең дамелла Нәҗип Әмирханов һәвел намазын хуш күрми, элеккедән бирле укылып килсә дә, туктатты. «Бу ничек?» – дип сорады. Без җавабыбызда әйттек: «Дамеллагыз ышанычлы, галим, динле кеше. Ничек кушса, шулай эшләрсез, аның өстеннән сорап, ачыклык кертү хәҗәт түгел». Соңрак моны да өстәдем: «Мәккә, Мәдинә, Мисыр, Шам, Истамбул, Бохара мәчетләрендә мондый намаз юк. Бу хәл сезгә дә яхшы галәмәт (билгеле – *А.Г.*). Ышанычлы китапларда да андый намаз бәян ителмәгән, шунлыктан Мәрҗани мәрхүм мәмләкәтебездә халык арасында таралган рәвеш белән укуны **бидгать** ди. Мөәзиннәрнең һәвел намазын укып, соңра мәетнең исемен әйтеп багышлауларын вәгъдә иттереп, дога сурәтендә булулары бигрәк начар сурәт алганын, безнең 5 нче мәчеттә гадәт булган рәвеш: мөәзин: «Фәлән фәлән улына дога үтенәләр» – [дигән] гыйбарә белән канәгатьләнеп, халык ике рәкәгать намаз укып, үзләре берәм-берәм дога әйтеп үтәләр, «Бу рәвеш аз гына җиңелрәк», – дидем. Моны да өстәдем: «Халык гафиллектә, гыйбадәттә игътибарлары, йөрәкләрендә Аллаһтан куркулары аз, ислам тәгълиматына рәхмәтләре аз, намазлары өчен фидия (сәдәка – *А.Г.*), һәвел намазлары белән кичерү һәм рәхимлек көтәләр. Мондый рәвеш ислам ысулы түгел, кеше ул эшләргә таянырга тиеш түгел. Үзе тиешле һәм сәламәт вакытында дини вазыйфаларын яхшы үтәргә, ислам әдәбен бар көче белән кайгыртырга тиеш. Шулай итеп тә, оҗмахка керә алса – бик зур ганимәт, игътибарсыз йөреп-йөреп тә, асылын анык нык булмаган намаз фидиясенә әһәмият бирүе, шулай ук кешеләрдән сорап, асылы мәгълүм булмаган һәвел намазлары укыту белән файда алу ниятендә булу тугры һәм дөрес юл түгел.

Искә алынган шәхес икенче мәсьәлә дә сорады: «Чистайда икенче мәхәллә имамы мулла Шиһабетдин мәчеткә хатыннарны җыеп вәгазь итә, элек бер дә булмаган эш, халык ятсына, хатын-кыз аяклары тимәгән җир бер мәчет калган иде, инде анда да аларның аяклары тиде һәм фәлән дип, гаеплиләр», – диде. Бу кеше, бәлки,

үзе дә шул фикердәдер. Вакыйганы яхшы аңлаганнан соң, болай дип җавап бирдем: «Хатыннарның вәгазь тыңлаулары – кирәкле эш, ирләрдән башка тәэсирле вәгазь әйтерлек кеше юк. Шунлыктан бу мәсьәлә яхшы башланган, дәвам итәргә кирәк. Аллаһ илчесе салләллаһү галәйһи вә сәлләмнән хатыннар: «Ирләр арасында яхшы ишетеп булмый, безгә аерым вәгазь итсәң иде», – дип сорауларына, бер көн аларга махсус вәгазь әйткән. Бу мәсьәлә ачык. Шунлыктан мулла Шиһапның бу эше күркәм, шәригатькә каршы түгел. Хатын-кыз галәме яхшы сүз, дөрес вәгазь ишетмәгәнлектән, ышанычларына төрле бозыклыклар, хорафатлар кергән, хәрам һәм хәләлне аеруларында байтак кимчелекләр күренә. Һәр җиргә аяклары ирешүдә дә моның тәэсире бар. Шунлыктан һәр җирдә дә яхшы имамнар шулай аларга вәгазь итсәләр, Коръән, хәдистән дәресләр бирсәләр, әлбәттә, зур файдалар туар, әхлакларына, ышанычларына байтак төзеклек ирешер», – дидем. Петропавел шәһәрендә торган вакытта ирләргә Коръәннән, «Сахих Бохари»дан дәрес биргәндә, хатыннары да үзләренә махсус вәгазь теләделәр, мәчеттә аларга да вәгазь сөйләдем. Файдаландылар, бара-бара халык та файдасын аңлый башлады.

«Хатын-кызның җәмәгать намазларына йөрүләре күркәм һәм фазыйләтле булмаса да, вәгазь мәҗлесенә баруында зыян юк, ләкин файдасы күп өметле», – дип бәян иттем. Хатыннарның үзләре генә булып, вәгазь мәҗлесенә барулары җәмәгать намазы хөкемендә түгел.

Җәмәгать намазына хатыннарны кызыксындырырга ярамый, бер хатын әдәп һәм шәригатьне кайгыртып чыга икән, гаеп ителми. Хатын-кызның һәм башкаларның гаеп итәргә хакы юк. Шулай да өйләрендә укулары мәчеттә җәмәгать белән укуларыннан артыграк.

Әмма вәгазь мәҗлесе башкача. Ирләр белән аралашырга теләмәсәләр, бер ирдән генә вәгазь ишетсәләр, файдасы булачак. Бу заманда һәртөрле җирләргә йөргән хатыннарның әдәп белән мәчеткә кереп, ихласлык белән вәгазь тыңлауларында бер тарафтан да зыян булмаса кирәк. Гаетләрдә дә мөселманнарның укый-язуын арттыру, вәгазь тыңлау, дога бәрәкәтеннән акыллы булу теләкләре өчен аларның булуына каршы чыгылмый. Хәтта кеше күзеннән яшерелеп торучы кызлар да чыгарлар, арусыз хатыннар да чыгарлар, ләкин болар намаз вакытыннан читтәрәк торырлар, дип боерылган.

Ислам шәригате тарафыннан иркен куелган, әхлакый һәм дини файдалану өчен киң ачылган юлларны юк-бар котыртулар һәм иярүләр белән тарайту һәм каплау тиеш түгел. Хатын-кыз галәменә яхшы тәрбия һәм дини вәгазь, тиешле гыйлемнәр бирү кирәк. Балалар тәрбиясендәге җаваплылык, әхлакый кагыйдәләрнең яртысын тәшкил иткән бу төркемне тәрбиясез калдыру, надан остабикәләрдән начар тәгълимат, юк-бар хорафат астында калдыру – тиеш булган гамәл түгел. Бу тәкъдирдә без яхшы уяныргa, сөннәтләр һәм сира (пәйгамбәр тормыш юлы – *А.Г.*) китапларын яхшы тикшерергә, заман хәлләренә гыйбрәтле күз белән карарга тиешбез. Кешелек та үзләренең иялэшкән нәрсәләренә ияреп, инкяр итмәскә, каршы тормаска тиеш. Казан шәһәрендә, мәсәлән, иң карт һәм диндар, ягъни абруйлы, халык тарафыннан гаеп ителмәслек имам тарафыннан атнага бер мәртәбә хатыннар өчен вәгазь мәҗлесе оештырылырга тиеш. Мәчеттән башка киң урын булмаганлыктан, вәгазьләр мәчеттә булырга тиеш. Авыл җирләрендә остабикәләрнең вәгазе белән генә канәгатьләнмичә, галим имамнарның үзләре сөйләве яхшырак булачак. Бу инкыйлаблардан соң халыкның ир һәм хатынында, карт һәм яшендә, бай һәм фәкыйрендә әхлак кузгалды, рух алмашынды, эзләнү башланды, динне яхшы аңлау, һәрнәрсәне дөрес белү фикере туды. Шунлыктан һәр эштә дөрес гыйлем, туры юл күрсәтү зарур булып китте. Һәр халыкка яхшы вәгазьләр кирәклеге беленде. Мәдрәсә һәм мәктәп өйрәтүләреннән дә артыграк вәгазь укытулар тиешле, файдасы зур булачак, иншаллаһү Тәгалә.

## Татарстан җөмһүрияте рәисе Сәхипгәрәй Сәетгалиев белән сөйләшү

31 августта ревкомда очрашу өчен, соравыма күрә, искә алынган рәис хәбәр иткән иде. Көндезге бер ярым (13:30 – *А.Г.*) сәгатьтә очрашырга булдым. Элекке Казан округының хәрби рәисе Сандицкий торган яхшы дворецта урнашкан. Җөмһүрият әгъзасының хөкүмәте дә, иске буржуазный даирә дә эш күрәләр икән. Җөмһүриятне тәбрик итеп, дәвам итүен һәм куәтле дәрәҗәгә ирешүен теләвемне әйткәннән соң, Мәскәүгә барып сораган һәм уңай җавабын алган маддәләрне сөйләдем. Сорауның нөсхәсен сорап алып калды, җавабының нөсхәсе янымда булмаганлыктан,

җибәрергә вәгъдә иттем. Мәктәпләр турында җавап бирсәләр дә, мәдрәсәләрнең күбрәге автономияле татар-башкорт җөмһүриятләрендә булуларын, алар кул астында калуларын сөйләдем, тиеш күргән вакытларында сездән сорарлар, дидем.

Мәктәпләрдән Коръән укытуны чыгаруда фикеремне сорадылар, җавабым: «Коръәнне яшь балалар аңлап укымыйлар, бары гарәпчә тел күндерү өчен укыйлар. Шунлыктан балаларның Коръән өйрәнүләре коммунизмга да каршы булмас. Әмма мәктәпләрдә укытмау халыкка бик авыр тәэсир итәр. Коммунизмның бөек нигезләреннән булмаган кечкенә әйберләрне мәйданга куюда ашыкмыйча, халыкның фикере белән хисаплашыбрак эшләү сезнең өчен дә зыянсыз булыр иде. Хөкүмәт сугыштан бушанып, сәясәтен тәмам урнаштырганчы, мөһим булмаган, кечкенә нәрсәләр белән бәйләнешүне файдасыз күрәм», – дидем, инкяр итмәде.

Казанга кайту фикеремне әйткәч: «Кайт, бик яхшы, мәҗлесләр ясарбыз, зур җыеннар туплап, сез дин буенча, мин коммунизм буенча сүзләр сөйләшербез» – дип, бераз коммунизм ысулын да бәян итте.

Арада дин һәм Коръәнне яхшы аңламаган яшьләр тарафыннан сөйләнә торган: «Коръән борынгы заман хәленә яраклы рәвештә ысул күрсәткән, хәзер хәл үзгәрде, башка төрле тормышлар мәйданга чыкты, фәлән-фәлән», – дип ашыгыч-ашыгыч сүзләр сөйләде. Тиз бер җиргә барачак икәнен дә аңлаган идем, әйттем: «Бу мәсьәлә – байтак озын мәсьәлә. Коръән турында яхшы аңлап җитмәгән муллалар тарафыннан һәм башка язучылар тарафыннан байтак төзәтүләргә мохтаҗ бәяннәр таралган, сез шул бәяннәргә күрә сөйлисез, форсат булганда мин сезгә, иншаалла, Коръәнне канәгатьләнерлек [итеп] аңлатырмын», – дидем дә, ул бабта сүзне бик озайтмадым. Мәскәүдән алынган, Солтангалиев имзасы белән бирелгән ихтирамлы һәм яхшы урын [табарга] киңәш иткән язуны күрсәтеп, астына шулай ук киңәш өстәде, көймәдә аерым бүлмә, тимер юлда делегатный вагоннан урын бирелүне үтенеп язды. Саубуллашып чыктым. Беренче сентябрьдә пропуск әзерләп куячагын вәгъдә иткән иде, вәгъдәсен үтәде.

Югарыда искә алынган Сәхипгәрәй Уфада туган, дамелла Хәйрулла Госман мәдрәсәсендә, хәзер Никифор имамы Исмәгыйль әфәндедән башлангыч белем алган. Чыгышы Уфа өязендәге Торна

дигән авылдан икән. Сөйләү куәте яхшы, мантыйгы дөрес, акылы үткен, коммунизмда җитди, юлында нык адәм [булып] күренде.

## Казанда янгын афәтләре, кадерле китапханә әрәм булды

Казанда 1919 елның августында Кызыл мәчет һәм Ак мәчет мәхәлләләреннән байтак өйләрне яндырган, күп кешеләргә икътисади афәт ирештергән, күпләрне йортсыз, урынсыз калдырган зур һәм куркыныч янгын булган иде. Безнең Тукай урамына тәмам чыгып җитмичә, шул урам кешеләреннән байтагының эчтәге өйләре янган иде. Арттагы Мещанский урамында исә мәхәлләбез яныннан Гайнетдин Мөэминов йорты буе белән килеп, бертуган Габдрахман Баруди өенә ирешеп, барча каралтысы янып, ватылып, торак өйнең тәрәзәсе һәм кайбер өлешләре янып, бинасы үзе сәламәт калып, янгынга чик булган иде.

Икенче мәртәбә 1920 елның 6 июнендә Казанга кайтып җитүдән берничә көн генә элек Зәңгәр мәчет һәм Борнаев мәхәлләсендә дәһшәтле янгын булып, Зәңгәр мәчетнең югары өлеше, Тәкәрҗиб урамының күпчелеге, мәчет урамы тәмам, бу җөмләдән Зәңгәр мәчет каршындагы Ләбибә ханымның зур Кызлар мәктәбе, үзенең торак өе тәмам көл булды.

Соңрак, августта безнең Мәскәүдә вакытыбызда өченче дәһшәтле янгын булып, Борнаев мәхәлләсенең күбесен көйдергән. Борнаев мәчетенең күршесендә мулла Габдулла Апанай шәһитнең йорты, чиркәү турысы тарафыннан Габдерәшит бай Юнысов балалары йортлары тәмам янган иде. Бу рәттә фәкать мәчет, бераз михраб тарафы кызып, көеп, үзе сәламәт калган, шулай ук Платон чиркәве сәламәт калган. Бу янгында булган фаҗигаларның иң зурысы – Әхмәтгәрәй бине Габдерәшит Юнысовның кыйммәтле китапханәсенең шул утта корбан булуы, һич булмаган кебек югалуы. Югарыда әйтелгән Әхмәтгәрәй Мөхәммәдкәрим хәзрәт мәдрәсәсендә мөбарәк гыйлемнәрдән хәбәрдар булып, мәдрәсәдән аерылса да, кәсеп һәм сәүдәгә артык кермичә, гыйлемгә омтылып, остаз Сәлахетдин мәдрәсәсендә, «аксак иясе» кушаматлы Сәхибетдин коръәнхафиз бер дәрәҗәдә өйрәнүче, фәкыйрь шәкертне өенә җәлеп итеп, мөбарәк гарәп кагыйдәләрен яңартып, фикыһ һәм башка дини китапларны өйрәнүгә керешкән иде. Китапны өйрәнүгә

керешеп, кулъязмалар өйрәнеп, яхшы китапларны үзендә булдырган иде. Бу җөмләдән Яңа бистә имамы мулла Габедлгафур бине Мәхмүткә бер мөнәсәбәт белән хөкүмәт тарафыннан бүләк ителгән, язуы матур булган шәех Такыеддин әш-Шәмәнинең «Шәрхе мохтасар әл-викая» нөсхәсе искә алынган мулла кызының баласы булган мулла Шакир бине Хөснетдин тарафыннан, искә алынган Әхмәт Юнысовка алтмыш сум көмешкә сатылган, вакытында бик кыйммәт күренеп, халыкның гаҗәпләнүен кузгаткан иде. Мәмләкәтебездә китапның кадере аз, чын кыйммәтен белүче кеше янә аз, шәрехнең кыйммәтен һәм кадерен таныган галим бигрәк тә аз булганлыктан, гаҗәпләнерлек нәрсәләр бар иде.

Соңрак Сабир мәхдүм бине мулла Хәмматның үз каләме белән күп риваятьләр һәм өлешләр өсләлгән һәм төзәтелгән «Көһестани шәрехе»н илле сумга алуда күп гаҗәпләнмәделәр. Мөнавинең «Әлҗамигъ әс-сагыйрь» бәрабәрендәге «Фәйз әл-кадир» исемле өч зур томнан гыйбарәт [булган] зур шәрех тә бу адәмдә бар иде. Кыскасы, бу Әхмәт әфәнде бик зур булмаган суммасын кызганмыйча, байтак яхшы китаплар туплаган. 1874 елда Троицкида мәшһүр оста дамелла Әхмәт бине Халиднең нәфис китапларын варисларыннан мин алгач, искә алынган Әхмәтгәрәй Юнысов та ул вакытта шул шәһәрдә, шул ук өебездә булып, хәбәрсез калуына кайгырып, шәех Камаледдин әл-Бабәртинең «Китаб әл-гыйная» буларак билгеле булган ике томлы, гүзәл каләмле «Шәрх әл-һидая»не бик хуш сөлес язулы «Тәхмис әл-бүрдә» нөсхәләрен минем килешүем тәмам булса да, көчләп алган иде.

Бу китапханәсен вакыф итәргә (дин файдасына бүләк итәргә – *А.Г.*) булып, сөйләнеп йөрсә дә, һичнәрсә эшләмичә, вафат булып, варислары бер кыз сабый, хатыны, бертуганы Гали бине Габдерәшит калып, туганы да тыйнак адәм булганлыктан, кызы тарафыннан куелган опекуннар Гобәйдулла бине Рәхим бине Исхак Юнысов, Габделвәли бине Закир бине Габделкәрим Апанай, хатынының соңгы ире Габдулла бине Исмәгыйль Бәләбәи тарафларыннан мирасында төрле начар идарә итүләр булып, туганы Гали кулына да бернәрсә күчми, китаплары аның йортында, фатирда торучы Исхак исемле берсенә күчеп, суган бәясе акча бәрабәренә булса булгандыр, бүлмәсендә урнаштырылган булган. Мәскәүгә чыгар көнемдә опекуны Габделвәли бине Закир Апанайны күреп, күрер өчен генә «Шәрхе әл-җамигъ әс-сагыйрь лил-Мөнави» нөсхәсен сорадым. Янында булган кешегә мөрәҗәгать итеп, күрсәтергә теләсә дә, шул

көндә мин Мәскәүгә юнәлдем, кайтканчы китапның көле күккә очты. Казанның бу өч янгынында миллион-миллион акча һәм мал казасы, ничәшәр миллионлык өй казасы күп булса да, иң зур каза – шушы кыйммәтле китапханә казасы. Бичара Әхмәтгәрәй Юнысовның дөньяда әсәре калмады, бик зур ядкяр булырдай китапханәсе югалды, китте. Иннә фи зәликә лә-гыйбратү ли-үләл-әлбәб (Чынлыкта, монда акыл ияләре өчен гыйбрәт бар – *А.Г.*).

## Китапханә бинасына фатирчы нияте

Сентябрь башларында йортыбыздагы китапханә бинабыз турында бераз шикләнүләр дә булып узды. Тышкы тарафтан күренгән бина, фатирга мохтаҗ кешеләрне кызыктырырлык яхшы өй булып, буш күренә. Янгын сәбәпле, торыр җир тапмаган кешеләр, бәлки, хөкүмәт хезмәтчеләреннән төрле юллар белән алырга теләрләр. Рәсми рөхсәт язуы алып, 24 сәгать эчендә бушатыгыз дип, изүчеләрчә, Николай һәм Иван Грозныйча фәрманнар игълан итеп китсәләр дә, китапханә китаплары һәм бинасы белән рәсми рәвештә гомумислам китапханәсенә булып, Мәгариф идарәсе тырышлыгы белән кире кайтарылды. Сәфәр көнемнән бер көн элек сәламәт калуы билгеле булды. Шул ук көндә мулла Әхмәтҗан хәлфә Мостафаның Хәдичә исемле кызын хәзерге мәгариф министры Габдерәүф бине мула Җәләлетдин Алмаев әс-Сайманига никях уку мәҗлесендә, Казан җөмһүрияте рәисе Сәхипгәрәй Сәетгалиев, искщ алынган кияү-мәгариф министры һәм башка әгъзалар бар иде. Кыскача вакыйганы соң булса да сөйләп үткәрдем. Ревком рәисе Сәетгалиевка ахыр чиктә генә әйтеләчәк булганлыктан, хәзер хәбәре булмаганы аңлашылды. Ләкин кәефсез булды. Габдерәүф әфәнде дә: «Мөмкин булган эшкә керештеләр, һич тә алырга мөмкин түгел, әлбәттә, саклану» дигщн мәгънәдә аңлатты.

Мәсьәләгә әхлакый караш: янып, аяк астында, лапас асларында, анда-монда үткәреп, аптырашта калган кешеләргә мәрхәмәт итү, әйтелгән бинаны бушатып бирү тиеш түгел идеме? Тырышлык белән алып калу яхшы эш булдымы? Җавап: мәрхәмәт һәм шәфкать тиешле. Ул бичараларга фатир табышып бирү кирәк, ләкин бу җәһәттән берничә искәрмә бар:

1. Кызыгып йөрүчеләр ышанмаслар да, бина кыш көннәрендә торырга лаек түгел, дивары юка, туфрагы аз, хәтта үзем торып, күп утын ягып тәҗрибә үткәргәч, октябрь аенда да сабыр итә алмаган идем, шунлыктан фатирга кирәргә теләгәннәрнең аз гына вакытта күп мәшәкать чигүләрен теләмәдем.

2. Хөкүмәт түрәләре үзләре теләгәнчә җиде-сигез мең кадәр эре һәм күп язма китапларны, китапханә астындагы һәммә шүрлекләре төрле китаплар белән тулы урын җиренә чүп-чар, башка түбән нәрсәләр тутырган кебек өелсә, артык хурлау булу өстенә, дым тартып юкка чыгулары да хәвефле иде. Кешегә мәрхәмәт итүдә исә, малны әрәм итү, аеруча бу китаплар кебек кадерле һәм кыйммәтле, бик югары булган нәрсәләрне зарарлау дөрес күренми.

3. Китапханә китаплары бинасы белән Шура хөкүмәтенә ачык күрсәтелгән иде. Шунлыктан хөкүмәтнең Мәгариф министрлыгы бу мәсьәләдә нык керешеп, үз малын саклаган кебек саклады, вазыйфасын үтәде.

## Китапханәне Шурага тапшыру хикмәте, вакыф итү

Китапханәне күп заманнан бирле халык файдасына тапшыру ниятләнгән иде. Юлы юк, чыгымнары авыр булганлыктан гына, тукталып тора иде. Элекке вакытларда Шура хөкүмәтенең конфискацияләү куркынычы да булды. Кузнецкий өлкәсендәге Дибирдиевларның зур, бай китапхпнәләрен бер ел элек конфискацияләделәр, һәр җиргә тараттылар. Күп кадерле китаплары юкка чыгып тора. Нәтиҗәсе ничек булып калыр. Хәзер таркатылмаса да, халык файдасына кую теләгебез, бу июль аенда гомумислам китапханәсе өчен сайлап алынган әгъза белән фикер алышып, аларның идарәсенә тапшыруны белдергән идем. Бу Уфага сәфәрем сәгатендә кулымнан язып, телдән әйтеп, язу язып калдырдым. Язуымның нөсхәсе:

«Казанда 1920 елның 24 июлендә, үземнең йортымда, аерым урын тәшкил иткән китапханәмне, бинасын, эчендә сакланган кадерле китапларны, Казан шәһәрендә тәшкил ителәчәк гомумислам китапханәсенә тапшырам. Түбәндә язылачак шартларны әйтүне тиешле күрәм:

1. Зур гомумислам китапханәсе тыштан ут кермәслек дәрәҗәдә (ишек һәм тәрәзәләрен тимер белән каплау, түшәмнәрен ташка

әйләндерү рәвеше белән) саклaнганлыктан соң, минем китапханәдән китаплар әлеге китапханәгә күчерелер.

2. Китапларның һәркайсына минем исемем (әлбәттә, Сәлахетдин хәзрәт вакыфларыннан башкасына) язылыр һәм вакыфлык мөһере басылыр.

3. Тәртипле, ысуллы китапханәләр тәртибенчә, яхшы дәфтәрләр белән тәэмин ителер (үзләренә махсус дәфтәрләрдә).

4. Язма, сирәк очрый торган китаплар элекке урынында, минем йортымда булган китапханәдә, янә гомуми китапханәдә калдырылыр һәм сакланыр.

5. Биналарның, китапларның тиеш булган чыгымнары һәркайсы гомуми ислам китапханәсе хәзинәсеннән булыр.

6. Матди тормышымда китапларны өйрәнүдә, гадәттән тыш вакытларда да үз өемә алып кайтып файдалануда да ихтыярлы булырмын. Әлбәттә, саклау, тиешле урынына кайтару шарты белән.

7. Искә алынган китапларга күп заманнан бирле таныш, китапларны саклау бабында диккатле булганлыктан, китапларны тиешле тәртип белән тапшыруда Шәһәр Шәрәф әфәнде вәкил һәм саклаучы ителсә иде.»

Имза һәм мөһер белән тапшырылган. Язуым 4 сентябрьдә язылган булса да, элегрәк тәкъдим ителде. 3 сентябрьдә шимбә көн Уфаны карап чыгачак булсам да, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөдәррисләреннән мулла Әхмәтҗан Мостафаның кызы Хәдичәне хәзерге мәгариф министры Габдерәүф бине Җәләлетдин Алмаев әс-Сайманига никяхы булу сәбәпле, сәфәрем якшәмбегә калдырылды. Сәгать дүрттә әлеге никях мәҗлесенә бардым. Кияү кеше хөкүмәт хезмәтендә, коммунист, шуңа күрә дә мәҗлестә коммунистлардан Казан җөмһүрияте рәисе Сәхипгәрәй Сәетгалиев, Гасыйм Мансуров, янә Әхмәтҗан бине Хәсән Алмаев бар иде.

Сәгать биштә Әхмәтҗан хәлфә никях укуымны теләде, аерым бер искәрмә әйтте. Килешүдә алдым-бирдем галәмәтләре юк, өйләнешүләре турындагы сүзләр белән генә әйтүләрен теләделәр. «Яхшы», – дип, шулай парлашу гыйбарәләре белән эшне җиренә җиткердем. Яшьләр фикеренчә, хатыннарга күбрәк хокук бирү тиешле, элек аларның хокукларын тарайтканнар, мәхлүк бер мал рәвешендә йөрткәннәр, дип, алу-бирү галәмәтләре дә шул элеккеге хәлне аңлатканлыктан, аннан сакланганнар, дип уйланылды. Ислам дине белемендә никях, парлашу гыйбадәтләре – дөрес сүзләр, мондый яшьләрнең күңелләренә дә муафикъ сүзләр. Ләкин хатын-

кызның бөтен тормыш чыгымнары ир өстенә йөкләнгәч, аның һәртөрле эшләрдә дә ярдәме, саклавы иргә кирәк булгач, шәригать һәм акыл буенча моның каршысында хатынның иргә буйсынуы һәм гүзәл буйсынуы кирәк булгач, ире ияртүче, хатыны иярүче булганлыктан, табигать галәме, тормыш низамы, намусы буенча да шулай булгач, ияртүченең өстенә йөкләү һәм саклавына алу мәгънәсе белән алуы, хатынның да бирелүе ят сүз түгел, чирканырлык сүз түгел.

## Казаннан Уфага сәфәр

Китапханәнең фатирчылар тарафыннан соралуын туктатып, аны хөкүмәткә тапшыру кәгазен тәмамлагач, 4 сентябрьдә якшәмбе көн иртәнге сигез ярым (8:30 – *А.Г.*) сәгатьтә өйдән Уфага юнәлеп, Самара көймәсен сорап киттек. Анда иске Волский көймәсе китә дигәч, билет сату вакыты булмаса да, Закирҗан бине Хисаметдин Үсиннең танышлыгы һәм Хәсән Сәгыйи ярдәме белән ике кешегә 181 сумнан 362 сум түләп, билетлар алынды. Киң бер кешелек бүлмәгә урнаштык. Сатучы кеше дүрт кешелек (элек ике урынлы) каюта дип бирсә дә, күрсәткән номеры бер кешелек бүлмә булса да, шуңа канәгать иттек. Хәзерге идарәдә бер кешелек сәке икегә, икелек дүрткә бирелә икән. Ләкин бүлмәләр киң булгач, сыймаслык түгел иде. Бу сәфәребездә Закирҗан Хисам бик яхшы хөрмәт һәм хезмәт итте. Һәрвакытта да ихтирамлы, игътибарлы мөнәсәбәтле шәкертләремнән берсе.

Төштән соң 2 сәгать 40 минутта көймәбез хәрәкәт итеп, сәламәтлек белән биш ярым (17:30 – *А.Г.*) сәгатьләр чамасында әүвәлге Болградның иске йортына иреште. (Богородский сүзеннән чирканып, Болград дип әйттем һәм әйтәм). Бу хөкүмәт һәр эшне үз кулына алу ниятеннән булганлыктан, ут көймәләрен дә үз карамагына алган. Шунлыктан үз эшләре буенча гына йөртәләр. Мәсәлән, безнең көймә Казанда бер тәүлек кадәр торган. Болградка килгәч, куначак. Хәтта икенче көндә дүшәмбе көн 12 сәгатькәчә торачак булды. Димәк, 14–15 сәгать калачак булды. Шул арада югарыдан Болградкача килгән көймәләрдән кешеләр йөкләр кабул итте. Көймә тәмам бушады. Юлларда кеше урнашты. Бушаткан көймәләр Казан тарафына китә икән.

Сәгатьләр үтте. Нәрсә булса да, әлхәмдү лилләһ, сәламәт кичте. Мәчет сәгате 10 да 40 минут булганда, түбән таба Болградтан хәрәкәт итте. Безгә һәм башка халык өчен куаныч булды. Аллаһ белә, алда ни булыр. Самара юлыннан китәм дигәч, халык: «Бик яхшы, тиз барырсыз, бер тәүлектә Самарага төшәрсез, аннан да бер тәүлектә тимер юл сәфәре» – дип, алдагыга карар биреп сөйлиләр иде, ләкин бәндәнең вазыйфасына сыймый торган чамалар. Һәр эш Аллаһның теләге белән булганлыктан, гадәткә карап кына алдагыны чамалау, хөкем итмәү яхшырак. Һәр эшнең иң яхшы юлын уйлап, иң гүзәл рәвештә эшләү тиешле. Ләкин алай булыр, болай булыр, дип хөкем итү вазыйфага керми. Аллаһка тапшыру хәерле, хәлне аннан көтү бәндәнең вазыйфасы. Вәс-сәлам.

6 сентябрьдә дүшәмбе көн сәгать 9 чамаларында Сембер шәһәренә ирештек, биш-алты сәгать кадәр торып, көймә хәрәкәт итеп, сәгать 8 чамасында Сингеле шәһәренә ирешеп, ярга чыктым. Бик пешкән помидор күренеп, 200 сумга бер дистә алдым. Башка кешеләр арзан дип алма алдылар. Алма Казанда 250–300 сум булгач, мондагы 100 сумны арзан күрделәр. Сингеледән хәрәкәт иткәннән соң, билетларны һәм рәсми сәфәргә ярдәм язуларын тикшереп чыктылар. Берсе кичке сәгать 6 да Самарада булачагын хәбәр итсә дә, Аллаһның теләге ничек булган: сәгать 11 дә бер җирдә туктар өчен борылыш ясаганда, койрык чылбыры өзелеп, шактый мәшәкать чикте. Көчле җил көймәне уйната, акрын-акрын корыга таба илтә. Кайбер кешеләрнең кәефләре китә, коскан кешеләр дә булган, кайберләре ятыбрак үткәрергә тиеш булган. Көймәнең машина куәте йөртер өчен, койрык юлны саклар өчен кирәкле өлешләре ки, койрыксыз көймә бернәрсәгә яраклы түгел. Нәрсә булса да, берәр сәгать мәшгуль булганнан соң, төзәтелде, яхшы хәрәкәт булдырылып, юлына куелды. Әлхәмдү лилләһ!

Әхлак галимнәре сәфәргә һәм сәяхәткә кызыктыру юлында шактый гына файдалар, ягъни сыйфатларны да бәян иткәннәр. Сабырлыкка, төрле күнекмәләргә өйрәнү, канәгатьлек файдаларын тәҗрибә итү, һава алышыну сәбәпле түзү кебек сыйфатларны үзләштерергә кирәк. Көймә һәм тимер юл арбаларындагы сәфәрләр иҗтимагый сурәттә булганлыктан, сабырлыкка, канәгатьлеккә барырга үзләреннән-үзләре юл бирәләр. Сәфәр вакытында намаз үтәүнең авырлыгы, чын күңелдән һәм көчле теләк белән булганда, байтак әҗер-савап арттырырга да сәбәп булырга мөмкин. Вәллаһү йәһди мән йәшәъ (Аллаһ кемне тели, шуны туры юлга күндерә – *А.Г.*)!

## Самарада ике көн

7 сентябрьдә сишәмбе көн кичке җиде ярым (7:30 – *А.Г.*) сәгатьтә Самара шәһәренә ирештек. Чыга торган халыктан соңрак, әйберләребезне күтәрешергә йөкче алып, мулла Гатаулла ахун белән бергә чыктык. Чыкканда әйберләребезгә күз салмадылар. Билетларны алудан башка эш кылмадылар. Сәфәр пропускын да тикшермәделәр. Җиңеллек белән яр буена чыксак та, тансык булган, ничә айлардан соң сагынып торган җиңел генә яңгыр сипсә дә, аннан авырсынмыйча гына югары урамнардан эзләп китерелгән арбаны көтеп, сәгать ярым кадәр сабыр гына көттек. Аннан соң әйберләребезне башка кеше әйберләре белән бергә урнаштырып, аннан үзебез әкрен генә арба артыннан иярдек. Иделдән бер урам югарыдагы Казанский урамындагы ахун мулла Шиһабетдин Минушев әфәнде өенә юнәлдек. Сәгать тугызда аның кунакханәсенә урнашып, чәй һәм башка ризыклар белән сыйланып, кичке гыйбадәттән соң ял иттек. Минем сентябрь башында ук «4 сентябрьдә чыгабыз», дигән телеграмма мулла Фатих мөхтәсиб Мортазага ирешеп, бер-ике көн Казаннан килгән көймәләрне көтсәләр дә, безнең көймәбезнең килешенгән вакыты узып, сәгать ярым кадәр элек кайтып киткәннәр икән.

Өй хуҗасы мулла Шиһабетдин ахун асылы белән Буадан, Хөснетдин Минушев Буада 15–16 ел кадәр мәдрәсәдә укып-укытып, яхшы гына хәлфәлек кылып, күбесенчә дамелла Габденнасыйр Әмин янында, ике ел кадәр дамелла Нургали бине Хәсән вакытында торганнан соң, бу Самара шәһәренә имам булган иде. Мәчет торгызып, аскы катында укытып, яхшы гына шәкерт туплап, тырышып, дөрес тәртипләр белән дәрес биреп, байтак туры юллы адәмнәр җитештерде. Мәхәлләгә яхшы тәэсире булып, дин һәм дөньялары яклары буенча яхшылык һәм алга китүләренә сәбәпче булган иде. Ләкин соңгы заманнарда гына, башка җирләрдәге мәдрәсәләр кебек, мәдрәсәсенә зарар ирешеп, мәктәп укытуы гына калып бара.

Югарыда искә алынган затның остазы – дамелла Габденнасыйр хәзрәтләренә бик ышанучы, һәр хәрәкәтендә аңа иярүче, мәгълүматлы, тугры фикерле кеше. Күп еллар узганнан соң, бу кешедә кунак булып, ихтирамлык күреп йөримен. Бу сәфәрдә тууын соравымда, миладинең 1856 елда икәнен әйткәч: «Миннән бер елга өлкән икәнсез», – диюемә гаҗәпләнде. Яшь көнемнән бирле олы

яшьле кешеләр белән дуслыгым, аралашуым күп булгангамы, күп кешеләр яшемне зуррак дип чамалый иделәр. Дамелла да минем турыда шулай уйлый иде. Үзе мәхәлләнең хезмәтләреннән бушанып, мәдрәсә хезмәтен дә дәвам итәр өчен тугры фикерле, акыллы шәкертләреннән Фатих Мортаза исемле егетне яхшы ихтыяры белән икенче имам итеп сайлаткан. Фатих әфәнде бервакыт «Икътисад» исемле журнал нәшер иткән иде. Соңгы мөхтәсибләр киңәшмәсе вакытында, Самарада мөхтәсиб итеп сайланды.

Самарада пропуск мәсьәләләре булып, шулай ук табигатьтә аз гына ял итү дә файдалы булыр дип, бер көн калуны тиешле күрдем.

Юлда көймә сәфәребез сузылудан, Казаннан алып чыккан азыкларыбыз аз иде. Самарадан ике данә кечкенә 2–3 кадаклы күмәч алдык. Һәр данәсе өч йөз сумнан, Казан бәяенә караганда шактый арзан күренде. Казанда бу бәһагә бирсәләр, арыш икмәге бирерләр иде. Самара бодай азыгының урыны булса да, Казан башкаларга күп ташуларыннан бәяне күтәрделәр. Көймәдә килгән күп адәмнәр Самарадан он алып китәр өчен киләләр икән. Бодай онының поты 12–13 мең сум, бер пот, ике пот алып кайта алсалар да, 25–30 мең сумгача саталар. Юл һәм пропуск өчен тотылган акча, хәтта пропуск бирүчеләргә дә азрак өлеш чыгарсалар да, җитәрлек була.

Самараның ике яхшы урамында Русия императоры Искәндәр II бине Николай бине Павелның бик күркәм рәвештә ясалган һәйкәле бар иде. Дагыстан имамы шәех Шамвил (Шамил) хәзрәтләрен җиңүе, Плунә сугышында Төркияне җиңүе, Төрекмән һәм Төркестанны басып алуы, крестьяннарны азат итүе тарихлары рәсемнәре белән, соңгысыннан башкалары хурлап ясалган. Барча күргән мөселманнарның дини һәм милли хисләренә тиярлек, вөжданнарын рәнҗетерлек рәвештә иде.

Кызыллар Самарага хуҗа булгач, бу һәйкәлне урыныннан алганнар, каядыр, дөрес булса, бер музейга күчергәннәр икән. Астындагы ахак ташыннан төзелгән урындыгы һәм баганалары гына калган. Бу вакыйганы ишеткәч, барып, күзем белән күреп кайттым. Элек җанымны рәнҗеткән хәлнең югалуын, башындагы һәйкәлнең алынуын күреп, рәхәтләнеп кайттым. Бу да большевикларның очраклы рәвештә мөселманнарга яхшы тоелган эшләреннән. Ибраһим исемле юлдаш, пропуск артыннан йөреп, кичкырын юнәтеп кайтты. Ләкин игътибарлы, делегатный урын

билгеләү турысында махсус станция комендантын күрергә кирәк булып, бу эшне поездның китәр вакытына калдырган.

9 сентябрь пәнҗешәмбе көн сәхәр вакытында сәгать өчтә торып, сәфәр әзерлеген күреп, иртәнге намазны үтәп, вокзалга юнәлдек. Барып җитүебез белән, бер йөкче килеп, әйберләребезнең авырларын күтәреп, аның артыннан без дә вокзалга керсәк, ни күзебез белән күрик – адәм диңгезе, өч зур бүлмә дә сәфәрчеләр белән тулган. Кешеләр арасыннан читенлек белән генә аяк басарлык урын табып, мең мәшәкать белән кайбер вак әйберләребезне үзебез күтәргән хәлдә, мунча ләүкәсе тиренә чумарлык, тыгызланып, әйбер куярлык җир булып, күрше тәрбиясез марҗаларны ачуландырып, әйберләребезне алай-болай итеп урнаштырдык. 5–10 минуттан соң мөхтәсиб мулла Фатих Мортаза, элек «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә булып, бераз укыган Тархан авылыннан Габдешшәкүр әфәнде, пропускны юнәткән Ибраһим әфәнделәрдә калган кайбер нәрсәләребез белән килеп җиттеләр. Болар килгәндә касса алдында йөздән артык кеше тезелгән, чират саклау тәкъдирендә, чират я җитә, я юк, дип шикләнә идек. Чират җитмичә, биш-алты көн көтеп яткан бичаралар турында сөйләделәр. Мәскәү һәм Себер тарафларына китүчеләр чиксез-сансыз дәрәҗәдә күп. Санап караганда, бәлки, биш-алты меңнән артмаса да, әйберләре арасында тәртипсез яткан, ятмаганы тәртипсез хәрәкәттә булганлыктан, адәм диңгезен хәтерләтә иде.

Көнлек поезд һәр тарафка бер генә, аның да локомотивы зәгыйфь, иске, көчсез булгач, күп арба өстери алмый икән. Шунлыктан күп мөсафирлар аяк астында ятып, көтеп торырга мәҗбүрләр икән. Шул арада Мәскәү тарафыннан безгә кирәкле поезд да килеп җитте. Безнең өчен командир аерым чират ирештергәч, тиз заманда Габдешшәкүр Тархани икебезгә 560 сумга Уфага кадәр ике билет алып килде. Урынны билгеләү өчен Ибраһим әфәнде комендант артыннан йөреп, чиратлар көтә-көтә йөрсә дә, делегат арбасында урын юк, тулып килгәннәр, дип хәбәр китерде. Поездга чыгачак юл ачылу белән халык чыга башлап, без дә кузгалдык. Ләкин вагоннар бар да тулы, урын юк. Кайбер кешеләр документлары белән делегатный вагонга бик тыгызлык белән эченә, коридорына керәләр, без дә аякта торырлык кына җир табып бастык. Мин кергәндә әйберләребезне урнаштырганнар иде. Бу вагонда Казан-Мәскәү юлы кебек түгел икән. Командир кешеләр һәм гаскәриләр бик күп, Мәскәү тарафыннан ук вагон-

нарны тутырганнар. Аның өстенә, җитез кешеләр Самарадан да кереп басканнар, безгә аяк басарлык кына урын калган иде. Урнашканнан соң, Уфадан килгән Мәскәүле Таһир Бахтузин исемле егет штабный вагон өчен хәбәрләшеп йөрсә дә, мөмкин булмады. Бу сәфәр юл йөрер өчен гыйбрәтне арттырды. Сәфәр сабагын алданрак яхшы укырга кирәклеген белдерде. Мөмкин кадәр тыныч ук урын әзерләү, шуның әсбабына тиешле әйберләр белән керешү кирәк икән. Пропуск язуын, командировочныйларны кую кирәк. Бу сүз булмаганда, поездда йөрү мөмкин булса да, аерымрак вагонда мөмкин түгел икән. Хәер, безнең: «Диния нәзарәтеннән Мәркәзгә доклад өчен командировать ителде», – дигән язуыбыз, аның өстенә, Мәскәүдән Солтангалиевтан (милләтләр коллегиясеннән): «Бу – татарларның хөрмәтле бер профессорлары, ихтирам ителсен», – дигән рәсми язуына Казанда Сәетгалиев та: «Көймәдә аерым бүлмә бирелсен, тимер юлда делегатлар вагонына урнаштырылсын», – дип язган һәм тиешле мөһерләр басылган иде. Бу ике кәгазьләремә Самарадагы тикшерү комиссиясе дә мөһерләрен басканнар иде. Шулар белән делегатлар вагонының коридорында аяк басарлык, букчаларыбызны куеп, өстенә утырырлык урын да хасил иттек. Моңа да күп шөкер. Яңарту-өстәү мөмкин булмагач, ашау-эчүне азайттык. Өйлә, икенде намазларын **берләштереп**, ишарә белән генә укыдым. Тышка чыгу, халыкны кузгату авыр, башка әмәл юк иде.

## Исәкәйдән Каһарман хәзрәт

Пәнҗешәмбе көн бары өйләдән соң [сәгать] 3–4 чамаларында эчкән чәебез булды. Сәгать 6 ларда Исәкәй турысында аз гына сузылган үрдә машинабыз хәлдән таеп, туктарга мәҗбүр булды. Халык кырга төште, мин дә төштем, ахшам укыдым. Исәкәй адәмнәреннән ике кеше юлыкканлыктан, үземне әйтеп җибәргән иде. Күп вакыт та үтмәде, Каһарман хәзрәт килеп тә җитте. Аның артыннан мөхтәсиб Габделһади хәзрәт тә килде. Каһарман олуглыгы: Казанда дамелла Сәлахетдин остазда, аның дәрес бирү вакытында аралашып, яхшы дәрес укыткан хәлфә иде. Аның вафаты елында – милади 1875 тә – Исәкәйдә имам булып, байтак вакытлар дәрес бирде. Галим, динле кеше. Яхшы әхлаклы, түбәнчелекле зат 45 ел кадәр имам булып, таза хәлдә яшәгән. Гадәте

буенча, яхшы әхлаклы, сабыр иясе, шулай яшиләр. Бу көндә 83 яшендә икән. 28 ел элек Казанда булган иде. Шул вакыттан бирле күрешмәдек. Кызгылт-сары сакаллы, мыегы ап-ак булган. Тавышыннан башка, йөзеннән танырлык иде. Мөхтәсиб Габделһади хәзрәт, Шәлчеледә казый Ризаэтдин җәнаблары белән иптәш булып, намуслылык белән укыган. Гадел фикерле кемсәнә, намуслылык иясе диләр. Һәр ике хәзрәт өйләренә чакырсалар да, машинаның тиз килү ихтималы булганлыктан, ашыгу астындагы кунаклыктан ләззәтләнү мөмкин булмас, дип [чакыруларына] җавап бирә алмадым. Берәр тәүлеккә калуны, кичегү өстенә кичегү була, дип, кабул итмәдем. Өметләре киселгәч, мөхтәсиб Габделһади йортыннан җиде-сигез кадаклы ак бодай икмәкне, өч кадак чамалы май китереп, кабул итүен үтенгәнгә, юл азыгы сыйфаты белән кабул ителде. Байтак сөйләшүебездән соң ястү фарызын үтәп, болар белән саубуллашып, вагонга кердем. Болар да очрашуыбыздан шат булып, авылларына юнәлделәр. Берәр сәгать үткәннән соң караңгы вагон ишеге тарафыннан: «Хәзрәт, хәзрәт», – дигән тавышка юнәлсәм, Каһарман хәзрәт белән бергә килеп киткән кияве ашъяулыкка төргән бер төен тәкъдим итеп: «Хәзрәт аз гына күчтәнәч җибәрде, кабул итүегезне үтенде», – диде. «Мәшәкать тарту кирәкмәс иде һәм фәлән», – дип кабул иттем, бер җиргә урнаштырдым. Иртәнге көнне ачтым, бер кечерәк кисәк икмәк, ике-өч кадак пешкән сарык ите, бераз бавырсак һәм берәр кадак чамалы май икән. Бу вакытка күрә, болар – зур бүләк. Җәзәһүмәллаһү хайра (Аллаһ аларның икесенә дә әҗерен бирсен – *А.Г.*)!

## Вагон җәфалары

Вагонда янә биш-ун хезмәт белән баручы солдатлар артып, көндезге тыгызлыкны сагынырлык дәрәҗәдә тыгызлык туган иде. 1916–1917 елларда бу халәт күренә һәм ишетелә иде. Йөреп булмаслык, тәһарәтханәгә чыгу мөмкин түгеллек, бәлки, тәһарәтханәдә дә адәмнәр урнашу булды. Аның өстенә караңгылык, кяфернең караңгы караңгылыгы кебек тарлык һәм караңгылык иде. Бу сәфәр тәмугның бер өлеш халәтен күрсәтте. Утырган хәлдә йоклау мөмкин иде, ләкин иркен утыру кайда?! Тезне тезгә бәреп, кысылып кына утырып чыктык. Элекке нәрсәләребез (зур бер букча) өстендә икебез рәхәт утырып килгәнбез икән. Инде бу кадәр

җиргә ике солдат кушылып, аяк куяр урыннарны бетерделәр. Кәвешләрне салып, тезләнеп утыргандай гына утырып, таң аттырдык. Бу вакытта күршемдәге кысрыклап торган рус малае чыгып, алдагы солдат аның урынына күчеп яткан иде. Миңа да аның кутюмкасы өстенә аз гына авышу мөмкин булып, аз-маз гына черем иткәләдем. Иртә [белән] халык кузгалгач, күрше ярым бүлмәдә газапланып килүче мөгаллим Габдрахман бине Хәйдәр бине Садыйк бине Мияссәр Чистайи белән хатыны Сәүдә бинте Сәмигъ бине Сибгатулла бине Габделкадир Орыviларның бүлмә иптәшләре чыгачак булганлыктан, тиз генә анда барып утырдык. Әйберләребезне дә күчереп, бер диванда биш-алты адәм булып, уйлаганнан артык ял белән, калган 5–6 сәгатьлек сәфәребезне шатлык белән үткәрдек. Ашау-эчү дә мөмкин булды. Рәхәт утырдык. Аннан артык җәфа һәм тарлыкны күргәнчә, бу хәл тар һәм авыр булса да, әүвәлге көнебездә һәм төнебездәге хәлебезгә караганда күпкә рәхәт һәм шөкер итәрлек иде. Бу йөрешебез Ауропадагы машина йөрешенә охшаган бер йөреш булды. Анда сәфәрләр кыска, бер мәмләкәтнең бөтен аркылы чыгышы биш-ун сәгатьлек юл булып, вагоннарда йоклау зарурлыгы булмады. Бер диванда дүрт-биш кеше утырып баралар. Йокы килсә, утырган хәлдә генә аз-маз йоклап алалар. 1907 елда Вологдадан Истамбулга барышыбызда Русиядән Венага, аннан Будапешт шәһәренә, аннан Белградка барышыбызда, шул рәвешле утырып кына барган идек. Ауропалылар өчен бу рәвеш авыр түгел, әйткәнемчә, сәфәрләре кыска, поездлары бик тиз йөри, мөсафирлары әйберсез генә шәһәр эчендәге трамвайда йөргән кебек кенә утыра да китә, безнең төрки халык күп әйбер белән йөрергә өйрәнгәнбез, үзебезгә күп авырлыклар йөкләп йөрибез, шунлыктан сәфәрдә дә артык мәшәкатьләргә очрыйбыз.

Нәрсә булса да, Аллаһның ярдәмендә, җомгадан соң ике ярым (14:30 – *А.Г.*) сәгатьтә Уфаның вокзалына якынлаштык һәм ирештек. Уфа вокзалына килсәк, музыка тавышы ишетелә башлады. Тәрәзәгә карасам, саф-саф тезелгән гаскәр һәм коммунистлар күптөрле байраклар белән торалар. Соңыннан гына белдек, безнең поездыбызда Мәскәү һәм Кавказга юнәлдерелгән баш комиссар, Уфаның ЧК рәисенең җеназасы кайткан икән. Вокзалда кайбер хезмәтчеләребезнең әйтүенә караганда, черкаслардан берсе үтергән икән.

Мәет эшлекле һәм көчле түрә булганлыктан, Кавказда байтак эш күргән булса кирәк, черкасларда үч алу куәтле булганлыктан, кайбер каннарны буш итмәгән булсалар кирәк. Вәллаһү газизүн зү-интикам (Аллаһ Хаким, Үч алучы – *А.Г.*). Ул җеназа авышкач, юллар ачылып, әйберләребезне ике кешегә күтәртеп, 500 [сум] белән аларны риза итеп, 2500 сумга яхшы фаэтон тотып, исән-сау 10 сентябрьдә җомга көн сәгать 4 тә өебезгә ирештек. Әлхәмдү лилләһи галә зәлик (Аның өчен Аллаһка мактау – *А.Г.*)!

Йортыбыз, әйберләребез, казыйлар һәм башка дусларыбыз сәламәт торганнар. Казыйларда һәм имамнарда съезд әзерлеге дәвам итә. Хәерле съезд булса иде, дип өмет итеп торалар икән. Казанга 12 июньдә пароходта сәфәр кылган идек. Өч айга якын узды. Мәскәү сәфәре озын булганлыктан, вакыт бәрәкәтсез булды. Казан артына чыгу, башка эшләр эшләү тиешле иде. Икътисади хезмәтем дә бар иде, мөмкин булмады. Аллаһ теләсә, съездда халыкка хезмәтемнән алуларын тәкъдим итеп, ярдәмнәрен ала алсам, кышка, иншалла, Казанда булырмын, иркенләп барырмын, дип өмет итәм. Аллаһ ахырын хәерле кылсын!

## Уфада галимнәр съезды

Электән үк мөхтәсибләрне җыеп, тиешле мәгълүмат бирү, халыкның рухларыннан хәбәр алу фикере булса да, мөмкин булмыйча үтте. Быел язда гомумирак бер съезд төзергә булып, җирле Коммуна идарәсе дә бу эшкә яхшы караганлыктан, бер съездга карар бирелде. Төрле сәбәпләр белән вакыты 1920 елның 16 сентябрь көненә билгеләнгән иде. Съездда рәсми каралачак мәсьәләләр:

1. Килүчеләрнең докладларын тыңлау.
2. Диния нәзарәтенең үткәндәге эшләре хакында хисапны тыңлау.
3. Диния нәзарәтен һәм мөхтәсибләрне киләчәктә ни рәвештә дәвам иттерү хакында сөйләшү.
4. Диния нәзарәтенең һәм мөхтәсибләрнең киләчәктәге эш планы хакында сөйләшү.
5. Мәхәллә кешеләре һәм хадимнәренең икътисади хәлләре хакында.
6. Мәхәлләләр өчен дин хадимнәрен җитештерү хакында.

7. Мөселманнарга дини белем һәм тәрбия бирү хакында.

8. Мөселманнарны дини китаплар белән тәэмин итү чаралары хакында сөйләшү.

9. Шуралар хөкүмәтенең канун нигезләре декретларының дингә тагылган маддәләре белән танышу.

Һәр мөхтәсиб үзе, төбәгеннән ике имам, ике мөтәвәлли сайлатып китерәчәк, әгәр чыгымнарда тарлык кебек киртәләр булырдай булса, бер имам һәм бер мөтәвәлли китерергә тиеш.

Бу съездның булуы турында шөбһә дә булган, кирәкмәгән һәм теләмәгән эшләр чыгуына сәбәпче булмаса иде, дип куркучылар булды. Иптәшләребездән Ризаэтдин казый җәнабләре дә шул фикердә булды. Мәхкәмәнең күпчелеге күбрәк өлешнең теләкләренә туры китереп булдыру тарафында булган иде. Съездны кирәксенү сәбәпләре, югарыдагы маддәләрдән аңлашылган файдалар өстенә:

1. Мәхкәмәи-шәргыянең халык белән яхшырак танышуы һәм фикерләренә дөресрәк рәвештә аталуы хәҗәт, Мәхкәмәи-шәргыягә караш дәрәҗәләрен белү зарур иде.

2. Мондый рух төшкән, гайрәте сүнгән заманда мөселманнарның җыелуы ничек тә бераз рухланырга сәбәп булыр, күрешерләр, танышырлар, сөйләшүләр булыр, бер-берсеннән байтак дини һәм әхлакый файдалар туар, дип уйланылды.

3. Халык гайрәт белән җыелса, диндә ныклыклары һәм Дини мәхкәмәгә дә яхшы карашлары беленеп, сәясәт күзендә дә файдалы эш булып чыгуы өметле иде.

Боларга охшаган юнәлешләрне игътибар белән уйлагач, съездның төзелүенә карар бирелде.

Бу съездда минем хосусый теләгем дә бар: халыктан үтенеп, бу хезмәтемнән азат итүләрен сорарга булам. Әгәр гыйлеменә, диненә, тәрбиясенә ышанырлык кеше тапсалар, рөхсәт итәрләр, дигән уйда торам. Ял итәргә дә ихтыяҗым бар, гыйльми вәгазь хезмәтен мин булдырам, Нәзарәттә иң ихтимал булган реформа, мәктәп мәсьәләсенең юлы Милли идарә вакытыннан ук киселде, төп омтылышым шуның өчен генә иде. Халыкның миннән көткән хезмәтләрен хәзерге хәлдә җиренә җиткерү мөшкел, шунлыктан минем эшемә кимчелек китерәләр. Аллаһ Тәгалә ярдәм һәм рәхмәтен салып, мине һәм гомуми милләтне хәерлегә муафикъ итсә иде. Әмин.

Ишетелүенә күрә, халык һәр җирдә бу съездны ышаныч һәм шатлык белән кабул итәләр. Юл чыгымнарын тар тотмыйча, һәр җирдә диярлек әзерләнеп, вәкилләр сайлап, Уфага җибәрә дә башлаганнар. Башлап Том вилаятеннән Хәмзә ахунның Мөхәммәд исемле улы 11 сентябрьдә үк Уфада күренде. Дүшәмбе 13 сентябрьдә Казан-Сембер вилаятьләреннән байтак, 14 сентябрьдә дә килгәннәр, халык бик шат, бик кирәксенеп килгән [кебек] күренәләр.

15 сентябрьдә күп кеше җыелды. Бүген өйләдән соң сәгать 3 тә танышу өчен Мәхкәмә бинасына җыелдылар. 150 гә кадәр кеше җыелды. Һәр кайсына билгеләнгән бүлмәдә берәр чынаяк чәй биреп, килүләрен теркәп, дин юлында юл михнәтләрен тартулары турында сөйләшеп утырдылар. Күп кешеләр хосусый бүлмәмә кереп, күп кешеләр минем эштән китү хәбәремне ишетүләреннән кәефсез булып, хезмәтемне дәвам итүемне теләделәр. Минзәлә төбәгендә мөхтәсиб мулла Әбелмөхҗин әфәнде шактый хикәят рәвешенчә бу турыда күңелле итеп сөйләде: «Рәхәт өмет итеп тә, мәшәкатьләр күбәйгәннән авырсынып, хезмәттән чыгып буламы, дигән начар уйларга да барабыз», – диде. Сибирия вәкилләре, аеруча казаклар, минем эштән китү тәкъдирендә, бу Мәхкәмәи-шәргыядән аерылачакларын бәян иттеләр. Төрле төркемнән, төрле нәрсәләргә таянып, бу теләкләр ишетелә, кайбер һәвәскәр кешеләрнең хакыйкатькә якын да булмаган тәнкыйтьләре дә ишетелә. Үзем дә эштән чыгарга карар итсәм дә, бу кадәр халыкның соравы, төрле дулкыннар алдында торган милли эшләр һәм дини хәлләрнең иярүе дә уйланырга алмаслык түгел. Диненә, яхшы уйлап эшләүгә ышанырлык адәм мәйданда булса да, бер хәерле алмашка тапшырып, бу хезмәтемнән чигелсәм, ял итсәм, ләкин күренмәде шул. Үзем кадәр яки яхшырак бер кеше юлына, дөрес хезмәтенә тоткарлык та буласым килми. Бу рәвешле хәл булса, мин зур әхлаксызлык үрнәге булыр идем. Халыкка бу хәлне сөйләдем һәм сөйлим. Муса әфәнде, Зыя (Пәрваз) һәм Габдерәшит әфәнделәрдә дә һәвәслекләре, тәртипләре буенча да хәрәкәт сизелә, ләкин халыкның күбесендә ул тарафка кызыксыну сизелми. Риза казыйның укучылары күп булса да, үзе катгый рәвештә баш тарта. Минем иптәшләрем казыйлык хезмәтен дәвам итсәләр дә, үзләре мөфти булмаячаклар.

Әйттем: «Үзең ихтыяр итмисең, мине кызыксындыртасың». Әйтте: «Башта киңәшләшкән булсаң, кабул итмәгән дә булыр идем,

халык арасында элекке зур хезмәтеңә кимчелек ирешәчәген әйткән булыр идем, ләкин инде бер кергәч, дәвам итүең ярый, буласы булды.»

Зыя әфәнде турында төрле яңа эшләре мәйданда булгач, халыкның күпчелеге оешырдай күренми, диләр. Муса әфәнде аның хакында Мәскәүдә үземә әйткән иде: «Сезнең (хәзерге хәлнең) эшсезлегегез, иренүегезгә караганда Зыядан туачак начарлыкның золымы һәм зарары кимрәк». Кәефемне бозмыйча әйттем: «Кайсы мөмкин булган эшне эшләми калдырдым?» Бераз уйлап торганнан соң әйтте: «Имамнарга дин укыту юлында кисәтү ясарга кирәк иде, эшләмәдегез». Әйттем: «Бу эшне үткән ел ук эшләдек. Аерым күрешү мөмкин булмагач, һәркайсы мөхтәсибкә кисәтүләр язып җибәрдек. Һәркайсы имамга таратырга куштык.» Инкяр итсә дә, мәҗлескә килгән имам мулла Габделкаюм бине Фәттахетдиннең: «Тараттылар. Хәтта ишеткәч, мөхтәсибебездән, Мәхкәмәдән килгән кәгазьне сорап алдык, яшьләрдән куркып биш ай үзендә саклаган булган» сүзе белән аптырады. Ләкин икенче [вакыт] очрап, искә алынган мулла Габделкаюмны күреп шелтәләгән. Бичара Габделкаюм гафу үтенде. Петропавелдан казакъ казые мулла Мәһди, мөхтәсиб мулла Сәет Габделҗәлил, Күкчәтаудан мөдәррис мулла Галиәсгар, Акмулладан мөхтәсиб Әбүбәкер Давылбай, Атбасардан Шакир Хәялетдинов килделәр. Акмулла имамы казый Хөҗҗәтелхәким әфәнде дә килде.

## Казакъ галимнәреннән мөхтәсиб мулла Исхакның вафаты

Болар белән бер уйга калдырган хәбәр дә килде, Петропавел өязендәге мөхтәсиб казакъ мулла Исхак бине Бирдехуҗа бу тарафка сәфәрендә йөргәндә тиф хасталыгы белән, 1338 елның 12 зөлхиҗҗәсендә 62 яшендә дөньядан кайткан икән. Казакълардан мактаулы галим, фикерле зат иде, яшь кыяфәтле, күркәм сурәтле, саф кеше иде. Троицкийда дамелла Җамалетдин бине Сөбханкол мәдрәсәсендә гыйлем алган, хәтта күп еллар анда укытканлыктан, шәех Зәйнулла Нәкышбәнди хәзрәтләреннән тарикать алып, файдаланып, үз даласына килеп, имам һәм хатыйп булып, дәрес укыткан зат иде. Милли эшләрдә дә хезмәте күп иде. 1905 елларда Череванскийның казакъларны шамани дип хөкем иткән вакытында

Петербургка барып, сөйләшүләрдә һәм бәхәсләрдә булган гайрәтле һәм батыр адәм иде. Гафәраллаһү ләһ (Аллаһ аны кичерсен – *А.Г.*). Минем хакта да яхшы уйда, пакь күңелле иде. Хат язышуыбыз бар иде. Петорпавелга сәфәребездә күп сөйләшүләребез булды[24].

## Съездының ачылуы

12 сентябрьдә пәнҗешәмбе көн иртә белән галимнәр съезды ачылды. Беренче мәчет эчендә ачылу рәвеше: якынча 150 вәкил әзер булгач, минем рәислектә эш башланды. Эшне имам Җиһангир әфәнде Абызгилдин Коръән укып башлап, дога әйтелде. Соңрак төрле җирләрдәге халыкның бу съездга шат күңел белән карап, зур чыгымнар тотып килүләренә, юл авырлыкларын сабырлык белән үтүләренә рәхмәтемне белдердем. Һәркайсының хәрәкәтләре дингә мәхәббәт белән булганлыктан, үземне шундый сыйфатта булган халык алдында күреп куанычымны бәян иткәннән соң, мәҗлеснең ачылуын игълан иттем. Элек, эш буларак, түбәндәге сүзләрне укыдым[25]:

«Хөрмәтле вәкилләр! Сез – дин җәһәтеннән шушы Мәхкәмәи-шәргыягә ияргән бөтен ислам халкының вәкиләре! Миллионнар белән булган мөселманнарны бер кыяфәт хәлендә күрсәтеп торасыз. Бу Мәхкәмәи-шәргыя сезнең дини мәхкәмәгез. Анда хезмәт итүче әгъзалар – үз тарафыгыздан сайланган кешеләр. Бу әгъзалар бу көнгә кадәр үз бурычларын үтәп тордылар. Хәл һәм килешү ияләре тарафыннан төзелеп бирелгән законнар җыентыгына муафикъ [булган] үз вазыйфаларын башкарып килделәр, хезмәтләрен кичектермәделәр. Кимчелекләрен Аллаһ Тәгалә гафу итсен! Бәндәчелек белән булган хаталарын сез дә багышлагыз. Әгъзалар моны сездән самими рәвештә үтенәләр. Бу Мәхкәмә инде бу көннән һәм бу сәгатьтән башлап сезгә тапшырылды. Моңа кадәр хезмәт

---

[24] Иң соңгы хатыннан нөсхә: Бисмиллаһи-р-рахманир-рахим. [...]. Әмма казакъ тарафлары, Ленин кавемнәре малларына һәм әйберләренә зарар китерсәләр дә, иминлекләренең күпчелегенә нисбәттә юк. Ләкин халкыбызда тиф кебек авырулар гаять тә күп. Петропавел тарафы казакъларының ихлас мәхәббәтләре, сагынулары көннән-көн арта. Мөхтәсиб Исхак бине Бирдехуҗа 1338 елда 8 май шәүвәл (милади 1920 елның 25 июне).

[25] Ризаэтдин казый язуы иде.

итеп килгән әгъзалар өстендәге җаваплылык бөтенләе белән сезгә күчте. Чират җиткәннән соң, кирәк кадәр әгъзаларны сайлап, Мәхкәмәне шуларга әманәт итәрсез. Әлеге әгъзалар шул сәгатькә кадәр хезмәт итеп торырлар да, үз кулларындагы вазыйфаларын вәкилләрегезгә тапшырырлар, өсләренә булган бурычларыннан бушанырлар. Аллаһ Тәгалә ярдәмчегез булсын. Мөселманнарның мәнфәгатьләре табылачак эшләрне Аллаһ Тәгалә күңелләрегезгә салсын. Үзегезне сайлап җибәргән мөселманнарны шатландырсагыз иде. Сүбхәнә раббикә раббил-гыйззәти гаммә йәсыйфүн. Вә сәләмүн галәл-мүрсәлин. Вәл-хәмдү лилләһи раббил-галәмин (Коръән аятьләре – *А.Г.*)».

Бу сүзләрдән соң һәр әйбернең вәкаләтнамәсен тикшерү өчен бер комиссия, тикшерүгә куелган мәсьәләләрне карап, мөмкин булганнарын килештереп, мөмкин булмаганнарын, әһәмиятләренә күрә, шул хәленчә карап, зарур күрелгәннәрен мәҗлескә җиткерү өчен икенче бер комиссия сайланды. Соңрак мәҗлес җыелып ачыклау өчен төштән соң сәгать 4 тә янә мәҗлес булып, рәислек буенча съезд өчен рәис билгеләмичә, чират беләнме, кирәгенчәме, җыелыштан берсе мәҗлескә рәислек итәргә карар бирде. Мәҗлес өчен президиум сайлауларына керешелде. Кайбер шикләнүләр сәбәпле, эш тукталып, караңгылык төшкәнче дәвам итеп, тәмам булмыйча, рәислеккә 7 санда билгеләнсә дә, казакълардан сигезенче булып, бер кеше арттырырга карар иттеләр.

## Съезд вакытында җомга намазы

17 сентябрьдә җомга намазы тәмамлангач, халыкка, күбесе имамнардан гыйбарәт булгач, бераз вәгазь сөйләдем. Бу рәвешчә: «Ислам дине – Аллаһның пәйгамбәре аркылы безгә җибәрелгән әманәте. Аны саклау тиешле һәм тиешле урынына ирештерү имамнар өстенә йөкләнә һәм имамнарның канатлары булган ил агаларына һәм дин әһелләренә йөкләнә. Тиешле һәм кирәк була ки, бу әманәтне яхшы саклап, урынына ирештерү өчен элек без һәм сез имамнар башта үзебезне шул дин буенча тәрбияләп, шул дингә һәр ягыбыз белән тапшырылып, халыкка яхшы үрнәк булып, телләребез белән дә халыкны туры юлга күндерик. Мәчет хуҗалары, картлар да безгә ярдәмче һәм канат булсыннар. Галимнәр пәйгамбәрләрнең варислары булырга тиеш. Шулай ки, Аллаһ илчесе салләллаһү

галәйһи вә сәлләм Аллаһ биргән гыйлем белән камил гамәл кылып, өченче дәрәҗәдәге халыкны бөтен эшләре, сүзе белән тәрбия иткән. Аллаһ ризалыгына халыкны чакырып, бәхет юлын күрсәткән. Пәйгамбәр варисы булган кешедә дә мондый рәвеш һәм сыйфат булу кирәк. Әмма муллаларга халыкны туры юлга кертү, дини, әхлакый тәрбия, пәйгамбәр мирасы буларак, кирәк. Дин өчен төрле афәт туып торганда, көннән-көн артып торганда фидакарь рәвештә хәрәкәт итү тиешле. Дөньяда диннән башка юанырлык ни бар? Җан һәм малның ничә мыскал әһәмияте барлыгын тәҗрибә белән белдек. Бу көнгәчә ялгыш аңлап йөргәнбез. Иң әһәмиятле эшебез дин булганга, бар көчебез белән имамнар тырышырга тиеш. Олы кешеләрне мәчет вәгазьләре белән, балаларны мәктәптә, өйдә, мәчеттә укыту юлы белән тәрбияләү һәм туры юлга күндерү тиешле. Халыкны, олысын-кечесен яхшы тәрбия итү – һәммәсе муллалар муенында бурыч. Бер авылда бер имансыз була икән, кыяматтә аның турында имам җаваплы ки, тиешенчә аны вәгазь һәм нәсыйхәт иткәнме яки буш торганмы? Карендәшләрем, имамнар, бу бабларда диккать итә күрегез. Тырышлык күрсәтегез, муеныгызга зур хезмәт йөкләтелгән. Үтәү өчен Аллаһ ярдәм бирсен! Аллаһ хозурында барчабызның йөзләребез ак булып, Аллаһ илчесе саллаллаһү галәйһи вә сәлләм янында да оятлы булмасак иде».

Җомгадан соң сәгать 3 тә мәҗлес җыелып, үзләре өчен президиум сайладылар, ләкин тәмам булып җитмәгәч, 18 сентябрьдә иртә белән тәмамланды. Түбәндәге кешеләр сайланды: 1) Габдерәшит казый Ибраһим, 2) Мәсгуд бине Габделгали Бәйрәкәви, 3) Хәсәнгата казый Габәши, 4) Садыйк Иманколый Казани, 5) Муса Биги, 6) Кәрим Диберди мөтәвәлли, 7) карый Җамалетдин Хурамшин Бәләбәй. Казакълардан бер кеше арттыру тиеш күренеп, мәҗлес ризалыгы белән, Акмулла мөхтәсибе мулла Әбүбәкер Давылбай сигезенче булып керде. Боларны сайлау эше тәмамлангач, съезд эшен президиумга тапшырдым. Хөкүмәт аркылы үткәреп алынган тәртип һәм программадан чыкмыйча эш итүләрен киңәш итеп, элекке көннәрдә съездның керешендә хәрәкәт итеп, чын мәҗлес бу сәгатьтән башлануын искә төшереп, хәерле эшләр насыйп булуын Аллаһтан сорап, урыныма аларны утырттым. Идарә тәртибе (регламент) укылып, Уфада милләтләр эше башында булган комиссар Габделхәй Дәүләкәй Шура хөкүмәтенең юлын, большевиклар ниләр кылуларын, дәүләт һәм байлыкны ничек екканнарын, фәкыйрьләргә ярдәм ниятендә булуларын, үзләренең

баскаклык сүзләрен, егетлек һәм кыюлык белән сәгать ярым кадәр сөйләгәч, беренче доклад буларак минем хәлем белән эш башланды.

## Мөфти һәм казыйларның съездда докладлары

Аллаһны мактаудан һәм пәйгамбәребезгә салават-догалардан соң, мөфтияттә иң мөһим ике мәсьәлә: берсе – мәктәп һәм мәдәрәсәләрне дин рухында яхшы үзгәртү (реформа), икенчесе – имамнарның хәлләрен яхшырту һәм аларны чын дин хезмәткәрләре хәленә китерү иде. Мәктәпләр төрле сәбәпләрдән Диния Нәзарәте ихтиярында калдырылмады. Имамнарның хәле дә төрле сәбәпләргә, тоткарлауларга очрап, теләгебезчә эшләнми тора, шулай да өметле хәлдә.

Бу тәкъдимнәр һәм максатлар өчен Диния нәзарәте элек имтихан мәсьәләсен үзгәртеп, аерым тәртип, программа буенча эш күрүен, 130 кадәр адәмнең кире кагылуы бәян ителде. Гаилә мәсьәләләрен Коръән рухына карап байтак җиңелләштерелгәнен, хатын-кызларга мәрхәмәт белән мөгамәлә юлларын күрсәтү башланды. Мәхкәмәнең башка эшләрендә дә бер дәрәҗәдә яңалык белән эш күрелде. Соңрак Мәхкәмәнең фикер һәм мөнәсәбәт күрүенә туры килгәнчә, 1918 елда Мәскәү сәфәрендә йөреп килгәнемне, соңра Казакъстанда сәфәр кылуымны, Романов хөкүмәте вакытында казакъларның исламнарын танымыйча, шамани һәм фәлән дип төрле котырту һәм фетнә астына алынганлыкларыннан, Милләт мәҗлесе әгъзалары һәм башка гыйлем ияләре тарафыннан сәяхәт кылып, хәлләре белән танышып, күрешеп, рухланып кайтуны кирәксенүләре сәбәпле, 1917 елда Мәскәүнең зур съездында бу мөфтилек яклавына керүләрен игълан иткәннәренә күрә, рәсми мәчетләр ачу, имтиханнар оештырып, имамнар билгеләү, мәктәпләр ачу, мөгаллимнәр урнаштыру хезмәтләрен дә күздә тотып, ул тарафка сәфәр тиеш күрелеп, 1918 елның 17 августында Акмулла вилаяте казакъларын күрү нияте белән Петропавелга сәфәр иттем. Шул шәһәрдә, Өмбе шәһәрендә, Күкчәтау шәһәрендә һәм аннан башка бар урыннарында булып, 22 кеше имтихан бирде. Элек бер волостьта бер мәчет кенә төзү рөхсәт ителү сәбәпле, ислам тарала алмый, шуңа күрә һәр авылга балчыктан, туфрактан булса да, бер мәчет төзеп, аның каршысына яңа бер бүлмәсендә мәктәп торгызу тиеш күрелеп, фәрман бирелде.

Байтак гаилә дәгъваларын, мөгамалә, низагларын күреп, хәл итеп, тынычлык урнаштырылды. Казакъстан халкы үзләренең мөфти ярдәменә керүләрен, иске хөкүмәтнең архирей кулына тапшыру нияте булуын җиткереп, күп шатлыклар күрсәттеләр, рәхмәтләрен белдерделәр. Ул сәфәремнән октябрьдә Уфага кайтырга ниятләп, Чиләбегә килсәм дә, шул көндә юл киселеп, чикләнеп калдым. Юл ачылу мөмкинлеге һәм башка рәвеш белән дә сәфәр мөшкел күренгәч, өметсез булып, Петропавел шәһәренә кайтып, кышны анда үткәрдем. Бу хәлләрне һәм әйтергә теләгәннәрне яздым: Диния нәзарәте өстендә төрле күренешләр, хәлләр чыгу Мәхкәмәнең карары буенча быел Мәскәү сәфәре кирәкле күренде. Анда бер ай чамасы яшәргә мәҗбүр булып, бу кәгазьне алып кайттым. Бу урында Мәркәздә муллалар эшен карый торган бүлеккә бирелгән гариза һәм алар тарафыннан бирелгән җаваплары гына укылды. Монда шул гариза һәм җавапның нөсхәсен генә язабыз:

«Милләтләр эшен карый торган халык комиссариатына.

Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының мөфтиеннән Антантаның сәяси һәм икътисади золымы астында яши торган шәрык халыклары үзләренә бәйсезлек алырга һәм икътисади коллыктан котылырга сусап торалар. Шуның өчен дә бөтен мөселман халкының милләтләргә бәйсезлек бирүне вәгъдә итеп, ул вәгъдәсен гамәлдә күрсәткән Совет хөкүмәтенә авышуы табигый. Бөтен дөнья империализмын җимерү Совет хөкүмәтенә кирәк булган кебек, шәрык халкы булган мөселманнарга сәяси, икътисади азатлыкка ирешү өчен кирәкле эш. Безнең дошманыбыз уртак булган кебек, сугыш сафыбыз да уртак булырга тиеш. Дошманны һәм сугыш сафының уртаклыгы сәбәпле, мөселманнар Совет хөкүмәте тирәсенә җыелгач, Совет хөкүмәте дә мөселманнарны якларга, аларга мәдәни дәрәҗәләре, сәяси һәм икътисади урыннарын игътибарга алырга, аларның гадәт һәм башка хәлләре белән хисаплашырга тиешле күрәләр. Эчке Русия һәм Сибирия мөселманнарының рәисе булган мин мөфти Совет хөкүмәтенә мөрәҗәгать итеп, мөселманнар каршында диннең мәдәни һәм әхлакый яктан нинди мөһим урын тотканлыгын белдерүне үземә бурыч дип хисаплыймын. Мөселманнар өчен дин беренче нәрсә, шуның өчен Мәркәз хөкүмәте һәм җирле хөкүмәт мәсъәләләре дә Совет хөкүмәтенең файдасын күздә тотып, мөселманнарның дини хисләрен сүз һәм эш белән кимсетүдән сакланулары кирәкле. Эчке

Русия һәм Сибирия мөселманнарының дини хәҗәтләрен үтәү өчен совет хөкүмәтенең түбәндә әйтеләчәк эшләргә игътибар итүен кирәкле табамын:

1. Мөселманнар дин хәҗәтләре өчен үз араларыннан ихтыяри иганәләр җыярга, сәясәткә катнашмый торган дини оешма һәм җәмгыятьләр төзергә хаклы булсыннар.

2. Мөселманнарга дини һәм әхлакый тәрбия бирү өчен кирәкле булган имамнар, мөәзиннәр һәм Диния нәзарәте әгъзалары гаскәри һәм мәҗбүри хезмәттән азат булсыннар.

3. Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының дини эшләрен йөртү өчен Уфа шәһәрендә мөселманнарның үз иганәләре белән оештырылган Мәхкәмәи-шәргыяләре мөселманнар үзләре теләгән рәвешчә дәвам итсен.

4. Диния нәзарәтенең (Уфа шәһәрендә Тукаевский урамында 50 нче номер) бинасы мөселманнарның үз иганәләреннән төзелгән булганга, мөселманнарның үз милекләрендә калдырылсын. Бу бина биредә башка кирәкләр өчен алынмасын. Диния нәзарәтенең бинасына каршы кителмәячәге электән директ белән белдерелгән иде. Ләкин 1919 елның ноябрендә Уфа коммунистлары бу бинаны музей дип игълан иттеләр. Акрынлап Диния нәзарәтен кысып, кайбер биналарны ала башладылар. Бу вакыйгалар мөселманнарга һәм коллегия әгъзаларына начар тәэсир итте. Халык каршында бу эшләр динне кысу дип каралырга мөмкин.

5. Диния нәзарәте сәясәттән ерак булса да, Совет хөкүмәтенең сәясәтенә каршы килмичә, ислам дине мөмкинлек биргән кадәр аңа һәрвакыт ярдәм итте. Шуның өчен Совет хөкүмәте бу Нәзарәт әгъзаларына теләгәнчә йөрергә, үзләренә каршы килмәскә хак бирелсә иде.

6. Динне һәм әхлакны таратуда булырга, типография һәм почта белән файдаланырга Диния нәзарәтенә хак бирелсә иде. Моннан башка Уфа шәһәрендә җыелачак съезд һәм җыелышлырның вәкилләренә, бару-кайтуларына иркен юл куелса иде.

7. Мөселманнарның үз чыгымнары белән торгызылган мәктәп һәм мәдрәсәләре алынмаска тиеш. Бу мәктәп һәм мәдрәсәләрдә дин укуга камил иркенлек бирелеп, алынган мәктәп һәм мәдрәсәләре үзләренә кайтарылсалар иде.

8. Дин укуларны юлга салу өчен мөселманнар мәктәп һәм мәдрәсәләрне эчтән, тыштан үзгәртергә ирекле булсыннар, шул

максат өчен иганәләр җыярга, җыелышлар һәм җәмгыятьләр төзергә хаклы булсыннар.

9. Авыл, волость, өяз советлары кайсыбер җирләрдә булып үткән кебек, муллалар сайлау, раслау эшләрендә катнашмасыннар иде. Бу эшләрне башкару фәкать Диния нәзарәте вазыйфасы гына булып торса иде.

10. Күп җирләрдә волость советлары гражданский никях белән шәригать никяхларын болгаштыралар да, шәригать дөрес күрмәгән никяхларны үтәргә руханиларны да этәрәләр, мәсәлән, гражданский юл белән генә беренче иреннән аерылган хатынны икенче иргә никяхлау кебек маддәләрдә. Мондый йөкләүләр булырга волость советларының хаклары юклыгын белдерсә иде.

Югарыда язылган маддәләрне Русия социалистический федеративный республика мәхкәмәсенең каравына җиткереп, мөселманнарның дини хәҗәтләренә тиешле рәвешчә игътибар ителер һәм җентекле әмерләр чыгарылыр, дип өмет итәмен.

Имза: мөфти Галимҗан бине Мөхәммәдҗан.

Мәскәү, 1920 елның 12 августы».

Бу гаризага милләтләр эшен карый торган бүлектән җавап:

«Оренбург Мәхкәмәи-шәргыясе мөфтиенә.

Сезнең быелгы 12 августта 62 номерлы мөрәҗәгатегезгә җавапта милләтләр эшен карый торган халык комиссариаты түбәндәгечә бәян итә:

Сезнең мөрәҗәгатегездә әйтелгән 1, 2, 5, 6, 8 нче маддәләр хакында ачык бәян итүен сорап турыдан-туры Халык комиссариатының юстиция бүлегенә мөрәҗәгать итәргә мөмкин, чөнки Совет хөкүмәтенең юстиция бүлеге күрсәтүе буенча басылган бөтен декрет һәм әмерләре сез уртага салган мәсьәләләрне тәмам хәл кылалар.

Мөрәҗәгатегезнең башка маддәләренә килгәндә, милләтләр эшен карый торган бүлек үзенең түбәндәге фикерен бәян итә:

3 нче маддә буенча Уфа шәһәрендә тора торган һәм бөтен эчке Русия һәм Сибирия мөселманнарының дини хәҗәтләрен үти торган Диния нәзарәте хосусый оешма булып, мөселманарның үз чыгымнары белән тәрбияләнеп дәвам итәргә мөмкин, ләкин аңа сәясәткә катнашмаучылык шарт ителә.

4 нче маддә буенча Диния нәзарәте бинасын мөселманнарның үз чыгымнары белән төзелгән булганга, Нәзарәт кулында калдырыла.

7 нче маддә буенча мөселман мәктәпләренең биналары элек дини мәктәп булып, мөселманнарның үз акчаларыннан гына төзелгәнлекләре исбат ителсә, кайтарылырга мөмкин. Мәдрәсә биналары турында сезгә Шәрык җөмһүриятләренең мәгариф бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк, чөнки сезнең мәдрәсә биналарының күбесе шул җөмһүриятләр эчендә тора. Бу җөмһүриятләр исә мәгариф эшләрендә автономный-мөстәкыйль игътибар ителә.

3 нче һәм 10 нчы маддәләрдә әйтелгән нәрсәләрегез игътибарга алына һәм Совет хөкүмәтенең мөселманнарның дини эшләренә катнашуы кирәк түгеллеген тиешле мәхкәмәләр аркылы әмерләр, хәбәрләр җибәреләчәк. Диния нәзәратенең бинасын Нәзарәт кулына калдыру турында эчке эшләрне карый торган Халык комиссариаты аркылы әмер ителәчәк.

Милләтләр эшен карый торган коллегиянең әгъзасы: (имза).

Мөдир: (имза) (бу әгъза Мирсәет Солтангалиев).

Номер 2117, 1920 елның 21 августы, Мәскәү шәһәре».

Миннән соң казый Ризаэтдин әфәнде Мәхкәмәнең ике еллык тарихын үз язмасыннан укып чыкты. Бу тарихында байтак файдалар язылган, мәмләкәтебездә Дини мәхкәмә ачылудан элек булган каза һәм фетнәләр, шул фетнәдә үк бер җиргә тупланган булмаса да дарелказалар (казыйлар йорты – *А.Г.*), фәтваханәләр булганын яхшы аңлатып, Екатерина II (Әби патша) вакытында Мәхкәмәишәргыя ачылып, хөкүмәт тарафыннан бер мөфти билгеләнеп, Казан вилаятеннән өч казый сайланып куелып килүен, өченче дәвердә мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов вакытында, аның аңлатуы буенча, казыйларны мөфти күрсәтеп, Эчке эшләр министрлыгына билгеләү, мөфтине ачык күрсәтеп, патша билгеләү ысулы чыгуын, законда мөфти мөселманнарның сайлавы белән куелса да, гамәлгә куелмавын сөйләде. Соңгы дүртенче дәвердә генә мөселманнарның үз теләкләре белән бер мөфти Галимҗан Баруди, алты казый: 1) Кәшшафетдин Тәрҗеман, 2) Салихҗан Урман, 3) Хөҗҗәтелхәким Мәхмүт, 4) Габдулла Сөләйман, 5) Гомәр Карашый казакъ, 6) Мөхлисәбанат Габделгаллэм Буби сайлануын һәм моның кебекләрне җиткерде.

Беренче милләт мәҗлесендә Гомәр Карашый казакъ бүлегенә күчкәнлектән, казый Ризаэтдин бине Фәхретдин сайлануы бәян ителде.

Соңрак инкыйлаблар вакытында төрле куркыныч вакыйгалар булып, Мәхкәмәи-шәргыянең һичбер җиргә кузгалмый сабыр итүен,

урынында һәм хезмәтендә нык торучанлыгы, чыдамлыгы һәм соңрак та Мәхкәмәнең бинасына һәм казыйларына булган мөнәсәбәте бәян ителде. Ризаэтдин казыйның проекты, бер тарихи китабы хисап ителергә лаек булып чыкты.

Өченчедә Кәшшафетдин Тәрҗеман казый тәкъдимен укыды. Моның проектында (тәкъдимендә) Мәхкәмәнең һәммә эш тарихы җиткерелде. 1920 елга кадәр ничә имтихан булганлыгы, 125–130 лап кешенең кире кагылуы, ни кадәр гаилә эшләре каралып, кайсысының хәл ителүе, ни кадәр мал эшләренең җентекле карау, мәктәп һәм мәдрәсәләр эшендә үзгәрешләр кертү турында хәрәкәт һәм эшчәнлек алып барылу, шулай ук Мәхкәмәнең башка эшләре турында җиткерелде. Бу тәкъдимнәрнең һәркайсында халык башка ачыклыклар теләсә дә, аңлатуны сорасалар да, шуның белән канәгатьләнделәр. Кайбер начар караучыларның: «Диния нәзарәте яхшы эшләмәде, тырышлык куймады», – дигән яла сүзләренең хакыйкате беленеп, боларның өметсезлекләренә сәбәп булды.

Гәрчә Диния нәзарәтендә эш белән танылган, милләт һәм дин кирәкләрен кайгыртучан, ялгыз ярым-йорты вазыйфа белән канәгать булып, элеккедәге булган керемнәрен ташлап хезмәт иткән кешеләр булсалар да, һәркемгә билгеле иде. Капма-каршы сәясәт, инкыйлабта Мәхкәмәне саклау һәм аның уртасында булып дәвам иттерү, бинасын ни кадәр һөҗүмнәргә юлыгып торып, милләт әгъзасыннан гыйбарәт вәкилләрнең үз кулларында калдыра алу вөҗданнары алдында олы хезмәт санала иде. Съездның күбесе моны яхшы белделәр. Аның өстенә, рәсми эшләр бар да тиз һәм яхшы рәвештә эшләнде. Андый-мондый караңгы мөгамәләләр катыштырылмады, әлхәмдү лилләһ.

Диния нәзарәтендә, шәхсән, үзебез янында явыз нияттә булган кешеләр турында да ишетелде. Габдерәшит казый Ибраһим, Муса Биги, Зыя Камал әфәнделәрнең мөфтилек теләгендә булулары һәм шул юлда авторитетлары белән кызыксындырулары, бер-берсе белән берләшеп, безнең хакта сүзләр сөйләүләре, хәтта Уфа имамнарының да иярүләре беленде. Ләкин бу өч кеше тиз кызучанлык беләнме, мәгънәви начар тәэсир сәбәплеме – съездның начар карашларын, хәтта нәфрәтен җәлеп иттеләр. Съездны өметсез һәм мәхрүм булып үткәрделәр.

Габдерәшит әфәнденең гаҗәпкә калдырганы: бер сөйләшүдә: «Халыкка сүз аңлату авыр, Тара халкы миңа бик ышанычлы һәм ихласлы, һәр бабта сүземне кире какмыйлар. Шулай да Муса

турында һич ышандыра алмадым. Нәзарәткә дигән иганәләрен, әгәр Муса яки Зыя мөфти булсалар, тапшырмый алып кайт, диделәр», – дип сөйләгән иде. Ләкин соңрак китешендә иганә турында бер дә сүз чыгармый, Диния нәзарәте кассасына тапшырмый китте. Аллаһ белер, бәлки, тар әхлагы, галим җанны да искә алынган ике кешегә йөз юнәлткәннәрдер. Ләкин Г. әфәнде, булганда ачык әйтүдән бер дә тартынмый торган иде.

Съездда һәркөн иртә белән 12 гәчә өч сәгать, өйләдән соң өч сәгать киңәшмә дәвам итте. Төрле тарафтан килгән 50–60 кадәр докладларны кыскарту өчен бер комиссиягә тапшырылды. Мәхкәмәи-шәргыя өчен оештырылган комиссиянең докладын Уфада беренче мәхәлләнең имамы ахун Җиһангир Абызгилдин әзерләгән иде. Үзе съездда докладчы булып, йомшак кына, рухсыз гына укыды. Бу кеше элек Диния нәзарәтеннән гадәттән тыш эшләр көтә иде. Уфаның башка муллалары шуның кебек иде. Шунлыктан бу оешманы аларга бирергә карар итәргә идек ки, юл күрсәтсеннәр, эшләве мөмкин булган эшләрне мәйданга куйсыннар, дигән идек. Докладын съезд алдында Нәзарәттә укып күрсәтте. Докладында көлке бер каршылык чыгып, комиссия әгъзасы алдында оятлы булып, съездда укыганда Нәзарәтне тәнкыйть маддәсен сөйләмәслек икәне аңлашылды. Шулай ки, элекке язганында Диния нәзарәте яраклы санала торган эш күрмәде, дигән мәгънәдә бер сүз язган хәлдә, үзләре тарафыннан дәрәҗә ителгән эшләр һәм оешмалар барчасы Нәзарәтнең тәртибеннән һәм гамәленнән гыйбарәт иде. «Яраклы эш эшләгән Нәзарәтнең тәртибе, реформа юлынча төзелгән докладыннан тәртип алынуы, башка бер дөрес, артык кадере булмавы ничек, ышануыгызга каршы килмиме?» – дип каршы чыгуы Кәшшаф казый тарафыннан комиссия мәҗлесендә җиткерелде. Шул сәбәптән булса кирәк, исбатсыз тәнкыйть, хурлау съездда укылып, кире кагылган иде.

Өченче мәхәлләдә ахун Сабир Хәсәнов декретларның исламга мөнәсәбәтле маддәләрен озын итеп укыды. Ләкин башында кереш сүз буларак, югары уку йорты дәресләрендәге хокукка караган байтак сүзләр җиткерелеп, мәхәлләгә мөнәсәбәте булмаган халыкны бераз ялыктырды. Алай да яхшы, байтак мәгълүмат туплаган иде. Докладлар аерым тупланып, тәнкыйть һәм үзгәртүләр, яңартулар өчен дә тапшырылды.

Оешмада рәислек иткән Муса әфәнде үзенең докладын башка җиргә тәкъдим итмичә, съездда укуны таләп итеп, эшен күп кеше

тәнкыйть итсә дә, Габдерәшит Ибраһим: «Мин күрдем, зыянлы нәрсә юк», – дип ышандырып сөйләп, укый башлады. Доклады шактый озын, 50–60 кадәр маддәдән гыйбарәт, язмасы рухи сәясәткә бәрелгән кебек тоелып, сәяси кеше, Милләтләр комиссариаты рәисе Габделхәй Дүкәев, аның фикерләренә каршы төшеп, туктатты.

Докладын үзенә алып укып чыкканнан соң, иртәнге көндә мөмкинлек бирсә дә, берәм-берәм фикер әйтергә рөхсәт итмәде. Докладны шактый файдалы нәрсәләрне үз эченә алса да, гамәлдә куллану мөмкин булмаган, коры сүз булып кала торган маддәләре дә байтак бар. Чөнки, нигездә, Муса, гамәли адәм булмыйча, теоретик, яхшы фикерле кемсәнә булганлыктан, карашын куллану һәм үтәүгә кую бабында күп кайгыртмый, халыкка фикер күрсәтсә, канәгатьләнер кебек була. Съезд халкының рәвешеннән мөфтилек өмете дә өметле булмаганга, күңеле төшеп, кискен сөйләшүләре булып, үзенең абруен бу съезд эчендә һәм тышындагы хәрәкәте белән байтак киметте. Тиз кызучанлык бабында Габдерәшит Ибраһим да киредә калмады. Бераз арттырды да.

Съездның рөхсәтендә сәясәттән ерак булу, сәяси мәсьәләләрне фикер алышуга куймау билгеләнгән һәм шарт ителгән, миңа Мәркәздә телдән дә әйтелгән булса да, Габдерәшит әфәнде рәислеккә һәм башкаларга әйтмичә, кабат сьездга шәрык мәсьәләсен күтәреп, мөселманнарның бу турыда хөкүмәткә мөнәсәбәтен, өч-дүрт әгъзасын һәм берәр хөкүмәт әгъзасыннан бер комиссия төзеп, бу мәсьәләне яхшы хәл кылу тиешле, дип игълан итте. Халык бик борчылып китте. Хөкүмәт алдында авыр хәлгә калдылар. Сәяси мәсьәлә, ничек кенә булса да, фикер алышуга куелмаска тиешле. Икенче халыкның хөкүмәткә мөнәсәбәте һәм шәрык мәсьәләсенә катышулары хакында бер дә вәкаләтләре юк, алай да сәяси мәсьәләгә кермибез, дип фикер алышудан алдырдылар. Үзе генә хөкүмәт әгъзасы алдында яхшы атлы булып калса калгандыр, ләкин халык алдында алай түгел. Шул көннәрдә бер хосусый кунак мәҗлесендә Габдерәшит һәм Муса әфәнделәр бу мәсьәләне янә кузгатып, катнашмаганнарны гаепләп сөйләүләрендә, мулла Сабир Хәсәни тарафыннан түбәндәге сүзләр сөйләнде: «Шәрык мәсьәләсенең хәле, соңы билгеле түгел. Мондый мәсьәләне халыкка җиткерү, аларны аңа чакыру кирәк түгел. Мондый мәсьәләгә катышырга бер вәкилнең дә вәкаләте юк. Булса, бары элек бер оешма тарафыннан этрафлы фикер йөртелеп, план күрсәтү тиешле.

Соңрак аңлату, җиткерү кирәк», – диде. Бу бер дәрәҗәдә акыллы фикер итеп күренеп калган иде. Безнең Ризаэтдин казый да, Муса әфәнденең аерым ихласлыгы булган хәлдә, мондый буйсынмаучылыкны, кирәк һәм кирәкмәс мәсьәләләрне киңәшләшмичә гомуми мәҗлескә җиткерүләре сәбәпле, мәшәкать чыгаруларын сөйләде.

Шимбә көн 25 сентябрьдә Диния нәзарәтенә әгъзалар (мөфти һәм дүрт казый) сайлаулары башланып, элек исемен билгеләү кәгазьләре тупланып, соңрак шар салу тәртибен карарга куелды. Мин исә байтак заманнан бирле эштән азат итүне теләп, Казанда бу фикергә килгән идем. Ләкин күп кешенең теләкләре, хәерле алмаш булырдай бер кешенең мәйданда күренмәве, яраклы күрелгән Габдерәшит, Муса, Зыя Камали әфәнделәр турында халыкның оешуы ихтималы булмавы мәйданда анык иде. Шимбә көн күпчелек тарафыннан минем ризалыгымны сорар һәм аларның фикерләрен миңа ирештерү өчен Хаҗитархан мөхтәсибе мулла Габдрахман Гомәри һәм иптәше килеп мөрәҗәгать иттеләр. Әйттем: «Мин үзем теләмим, башка бер лаеклы, милләтнең һәм диннең хокукын саклардай кеше булса, мин чыгар идем. Лаек кешенең юлына киртә булмыйм, ял итәргә дә теләгем бар, ләкин халыкның көчле теләге мине бераз аптыраштa калдырды. Шунлыктан оешманы шулай калдырсалар, милләтнең теләген юкка чыгармам», – дидем.

## Мөфти һәм казыйлар сайлау

Съездга 340 кадәр адәм килүе мәгълүм булса да, съезд шактый акрын барды. Кайберләре ялыктырдылар. Бу комиссия сайланган вакытта 307 кадәр кеше беленде.

Җомга көн язу белән күрсәтүдә әлеге рәвеш беленгән: мөфтилек өчен миңа – 257 [тавыш], Габдерәшиткә – 11, Мусага – 29, Зыяга – ? [ничә тавыш икәне язылмаган – *А.Г.*]. Бу рәвеш күренгәч үк, бу өч кеше шарга куелмаячакларын мәҗлескә игълан иттеләр. Казыйлык өчен Ризага – 295, Кәшшафка – 276, Мөхлисәгә – 151, Габдулла Сөләйманга – 102, Зыяга – 69, Гыйнияткә – 61, Сабир Хәсәнигә – 55 Урмановка – 53, Габдерәшиткә – 38, Мусага – 25, Хәсәнгатага – 16, Җиһангирга – 35, Мәсгуть мәхдүмгә – 13, Хаҗи Галигә – 10 [тавыш] күренеп, Риза, Кәшшаф, Мөхлисә, Гыйният, Хаҗи Галидән башкалары барчасы сайланудан баш

тарттылар. Шимбә көн шар сайлаулары булды. Миңа мөфтилек өчен 257 ак, 44 кара шар булган. Казыйлык өчен Риза казыйга 295 ак, 4 кара. Кәшшафка 271 ак, 29 кара. Мөхлисәгә 207 ак, 98 кара, Гыйнияткә 128 ак, 45 кара, Хаҗи Галигә 65 ак, 193 кара булды. Төшкә хәтле бу сайлаулар үтеп, янә бер казый кирәк булгач, төштән соң Сабир муллага сайлау булып, акка чыгып сайлану булды. Уфаның кайбер имамнарына һәм аларга кушылган кайберәүләргә эшләрнең, сайлауларның теләкләренә туры килмәгәнлектән, съездны таплы итү, халык һәм хөкүмәт күзендә кара күрсәтү өчен Уфадан Сабир мулланы баш тарттыру өчен, Гыйният казыйны сайлату фикере бик куәтле йөрсә дә, зур тәэсире булмыйча, тиешлесе сайланды, тиешсезе төшеп калды.

Бу сайлауда диккатьне җәлеп иткән нәрсә – Мөхлисә ханымның сайлануы. Тарафның күпчелегеннән алынган хәбәрләргә һәм съездда күренгән хәрәкәтләргә, ишетелгән сүзләргә караганда, аның яңадан сайлануы мөмкин күренә иде. Үзе дә моны аңлап, гомуми коллегиягә эштән китү турында махсус гариза да тәкъдим иткән иде. Ләкин хатын-кызлар хәрәкәткә килеп, рәислеккә аның яки башка хатын-кызның сайлануын теләп, бер гариза тәкъдим иттеләр. Халык арасында ахырдан мәхәллә хөкүмәтенең мөселман бүлегенә дә, рәсми булмаса да, мөрәҗәгате һәм аларның, рәсми булмаса да, тәэсирләрен таләп итәчәкләре дә беленде. Эшнең рәвешен аңлагач, Бәйрәкә Мәсгуд мәхдүм тарафыннан бу турыда съездга озын бәян сөйләнде. Ахырда, фетнәдән саклану нияте белән, күпчеклек аның сайлануына ризалык күрсәттеләр.

Искәрмә: Мәхкәмә әгъзасы берсе дә мөстәкыйль казый түгел, һәркем үзенә тапшырылган өстәл эшен идарә итеп, җәмгыять белән карар һәм хөкем чыгарыла. Югарыда искә алынган хатын булса да, хатыннар хакында булган катгый ислам әдәбен кайгыртучы. Шунлыктан халыкның бу теләге каршылык тудырмый.

25 сентябрьдә ике көннән бирле зарур мәсьәләләрне калдырып, Муса әфәнде тарафыннан тәкъдим ителгән, Мәркәзгә биреләчәк телеграмма тәртибен җентекләп тикшереп, байтак яхшы мәҗлес беткәннән соң, казый җәдид мулла Сабир Хәсәни тарафыннан тәкъдим ителгән нөсхә күпчелек тарафыннан кабул ителде. Нөсхә түбәндәгечә: «Мәркәз һәм җирле хөкүмәт ярдәме белән Уфада 1920 елның 16 сентябреннән башлап ун көн дәвам иткән эчке Русия һәм Сибирия галимнәре, дин белгечләре съезды үзләрен сайлаучылары тарафыннан тапшырылган һәммә мәсьәләләрне хәл иткәннән соң,

шәрык уңышы юлында ярдәм итүче Мәркәз, советлар хөкүмәтенә дә, җирле хөкүмәт идарәләренә дә сәлам һәм рәхмәтләрен белдерә. Шәрык һәм мөселманның рәнҗетелгән халкын коткару юлында хәрәкәт итүче Шуралар хөкүмәте кызыллар гаскәренә һәм шул юлда бергә баручы төрек һәм башка милләт гаскәрләренә галимнәр съезды сәлам җиткереп, уңыш тели».

Съездның тәртибе белән докладлар укылып, туры килгәннәре кабул ителә барды. Диния нәзаратенең эшләрен тикшерү идарәсе докладны рәисләре Габдессамат мөхтәсиб Буави тарафыннан укылды. Яхшы тикшергән булсалар да, тапкан җитешсезлекләре, юлларның авырлыгы, кассаның бушлыгы сәбәпле, кайбер эшләрнең мәйданга куела алмавы кебек сәбәпләр алга чыкты.

Мәктәпләр докладчысы Габдрахман Гомәри, Хаҗитархан мөхтәсибе, үзенең докладын яхшы укыды. Кайбер маддәләрдә үзләренең проектларын бераз үзгәртеп, Муса әфәнде һәм Зыя әфәнденең каршы килүләренә саташу сурәте белән карап, көлдергеч рәвештә көлке җаваплар белән үткәрде. Бераз хурлау аралаш булса да, җаваплары канәгатьләнерлек булып күренде. Мәктәпләр докладында иске һәм мәгълүм маддәләрдән артык яңа бер фикер күренмәде. Тик Муса әфәнде Шура мәктәпләрендә дәрес араларында ук берәр сәгать дин укытылсын, дигән маддәне кертүне тәкъдим итсә дә, декретларның фикере, хөкүмәтнең фикере һәркемгә мәгълүм булып, моны кабул күрмәделәр.

Соңгы Диния нәзаратенең сметасы каралып, октябрь башыннан мөфтигә илле мең сум, казыйларга кырыгар мең сумнан, мөхтәсибләргә унар мең сумнан айлыклар билгеләнде. Кайбер хадимнәргә хезмәтләренә күрә юмартланып, бу бабны тәмамладылар.

Мөхтәсибләр турында Мәхкәмәнең электән бирле булган үз фикере ачык булса да, мәҗлеснең байтак өлеше мөхтәсибләрдән гыйбарәт булгангамы, кабул ителмәде. Мәхкәмәи-шәргыя электән үк мөхтәсибләргә вазыйфаларны үзләре тарафыннан тупланып килгән иганәләрнең бер өлешен бирүне күздә тоткан иде, чөнки кайбер мөхтәсибләр сорыкорт кына булып яталар. Башка даирәләрдән килгән иганәдән аларның вазыйфа алулары муллыктан түгел иде. Күпчелек мөхтәсибләр тарафыннан тупланып Нәзарәткә тапшырылган иганәләр йөз меңнән ким иде. Эшләренә карасалар да, аена бер-ике шөгыль белән генә үткәргәннәре байтак иде. Шунлыктан мөхтәсибләргә бу вазыйфа күп булуы, яртысы җитәрлек

булуы өстенә, үзләреннән җыелган иганәләрнең яртысы булуы кебек тәкъдир ителүе гадел иде. Шаять, эш күрсәтер. Аллаһ хәерле кылсын!

Мөһим мәсьәләләрдән бер гыйльми җәмгыять тәшкил итү мәсьәләсе булса да, вак мәсьәләләр белән дә вакыт күп үткәнлектән, сөйләшүгә вакыт тапмадылар. Хәер, җәмгыятьнең оешуыннан да беркадәр берлек булмау, кайбер имамнар Нәзарәттә тырышучы, хөкем чыгаручы кебек булсын, кайберләре киңәшче дәрәҗәсендә булсын кебек фикерләр сөйләделәр. Муса һәм Зыя әфәнделәр бу җәмгыятьне кирәксенсәләр дә, һаман чын рәвеше һәм вазыйфалары белән аңлатылмады. Җитди уйлаган кешеләрнең фикеренчә, бөтен Русиядән иң кадерле, гыйлеме һәм дине белән танылган затлардан җыелган мактаулы хезмәт итәрлек, Академия тәртибе кебегрәк, елга бер мәртәбә булса да җыелып, мөһим мәсьәләләрдә карарлар чыгарып, байтак хезмәтләр күрсәтерләр һ.б. Ләкин форсат аз булу сәбәпле, бу мәсьәлә сөйләшүгә тиешенчә куелмады.

## Каргалы халкына мөрәҗәгать

Съездда төрле тарафлардан мөселманнар җыелсалар да, иң мәшһүр шәһәребез булган Каргалыдан һичкем килмәде. Башкортстанда аерым бер Диния нәзарәте төзелеп маташуларыннан, Каргалы Башкортстан идарәсендә булгач, бу съездга катнаша алмадылар. Съезд халкы бу турыда аларга мөрәҗәгать итүне, гомуми Башкортстанның өстен һәм ихтыярлы булып, дини эшләрдә бергә булуларын теләп, карар чыгарганнар иде. Шунлыктан мин Каргалы имамнарына, дин хезмәткәрләренә бу турыда бер хат яздым. Бисмилла һәм Аллаһны мактаганнан соң түбәндәгечә язылды: «Ахун Фазыл шәех Хәйрулла әфәнде хәзрәтләре, хөрмәтле имамнар, бөек галимнәр, җәмәгать һәм башка тәүхид (бераллалык – *А.Г.*) һәм бердәмлек ияләре! Сәлләмәһүмүллаһү Тәгалә вә вәффәкаһүм... (Аллаһ Тәгалә аларны коткарсын һәм ярдәм итсен... – *А.Г.*). Галимнәрдән һәм мөтәвәллиләрдән гыйбарәт [булган] 340 кадәр мөселманнар, бер сүздә җыелган булып, ун көн вакытында дини хәҗәтләр бабында сөйләшүләр алып барып, хәерле күренгән эшләрдә карар чыгарып, тынычлык һәм шатлыкта таралдылар. Вәлхәмдү лилләһи галә зәлик (Аның өчен Аллаһка мактау – *А.Г.*)! Тик съездыбызның бер кызганыч нәрсәсе – Каргалы кебек зур

ислам шәһәренең, галимнәр һәм фикер ияләре шәһәренең катнашмавы бу зур ислам җәмгыятеннән читтә күренеп калуы турысында булды. Каргалы бөтен Болгар мәмләкәтебездә гыйлеме һәм әхлагы белән дан тоткан зур шәһәр булган хәлдә, ислам җәмгыятендә булмаулары җәмгыятькә бер кимчелек булган кебек, әлеге шәһәрнең дә бераз кадерен бозган кебек хөкем чыгарылды. Башкортстан мохтариятенең уңышын, сәяси һәм иҗтимагый эшләрендә, бәйсезлек хәрәкәтләрендә даими җиңүләрен телибез. Ләкин дин эшләрендә – кирәк эчке карашларда, кирәк тышкы сәяси күзләрдә – бер сүз һәм бердәм идарәдә җыелган булып, хәрәкәт итүләре, зур белемнәренә кушылган булып, дини гадәтләрне саклауда тырышулары бик кирәкле күренә иде. Бу кадәр төрле ерак тарафлардан җыелган мөселманнарның да теләкләре һәм рәсми карарлары да бу югарыда әйтелгән бердәмлек һәммәсенең Башкортстан кешеләренең һәм башка төрле шәһәрләр халкының бу Уфадагы Диния нәзарәтенә җыелулары һәм бердәмлекләренең кирәклеге белән булды. Шуңа күрә мин фәкыйрегез – галимнәрнең һәм мөселманнарның хадиме – бу бабта сезнең уйларыгызны һәм кайгыртулы рәвештә киңәшләшүләрегезне, өмет итеп яздым. Вәссәләмү галә мән әтбәгаль-һүдә вә җәнәбәл-бидгатә вәл-һәвә (Туры юлга иярүчеләргә һәм бидгатьләрдән, нәфесләренә иярүдән ерак торучыларга Аллаһның сәламе булсын – *А.Г.*)! 1339 елның 16 мөхәррәме».

Шимбә көн кич 25 сентябрьдә халыкның яртысына якыны киткәннәр иде. Мәҗлесне тәмамлау тиеш булганга, ахшамнан соң мәҗлес ябылды: комиссия җитәкчелеге мәҗлескә, Мәркәз һәм мәхәллә хөкүмәтләренә рәхмәтен белдергәч, үзләреннән кузгалып, мәҗлеснең һәм съездның төп җаваплылыгын, рәислекне Диния нәзарәте әгъзасына тапшырды. Рәислекне кабул итеп, рәхмәтебездә мондый зур җыелышка ярдәмен, мәхәллә мөселман даирәсенең яхшы күзәтеп, уртак фикердә булып булышуына олы рәхмәтеннән соң, съездның тәмам булуын әйтеп, бәхет белән вәкилләрнең таралуына рөхсәт биреп, төп тәгәлләү сүзе – Бәләбәй имамы Җамалетдин карый Хурамшин тарафыннан Коръән укылып, съезд тәмамланды. Һәркем кузгалып, кайберләре ахшам намазын укып, вәгъдәләшеп тaралдылар. Җәгаләллаһү гакыйбәтәһү ләнә вә лигаммәтил-мүслиминә вәл-хәмдү лилләһи раббил-галәминә вә салләллаһү галә Мүхәммәдин вә әлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн (Безгә һәм мөселманнарга Аллаһ аның нәтиҗәсен бирсен. Аллаһка мактау

булсын. Аллаһ Мөхәммәд пәйгамбәрне, аның гаиләсен һәм барлык сәхабәләрне олыласын – *А.Г.*). Язылды 17 мөхәррәмдә, 30 сентябрьдә.

Бу съезд арасында Бохара хәленнән хәбәр ишетелде. Риваятьләргә караганда, Шура хөкүмәте Бохарага кергән, үз идарәсенә алган, инкыйлаб тарафлы яшьләрнең зарарында булган галимнәр һәм әмирләрне дөньядан югалткан, әмирне тоткын иткән. Һәм бер риваятьтә, качкан икән. Бу хәбәрләрнең нигезе бик мәгълүм булмаса да, асылының дөреслегенә күңел карар таба. Мәскәү газеталарында кыска гына язылып үткән. Һәлак итүләре табигый[26]. «Ысуле җәдид ияләре – кяферләр, инкыйлаб – шулай ук», – дип фәтвалар төзеп йөргән мулла Халморад мөфти һәм мулла Камәреддин Нугай кебек мөдәррисләр – инкыйлаб ияләре һәм реформа ияләре тарафыннан танылган, зарарлары тәҗрибә ителгән затлар. Шулай ук казый Мирборһан бине Бәдретдин бине Садретдин искелек һәм каршы тору тарафында булып танылган. Ни хәлләр булса да, Аллаһ ахырын хәерле итсә иде. Шаять, кайбер начар төркемнәрдән дә хәерле гамәл туар, фикерләре, игътибарлары артып, эзләнеп, реформа юлына басарлар, гыйльми һәм иҗтимагый эшләрендә уртак бер фикергә килерләр, хаклыкка якынлашырлар. Вәллаһү хайрун-нәсыйрин (Аллаһ – иң яхшы ярдәм итүче – *А.Г.*).

## Бу съездан алынган тәэсирләр

Съезд Русия мәмләкәтендә булган съездларның икенчесе дип исәпләнергә хаклы, 1917 елның 18 июлендә Керенский идарәсе вакытында зур гыйльми съезд булган иде. Ләкин ул съезд тик галимнәр сыйныфында булып, ике йөздән артыграк галимнәр җыелган иде. Бу съезд 1920 елның 16 сентябрендә галимнәр белән мөтәвәллиләрдән җыелган булып башланып, акрынлап 350 гә якын адәм җыелган иде. Хөкүмәт, мәмләкәт коммунистлар кулында булса да, рәсми мөмкинлек бирелеп, юллар бик тар булган хәлдә,

---

[26] Декабрьдә ишетелде: Бохарада зур митинг булып, гомуми караш белән коммунистлар да аларга яраклаштырып булса кирәк, казый Мирборһанны һәм рәисе Гыйсаметдин бине дамелла Гарифколны, Кошбигине (Низаметдин Үргәнче булса кирәк) үтергәннәр. Мулла Халморад һәм мулла Камәр турында хәбәр ишетелмәде, качканнардыр, шаять.

килү-китүгә дә гореф-гадәт белән рәсми ярдәм алынып, вагон, көймә (параход) тарлыгыннан башка тарлык күрмичә, җыелу һәм аерылу булды.

16 сентябрьдән 25 енә кадәр сузылган 18 мәҗлес кадәрле дә мәхәллә милләтләре бүлеге тарафыннан рәисе Габделхәй Дәүкәй күзәтеп, сәяси хакыйкать булмаса да, шөбһәле, хәтта рухи сәясәтне аңлаткан маддәләрдә дә каршы чыгуда ялкаулык итмәсә дә, гомуми күзәтүе зарарсыз һәм гаделлек белән булды.

Халыкның иҗтимагый эшләрендә осталыгы, булдыклылыгы алга барган кебек күренсә дә, канәгать итәрлек дәрәҗәдә түгел иде. Җыелышларда түбәндәге кимчелекләр күренде:

1. Сүзгә оста кешеләрнең кирәк булса-булмаса сөйләргә кызыгулары.

2. Кечкенә һәм әһәмияте аз мәсьәләләрдә озын әңгәмәләр әйтүләре.

3. Эшләр арасында әһәмиятле хисапланган аермаларны гамәлдә тәкъдир итә алмаулары.

4. Шәхси гаризалардан бөтенләй саклану мәсьәләсендә кимчелекләре. Шактый өстен кешеләрнең бу бәладән сәламәт булмаулары.

5. Комиссия һәм секция сайлауларында, көчләренә һәм сәләтләренә карамастан, үзләреннән авыштыру өчен генә ризалык күрсәткән кебек, уйламыйча гына сайлыйлар. Рәислек сайлау вакытында күрелгән кимчелекләр дә шушы нисбәттә.

6. Булдыра ала торган эшләрдә ваемсызлыклары, дөрес хисап ысулын белмәүләре. Мәсәлән, съезд вакытында һәр тарафтан яхшы иганәләр туплану белән 3 миллион кадәр мал тупланган иде. Кыска фикер белән тикшерү оешмасы да моны күп күреп, гүяки бетмәс хәзинә күрделәр кебек, чамасыз кебек билгеләп, кирәксез премияләр биреп, бер ярым айда бу иганәне бетерерлек хәлдә смета төзеделәр. Бу премияләр Мәхкәмә хезмәткәрләренә булып, Мәхкәмә әгъзасының киңәше һәм фикере белән буган хәлдә, Мәхкәмә әгъзасына итәгатьсезлек белән гаҗиз иткән һәм доноslары белән куркытып торган кайберәүләргә илле мең сумнан премия бирделәр. Бу хәлне әгъзага бер зыян [дип] хисапларга мөмкин.

7. Һәр бабта тиешле, дини һәм дөньяви эшләрнең барчасында кирәк булган игътибар һәм уйлану дигән төшенчәнең азлыгы, киңәшкә игътибар итмәүләре.

Мондый кимчелекләр Мәхкәмәдә калган вәкилләр өчен шактый кулайсызлык тудырырга мөмкин, Аллаһ Тәгалә ахырын хәерле кылсын! Мәхкәмәнең иске комиссиясенә каршы кемсәнәләр, шул ук комиссиянең сайлануына яман күз белән каравыннан, кайбер акылсыз хәрәкәтләр туган булуы да ихтимал.

Шулай да халык булдыксыз түгел, яңа өйрәнчек булсалар да, алдагы көндә өйрәнүләре өметле, ихтимал, диннәре куәтләнер, вөжданнары сафланыр, Аллаһның ярдәме белән хәерле эшләр тудырырлар. Мондый кимчелекләр безнең халыкта гаҗәп тә түгел, элек Романовлар вакытында хөкүмәт тарафыннан бик кагылдылар, үги бала дәрәҗәсендә генә тордылар, тиешле хокукларына ирешә алмадылар. Мондый зур җәмгыятьләр күреп өйрәнмәделәр. Булса да, качып-посып кына эш күрделәр. Гыйлемнәре дә аз, башка эш төшмәгәч, сәяси һәм иҗтимагый бабларда тәҗрибәләре дә аз, затларында һәм табигатьләрендә булган зирәклек һәм үткенлек эшкә күп кушылмый торды.

Инде чын мәгънәсе белән хөрриятләр[27] туса, фикер, сүз һәм эшкә мөмкинлек бирүләр мәйдан алса, иншалла, безнең болгар мөселманнарыбыз, төньяк төрекләребез башкалардан түбән калмасалар кирәк. Вәллаһү йәһди мән йәшәъ (Аллаһ кемне тели, шуны туры юлга күндерә – *А.Г.*)!

Бу кадәр кыскача сөйләү белән съезд хәлләреннән иң мөһим булганнары бәян ителде. Минем мөфтилекнең элекке дәвере тәмам булып, казыйларның да шулай булды.

Инде быел 1920 елның 1 октябреннән яңа комиссия исемендә булып, эшкә керешелә, иншалла. Аллаһ Тәгалә барчабызга да дөрес ният, ихлас йөрәк белән дин һәм милләт юлында хәерле эшләр күрергә һәм эшләргә насыйп итсә иде. Сүбхәнә раббикә раббил-

[27] Хөррият сүзе мөнәсәбәте белән Габдерәшит әфәнде Ибраһимның кайбер мәзәкләре хәтеремә килде:

Бер мәҗлестә хөррият сүзе искә алыну белән, исеме бар, атамасы юк нәрсәләргә мисал китерә иделәр. «Моның иң туры килгән мисалы хөррият. Исеме күп заманнан бирле телләрдә йөрсә дә, атамасын күргәнебез юк һәм бер кеше дә күрмәгән. Хөррият иң муафикъ мисал буларак искә алынуга лаек», – дигән иде.

Кардәшебез Габдерәшит әфәнде рәсми мәҗлесләрдә куәтле хәрәкәттә булып, мантыйкка каршы хәрәкәтләрдә булса да, сөйләшүләрдә хөрриятче, аңа кагылган мәзәкләр торгызучы. Мәҗлесне кызыклы итәргә куәтле. Аллаһ аны гафу итсен!

гыйззәти гаммә йәсыйфүн. Вә сәләмүн галәл-мүрсәлин. Вәл-хәмдү лилләһи раббил-галәмин (Коръән аятьләре – *А.Г.*).

Моны сайланган мөфти Галимҗан бине Мөхәммәдҗан бине Бинеямин бине Гали бине Колмөхәммәд Баруди Казани язды, 1339 елның 17 мөхәррәме.

## Мөфти һәм казыйларның кыскача тарихлары

Бу урында Диния нәзарәтенең бу сайлаудагы әгъзаларының кыскача гына тәрҗемәи хәлләре бәян ителсә, зыян итмәс уе белән языла.

**Мөфти Галимҗан бине Мөхәммәдҗан бине Бинеямин бине Гали бине Колмөхәммәд Баруди** 1273 елның 17 җөмадиәл-ахире, милади 1857 елның февраль башында Казан тирәсендәге Кече Кавал исемле авылда туган. 1278 ел ахырында, милади 1862 елның май аенда Казанда дамелла Сәлахетдин Сәгыйдь мәдрәсәсендә уку башлап, башлангыч, урта белем дәресләрен тәмамлап һәм кайбер югары [белем] дәресләре күреп, бер тарафтан өйрәтүче булып, 1392 (1875) елда Бохарага барып, тулы белем алып, соңгы 3–4 елында гыйлем алу вакытында дәрес укытып, фәннәр өйрәнү арасында математика фәннәрен күреп, 1299 елның шәгъбанында, 1882 елның июнендә Казанга кайтты.

Шул ук елның октябрендә, 1300 елның 1 мөхәррәм көнендә, милади 1882 елның 12 ноябрендә Казанның бишенче мәчетендә (Ак мәчет) икенче имам һәм мөдәррис булып билгеләнде һәм указ алды. Шул көндә бер-ике шәкерткә дәрес башлатып, акрынлап дәресен арттырды. Акрынлып мәдрәсә торгызып, бу көндәге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен торгызып, милади 1908 елгача мәктәп һәм мәдрәсә дәресләренә байтак реформа кертеп, дәрес укытты. 1304 елда Исламбул, Мисыр, Хиҗаз сәфәрләрен кылып, хаҗ фарызын үтәп, дини мәгълүматларын һәм мәдрәсәләрне яхшырту турысында фикерләрен киңәйтеп, кайтты. Шул вакытта 25 ел кадәр мәчетендә атналык вәгазь мәҗлесен дәвам иттерде.

1908 елда Вологда шәһәренә ике елга сөрелде. Анда дүрт ай торганнан соң, Эчке эшләр министрлыгыннан рөхсәт белән Вена, Будапешт шәһәрләрен күреп, Истамбул, Мисыр, Мәккә, Мәдинә, Шам, Бәйрут, Тараблис, Бәгъләбәк шәһәрләрендә булып, ганимәт сәяхәтеннән милади 1910 елда Казанга кайтты. 1912 елда яңа указ белән имам-хатыйб һәм мөдәррис исеме белән эшкә кереште. 1917

елда өченче тапкыр Төркестанга сәяхәт итте һәм бу сәяхәтендә баш инкыйлаб мөнәсәбәте белән хөррият, бөек фикерләр һәм дәресләргә реформа турыларында, Фәрганә вилаятьләрендә, Ташкентта һәм башка җирләрдә байтак сөйләде һәм фикерләр таратты. Чәмкәнд шәһәрендә вакытында Мәскәүдәге гомуми Русия мөселманнары съездында беренче булып мөфтилеккә сайланды. 1918 елда Беренче милләт мәҗлесендә янә сайланып расланды. Бу 1920 елда булган галимнәр һәм дин әһелләре съездында өченче мәртәбә буларак сайлануын теләмәвенә каршы, халыкның теләкләренә күрә, кабул итеп, янә сайланды. Аллаһ Тәгалә хәерле эшләргә муафикъ итсә иде! Ахыргы эшләребезне яхшы тәмамларга насыйп итсә иде! Әмин!

Юлым һәм фикерләрем:

Мәктәп һәм мәдрәсәләрне дингә якынлаштырырлык һәм тормышка файда итәрлек рәвешчә яхшыртырга итешле. Яшь һәм карт – барысы да дингә ябышу, бар көче белән аны хөрмәтләү, әдәпләрен җиренә китерү тиешле. Дин гыйлем түгел, бәлки, гамәл һәм һәр гыйлемнең максаты – гамәл. Дин һәм хаклык бабында сукырларча иярүсез карап, һичкемгә икейөзләнү кылмыйча, диннең бөеклеген саклау – һәркемнең бурычы. Ләкин һәр эштә акрынлык кирәк. Кешенең ияләшкән нәрсәсеннән аерылуы авыр булганга, үзгәрүне булдырмау, зур дулкынлану һәм курку була.

Гыйлем иясе һәм көчле адәм имам булып, дин гыйлеме таратырга, халыкның әхлагын төзәтергә, халыкның ир һәм хатынын Аллаһка якынлаштыру турысында хезмәт итәргә тиеш. Имамлык һәм укыту өчен мөмкин кадәр айлык алмаска тырышырга тиеш, эшнең һәм хезмәтнең бәрәкәтсез булмавына сәбәп ачкүзлелеккә бәйләнгән.

Һәр бабта Аллаһка мөрәҗәгать һәм Аңа ялвару кирәк. Тышкы сәбәпләргә (кирәклегенә ышанган хәлдә) таянмаска һәм фәкать тышкы сәбәп икәнлеген онытмаска тиешле. Аллаһтан үземә, гаиләэһелләремә, кардәшләр һәм иярченнәремә туры юл сорыйм. Барча ислам әһелләренә яхшы юлда булулары өчен дога кылам. Вәллаһү һүвәл-һәди (Аллаһ – Туры юлга күндерүче). 1339 елның 1 сәфәр ае.

**Казый Ризаэтдин бине Фәхретдин бине Сәйфетдин бине Собханкол бине Бикмөхәммәд бине Юлдаш әш-Шырдани**. Чыгышы Казан, Зөя төбәге Шырдан исемле авылдан күчеп, Бөгелмә төбәгендәге Кичүчат исемле авылда урнашып, «типтәр» исемен алган. Югарыда искә алынган зат милади 1858 елның 31 декабрендә туган. Белем алуы Бөгелмә төбәгендә, мәшһүр Шәлчеле авылында

мөдәррис Габделфәттах бине Габделкаюм янында булып, бер кадәр укытучы һәм хәлфәлек вазыйфасын да үтәгән.

1889 елда шул ук төбәктә Илбәк исемле авылда имам һәм мөдәррис булып, шәкертләр укыта башлаган. 1891 елның 2 августында ахунлык мәртәбәсе бирелгән. 1892 елның 8 гыйнварында указын Илбәк авылыннан Кичүчат авылына күчерткән. 1891 елның февралендә Уфага казыйлык хезмәтенә күчкән. Бу тарихтан 1906 елның май аена кадәр казыйлык хезмәтен дәвам итеп, май аенда Оренбургка күчеп, мәшһүр «Шура» журналында баш мөхәррирлек һәм мөдирлек вазыйфасын үтәгән.

1918 елның 9 гыйнварында Беренче төрек-татар милләт мәҗлесе тарафыннан янә казый булып сайланып, шул ук елда март башыннан хезмәткә керешкән. 1920 елда янә галимнәр һәм дин әһелләре съездында казыйлыкка сайланып, хезмәт итүдә. Аның гыйлем һәм әдәп хәлләре мәйданда, күп галимнәргә һәм фикер ияләренә мәгълүм, яхшылык һәм югарылык белән танылган. Соңгы заман халкы өчен төп текст буларак бәян итәм: гыйльми куәте яхшы, гарәп телен белүе төзек, иң мөһим булган хәдис гыйлемен белүче, юлы һәм дөрес рәвеше белән яхшы исем хасил иткән. Ислам тарихында, аеруча галимнәр тормыш юллары турында яхшы мәгълүматы бар. Бу илләребездә (Казан, Болгар һәм Кыпчак вилаятендә) үткән галимнәр һәм мәшһүр затлар хакында гүзәл әсәрләре бар.

Диндә һәм иманда ныклы, дини вазыйфаларында тугры, әхлагы сабыр, чыдамлыгы күркәм, аз сүзле, күп эшле, һәркемгә хәерлек теләүдә, әманәтле һәм туры сүзле зат.

Табигатендә яхшырту фикере өстенлек итә, шунлыктан һәр кемгә, һәр эшкә, һәр сүзгә тәнкыйди фикер белән караучан, суфи тарикатьләренә һәм башкаларга тәнкыйте кирәгеннән артыграк. Кайбер язулары һәм фикерләре белән тел һәм каләмгә бирелгән яшьләрнең арттыру һәм чамасызлыкларында алдынгы булып китә.

Кайбер җитешмәгән җирләре булса, остазларга аз юлыгып, ислам илләренә дә сәяхәт итмичә, һәр бабта фикер һәм өйрәнү куәте белән генә камилләшүдән туган кимчелек булырга мөмкин. Кимчелексез кайсы бәндә бар, ничек тә заманыбызның ганимәтләреннән бер мөхтәрәм шәех. Аллаһ гыйлеменә һәм гомеренә бәрәкәт бирсен! Әмин!

**Казый Кәшшафетдин бине Каваметдин бине Камалетдин бине Тәрҗеман бине Колшәриф бине Исмәгыйль бине Йосыф бине Юныс Болгари** 1877 елның 22 июнендә туган. Казанда

Мәрҗани мәдрәсәсендә мөдәррис Борһанетдин Мөхәммәд бине Һарун Шиһабетдин Мәрҗани янында тулы белем алган. Шул ук мәдрәсәдә 7–8 ел дәрес укыткан, рәсми мәктәптә дә мөгаллимлек иткән. 1904 елның 7 августында имам-хатыйб һәм мөдәррислек дәрәҗәсенә имтихан тотып, 7 сентябрьдә вилаять Мәхкәмәсе тарафыннан расланган. Казанның Яңа бистәсендә Орнашбашның Мөхәммәдрәхим бай төзеткән 11 нче номерлы мәчеткә имам итеп билгеләнгән. Шул ук мәхәллә мәдрәсәсендә дә 1912 елдан 1917 елгача «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең мөгаллимнәр комиссиясе төркеменә кереп, дәрес биргән. 1917 елның май аенда Мәскәүдә булган гомум Русия мөселманнары съездында Мәхкәмәи-шәргыядә казый булып сайланган. Шул ваыттагы вакытлы хөкүмәт тарафыннан расланган. 1918 елның 9 гыйнварында мөселманнарның Беренче милләт мәҗлесе тарафыннан янә казыйлыкка билгеләнгән. 1920 елның 16–26 сентябрьләрендә Уфада булган галимнәр һәм дин әһелләре съездында янә казыйлык хезмәтенә сайланган.

Шәхси хәлләре:

Гыйльми фазыйләтләре һәм ислам әхлагы яхшы, гарәп телен белүе дөрес, өйрәнүе тугры, Коръән һәм Сөннәт гыйлемнәренә мәхәббәтле, иске һәм яңа фәннәрне белүче, гадел фикерле, сәламәт йөрәкле, эчке халәте дөрес, мөхтәрәм зат. Үзенә йөкләгән эшендә йөкләмәләре яхшы, ләкин кичектерүдән азат түгел. Сөйләү куәте бар, каләме һәм язуы зарарсыз, яхшы, ачык яза, русчадан тәрҗемәләре дә бар. Хәзер Мәхкәмәнең Мәгариф бүлеген идарә итүдә. Мәхкәмәнең сәясәткә бәйле һәм хөкүмәткә караган хезмәтләрендә яхшы уйлап эшләүдә.

Өченче казый Мөхәммәдсабир бине Мөхәммәдҗан Хәсәни Уфада өченче мәчет төзелгәч, имам булган иде. Һаман да шул имамлык хезмәтендә. Башлангыч гыйлемне агасы мулла Газизҗан Карачидан, аннан Троицкида мөдәррис, мәшһүр дамелла Җамалетдин бине Собханкол янында булып, аның вафатыннан соң шәех Зәйнулла Рәсүли хәзрәтләре янында, нәкышбәндия тарикатендә булып, дини гыйлемнәрен байтак арттырган. Аның мәдрәсәсендә берничә еллар укыткан. Соңра Уфага имамлык өчен чакырылган. Уфада байтак еллар мәдрәсә тотып, урта һәм югары белем алуга хәзерләү дәрәҗәләрендә шәкертләр укыткан. Соңгы дәвер елларына кадәр мәдрәсәсе бик куәтле булмаса да, дәвам иткән. 1907 елда Государственный думага вәкил [итеп] сайланып, бераз заман Петроградта калган, шул вакытта Уфада булган мәдрәсә һәм мәчет эшләренә зарар ирешкән.

## Эчтәлек

Кереш сүз ........................................................................................ 3
Кереш................................................................................................ 9
Уфадан сәфәр. Көймәдә (параходта) хәлләр..................................... 11
85 яшьлек Гайсә мулла белән сөйләшеп утыру ................................ 13
Сәфәрдә ураза, сусау, чәй, су мәсьәләләрендә.................................. 14
Бирскида имам һәм мөәзин................................................................ 17
Уфа тарафында рамазан вәгазьләре.................................................. 18
Рус халкында бала тәрбиясе ............................................................. 19
Бохаралы казый Гавделвахит ............................................................ 21
Көймәләрнең хәлләренә бер караш.................................................. 22
Чаллыда Хәлфиннәрне искә алу........................................................ 24
Дөньяның ләззәтләре......................................................................... 25
Казанга якынлашу, хәсрәтләнүләр.................................................... 27
Диния Нәзарәте һәм аның дәвам итүе .............................................. 27
Диния нәзарәте хакында фикерем..................................................... 30
Чистай, Болградтагы хәлләр.............................................................. 33
Казанга ирешү.................................................................................... 34
Казанда бер көн элек гает уку,
имамнардан җавап алу ................................................................. 35
Гает укуда имамнар фикеренә кушылуның сәбәпләре ..................... 37
Казанда гаетне вакытсыз укыйлар.................................................... 38
Гаеттә ният өйрәтү ............................................................................ 39
Гаеттән соң күрешү мәсьәләсе .......................................................... 40
Гаетләшү, күрешеп йөрү.................................................................... 41
Казанда янган урыннарны карау........................................................ 41
Җомгадан элек вәгазь сөйләү ничек ................................................. 44

Җомга намазында «Җомга» һәм «Мөнафикыйн» сүрәләре [уку] сөннәтлеге ........ 46
Шәмсевәли хәлфә, тәрҗемәи хәле ........ 46
Татарстан җөмһүрияте турында имамнар белән сөйләшү ........ 48
«Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә бару һәм тәэсир ........ 48
Барудиядә Габдуллаҗан мөәзиннең тамга җыюы ........ 49
Татарстан җөмһүрияте файдалы булырмы? ........ 50
Ташкент автономиясе ........ 51
Татарстан җөмһүриятенә караш һәм аның юлы ........ 51
Театр мәсьәләсендә дөрес караш ........ 55
Сөембикә манарасына вәисиләрнең ай куюлары ........ 56
Казанда туй кыланышлары ........ 59
«Ислах» җәмгыяте ........ 61
Яңа Бистәдә Зариф хәзрәт Әмирханда ........ 61
Хәсән карины имтихан кылу ........ 63
Оры Сәмигулла мәхдүм ........ 65
Зират өсте мәчете һәм имамы ........ 66
Әхмәтҗан хәлфәнең кызылларга карашы ........ 67
Ак мәчет халкына имам алу хакында бәян ........ 68
Карахуҗа имамы Садыйк хафиз белән сөйләшү ........ 70
Мулла Әфтах Тәрҗеманиның никях хөтбәсе ........ 72
Яңа Бистәдә мулла Садыйкның намазы ........ 73
Галимнәр һәм имамнарның хәлләренә караш ........ 73
Имамнарның вазыйфа алулары ........ 74
Гаскәри ахун Гатаулла Баһаветдинов ........ 79
Чистайдан мулла Нәҗип Әмирханның тәрбия хакында фикере ........ 80
Гыймади агай ........ 81
Шәһәр Шәрәфнең беренче җомгасы ........ 83

Галимнәр һәм мөтәвәллиләрнең дини мәдрәсә турысында җыелышлары ........ 85
Шәһәр идарәсеннән алынган ашамлыкның хәләл булуы ........ 88
Шәһәр Шәрәфкә имамлык өчен карар. Бозыклар гаугасы ........ 89
Акылсыз кыяфәтендәге зиһенле бер наданның киңәше ........ 91
Казанда юстиция урынбасарын күрү. Кызыл муллаларның зарары булуы ........ 93
Казан имамнары белән ял итәргә чыгу. Имамнарның теләкләре ........ 95
Казан мөхтәсибенә бирелгән ярым рәсми кәгазь ........ 96
Имам сайлауда әүбашлар җыелышы ........ 96
Китапханә турында Һади Максуди белән сөйләшү ........ 97
Мәркәздәге төрле милләтләр идарәсенең вәкиле Диманштейн белән көрәшү һәм сөйләшү ........ 98
Казаннан Мәскәүгә сәфәр ........ 102
Юлда укылган китаплар ........ 103
Инглиз һәм Шура хөкүмәте арасында сәяси сөйләшү ........ 106
Өченче интернационал мөнәсәбәте белән демонстрация ........ 108
Бәйрәмнәр файдасы, гыйлемнән бигрәк гамәл кирәк ........ 109
Гыйсмәти белән сөйләшү ........ 112
Мәчеттә кояш сәгате ........ 115
Мәскәүдә Төркия түрәләренә бару ........ 117
Җаубаштан мулла Гарифның вафаты, тәрҗемәи хәле ........ 119
Инглизләргә нәфрәт бәяне ........ 120
Төркия-Шура мөнәсәбәте һәм инглизләрнең фикер йөртүе ........ 121
Мөфтилеккә сайлану хәбәре ........ 130
Бохара вәкилләре һәм Бохара хакында фикерем ........ 132
Бохара хакында минем фикерем ........ 133
Милли эшләр комиссариаты әгъзасы ........ 135

Бер кабардин белән сөйләшү ........................................................ 139
Төрек вәкилләре белән сөйләшү ....................................................... 142
Хәлифәлек мәсьәләсе ........................................................................ 142
Мөхтәсиб Лотфулла Исхакый белән сөйләшү ................................. 149
Мөхтәсибләр җыелышы ни өчен кирәк? ......................................... 150
Мәскәүдә ислам мәмләкәтләре вәкилләре ........................................ 151
Мирза Бидел тәрҗемәи хәле ............................................................ 156
Гомеопатия ысулынча табиб ............................................................ 158
Үлемне истә тотуның файдалары .................................................... 161
Милли эшләр мәсьәләсе буенча бирелгән гариза ............................ 163
«Сөбател-гаҗизин» китабы турында ................................................ 165
Пәйгамбәр нәселеннән булган имамнардан имам Мөтәвәккил
Гали хәлифәнең вәгазьдә матур шигырьләре ............................... 167
«Рухел-бәян» тәфсире турында ........................................................ 169
М. Солтангалиев белән сөйләшү ..................................................... 170
«Мәснәви-шәриф»тән кайбер шигырьләр ........................................ 171
Әнвәр паша белән сөйләшүләр һәм аның фикерләре ...................... 172
Татар-башкорт җөмһүриятләре ......................................................... 177
Җомга хатирәләре .............................................................................. 179
Әфган вәзире һәм вәкиле белән сөйләшү ........................................ 179
Милли эшләр комиссариатыннан җавап .......................................... 180
Мәскәүдән Казанга юнәлү ................................................................. 182
Обсерватория хисаплары .................................................................. 184
Гает хөтбәсе һәм Корбан хикмәтләре ............................................... 185
Һәвел намазы, хатыннар вәгазе хакында сорау-җаваплар .............. 187
Татарстан җөмһүрияте рәисе Сәхипгәрәй
Сәетгалиев белән сөйләшү ............................................................ 189
Казанда янгын афәтләре, кадерле китапханә әрәм булды ............... 191
Китапханә бинасына фатирчы нияте ............................................... 193

Китапханәне Шурага тапшыру хикмәте, вакыф итү ........................ 194
Казаннан Уфага сәфәр ........................................................................ 196
Самарада ике көн ............................................................................... 198
Исәкәйдән Каһарман хәзрәт ............................................................... 201
Вагон җәфалары .................................................................................. 202
Уфада галимнәр съезды ...................................................................... 204
Казакъ галимнәреннән мөхтәсиб
мулла Исхакның вафаты .............................................................. 207
Съездының ачылуы ............................................................................. 208
Съезд вакытында җомга намазы ......................................................... 209
Мөфти һәм казыйларның съездда докладлары ................................... 211
Мөфти һәм казыйлар сайлау ................................................................ 219
Каргалы халкына мөрәҗәгать .............................................................. 222
Бу съездтан алынган тәэсирләр ........................................................... 224
Мөфти һәм казыйларның кыскача тарихлары .................................... 227

*Галимҗан Баруди*

**ХАТИРӘ ДӘФТӘРЕ:**
**1920 елның 12 июненнән алып сентябрь ахырына кадәр**

*Галимджан Баруди*

**ПАМЯТНАЯ КНИЖКА:**
**с 12 июня по конец сентября 1920 г.**

*На татарском языке*

Подготовка к публикации – *Айдар Марсилевич Гайнутдинов*

Компьютерная верстка – *А.Р. Тухватуллина*
Подписано в печать 28.09.2017 г. Формат 60x84 $^{1}/_{16}$
Печатных листов 14,75. Тираж 200 экз.

Отпечатано с готового оригинал-макета

ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОМ
*им. академика В.И. Андреева*

420108, г. Казань, ул. Портовая, 25а
Тел./факс: (843) 231–05–46, 231–08–71
E-mail: citlogos@mail.ru
www.logos-press.ru

Сайт
Института истории
Академии наук РТ
Татаровед.рф